

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1984



## *КПСС өлкә комитеты бюросы*
## *Татарстан АССР Министрлар Советы карары*

# 1984 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН АССРның Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:

1984 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирергә:

1. Еникеев Әмирхан Нигъмәтҗановичка (Әмирхан Еники), язучы, «Повесть һәм хикәяләр» һәм «Юлчы» китаплары өчен.

2. Мулюков Бату Гатаулловичка, композитор, **Родионов** Григорий Васильевичка (Гәрәй Рәхим), либретто авторы, **Васильев** Владимир Михайловичка, дирижер, **Сөнгатуллина** Зилә Даяновнага, **Бигичев** Хәйдәр Аббясовичка, опера солистлары,— М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» («Кара йөзләр») операсы өчен.

**КПССның Татарстан**
**өлкә комитеты секретаре**
**Г. УСМАНОВ.**

**Татарстан АССР**
**Министрлар Советы Председателе**
**И. САДЫЙКОВ.**



Әмирхан Еники



Б. Г. Мулюков



Гәрәй Рәхим



В. М. Васильев



З. Д. Сөнгатуллина



Х. А. Бигичев

# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ
АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

7

1984

## Бу санда

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. **Шигырьләр** . . . . 3
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. **Өй салуның ние бар!** Повесть 10
Р. ВӘЛИЕВ. **Шигырьләр** . . . . 68
М. ВӘЛИЕВ. **Дулкын.** Повесть . . . . 73

«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

Р. ХАФИЗОВА. **Урак есте. Хикәя** . . . . 109

Н. МАДЪЯРОВ. **Шигырьләр** . . . . 114

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ЗУЕВА. **Казанда Тукай урыннары** . . . . 116
Г. КАЙБИЦКАЯ. **Безгә кадерле йорт** . . . . 117

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Р. ГӘРӘЙ. **Ык буеның «Яңа юл»ы** . . . . 119

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

Л. ЗИННУРОВА. **Хезмәткә җыр кушылса** . . . . 127

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

М. ӘҺЛИУЛЛИН. **Яңыгызга кайтыр идем!** . . . . 137

СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

Н. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. **Әдәби оешмалардан — бердәм Союзга** . . . . 142

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. **Давыллы чор ядкарьләре** . . . . 152
Х. ӘШРӘФҖАНОВ. **Тәрәзәләр кая карый!** . . . . 154

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Ә. КӘРИМУЛЛИН. **«Гасыр» нәшрияты** . . . . 157
С. АЛИШЕВ. **Пугачев полковнигы** . . . . 166

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

**Җ. МӨХӘММӘТШИН, Т. ХЛЕБНИКОВА. Шәһре Болгар** . . . . . . 172

ЮБИЛЕЙЛАР

**Р. ӘХМӘТ. Саба җиледәй** . . . . . . 179
**Ә. ГАФФАР. Игелекле эш кешесе** . . . . . . 182

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

**З. НУРИ. «Шинельле юмор» дәфтәреннән** . . . 184

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . 187

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . 188

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . 192

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия:*
**ШАМИЛ БИКЧУРИН**
**МАНСУР ВӘЛИЕВ**
**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**РӘИС ДАУТОВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ЗӨЛФӘТ**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ГУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**ЗӘКИ НУРИ**
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**АТИЛЛА РАСИХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**НИЛ ЮЗИЕВ**

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

**В НАШЕМ НОМЕРЕ**

Стихи **Р. Файзуллина, Р. Валеева** и **Н. Мадъярова**. Повести **Ф. Шафигуллина** («Что нам стоит дом построить») и **М. Валиева** («Волна»). На конкурс «Подвиг продолжается»: рассказ **Р. Хафизовой** «Страда».
«К 100-летию Г. Тукая»: воспоминания **Г. Кайбицкой**, рис **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
В рубрике «Продовольственная программа — всенародное дело»: очерк **Р. Гарая** о тружениках колхоза «Якты юл» Мензелинского района.
«Идет II Всесоюзный фестиваль самодеятельного художественного творчества, посвященный к 40-летию Великой Победы». Статья секретаря Сармановского РК КПСС **Л. Зиннуровой**. Зарисовка **М. Аглиуллина** с литературного поста журнала — со строительства ТатАЭС.
«К 50-летию Союза писателей СССР»: статья **Н. Гиззатуллина**. В разделе «Библиография»: рецензии **Р. Ахметзянова** и **Х. Ашрафзянова**.
Статья **А. Каримуллина** из истории татарского книгопечатания («Издательство «Гасыр»). Статья **С. Алишева** о пугачевском полковнике Исхаке Ахметове. Статья **З. Мухаметшина** и **Т. Хлебниковой** «Великие Булгары».
Материалы к юбилеям композитора **А. Валиуллина** и писателя **В. Ганиева**.
Юмористические миниатюры **З. Нури**. «Занимательные истории» **Р. Батуллы**. «Дневник культуры». «На наших обложках» — творчество художника М. Хаертдинова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова* Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 4.4.1984 ел. Басарга кул куелды 27.6.1984 ел. ПФ 11240. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64026. Заказ К-123. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

# Равил Фәйзуллин

## Су асты көймәсендә

Гүя гильза. Ә эчендә
дары түгел — кешеләр!
Су төбендә Туган җирне
төштә күреп яшиләр.

Су басымы, кан басымы,
җан басымы... югары!
Ничәнче ай зәңгәр күкне
күргәннәре юк әле.

Уңда, сулда, өстә, аста —
гел тимер кыса гына...
Торпеда күк атыл идең
ярларның кочагына!

Адәм балык түгел дә бит
төпкә төшеп ятырга.
Нишләсен соң?— Түзә, чыдый
хыялдагы хакына.

Астагы сәер тормышны
төшеп яшәгән бәлә!
Анда көймә батуы да
тик... күтәрелмәү генә.

Су асты тын. Гаҗәеп тын.
Җан гына ала давыллап.
Җир иминлеген саклыйлар —
су астын каравыллап.

## Әфшанда

Сәмум җил булыпмы,
күчәр ком булыпмы,
очкан кош булыпмы?—
мин монда бер булган идем күк...

Шул арада меңләгән ел үтеп киткән!

Ни үзгәргән?
Әллә ни юк.
Күк түбәнәймәгән.
Таулар өелмәгән.
Диңгезләр күченеп килмәгән...
Яңалык шул:
Әбугалисина дигән рух кабынган
кешеләр күңеле күгендә.
Төрле илләрдән мосафирлар килә хәзер
шушы җирне изге санап.
Һәм Әфшан[1], үзе дә үзгәреп,
бәйрәмчә таш кием киенгән.

---

[1] Әфшан — кайбер тарихи чыганаклар буенча, бөек галим Әбугалисинаның туган җире. 1000 еллык юбилей уңае белән 1981 елда Әфшанда зур тантаналар уздырылды.

## Айну

Җиңеләеп кайчак,
диңгез миңа тубыктан! дип,
«сикергәләү» хисе уянса,
кызыгып куйсам, ялгыш, ярым көнләп,
«алтын яшьләр» кыланышына —
искә алам да
әниемнең кер уганда башы иелгән силуэтын,
авыруларның тәрәзәдән нәүмизләнеп торуларын,
оясында ятим калган кош балалар чыелдавын...—
үз хәлемә кайтам шундук,
илен җуйган мөһаҗир җан
сискәнеп уянган шикелле.

## Исемнәре генә калган

Нәҗми тегермәне.
Гыйлаҗ тегермәне...

Истә әле,
истә әле
картлар сөйләгәннәре,
су анасын күргәннәре...

Нәҗми тегермәне.
Гыйлаҗ тегермәне...

Тегермәннәр урынында —
дулкын-күбек түгәрәге...
Каберләре өсләрендә —
оча болын күбәләге...

●

Ерагайды юллар!
Һавалардан,
диңгезләрдән,
хәтта кайчак... җир эченнән!
Ә гомер озаймады.

Тыгызланды Вакыт!
Артты хәбәр.
Ишәйде сүз.
Ешайды йөз...
Ә бәхет күбәймәде.

Ят якларга баргач,
җәяү йөрим урап-урап —
урамнардан,
парклардан,
зиратлардан,
болыннардан —
тәпи-тәпи атлап, адымлап,
чигеп йөрим, имеш, Җир йөзендә,
зур-зур итеп,
Туган якның гөлләр сурәтен.

## Шерп[1] улына

*Были обстоятельства, и нам приходилось «шерповать»— таскать на спинах тяжелые снаряжения...*

(Эверестны штурмлау экспедициясендә катнашкан альпинист сөйләвеннән)

**Биеклеккә менгәнлекнең**
**даны әллә кемнәрдә!**
**Ә чын авырлык үзеге —**
**сезнең сабыр иңнәрдә!**

**Кемнәрдер биек үрмәли**
**сезнең җилкәгә басып.**
**Кемгә — түбә, кемгә — аста**
**нигез булырга насыйп.**

**Бәлки, сөенү кирәктер,**
**нигезең биек булгач.**
**Түбән хисләр ким буладыр,**
**Кояшка якын тугач.**

**Килгәннәр килә дә китә.**
**Ә сез каласыз тауда.**
**Тауларның йөрәге сездә,**
**ә сезнең җаннар — анда.**

●

*Альпинист Н. истәлегенә*

**Болытлардан да югары**
**җырлап аккан чишмәләр бар.**

**...Мәңгелек кар эчләрендә**
**өшеп яткан йолдызлар бар.**

●

**Әгәр җыйсаң бөтен ятимнәрнең, бөтен сабыйларның**
**ничарадан аккан күз яшен —**
**Җирне туфан күмәр иде!**
**Дөнья үзе, оятыннан,**
**тончыгып үләр иде!**

**Әгәр җыйсаң бөтен авазларын, нәфрәтен, ачу-ярсуын**
**сугышларда янган ирләрнең —**
**янартаулар күкрәве, зилзиләләр, бомба шартлаулар...**
**бер пышылдау булып калыр иде!**
**Бу тавыш-нәгъризән Җир үзе**
**меңгә ярылыр иде!**

**Әгәр җыйсаң бергә дөньядагы барлык кыз-хатынның**
**назлы чакта, мәхәббәттә, бәхетеннән әйткән сүзләрен,—**
**һәм укысаң аны китап итеп —**
**изге булыр иде һәр бәндә!**

---

[1] Шерплар — Эверест тавы итәгендә, Непалда яшәүче аз санлы чыдам халык.

## Үзалдына сөйләшү

*(Читләрдә гомер сөргән берәү авызыннан)*

Әнкәм дә юк, әткәм дә юк...
Инде кемнәрем калды?

...Ышаныч гөлләрем корды.
Өмет гөлләрем калды.

Язым да юк, җәем дә юк...
Нинди көннәрем калды?

...Яшьлектә яккан учакның
җанда көлләре калды.

Илем дә юк, җирем дә юк...
Нинди тиңнәрем калды?

...Туган якка исә торган
таныш җилләрем калды...

❁

Чабата, чыпта,
кара мунча,
салам түбә,
кабык арба —
хәзер кайда?

Булса булыр
китапларда.

Чулпы чыңы,
бишек җыры,
халык моңы...
Хәзер кайда?
Алар — җанда.

## Яңа моң

Күчтәнәчләр хәзер күп алынмый.
Кайткан саен — йөгем кечерәк.
Саранланмадым да, көчем дә шул...
Еллар, уйлар бүтән: ник кирәк?

Кемең калды хәзер урамыңда
балачактан таныш йөзләрдән?
Мәрхәп әби кая? Хәдичә апай?
Сабир бабай?.. Күптән гүрләрдә!

Бер тупыллар калды баш иягә.
Шул бер инеш калды — тыңларга...
Нindидер бер яңа моң төсмере
сизәм хәзер шаян җырда да.

## Умырзая

Кояшың булганда —
суык та... түзелә!
Ул — беренче чәчәк!
Ул — кояш күзендә!

Урман әле шәрә.
Бөтен нур — аңарга.
Яфраклар күләгәсе
төшкәнче янарга!

Боз, кырау — бер нәрсә.
Ә күләгә — башка!..
...Я беренче булырга!
Я — бер дә булмаска!

## Шекспирны укыганда

Исемнәр ят... Җирләр... Гадәтләр... Хәер, ул заманны
белеп бетермим дә бик үк мин...

...Корольләрнең язмыш безгә тия алмастыр,
Лирләрнеке менә — бик мөмкин!

## Җиргә барыбер...

Дөньялар тыныч чакта, имин чакта,
балигъ булган уллар, кызлар,
фатихалар алып калып,
тапшыралар Җир куенына
яшәп арган әтиләрен,
әниләрен...

Сугыш чакта, кырыш чакта,
киресенчә —
карт аталар, өлкән аналар
Җир куенына озаталар
(күп чак үзләре дә күрмичә)
япь-яшь, таза балаларын...

Ага суда төз бер нарат.
Салдан аерылганмы?

...Нарат үскән төптә ята
аккош каурыйлары.

## Үкенү дә, әзрәк өмет тә...

Кирәк чакта ишетә алмадым —
назлы теләк: «Әче! Ачы!»

...Шулай да, көмеш яшьлектә
татлы кисте алтын кайчы!

Бакыраер картлыгыма
калыр, ахры, тимер кайчы...

Кисәр әле тутыкканчы!

Аста — дулкын. Өстә — кояш!
Идел буе — чирәмлек!
Авыл шаулап туй үткәрә,
гөрли бөтен тирәлек!

Халык уйный, халык җырлый,
халык бии яр тулып!
Яшь киленнең ак күлмәге
үрли ак ялкын булып!

Авыл рәхәттән исерек.
Туктармы туй өч көндә?
...Көймәгә капланып елый
бер кыз Идел өстендә.

## Парлы ялгыз

Читләрдән караучыга без —
туйдагы пар ат кебек!
Ә эчләрдә яра саркый
чәерле нарат кебек...

Әйтәләрдер: бәхетлеләр!
Шат йөзләренә кара!
...Диңгездә ялгызак
калгач,
күзләрдән яшьләр тама.

## Минем беләң...

Андыйларны-мондыйларны инде байтак күргән бар, дип,
син уйладың бугай мине, бер гадәти җаный-яр дип.

...Еллар үтеп, шактый хәлләр кичте башың минем белән!
Биргән ашың, аткан ташың — онытмадым!— минем белән...
Хәзер инде бик яхшы итеп беләсең син, мин дә беләм:
ул гомерләр — терсәк кыска!— кайтарылмый берни белән!

Хәзер — элек булганнарны искә алган күк минем аша,
килерләрен бәһаләрсең чагыштырып минем белән.

●

Үзеңә өметләнәмме?
Җиткән миңа күләгәң дә!
Кояш нурыннан ни — китап
арасында сулган гөлгә!..

Мин синнән ваз кичә аламмы?
Бу хәл булмас үлгәндә дә!

Фәкать синең белән тулы
күзәнәкләр шушы тәндә!

Башта әйткән сүзләремнән
тәүбә!
Тәүбә!
Тәүбә!

## Әгәр миңа ышанмасаң...

Әгәр миңа ышанмасаң,
«Ул яратамы мине?» дип,
җилләрдән сорап кара!
Алар да, минем шикелле,
«Шуны да белмисеңмени?» дип,
чәчеңнән тарап торыр.

Әгәр миңа ышанмасаң,
«Ул миңа тугрымы?» дип,
күкләрдән сорап кара!
Болытлар, минем шикелле,
«Шуңа шикләнәсеңме?» дип,
мөлдерәп карап торыр.

Әгәр миңа ышанмасаң,
шул ук сорауларны биреп,
үзеңнән сорап кара!
Үзең мин булып кара!
...Күңелең тулы яшь булып та,
көлеп-елмаеп кара!

# Фаил Шәфигуллин

# ӨЙ САЛУНЫҢ НИЕ БАР?

ПОВЕСТЬ

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

### Беренче бүлек



Мина койрыктан егерме-утыз метр читтәрәк шартлады. Шартлау дулкыны беләк юанлыгы корыч арканнарны зыңгылдатып узганда прожекторларның пыялалары, секунды белән онга әйләнеп, тимер палубага сибелде. Катер да, сыртындагы чая егетне бәреп төшерергә теләгән чыгымчы ат кебек, үрлекырлы сикергәләде.

Борт яныннан гына узып киткән минаны диңгезчеләр артык каушамыйча, паникага бирелмичә, салкын кан белән озатканнар иде. Иң куркынычы — диңгездә адашкан минаны бортка якын китермичә, агач колгалар ярдәмендә саклык белән генә читкә этәргәндә булды.

Океан дулкыннары арасында сигезенче яңа елын каршыларга җыенган мичман Мурмильнең дә маңгаена бөрчек-бөрчек салкын тир бәреп чыкты хәтта. Мөгезләрен тырпайтып корабны сөзәргә килгән «тимер үгез» белән көрәшкәндә, дугаланып бөгелгән бамбук колгалар сынанитә калса дип, кораб белән мина арасына сикерергә әзерләнгәндәй, өлкән ярдәмче Назаренко кителен салып ыргытты. Тельняшкадан гына калгач, матросларның иң бәләкәе — Пончик кушаматлы Мазайкиннан да кечерәеп калгандай булды ул. Колгалар һаман бөгелә бардылар, Назаренконың бармаклары, фальшборт тимеренә батып кергәндәй, җәлпәкләнеп күренде.

— Шартласа нәрсә була? Башына кинәт килгән бу сәер уйдан калтыранып куйды Рәсим. Минаның мөгез төбенә терәлгән колгасы читкә шуа башлагандай тоелды аңа.

— Шартласа — шартласын, ычкындырмаска, шудырмаска! Башкаларның колгалары әнә ничек бөгелгән. Ә аныкы турырак түгелме соң? Этәргә, бар хәлгә этәргә, эчләр авырта башлаганчы, колга шартлап сынганчы этәргә...

— Полундра!

Назаренко, хәлсезләнеп, фальшборт өстенә бөгелеп төште. Кемнеңдер колгасы минага ияреп дулкыннар арасына кереп югалды. Мичман, әле моңарчы Рәсим ишетмәгән сүзләрне катнаштыра-катнаштыра җиде

---

Беренче кисәге журналның 1981 ел, 2 санында басылды.

катлы итеп сүгенде. Матрослар тельняшка җиңнәре белән бөрчек-бөрчек тир тамчылары тәгәрәшкән битләрен, маңгайларын сөрттеләр.

Рәсим күперчеккә күтәрелеп карады. «Полундра!» — дип кычкыручы капитан үзе булган икән. Капитанның һәрвакыт диярлек алсуланып торган тулы битләре суырылып, агарып каткан. Мыегы ирененә ябышмыйча, алга чыгып, һавада эленеп тора шикелле. Күзләре ят шәүләдән өркеп ярсыган ат күзләре кебек, зур булып ачылган. Бернәрсә дә күрми сыман ул һәм, мөгаен, күрми дә торгандыр. Күз караларының икесе ике якка киткәч, нәрсә күрсен ди инде кеше.

Катер, мөгезләрен уңга-сулга чайкый-чайкый, дулкыннар арасында тирбәлгән минадан тизрәк качарга теләгәндәй, тулы тизлек белән алга ташланды. Рәсим, катер койрыгы уңгарак авыша төшкәч кенә диңгезнең капитан текәлеп каткан турысынарак карады — анда яньчелгән казан төбенә охшаганрак карамчык су астыннан калкып чыкты да чираттагы дулкын ишелеп узганда күздән югалып торды, аннары янә аермачык булып күренде. Әле дә ярый көн болытлы, кояш нурында күзләрең чагылып, бернәрсә дә күрми калыр идең.

Әллә ничә мөгезле кыяфәтсез шар әйләнә-тулгана, бата-чума әлеге карамчыкка якынлашкач, Рәсим тагын капитан күперчегенә борылып карады. Капитанның авызы зур булып ачылган, башы җыерылып иңнәренә кереп бетә язган. Күзләре баягыдан да куркынычрак ялтырый иде аның. Тагын «полундра» кычкыра ахрысы. Рәсим, тирә-юньдәге хәлләргә бәя бирергә теләүдән бигрәк, инде җанына, бәгыренә үрмәләп керергә, салкын кармавычлары белән кан юлларын өшетеп узарга өлгергән курку тойгысын басарга тырышып шулай уйлады.

Башта шартлау булдымы соң? Юк, башта корыч арканнар зыңгылдады, аннары прожекторларның пыялалары он булып яуды. Капитанның фуражкасы кая китте соң? Югыйсә, соңгы мизгелдә Рәсим гел капитанга гына карап торды лабаса. Күз ачып йомганчы юкка чыкты капитанның фуражкасы. Аннары Рәсимнең баш чүмеченә китереп суктылар, аркасыннан сырт буйлап утлы шарлар тәгәрәп узгандай булды. Менә шул чагында гына ишетте бугай ул шартлау тавышын. Бәлки, алданрактыр, ә бәлки соңрактыр. Рәсим аңына килгәндә палубага әче төтен җәелгән, өченче штурман Петро белән беренче класс матросы Кулешов башы канга манчылган мичманны палуба буенча сөйриләр иде.

Рәсимнең күз алдында кызыллы-яшелле түгәрәкләр әйләнәләр дә туктыйлар, әйләнәләр дә туктыйлар. Алар туктаган арада куе төтен арасыннан, ямаулы ашъяулыктай чуарланып, диңгез өсте күренеп китә. Тавышлар ишетелми, бер тавыш та юк. Әллә чукракланды микән Рәсим? Яшь башыннан, әле яңа гына егермесе тулган килеш. Нәрсә басып тора соң аның гәүдәсен, нәрсә кысып тора башын? Нигә сулап булмый, нишләп күзләрдән бертуктаусыз яшь ага?

Рәсим тезләнеп торырга маташып карады. Палуба тропик сулардагы кебек кызган, учларны өтеп ала. Кулы пешүгә чыдый алмагач, Рәсим палубага терсәкләре белән таянды. Аның аңы ачыклана төшкәндәй булды. Колагына кинәт бөтен тавышлар берьюлы килеп керде. Диңгез шавы да, төтен стенасы артында кемнеңдер ыңгырашуын да, кемнәрнеңдер тимер палуба буенча йөгерешеп үтүләре дә җәлеп итмәде аның игътибарын, фәкать бер генә аваз, бер күкрәктән ике тапкыр чыгуы мөмкин булмаган җан тетрәткеч аваз гына бөтен көч-куәтен, яшьлек сизгерлеген бер ноктага тупларга, гәүдәсен убыр кебек басып торган авырлыкны селкеп ыргытып, башын манкорт «таҗы» кебек кысып торган кыршауны өзеп ташлап, аяк өстенә сикереп торырга мәҗбүр итте.

— Мичман, янабыз! Якорь салыгыз! Якорь! Янабыз!

Төтен. Мичман юк. Аны Кулешов белән Петро сөйрәп китте. Төтен пәрдәсе артында ялкын телләре дә күренгәли. Кайнар җил битләрне өтә. Утка түзеп була икән, ә менә бу каһәр суккан төтенгә түзәр хәл юк. Әгәр дә ялкын торпеда камерасына барып җитсә? Ул чагында... Ананны... Керфекләр чытырдап көйде, тагын бераз гына түзәргә дә. Әз генә... Тып-тып, тып-тып. Әллә тагын чукракланды инде Рәсим. Әх, курткага ут капкан, ут... Коткарыгыз!

Рәсим кызган палубага бөгелеп төште. Тагын сикереп торды, инде авыртуны сизми башлаган бармакларын күкрәгенең пешкән турысына батырып, иреннәрен тешләгән, күзләрен чытырдатып йомган килеш, төтен болыты эченә томырылды. Тагын бер генә секунд төтен эчендә калса, сулышы кабып егылачак Рәсим. Пешеп түгел, төтенгә тончыгып үләчәк Рәсим. Януын соңыннан янар, януын үзе дә сизмәс, бәлкем...

Сулыш юлларын тутырып саф һава узганда күкрәгенең чәнчеп-чәнчеп авыртуын тойды Рәсим. Ләкин аңы бик ачык иде аның. Хәтта бая капитанның: Янабыз!» — дигән дәһшәтле авазы ишетелгән чактагыдан да ачыграк эшли иде баш мие.

Инде күпме гомер узды икән? Якорьның кирәге дә юктыр. Катерга ут капканга әле өч минут та узмаган, ләкин Рәсим бу хакта бернәрсә дә белми, һәрхәлдә аңа әлеге минутларның һәркайсы елдай озын булып тоелган иде.

Рәсимне башта брашпиль тимерләренең салкын булуы гаҗәпләндерде. Ләкин шунда ук, электр моторы сафтан чыккан булса, дигән икенче шөбһәле уй баш миен көйдереп узды. Рәсим бөтен гәүдәсе белән диярлек чынаяк табагы зурлыгындагы тәгәрмәч өстенә капланды. Аның колагына тагын бик күп, төрле-төрле тавышлар килеп керә башлады. Төрле-төрле, бик күп тавышлар арасында, иң якыны, әлбәттә, брашпиль тавышы иде. Әллә ничек чыжылдап, зырлап, җырлап әйләнә иде брашпиль. Якорь берничә секунд доң-доң китереп бортка бәреп торды да чупылдап суга чумды. Катер бер урында бәргәләнде, сикергәләде, калтырады да акрын-акрын җил уңаена борыла башлады.

Катер җилгә яны белән борылгач, палуба минуты-секунды белән төтеннән арынды. Шуны гына көткәндәй, дөпе-дөпе килеп мотор эшли башлады. Әле анда, әле монда команда тавышлары яңгырады. Усаллanып, ярсып, чыжылдап, сызгырып ут белән су көрәшергә тотынды. Катерның кайсы турында кызган пар, кайсы төшендә күбек, кайсы җирендә төтен айкалганын һич тә чамаларлык-шәйләрлек түгел иде инде хәзер.

Ләкин Рәсим боларның берсен дә ишетмәде, күрмәде, ул яңадан аңын җуйган иде.

Катер койрыгыннан егерме-утыз метр ераклыкта су асты кыясына бәрелеп ярылган минаны Төньяк Атлантика блогына керә торган империя кораблары маневр вакытында юри ташлаганнардыр, яисә ялгыш төшеп калгандыр, дип уйлаган иде Рәсим. Хәер, бер Рәсим генә түгел, Советлар Союзы дигән бөек держаканың диңгез чикләрен саклаучы күп кенә хәрби экипажлар шулай уйладылар. Чөнки дөньяга атом куркынычы туган дәһшәтле чор, җир шарының әле теге, әле бу почмагында сугыш уты кабынгалап торган ифрат та хәвефле заман иде бу.

Бу заманда диңгездә яшь бозау чаклы иске минага түгел, фил башы кадәрле нейтрон бомбасына тап булсаң да гаҗәп түгел иде.

Ләкин бу вакыйга уңае белән махсус оештырылган комиссияләр килеп тикшергәч, шартлау дулкынының көчен, кыйпылчыклар траекториясенең ераклыгын хисаплап чыгаргач, әлеге минаның, чынлап та, узган сугышлардан калып, дулкыннар арасында бик озак үзенең корбанын эзләп йөрүе ачыкланды. Диңгезләрдә адашып йөрүче андый тимер газраилләр юк дигәндә дә очраштыргалый икән әле.

## Икенче бүлек

Ике ай ярым хәрби госпитальдә ятып чыккач, Рәсимгә бөтен эскадрилья алдында, тантаналы төстә «Батырлык өчен медале» тапшырдылар. Эскадрилья командиры үзе кадады аның күкрәгенә медальне.

— Киеренке моментта каушап калмаганы өчен, катерны һәм аның экипажын уттан коткарганда шәхси батырлык күрсәткәне өчен! — диде.

Рәсимнең:

— Советлар Союзына хезмәт итәм! — дигән сүзләрен тантаналы «ура» тавышлары күмеп китте. Сафлар дулкынланды, бескозыркаларның ленталары җилдә җилфердәп, сафлар буенча ефәк дулкыннар хасил итте. Диңгез җилләрендә каралган, яргаланган йөзләр, барысы да Рәсим ягына борылып, тынып калганнар, яшьлек романтикасы мөлдерәмә тулып торган күзләр Рәсимгә көнләшеп тә, сокланып та карыйлар.

Белмиләр шул әле алар, бу батырлык Рәсимгә бик кыйммәткә төшкәнен белми алар. Рәсимнең күкрәген күрсәләр, алай карамаслар иде, шәт. Рәсим аңына килгәч шаккатты: ике дә уйлап тормаган хирург, япь-яшь күкрәктән бияләй кадәр калҗаны кискән дә алган. Өстәвенә әле: «Бала имезәсең юк, бик җитеп арткан сиңа сыңар әммәтәй»,— дип азау тешләрен күрсәтеп көлгән була. Рәсимнең чынлап торып ачулана башлавын чамалагач кына мәсьәләнең асылын аңлатып бирде. Яшь тән булса да, пешкән күкрәктә гангрена башланган икән. Көлгәндә һәрвакыт азау тешләре күренә торган хирургның шаяртып әйтүенчә, туган якларына аяклары гына кайтып китәсе булган.

— Әле синең ярый, язмышыңа шөкрана кыл. Назаренко әнә анда дөм-сукыр калды,— дип очлады әңгәмәне.

— Марат Гавриловичмы?

Рәсим кисәк кенә шабыр тиргә батып, хирургка текәлде.

— Менә аңа операция ясап булмый инде,— диде хирург ниндидер бер җансыз әйбер хакында сүз барган төсле гади генә.

Бу төнне төшендә ул берөзлексез Назаренконың чиста күк йөзедәй зәңгәр күзләрен күрде. Рәсим ни генә әйтсә дә, фальшборт читенә чытырдатып ябышкан Назаренко инглиз телендә:

— Но сэр, но сэр,— дип такмаклады.

Рәсимнәр катерында хезмәт иткән диңгезчеләрнең һәммәсен дә азмы-күпме инглиз теленә өйрәткән иде Назаренко.

— Бер кирәге чыкмаса, бер кирәге чыгар, тел белү үзе һөнәр бит ул, һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс,— дип кабатларга ярата иде Назаренко.

Рәсимнең тел өйрәнүгә һәвәслеге ачылгач та, сөенеп бетә алмаган иде Марат Гаврилович.

— Ничә класс белемең бар әле синең, Шәйдуллин, сигезме? Ничего, кайгырма. Урта мәктәп программасын службадан бушаган арада узабыз да без синең белән имтиханнарны экстерн тапшырабыз. Аннары штурманнар әзерли торган училищега керәбез синең белән. Югары уку йортына керәбез синең белән. Капитан булабыз, чит илләргә зур кораблар йөртәбез. Башка милләт кешеләрен кимсетеп, борын астыннан гына үзара мыгыр-мыгыр сөйләшкән империалистларга инглиз телендә чатнатып:

— Исәнме, брат! Без Советлар иленнән килгән идек, хәлләрегез ничек? Сәүдә эшләре әйбәтме, ни сатасыз да, ни аласыз? — дип эндәшәбез.— Ә, Шәйдуллин!

...Ул көнне Рәсим тавышсыз гына елады-елады да, палатадагы иптәшләре төрлесе-төрле көйгә гырларга керешкәч, күкрәгенең әрнегән җиренә көч китермәскә тырышып, идәнгә шуып төште. Башы бик нык әйләнеп китсә дә, егылмады, кризисны койка иңсәсенә ябышып уздырды.

Ишек төбендәге өстәлгә башын салып йоклап утырган сестра янын-нан да тавышсыз-тынсыз, мәче кебек йомшак адымнар белән узды Рәсим.

Өлкән ярдәмче, биек түшәмсез шактый иркен палатада бер үзе генә ята икән. Төнге утның яктысы сүрән булса да, Рәсим Назаренконы киң иңнәреннән, күкрәгенә кушырып куйган зур кулларыннан таныды.

Йокламаган, ахры. Марляга чорналган баш акрын гына кыймылдагандай итте, марля арасыннан сизелер-сизелмәс кенә калкып торган иреннәр арасыннан:

— Сестра, спишь? — дигән йомшак сүзләр саркып чыкты.

Рәсим шыпырт кына кире китәргә дә уйлаган иде. Ләкин Назаренкога, бәлки, бер-бер әйбер кирәктер, дигән фикер аны ишек төбендә калдырды.

— Кем бар анда?

— Мин әле бу, Марат Гаврилович, Шәйдуллин.

Өлкән ярдәмче, терсәкләренә таянып, койкасыннан күтәрелә төште. Марля аша нәрсәдер күрә алгандай, Рәсим ягына төбәлеп торды. Һәм шул минутта, искергән пружиналарны шыгырдатып, яңадан койкасына сеңде.

Аның тавышы көр, сүзләре ачык иде.

— Хәлең ничек, Шәйдуллин?

— Терeләм инде,— диде Рәсим, ирененә агып төшкән яшь бөртеген теле белән ялап алгач.

— Ә нигә елап сөйләшәсең?

— Болай гына.

— Йоклап булмыймы? Булмас та. Режим бозылды безнең, Шәйдуллин. Тормышта әнә шундый очраклы хәлләр килеп чыга да режим бозыла. Хәер, үзебез йомшак камырдан әвәләнгәндер, күрәсең. Әнә, мичманның маңгае бер бармак иллесе ярылган иде. Повязкасын ике көн дә тотмаган. Ерак походлар вакытында элек тә пиратка охшап йөри иде. Хәзер, маңгаендагы мөһере белән бөтенләй котын алыр инде матросларның... Ә син утырып тор.— Назаренко сүрән лампа яктысында тагын да зураеп күренгән кулы белән койка янындагы урындыгын капшап карады.— Утырып тор. Сәгать өченчеме?

— Дүртенче егерме минут, Марат Гаврилович,— диде Рәсим урындыкны тавышсыз гына этеп.

— Сызлыймы яраң?

— Төзәлә инде, режим белән генә сызлый.

Назаренкоының ирен читләреннән елмаю билгеләре чагылып узды.

— Урта мәктәпне бетерәлмәдек без синең белән, Шәйдуллин. Син үзлегеңнән укырсың инде. Ләкин мин әйткәннәрне онытма. Онытмассыңмы?

— Намус турындамы, Марат Гаврилович?

— Намус кына түгел бит.

— Намус, кешелек, егетлек...

— Әйе, беренче намус, аннары кешелек, аннары гына егетлек... Ләкин боларның һәркайсы киң төшенчә. Әйтик, намус дигәндә без илгә булган мөнәсәбәтебезне дә, үзебезнең күңел сафлыгын, җаныбыз сафлыгын да, ил, халык ышанычын тапшырган эшкә, тирә-юнебездәге кешеләргә карашыбызны да күз алдында тотабыз. Хәер, нигә сөйләп торам әле мин боларны сиңа? Сезгә әллә ничә мәртәбә сөйләдем инде мин бу хакта.

Рәсим өлкән ярдәмченең күзләре авыртадыр, сиздермәгәндер, китәргә кирәк, дип урыныннан кузгалырга торганда, Назаренко каты бармаклары белән аның тез башына кагылды.

— Син, Шәйдуллин, мине кызганасың бугай, әйеме?

Рәсим, елап җибәрмәс өчен, авыртканчы аскы иренен тешләде.

— Кызган, Шәйдуллин, кызган. Тик, менә күрерсең, миңа пычагым да булмаячак. Мин күзсез калсам да, үкенмим. Мин адәм имгәге, әрәмтамак булмаячакмын, мин үземә эш табачакмын. Кояш чыгышын да, кояш баешын да күп күрдем инде мин үз гомеремдә. Беләсеңме, мин дөньяда инде тоташтан ике гасыр яшим сыман... Ә бит мин сугыш вакытында сезнең Татарстанга эвакуацияләнгән малай. Сөйләмәдемме мин сезгә бу хакта? Татарстанда әйбәт тәрбияләделәр мине, рәхмәт. Татар аналары үзләренең соңгы сыныкларын бүлеп биргәннәре хәтеремдә. Рәнҗетмәделәр мине Татарстанда. «Әни», «әпи», «май», «нәүрәп», «күкәй», хе-хе-хе. Дөрес сөйлимме татарча? Үзәккә, бәгырьгә үткән сүзләр алар, Шәйдуллин. Әтине мин бөтенләй хәтерләмим. Әти юк, әти сугышка кадәр үк югалган. Әни... күз алдында юкка чыкты. Ленинград — Мәскәү поездын немецлар бомбага тотты. Балалар гына иде ул поездда, Шәйдуллин. Ә мин бәхетле идем. Минем әнием дә бар иде. Минем әнием, минем әни... тәрбияче иде. Әнинең миңа таба сузылган куллары хәтеремдә. Тырнаклары алсу була торган иде аның. Ә бу юлы аның тырнагы күп-күмгәк иде... Ни төсле, дип әйтим. Ну, син мине гафу ит, ач бет күргәнең бармы синең? Ач бет төсле иде әнинең тырнаклары... Әни бик каты кычкырды да, без кызыл томан эченә кереп киттек. Бәлки, әни түгел, мин кычкырганмындыр, дүрт яшьлек малай каян хәтерләп бетерсен. Кызык... шул чактагы соңгы уем истә калган. Әни мине нишләп кысып кочакламады икән соң: нишләп кулларын гына сузып калды икән соң миңа, дип уйладым мин, Шәйдуллин, ул чагында. Син сугыштан соң туган малай, Шәйдуллин. Син әле күп нәрсәләрне белмисең. Дөрес, сугыштан соң да юллар ябык булды. Бигрәк тә безгә, әтисез үскән балаларга...— Өлкән ярдәмче, кинәт кенә йокыга талгандай, тынып калды. Иреннәре калтыранды аның, борын очы тирләп чыкты, куллары көзән җыерган чактагыдай, бер йодрыкланды, бер язылды.

— Марат Гаврилович, сестраны чакырыйммы, Марат Гаврилович,— дип каударланып урыныннан сикереп торды Рәсим.— Су кирәкме әллә, Марат Гаврилович?

— Су кирәкми, Шәйдуллин. Сестраны да борчыма. Режимга өйрәнсен бераз. Күзне әйтәм. Юкса, төнлә дә укол сорый башлады. Марля күзәнәкләре аша үтеп керәләр дә нәни генә шаян шүрәлеләр нәзек озын бармаклары белән күз карасын кытыкларга тотыналар... Сездә, татарларда бар ич әле бер әкият... Узды, китте, шүрәләләр... Кайда калдык әле, Шәйдуллин... Ә, әйе, намус турында сөйли башлаган идем. Гомер буе намуслы булыйм, гомерем буе йөзем ак, вөҗданым чиста булсын, дисәң дә, режимың бозылгалап куя кайчагында. Дөрес, барысы да синнән генә тормый... Син аңламыйсың бугай. Тыңла, сөйлим. Бер егет балаларны ярата, укытучы булырга хыяллана. Үзлегеннән укып, педагогия училищесында имтиханнар тапшыра, укытучы була. Аңа район үзәгеннән шактый ерак авылларның берсендә башлангыч мәктәп бирәләр. Авыр еллар. Балаларның аякларында чабата, ашаулары — бәрәңге ипие, крахмал күмәче. Мәктәп салкын. Мәктәп диярлеге дә юк инде. Түшәм ярыкларыннан йолдызлар күренә, идән ярыкларыннан балаларның китаплары төшеп югала. Бөтен класска өч карандаш, биш дәфтәр... Укытучыны шунысы гына сөендерә: балаларның укырга дәрте бар, бернигә дә карамый китап-дәфтәргә ябышып яталар алар. Укытучы авызыннан чыккан һәр сүзне отып алалар, үзләре дә аңа охшарга тырышып сөйлиләр.

Үр өстендәге лесхоз поселогыннан укуга бик чая бер малай төшеп йөри авылга. Алты яшендә генә булса да, беренче класска яза аны укытучы. Дөрес, роноданрөхсәт итмиләр. Ләкин укытучы үз намусы белән киңәш итеп караганнан соң, хакыйкатьнең малай ягында булуын чамалый. Укытучы уйлаганнан да сәләтлерәк булып чыга малаең. Икенче

класслар өйрәнә торган текстларны чатнатып укый, яттан шигырьләр белә. Ләкин укытучыга аның урманлы үрдән берүзе төшеп йөрүе генә ошамый. Көзге явымнар, кышкы салкыннар, бураннар килеп җитәр, авыл юлларының бала-чага түгел, олы кешегә дә читен чаклары еш була, дип борчыла. Бу хакта малайның әти-әнисе белән дә сөйләшеп карый. Һәй, пычагым булсынмы соң ул ташбашка, өч-дүрт яшендә кардонга киногa йөри иде инде, җен белән бер бит ул, дип кул гына селкиләр тегеләр. Ә малай йөри мәктәпкә. Бер генә дәресне дә калдырмый. Авыл балаларын берәм-берәм кызамык чире егып бетерә, ә моңа, мин сиңа әйтим, чир дә тими, чорт та...

Кышкы каникуллар җитәрәк, җәяүле буран себереп торган көннәрнең берсендә, малай мәктәпкә килми. Бер дәрес уза — малайның урыны буш. Ике дәрес уза — класс шып-шыр. Өч... Дүртенче дәрескә кергәндә укытучы түзми, балалар, сез үзегез генә укый торыгыз, мин дәрес бетәрәк кереп, теманы ничек үзләштергәнегезне тикшерермен, дип ишеккә юнәлә.

Лесхоздан төшә торган сукмакта бер генә эз дә булмый бу иртәдә. Җил искән саен юкә ботакларыннан шаулап кар коела. Юкәлекне узгач инде лесхозга да күп калмый. Уч табаны кадәр әрәмәлек, әрәмәлек артында киселгән урман. Укытучы малайның киндер букчасын әрәмәлек авызыннан табып ала. Яртылаш кар күмгән була аны. Сукмак читендәге гөлҗимеш куагы төбендә тагын бер карамчык шәйләнә. Мамыклары тузып чыккан бүрек колакчынын — малай мәктәпкә киеп йөри торган олы бүрекне кулына алгач, укытучы, башы әйләнүдән егылып китмәс өчен, чытырдатып күзләрен йома... «Бүреләр!» — дигән уй телеп уза аның бәгырен. Аннары малайның чәйнәлеп, өзгәләнеп беткән нәни чабаталары табыла. Төш кенә булсачы бу, төш кенә булсачы, дип, аптырап, гаҗиз калып, малайны кызганудан шаңар дәрәҗәгә җитеп, тагын берничә адым атлагач, укытучының ботинкаларына канлы кар ияреп чыга...

Укытучының бу мизгелдәге хәлен аңлыйсыңдыр инде син, Шәйдуллин? Әле бит малайның әти-әнисе берни дә белми.

Роно фикере белән килешмәде бит ул укытучы. Яше җитмәгән балага мәктәпкә йөрергә рөхсәт итте. Һәм менә сиңа нәтиҗә!

Әлбәттә, малайның әтисе белән әнисе якламаса, «утыртып» та куйган булырлар иде укытучыны. Ә болай мәктәптән куу белән генә чикләнделәр. Мәктәптән генә түгел, укыту системасыннан кудылар. Ә утыртсалар, яхшырак буласы иде. Нигә? Чынлап та, утырырга тиеш иде ул. Ә болай укытучының намусында җуелмаслык тап калды. Менә шулай, брат Шәйдуллин, таплы намус белән яшәүдән дә читен нәрсә юк дөньяда... Сәгать ничә әле, Шәйдуллин? Мин сине ялыктырып бетергәнмендер, м гаен. Бүген соңгы төн мин монда, Шәйдуллин. Иртәгә мине Мәскәүгә алып китәләр. Бәлки, бүтән күрешеп тә булмас...

Әллә теге коточкыч фаҗигага юлыккан малайны жәлләүдән, әллә өлкән ярдәмченең көтелмәгән сүзләреннән Рәсимнең бөтен йокысы качты, хәтта күкрәгенең чәнчешүе басылгандай тоелды.

— Ә беләсеңме, Шәйдуллин,— дип, ничектер җиңеләеп, бөтенләй сау кешедәй күтәренке тавыш белән сүзне Рәсим көтмәгән якка борып җибәрде Назаренко,— ир-егетләр күбрәк мәхәббәт мәсьәләсендә комга утыралар.— Өлкән ярдәмченең күгелҗем-кара иреннәреннән саран елмаю чагылып узды.— Бер яктан: «Покинуть женщину, с которой ты сблизился, аморально и распутно!» — дип әйтүе белән Толстой да хаклы. Икенче яктан... Хәер, дөресрәге, минем өчен тормыштагы бөтен мәсьәләләр ап-ачык сыман, ә менә мәхәббәт, хатын-кыз мәсьәләсендә, гафу ит, профан бугай мин. Чөнки башта рәтле-юньле итеп үз гаиләмне

кора алмадым. Намус турындагы фәлсәфәләрем кызларга да ошамый иде, хатыныма да ошамады. Мәхәббәтне, мөгаен, саф килеш сакларга, күз карасы кебек сакларга кирәктер, Шәйдуллин. Әй беләсеңме, мәхәббәтне кер тидермичә саклау өчен күпме түземлелек, күпме сабырлык, күпме көч-куәт таләп итеүә ир-егеттән. Ай-һай!.. Диңгез уртасында иске мина белән көрәшү генә түгел ул сиңа. Егетләргә иң әүвәле мәхәббәт мәсьәләсендә намуслы булырга кирәк, ә калган башка мәсьәләләрдә намуслы булуы аллә ни читен түгел. Ир-егет исемен йөрткән һәркем намуслы була ала башка мәсьәләләрдә. Ә мәхәббәт мәсьәләсендә кайчагында менә синең шикелле иптәшләре өчен утка ташланырга әзер торган гаярь ир-егетләр дә кабак боламыгына, киш-миш кесәленә әйләнәләр... Фу, җенем сөйми шундыйларны. Әйе, кеше булып туган кешегә бөтен гомере буе кеше булып калу һәм, ниһаять, кеше булып дөньядан китү шактый кыен эш.— Назаренко, үзе дә сизмәстән, кырысланды, сүз арасында озын бармаклары белән ак җәймә читен йомарлап-йомарлап алгалады.— Аннары, рәхәт тормышка бик нык ияләштек бугай без, Шәйдуллин. Рәхәт көннәр килгән саен рәхәткә сусыйбыз без. Рәхәттән рәхәт көннәр турында хыялланабыз. Көрәш рухы сүрелеп бара кешеләрдә. Шуны сизәсез микән сез? Мөгаен, сизмисездер. Яшьлекнең алсу таңында андый уйлар башка керми әле. Ә тормыш, уйлап баксаң, тоташ көрәштән тора. Тынычлык өчен көрәш, хакыйкать өчен көрәш, саф мәхәббәт өчен көрәш, табигать, җир иминлеге өчен көрәш, намуслы яшәү өчен көрәш. Ә көрәшләрнең иң авыры, Шәйдуллин, үз-үзең белән көрәшү. И, кыен да була инде кайчагында үз-үзеңне җиңү. Үзең сугасың үзеңә, үзең әйләнеп төшәсең, торып тагын үзеңне кабыргалап әйләндереп саласың. Бер якта куркак, мескен, түбән җанлы, битараф үзең бик тә яратучы үзең, ә икенче якта синең кешелекле, намуслы үзең. Үзең белән үзең көрәшкәндә һәрвакыт намуслы үзең җиңсен, Шәйдуллин... Ә хәзер йоклыйк инде, таң ата бугай... Сәгать бишме?

— Алтынчы ярты, Марат Гаврилович.

— Уһу.

— Бернәрсә дә кирәкмиме, Марат Гаврилович?

— Рәхмәт, Шәйдуллин, бернәрсә дә кирәкми. Нәни шүрәлеләрне куарга тиздән сестра кереп җитәр, хуш, Шәйдуллин. Батырлыгың өчен рәхмәт сиңа!

Рәсимнең бөтен йөзенә кайнар кан йөгерде.

— Һәй, Марат Гаврилович, китсәгез лә, нинди батырлык, ди. Мин бөтенләй дә батырлык турында уйламадым ул көнне...

— Хуш, Шәйдуллин! Без әле очрашырбыз. Син мине кызгана күрмә, берүк. Мин инде беркайчан да, теләсә нинди хәлдә дә харап булмыйм, мин чыныккан кеше... Үзеңне сакла, намусыңны сакла. Үзенең мәгълүм әсәренә Пушкин «Береги честь с молоду» дигән әйтемне эпиграф итеп юкка гына китергәндер, дисеңме. Ай, акыллы булган шагыйрь, һай, акыллы булган.

...Рәсим сулыш алгысыз кайнар сөрем, куе төтен эченә кереп югалгач, Назаренко да аның артыннан ташланды. Тәҗрибәсез яшь егетне коткару иде аның исәбе. Ләкин ул Рәсимне куып җитә алмады — фокмачтаны буярга дип әзерләп куелган эмаль банкасы шартлады һәм, гүя никдидер күзгә күренмәс явыз кул пычак очы белән Назаренконың ике күзен берьюлы чокып алды...

Рәсим бу кадәресен белми иде әле. Ул, күкрәгендәге медален кешегә күрсәтергә оялгандай, учы белән томалаштыргалый-томалаштыргалый яңадан госпитальгә барганда, Назаренконы махсус самолет белән башкалага озатканнар иде инде.

Ә тагын ике көннән Рәсимне, Кулешовны һәм тагын ике матросны демобилизацияләделәр. «Теләсәң, диңгез училищесына керә аласың, на-

правление бирәм, әйбәт характеристика язам»,— диде аңа капитан озатканда.

Бу сүзләрне Назаренко әйтсә, бәлки, уйлап караган булыр иде әле Рәсим. Ә хәзер аны ни өчендер берни дә сөендерми, күңелендә әллә нинди тел белән әйтеп-аңлатып булмый торган авыр тойгылар, сагышлы кичерешләр иде аның. Шуңа күрә капитанга кистереп:

— Авылга кайтам, әни карчык ялгызы гына,— диде.

### Өченче бүлек

Дөресен әйтергә кирәк, хәрби хезмәткә алынгач, Рәсим авыл турында сирәгрәк уйланды, әнисенә дә хатлар сирәк язылды. Ара ерак иде шул, бик ерак иде ара. Рәсимнәрнең катеры ел әйләнә илнең иң ерак чикләрендә булды. Хәтта техник карауны да, зур җиргә чыгып мәшәкатьләнмичә, бөтен кирәк-яраклар, ашау-эчү, кием-салым белән тәэмин ителгән атауда үткәрәләр иде алар. Почта вертолет белән килә. Аннары авылны элеккеге еллардагы кебек сагынмый да иде инде Рәсим. Өч ел балык флотында, ике ел хәрби флотта хезмәт итү, төне-көне салкын дулкыннар арасында тирбәлү тәэсиредер, күрәсең, Тәслимә турындагы уйлары да элеккеге кебек кайнар түгел иде аның. Рәсим тагын да кырыслана төште. Озын төннәр буе палатада күкрәгенең киселгән турын учы белән каплап, керфеккә-керфек какмый ятканда: «К черту, кайтмыйм авылларына, диңгездә калам»,— дип тә уйлап куйгалый иде Рәсим. Ләкин өлкән ярдәмче белән соңгы сөйләшү аның тискәре фикерләрен челпәрәмә китереп ташлады. Юк шул, алай җиңел генә өзеп ташлый алмый әле Рәсим үзен авылга бәйләп торган җепләрне. «Киткәндә карчык әниеңә адәм рәтле йорт салып калдыра алмаганга кайтмаска уйлыйсың син авылга, авылдашларыңнан оялaсың, ай-һай, оста, диңгездә кала, имеш, калмый тор әле!» — дип сүкте Рәсим үз-үзен, флотташ иптәшләре белән самолетка билетлар юнәтеп, берьялгызы гына ташлы диңгез буена төшеп утыргач.

Рәсим бармак очы белән күз төпләренә орынып алды. Бармак очлары юешләнгәч, сискәнеп китте. Елый түгелме соң ул? Егет елый. Утнысуны кичкән диңгезче егет елый. Адәм көлкесе. «Яргаланып беткән кара ташларны кочып иркәләгән диңгез дулкыннарын күреп булыр микән тагын?» — дип, яшь коядыр, бәлки, аның күзләре. Бәлки Назаренко язмышы шулай бертуктаусыз елатадыр аны. Ә бәлки Тәслимәдер... Тәслимә... Корабына ак җилкәннәр корып кайта алмады инде Рәсим Тәслимәсе янына. Киселгән күкрәк, ярты күкрәк белән кайтып бара менә.

Ә бу салкын битараф диңгез Рәсим шушы якларга килгәнче дә шулай кара ташларга сарылып уйнаган, Рәсим киткәч тә шулай дәвам итәр аның тормышы. Мең елларга, миллион елларга сузылган мәгънәсез хәрәкәт, нәтиҗәсез шау-шу. Я, корабларны батырдың, ди, кыяларны ашадың, ди, боз тауларын эретеп бетердең, ди. Шуннан нәрсә? Кешеләрне беркайчан да куркыта алмадың син һәм куркыта да алмассың. Алар синең ярсулы давылларыңа төкереп тә бирмичә дулкыннарың арасыннан йөзгәннәр һәм йөзәләр... Батыруы, җимерүе ансат ул. Төзеп кара син менә шундый зур көч-куәткә ия булгач, төзеп кара!

Диңгез, ярларыннан сикереп чыгарга теләгәндәй кайнап, күбекләнеп, таш кыяларга сикерде дә кире чигенде. Рәсимнең ботинкаларына, җиренә җиткереп үтүкләнгән кара чалбарына, хәтта күкрәгендәге медаленә су тамчылары чәчрәде. Рәсим тирә-юньгә елтыр нурлар чәчеп җемелдәп киткән медален учына кысты, тирә-ягындагы шәрә бушлыкта, ак кургаш төсле тонык кына ялтырашкан дулкын сыман дәрья өстендә айкалып йөргән шалама болытларга күз ташлап алды да, калтыранган

куллары белән медаль энәсен ычкындырды, медальне кульяулыгына төрде. Бик тә яшертен эш эшләгәндәй, тагын тирә-юньне күзәтеп чыкты. Шәрә ташлар арасында берьялгызы гына булуына ышанып, кыя киртендә яткан бәләкәй чемоданын бер хәрәкәт белән ачып җибәрде. Авыл карчыкларының сәдакага җыелган акчаларын саклый торган төенчеккә охшаган иде кульяулыгына төрелгән медаль. Төенчекне энисенә бүләккә дип алган күлмәклек штапель астына салып куйгач, Рәсим җиңел сулады. Чемоданындагы тельняшкалардан бөркелеп торган одеколон исе аңа тагын катер тормышын, диңгез суларын, Назаренконы исенә төшерде. Кайсыдыр бер рейстан соң портка чыккач, челтәрле тимер капка башына менеп кунаклаган кызыл чәчле, курнос борынлы малай аның артыннан:

Эй, моряк!
Штаны горят,

— дип кычкырып калган иде.

Штаны гына янса бер хәер иде Рәсимнең. Күкрәге янды, күкрәге. Авылда дус-ишләре белән мунча да кирәкмәс. Кызлар турында уйлыйсы да түгел. Тәслимә турында хыялланасы да юк. Рәсим кайтканчы, Әхмәт абыйсына гына кияүгә чыккан булса ярар иде. Юк, чыкмасын иде, чыкмасын иде әле. Сөйләшсен иде ул тагын бер мәртәбә Рәсим белән, бер генә мәртәбә сөйләшсен иде. Нинди икән хәзер Тәслимә? Тәмам пешеп тулгандыр, чибәрләнгәндер инде. Башка егетләр сөйгән кызлары белән хат алыштылар, арада сөйгән кызлары белән генә түгел, бөтенләй таныш булмаган кызлар белән дә хат язышучылар күп иде. Ә Рәсим бердәнбер Тәслимәсен дә йөрәгеннән йолкып ыргытты. Нигә кирәге бар сине яратмаган, синең өчен янмаган, көймәгән, сине сагынып көтмәгән кызның? Бик яхшы булды әле Рәсимнең күкрәге пешү. Югыйсә, бертуктаусыз йөрәге әрни иде аның, бер сәбәпсез әрни иде. Ә күкрәге пешкәч, җанының сызлануы, эчке газаплары басыла төште. Тән авыртуына түзәргә була, җан авыртуы бик яман.

Ә медальгә килсәк, медаль турында ул болайрак уйлый: ниндидер батырлык күрсәтү, кемнедер коткарырга омтылу, китапча итеп әйтсәк, бөек максат өчен җанын фида кылу хакында уйлап та карамады ич Рәсим ул көнне. Сулышны эче тәтен буган иде, шул төтеннән котылырга кирәк иде. Аннары, «Янабыз!» дип, капитан түгел, радист кычкырган икән. Тавык кетәге кадәр радиорубкасында төтенгә буылып калгач, кычкырмый нишләсен! Үлә башлагач, нибуч кычкырырсың — тавышы бик яман иде. Андый тавышка тәнендә җаны бар кеше түгел, мәет сикереп торыр. Кайнар сөрем эченә килеп кергәч инде Рәсим бернәрсә турында да уйлый алмады. Якорьны суга төшерүе дә ничектер уйламаганда, үзеннән-үзе килеп чыкты.

Шул да булдымы батырлык! Харап икән, бераү кайнар кургаш яудырып торучы пулемет авызына ташланган, диярсең. Назаренкога тиеш иде медаль, Рәсимгә түгел. Менә аны, ичмасам, әйтсәң дә ярый! Марат Гаврилович беркайчан да үзе турында уйламый. Нишләр икән инде ул бичара тома сукыр калса? Ничек кенә ярдәм итә ала икән аңа Рәсим? Мәскәүнең кайсы больницасында ята икән ул хәзер, ниләр уйлый икән?

Медален чемодан төбенә салып куйгач, уйлары чистарып, кәефе күтәрелеп киткәндәй булды Рәсимнең.

Ул җәһәт кенә урыныннан торды, кыя киртеннән чемоданын сузылып алганда, җөйле күкрәге чәнчешеп куйса да, элекке кебек чыраен сытмады, йөнтәс кашларга ук төшереп киелгән бескозырька тасмаларын җилфердәтә-җилфердәтә, инде Рәсимне үз итеп өлгергән, Рәсимгә иярләшеп җиткән, Рәсимнән аерылырга теләмәгән дулкыннарның сагышлы гөрелтесен тыңлый-тыңлый таш кыя читеннән олы тимер итеккә охшаш койрыгы күренгән самолетка таба атлады.

Биеклек — ике мең метр. Тизлек — сәгатькә тугыз йөз километр. Тышта температура илле градус. Аста өем-өем болытлар. Иллюминаторлардан караганда һич тә болытка охшамаганнар болытлар. Тауларга, мамык тауларына охшаганнар. Шул мамык тауларына сикереп төшәсе, рәхәтләнеп ауныйсы килә.

Самолет эчендә гадәтләнмәгән тынлык. Шушы яшенә җитеп, Рәсимнең мондый гаҗәеп тынлыкта изрәп утырганы юк бугай әле. Инде ничә елдан бирле ярсу дулкыннар арасында, ничә елдан бирле салкын җилләр патшалыгында яшәде ул. Төнге вахталар, приказ буенча җиде төн уртасында сикереп торулар, «полундра»лар. Өчәр тәүлеккә сузылган штормнар, үз-үзеңне күрәсе килми башлаганчы чайкалулар. Шулай да үкенми Рәсим. Күп нәрсәгә өйрәтте аны диңгез. Егет буласы килгән егетләр өчен бик шәп тормыш мәктәбе, егетлек мәктәбе икән ул.

Диңгез инде ерак калгандыр, болыт океаны астында, мөгаен, себер тайгасыдыр хәзер.

Салонда Рәсимнән гайре хәрби киемле кешеләр күренми. Аңа күренгән кешеләрнең һәммәсе дә диярлек күзләрен йомганнар. Рәсим янындагы күзлекле агай да, янәшә утыргычлардагы егет белән кыз да, йоклап баралар. Әллә самолетта очу куркыныч микән аларга? Шулай, ахры — самолет һава бушлыгына кереп нык тирбәлеп алгач, күзлекле агай күзләрен шарландырып ачты да борын астыннан гына авыл картларыча «ләхәүлә»сен укып куйды.

Рәсимгә кызык булып китте. Дөресрәге, күзлекле агай белән татарча сөйләшәсе килеп китте аның. Агай күзлек өстеннән Рәсимгә сөзеп карады да янә күзләрен йомды.

— Нәрсә, агай, әллә куркыттымы? — дип сүз катты Рәсим, тирә-юньдәгеләр ишетмәсен өчен шыпырт кына.

Агай гаҗәпсенеп Рәсимгә борылды, күзлеген кулына алды. Аның маңгае тар һәм күзләре бер-берсенә шундый якын урнашкан иде, күзлеген кигәч, агай кырмыскага охшап калды.

— Кем фарсит итеп йөри дисәм, себер салкынында юка гына бушлат белән, үзебезнең халык икән. Кайсы җирдә хезмәт иттең? Кая кайтасың? Тутырып кайтасыңмы хезмәтеңне, әллә ялга гынамы?

— Тутырып кайтам,— дип, сорауларның берсенә генә җавап биреп өлгерде Рәсим. Агай, пулеметтан сиптергәндәй, төпченергә тотынды:

— Ничә ел хезмәт иттен, кайда?

Рәсим күзлекле агайга текәлебрәк карады. Маңгай сызыкларына, яңактан борын төбенә сузылган җыерчыкларга, чаларган чигә чәчләренә карап-карап торды да сөенеп юлдашына эндәште:

— Сәләх абый, син ич!

Чак кына «Сорау Сәләх абый» — дип әйтеп ташламады Рәсим.

— Мин шул, ә син кем, үзең кем малае? — диде күзлекле агай гаҗәпләнми-нитми генә.

— Соң, ни бит инде, Сәләх абый. Элмәледән ич мин. Сезнең күрше авылдан, Хәят малае. Әле бервакыт синең белән бүрәнәгә дә барган идек. Акчаны суга салып кайттык.

Сәләх, нәрсәдер исенә төшерергә теләгәндәй, самолет түшәменә текәлде.

— Соң, гармун, гармун, Сәләх абый. Хәтерләдеңме Казлаука затонына барып кайткач, тальянымны биреп җибәргән идем мин сиңа. Исеңә төштеме?

— Ә-ә, синмени әле ул? — диде Сәләх, ни өчендер Рәсимнең күзләренә туры карамыйча.— Синмени әле ул? Я, өй салдыңмы соң инде?

Нәрсә дә нәрсә, ләкин Рәсим бу сорауны көтмәгән иде. Туры наводка белән тондырды Сорау Сәләх, Рәсимнең нәкъ авырткан җиренә тө-

зәп атты. Салон җиләс булса да, тирләп чыкты Рәсим, Сәләхкә сиздерми генә бушлат төймәләрен ычкындырып җибәрде.

— Салмадыңмыни әле әй?

— Малаең гармунда уйнарга өйрәндеме соң инде? — дип, үзе уйлавынча, Сәләхнең «провокацион» соравын урап узарга теләде Рәсим һәм теләгенә иреште.

— Син, якташ булсаң, кайдан кайтып киләсең, дип сорар идең башта, әтү сразу гармун. Уйнарга өйрәндеме,— диде Сәләх үпкәле тавыш белән.— Өйрәнде пычагым. Егерме яшенә тикле безнең җилкәне кимереп ятты да сугышып төрмәгә эләкте. Мин аны, тукта, бераз исәйсен, тукта, бераз буыннары ныгысын дип, авыл советларыннан, собеслардан справкалар юллап, военкоматларга йөреп, яше җитсә дә, армиягә җибәрмичә асрадым. Тапканнар бит кешесен — участковыйның кулын сындырганнар. Юкса, ике елдан котыласы иде, собака. Торып-торып ачуым килә. Шул бәхетсез яныннан кайтып киләм әле менә. Малай бит, жәл. Мең төрле нужа чигеп, мең чакрым җир үтеп булса да, хәлен белергә бардым. Азрак акча юнәтеп илттем. Син, гармун уйнарга өйрәндеме, дисең. Өйрәнде пычагым. Ата ялкау бит ул. Өйдә аркылыны буйга алып салмый. Синең гармунда уйнарга өйрәнә алмагач, хромка алып бирдем. Аны мотоцикл артына бәйләп (игә килмәсме азрак дип, мотоцикл да алып биргән ием),— һаңүз малае белән Вәсүк маржалары янына йөрделәр. Шунда самагун эчәргә өйрәнде, каһәр суккыры. Янгырлы көнне егылганнар. Аягы биртелеп, дүрт ай больницстә ятып чыкты малай. Хромкасының уйнарлыгы калмаган иде инде ул чагында. Тукта, көйгә килер, инде рәтләнер, шәт, аягы имгәнгәч, инде сабак алгандыр, дип баян алып бирдек, тана сатып. Тотып та карамады. Бик каты эчә башлады. Әнисенең пенсия акчасы, дип тормый, калай алырга җыйган акча, дип тормый, тотанаксыз эчә дә эчә. Аптырагач, өйләндермәкче булдык. Кем килсен исереккә? Үзе дә аяк терәп өйләнмәскә тырыша: «Яшь гомерләр ике килми, белегез кадерләрен!» — дип, авызын гына ера Вәсүктән самагун эчеп кайткач...

Сәләх абый, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, күзләрен сөртеп алды. Бер тамчы күз яше, йөзендәге җыерчык буенча тәгәрәп, алга чыгыбрак торган ияге очында тирбәлеп торды да, каракуль тун якасына сикереп төште.

Рәсимгә бик кызганыч булып тоелды бу минутта Сәләх абыйсы. Ләкин ул Сәләх абыйсын юатырлык сүзләр таба алмады. Аннары, Сәләх абыйсы сорау бирәсе урынга, үзе сорау бирүе өчен оялып һәм шул ук вакытта көләсе килеп, ләкин сорамыйча кала алмаячагына тәгаен ышанып:

— Сәләх абый, ә минем гармунны нишләттегез? — диде.

— Нишләтик, ята торгандыр чормада. Соңгы елларда әллә бездә гармун кайгысы булды дип уйлыйсыңмы?

— Уйламыйм.

— Уйламагач, нишләп шундый сорау бирәсең?

— Шәт, кире бирерсең ул гармунны миңа?

— Нишләргә уйлыйсың ул үтил белән?

— Тәк себя. Яшьлек истәлеге итеп саклармын.

— Авылда калырга уйлыйсыңмы?

— Белмим әле.

— Авылда торасылары килми хәзер яшьләрнең. Азган-тузган — базарда, эш сөймәгән — Казанда, диләрме әле?

— Белмим,— диде Рәсим, Сәләх абыйсының гармун турында өзеп әйтмәвен өнәп бетермичә.

— Туры кайтасыңмы? — диде Сорау Сәләх, стюардесса кыз кереп, пассажирларның хәлен белеп чыккач, ни гомер сорау бирми түзүе өчен үз-үзенә гаҗәпләнгәндәй.

— Туры кайтам.
— Авылгамы?
— Ие.
— Беләләрме өйдәгеләр?
— Юк.
— Телеграмм сукмадыңмыни?
— Юк. Әллә син туры кайтмыйсыңмы, Сәләх абый?
— Минме?
— Син.
— Юк, туры кайтмыйм. Бишбалтага керәм. Хатын ягыннан туганнар бар анда. Шуларның бер танышлары прукурур булып эшли. Берәр ничек статьясы юк микән, тизрәк кайтару җаен табып булмас микән малайны. Ятып калганчы — атып кал, дигәндәй, йөреп карарга кирәк инде. Хәрәкәттә — бәрәкәт. Исенә төшкән хәзер үзенең дә. Әткәчем, моннан исән-сау котылып кайтсам, ярты ел ураза тотарием, ди. Уразасын тотмас, анысына ышанмыйм, безнең җанны картайтмыйча яшәсен хет.

Сәләх абыйсы тәмләп-тәфсилләп туган яклар турында сөйләр, дип өметләнгән иде Рәсим, булмады. Үз кайгысы кайгы иде кешенең. Шул кайгысы аркасында хәтта холкын-фигылен үзгәртә язган, имеш, агай — сорауларын да элекке кебек бер-берсенә ялгап бара алмый. Әллә Рәсим, аның гадәтен яхшы белгәнгә, әллә вакытында контр һөҗүмгә күчеп өлгергәнгә, сораулар белән кумә алмый Рәсимне Сәләх абыйсы. Мөгаен, тегесе дә, бусы да бардыр. Аннан соң, картаеп бара бит инде агай — зиһене дә сыегая торгандыр.

Кыскасы, якташлар арасындагы әңгәмә җылынып китә алмады. Берәздән алар икесе дә, бик алҗыган кәяфәттә, күзләрен йомып, буыннарын йомшартып, икесе ике якка кыйшаеп, изрәп утыралар иде инде.

Дөресрәге, Сәләх абзый гына изри, Рәсим исә, бая стюардесса кыз кереп чыккач салонга җәелеп калган татлы хушбуй исеннән тәэсирләнеп утыра иде. Чәчәкле урман аланнарын, печән өсте болыннарын, сабан туе юлларын, әнисенең сөлге-җәймәләр, житен тастымаллар, борынгы эскәтерләр белән шыплап тутырылган олы яшел сандыгын, Тәслимәләрнең албакчаларында шаулап чәчәк атып утырган кәнәфер куакларын хәтерләтте Рәсимгә хушбуй исе.

Туктале, көз көне, бәрәңгеләр алып бетергәч, сарылы-кызыллы бөркәнчек ябылган урман авызында да шундый ис була торган иде ич.

Ат абзары буендагы чүп үләннәрнең дә кайсыннандыр шундый ис аңкып тора иде.

Кайсы көздә булды соң әле ул. Көз җитмәгән иде бугай әле, хәер. Август азаклары иде. Ак болытлар белән качышлы уйнап йөри торган җиләс төн. Җир өстеннән дулкын-дулкын булып күләгәләр йөгерә. Агач ябалдашларын сибелдереп тынгысыз җил йөри. Мондый төннәрдә авыл урамы буенча чабып йөрисе, нинди дә булса бер шуклык эшлисе, кемне дә булса куркытасы, шыпырт кына артыннан барып, «Һайт!» дип кычкырасы килә.

Тәслимәләр ул төнне келәт алдында ашлык чистарталар иде. Зернопульт тавышы түбән урамнарга кадәр ишетелде.

Рәсим клубтан кайтканда гармунын, гадәттәгечә, кычыткannar арасына куеп калдырды да, болыт күләгәләренә ияреп, дворга таба йөгерде. Каравыл йортында ут сүнгән, каравылчылар йоклыйлар иде, ахры. Ат сарае янында кеше-кара күренми. Рәсим барып җитәрәк, зернопульт тавышы да тынды. Моторына бер-бер хәл булгандыр, күрәсең — механик Сәлимнең, борын астыннан гына нәрсәдер мыгырданып, нинидер тимерләр шакылдатканы ишетелә. Анда-санда, тоныкк кына булып, фонарьлар яна, караеп ашлык тавы күренә. Кызлар ял итәләр, ахры, тавыш-тыннары юк. Ә-ә, әнә кайда икән алар. Кызлар да булсын, тавыш бирмичә дә утырсыннар. Ябулы ындыр табагы эченнән сиксән яшьлек

бабайларның да йокысын качырырлык чыркылдау ишетелде. Аһа икенчесе, өченчесе кушылды. Кызлар түшәм ярыгыннан да көлә, диләр, дөрес, ахры. Ә Рәсимгә шул гына кирәк тә. Ул олы капкадан кереп тормады келәт янына. Аннан керсә, Сәлим — әле ярый, үзе генә булса, кладовщик Вәсимәсе дә шундадыр әле, мөгаен — һичшиксез, сизәчәк. Шуңа күрә Рәсим биек рәшәткәгә ышыкланып туп-туры ат сарае янына килде.

Менә шул чагында килеп бәрелгән иде аның борынына әлеге ис. Нинди үлән исе булды икән соң ул? Ул төнне Рәсим ашыга иде шул, аны-моны карап тормады — хуш ис аңкытып утырган үләннәрне аралап, юан киртәгә, киртәдән багана башына, багана башыннан ат сарае түбәсенә менеп китте. Сарай түбәсенең саламы искергән — баскач, аяклар бата иде хәтта. Менә келәт алдын ай яктыртты. Кызлар түбә астында ук түгел икән, башларын бер-берсенә куеп, йолдызчык хасил итеп, көшел өстендә яталар иде алар. Леңгер-леңгер сөйләшкәннәре ишетелә, әмма сүзләре аңлашылмый. Сүзләре аңлашылса, кызлар серен тыңлап утырудан баш тартмас иде әле Рәсим.

Болай оеп утырырга ярамый, Сәлим моторын тәзәтеп бетерер дә, менә тагын эшкә тотынырлар. Нинди дә булса бер кызык эшләп калырга кирәк. Башларын башка терәп ятканнар дигәч, чәчләре чәчкә орынып тормый бугай әле. Уртада токмач җәярлек кенә урын калган. Рәсимгә шул гына кирәк тә инде. Ай болыт пәрдәсе артына яшеренеп торган арада — һап! Сикерде дә төште кызлар арасына. Аяклары тездән көшелгә батты, авыз-борынына кибәк тулды. Кызлар каравыл кычкырып урыннарыннан сикереп тордылар. Рәсимне танығач кына:

— Әбәү, шул кадәр куркытмасаң! Йөрәгемне яра язды, җен,— дип тиргәнә-тиргәнә өс-башларын кагарга керештеләр.

Авыл кызларын тегеләй итегез, болай итегез, дип өйрәтергә кирәкми. Кайсы вакытта ничек итәргә кирәклеген алар сүзсез дә бик яхшы аңлыйлар. Бу юлы да алар, тегене эшлисем бар икән, кара, фәләнен әйберем онытылып калган бит, диеп көшел өстендә Рәсим белән Тәслимәне икәүдән-икәү генә калдырып, төрлесе төрле якка таралышып беттеләр...

Тәслимә йөзтүбән ята. Аның яулык астыннан ишелеп чыккан чәчләрен сыйпап аласы килде Рәсимнең. Тәслимә ни өчендер еш-еш сулыш ала. Юка күлмәгенең җиңнәре дә, итәге дә җыерылган, тулы, тыгыз балтырлары, шәрә беләкләре ай нурында иркәләнә.

Тезләнеп утырган килеш Рәсим, кулына үлән сабагы алып, Тәслимәнең муенын кытыклады. Тәслимә муенын җыерды. Әмма бер сүз дә әйтмәде. Рәсим тагын кытыклады, Тәслимә, җәһәт кенә күтәрелеп, озын толымын муенына урап куйды, үзе тыелып кына көлде.

Бераздан Рәсим, көтеп-көтеп тә тел очына кирәкле сүзләр килмәгәч:

— Ай нинди кояшлы бүген,— дип ычкындырып ташлады.

Монысы «Ата казыгыз күкәй саламы, кодагый?»дан да кәттәрәк килеп чыкты. Тәслимә пырхылдап көләргә тотынды. Рәсим, колаклары кызышуын, яңаклары януын тойды.

— Иртәгә кояшы да айлы булыр әле,— диде Тәслимә, көлеп арыгач.— Сине әкиятләр күп белә, диләр. Әкият, я шигырь сөйләр идең, ичмасам.

Рәсим Тәслимәне шулай рәхәтләндереп көлдерә алуы өчен эченнән генә сөенеп куйды, үзе дә аңа кушылып көлде, мәсьәлә әкияткә килеп җиткәч кенә уйга калды. Нәрсә, нинди әкият сөйләргә соң? Тәслимәгә лаек әкият бармы икән соң Рәсимнең әкият капчыгында?

Ак болыт артында югалып торганда көшел өсте сөрмә белән бизәлгән көмеш тавына охшап кала, ай чыккач, ак алтын тәсенә керә, башка кызлар ындыр табагының икенче читендә серләшәләр, болыт ертыгын-

нан Җидегән йолдыз, теләр-теләмәс чекрәеп, җирне күзәтә. Әллә ул да Рәсимнең әкият сөйли башлаганын көтә микән.

— Борын-борын заманда яшәгән ди, булган ди, Гашыйк Гарип исемле ярлы егет. Бик оста җырлаган ди ул. Туйларда саз чиртеп, җырлап йөрүдән бүтән һөнәре булмаган аның. Бер туйда Гашыйк Гарип Маһимөһри исемле гүзәл кыз белән очраша да аңа гашыйк була. Күктәге ай-йолдызлар чүп кенә икән Маһимөһринең чибәрлеге янында... Маһимөһри дә ошата егетне. Маһимөһринең әтисе череп чыккан бай кеше булганга күрә, Гашыйк Гарип шикләнә инде кызга уйларын белдерергә. Бер көнне шулай алмагач бакчасында бик озак саз чиртеп җырлап ята да Гашыйк Гарип йокыга тала. Аның яныннан иптәш кызларын ияртеп Маһимөһри үтеп бара икән. Арадан бер кыз, Гашыйк Гарипне күреп, җырлап җибәрә. «Әй, бичара Гашыйк Гарип, яныңнан мәгъшукаң үтеп бара, ә син йоклап ятасың»,— ди. Гашыйк Гарип уяна. Маһимөһри дә аны күреп ала. Алмагач төбенә утырып сөйләшәләр болар. Маһимөһри әйтә Гашыйк Гарипкә: син мине яратасың, мин дә сине яратам, син мине әтиемнән сора, ул безнең юлга аркылы төшмәс, ди. Әй-әй, ди шунда Гашыйк Гарип, сез әнә нинди череп чыккан бай кешеләр, ә безнең бернәрсәбез дә юк, сорамыйм мин сине әтиеңнән, бик яратсам да сорамыйм, гарьләнәм, ди. Мин, ди, бүген бәхет эзләргә чыгып китәм. Син мине яратсаң, җиде ел көтәрсең, җиде елдан да кайтмасам инде, бер бик һәйбәт егеткә кияүгә чыгарсың, ди. Маһимөһри көтәргә вәгъдә бирә...

Рәсимнең әкияте шул урынга җиткәч, Тәслимә көшел еемен чокырайтып чалкан әйләнде, ак беләкләрен баш астына куеп, карашын һавага төбәде. Аның түм-түгәрәк күкрәк алмалары, гади ситсы күлмәкне ертып чыгарга теләгәндәй, еш-еш тирбәләләр иде.

— Я, я, шуннан, сөйлә инде,— диде Тәслимә түземсезләнеп.— Җиде елдан кайтамы егет?..

— Әкият кенә тиз сөйләнә, эш алай тиз эшләнми,— дип сүз арасына чын әкиятчеләрчә җор тәкъбир кыстырып җибәрде Рәсим.— Шуннан Гашыйк Гарип өенә кайткан. Өендә карчык әнисе белән кечкенә сеңелесе генә булган аның. Шулай да шулай дигән. Хәлне төшендереп биргән инде бу. Ярар, дигән әнисе, китсәң китәрсең инде, язмыштан узмыш юк, истәлеккә сазыңны калдыр, дигән. Шуннан өйдәгеләр белән саубуллашып чыгып киткән бу ерак юлга. Озак та бармаган, киң генә бер елга буена җитәрәк бер җайдак куып җиткән малайны. Караса, Хөршид бәк, имеш. Хөршид бәк бай малае булган инде. Ул да Маһимөһригә кызыгып йөргән. Килеп җиткән дә Гашыйк Гарип янына, әйткән бу, мин дә синең белән бәхет эзләргә китәм дип. Син чишен дә йөзеп чык елганы, киемнәреңне ияремә бәйләп үзем алып чыгармын, дигән. Гашыйк Гарип чишенеп, елганы йөзеп чыккан. Каршы ярга аяк баскач әйләнеп караса, Хөршид бәк атын бар хәлгә чаптырып елгадан ераклашып бара. Аның артыннан тузан гына бөтерелеп кала юлда. Гашыйк Гарип шыр ялангач калды бит инде. Төнгә кадәр куаклар арасына посып утырган да ул, караңгы төшкәч, шәһәр читендәге бер өйнең ишеген каккан. Яхшы кешеләргә тап булган ул. Аны киендергәннәр, ашатканнар. Моның өчен Гашыйк Гарип аларга иң матур җырларын җырлап күрсәткән. Ә Хөршид бәк нишләгән, дип уйлыйсың. Гашыйк Гарипнең күлмәкләрен ерткалап канга буяп бетергән дә, бичара карчык хозурына барып, улыгызны бүре ашады, менә киемнәре, дигән. Гашыйк Гарипнең анасы бик каты елаган. Елый-елый аның күзләре сукырайган. Яман хәбәрне Маһимөһригә дә җиткергәннәр. Маһимөһри ышанмаган, җиде ел үтмичә барыбер беркемгә дә кияүгә чыкмыйм, дигән.

Гашыйк Гарип чынлап та исән бит әле. Шәһәрдән шәһәргә йөри торгач, аның оста җырлавы турындагы хәбәр ханга да ишетелгән. Хан моны сараена алдырган. Бик рәхәт гомер кичереп ятканда, көннәрдән



Т. Хажиэхмэтов рэсеме.

бер көнне Гашыйк Гарипнең туган якларыннан сәүдәгәрләр килеп төшкән. Арадан бер сәүдәгәр, базарда Гашыйк Гарипне танып, капчыгыннан алтын кош-табак чыгарган да әйткән: «Син бит бу, Гашыйк Гарип, менә бу коштабакны сиңа Мәһимөһриең җибәрде, биргән вәгъдәсен онытмасын, дип әйтте»,— дигән.

Шуннан ашыгып хан сараена кайткан инде Гашыйк Гарип. Кайткан да читтә күпме гомер итүен исәпләп караган. Хисаплап караса — эш харап! Тагын бер тәүлектән моның өйдән чыгып киткәненә нәкъ җиде ел тула! Инде нишләргә? Еллар буе җыйган алтын-көмешләрен киндер букчага тутыра да Гашыйк Гарип, ханнан рөхсәт алып, чыгып йөгерә. Йөгергән хуттан килә бер бик биек кыя итәгенә. Мең чакрым юлны барыбер бер тәүлектә кайтып җитеп булмый, шул кыя түбәсеннән егылып кына үлимме, дип кыяга таба атлый Гашыйк Гарип. Шул чагында моның янында гына Акбүз атлы, мәһабәт буй-сынлы, ак сакаллы бер җайдак пәйда була, Гашыйк Гариптән хәл-әхвәл сораша инде бу. Шулай-шулай, ди Гашыйк Гарип, хәлен аңлатып бирә моңа. Менә шушы кыя түбәсеннән ташланып үләргә иде әле исәбем, ди. «Кая хәтле алып барырга соң сине?» — дип сорый Гашыйк Гариптән ак сакаллы. Мең чакрымын ук әйтсәм, бик ерак инде, дип уйлый Гашыйк Гарип Шулай да бер ике йөз чакрымын әйтә бу. Букчаңны ас ияремә, үзең артка менеп атлан, ди теге кеше. Гашыйк Гарип менеп атлангач, күзеңне йом инде хәзер, ди. Күзен йома Гашыйк Гарип. Ач, ди теге. Гашыйк Гарип тирә-ягына караса, ни күзе белән күрсен, ике йөз чакрым араны узып та киткәннәр болар. Агай, ди инде Гашыйк Гарип, миңа тагын өч йөз чакрым юл үтәргә кирәк бит, алып бармассың микән, ди. Нигә алдан ук әйтмәдең, ди инде теге, һай ялганчы адәм баласы, йом күзеңне хәзер үк, ди. Бераздан — ач, ди. Гашыйк Гарип күзен ачса, шакката — тагын өч йөз чакрым юл үткәннәр болар. Гашыйк Гарип ак сакаллы агайның могҗиза иясе булуына тәмам ышана инде хәзер. Әй, абыкачым, адәм баласы иртән ялганлый башласа, көне буе ялганлый, миңа өйгә кайтып җитү өчен тагын биш йөз чакрым юл үтәргә кирәк бит әле, берүк, ярдәм итә күр инде, ди. Яхшылыгыңны гомер буе онытмам, ди. Теге тагын сукрана инде. Бик тә алдакчы булып чыктың бит әле син, адәм страмы, ди...

Тәслимә, күзләрен шарландырып һавага карап яткан җиреннән, тыела алмыйча көлеп җибәрде. Әрем исе аңкып торган бармаклары белән Рәсимнең кытыршы чәчләренә орынып алды. Күз аллары иләс, миләсләнеп, башы әйләнеп китте хәтта Рәсимнең.

Тәслимә исә һаман чырык-чырык килде, әйтәсе сүзен көч-хәл белән генә җыйнаштырып әйтә алды:

— Уф, үтерәсең!.. Үләм! Адәм страмы, димәгәндер инде, бигрәк... бигрәк кызык сөйлисең... Я, я, шуннан?

— Шуннан, шуннан,— дип зиһенен тупларга тырышты Рәсим. Тәслимәнең җылылык бөркелеп торган килешле иреннәреннән күзен ала алмыйча.— Шуннан ни инде, матри, тагын бер алдасаң, адаштырып калдырам мин сине кыр уртасында, дип кисәткән Гашыйк Гарипне ак сакаллы агай. Күзеңне йом, дигән. Ач, дигән. Гашыйк Гарип күзен ачса, үзе яшәп торган шәһәр капкасын күреп, таң калган. Әй, мәрхәмәтле кеше, әй, могҗиза иясе, дигән ул аннары ак сакаллы җайдакка, син миңа күп изгелек эшләдең, бик зур рәхмәт сиңа, инде мин туган шәһәремә кайтып, кешеләргә: «Мең чакрым юлны күз ачып-йомганчы уздым, дисәм, берәү дә ышанмас бит, ничек ышандырырмын соң мин аларны?» — дигән. Ал минем атның тоягы астыннан бер уч туфрак, дигән Гашыйк Гарипкә ак сакаллы агай, шул туфракны җиде ел буе дөм-сукыр булып утырган кешенең күзләренә сөртсәң, аның күзләре ачылыр, дигән. Гашыйк Гарипнең Акбүз аттан төшеп, букчасын ияреннән чишеп, тояк астыннан бер уч туфрак иелеп алуы булган — җайдак күз алдында

юкка чыккан. Гашыйк Гарипкә булышкан әлеге изге күңелле агай Хөзер галәйһиссәлам булган, имеш...

Тәслимәнең күкрәкләре тирбәлүдән аз гына туктап торды.

— Ә кем ул Хөзер галәйһиссәлам? — дип сорады ул, башын калкыта төшеп.

— Шундый бер изге кеше инде. Әнинең дин китапларыннан укыганы бар. Ул җирдә бәлага тарган кешеләргә ярдәм итә, имеш.

Тәслимәнең күкрәкләре тагын еш-еш тирбәлергә кереште.

— Әллә ниләр беләсең син, Рәсим. Я, я, шуннан?

— Шуннан утырган да шуган. Әчеп бетердек чүлмәктәге сөтне, әкият тә шунда бетте.

Тәслимә җиңел генә торып утырды. Хәзер алар тезләрен тезгә терәп диярлек, кара-каршы утыралар иде. Тәслимә тагын бераз гына башын исә, аның йомшак чәчләре иягенә үк орыначак Рәсимнең. Әмма Тәслимә башын ими. Зәңгәрсу әңгердә тагын да серлерәк булып күренгән зур күзләрен киң ачып, керфекләрен дә кыймылдатмыйча, Рәсимгә карый ул.

— Я инде, Рәсим! Шаяртма! Иң кызык төшенә җиткәч кенә...

Рәсим түзәме соң инде мондый ялварулы карашка. Каршында менә шулай Тәслимә генә утырсын. Бер дә туктамыйча, өч көн, өч төн сөйләргә риза ул!

— Шуннан кичкырын туган йортына кайтып җитә Гашыйк Гарип. Сеңлесе ишек ача. Ләкин абыйсын танымый. Җиде ел җиде көн генә түгел ул сиңа. Бик нык үзгәргән була Гашыйк Гарип. Өс-башы яхшы. Борын астында күсе койрыгы кебек кенә мыегы да бар. Ул, мин сиңа әйтим, бакенбардлары...

— Фу, ямьсез!..

— Кем? Гашыйк Гарипме?

— Соң. Мәһимөһри урынында булсам, яратмас идем мин аны.

Рәсим вакыйганың мондый борылыш алуына үзе дә аптырап калды, хатасын төзәтергә ашыкты.

— Нигә исең китте аңа. Кырып ата бит ул сакал-мыекларын.

— Сөйлә син, сөйлә! Миңа карама. Мин болай гына.

— Шуннан өйгә килеп керә бу. Сәлам бирә. Әнисенең җиде ел буе дөм сукыр утыруын белгәч, бик кайгыра. Шулай да үзенең кем икәнлеген сиздерми. Исемең ничек, дип сорый моннан әнисе, тавышың моннан җиде ел элек югалган улымның тавышына охшаган, ди. Рәшит атлы мин, ди Гашыйк Гарип, ил гизеп йөрим, язмыш кушуы белән сезнең якларга да килеп чыктым әле менә. Аннары чөйдә эленеп торган сазга күзе төшә. Нәрсә ул, ди. Сеңелесе әйтә, югалган абыемның сазы ул, ди. Уйнап карарга ярыймы, ди Гашыйк Гарип. Карчык күтәрелеп кенә бәреләә. Юк, юк, орына күрмә, җиде елдан бирле кагылган кеше юк инде аның кылларына, югалган улымның бармак эзләрен саклый аның кыллары. Әче тулы моң аның, югалган улымның моңнары, кагыла күрмә, ди. Ә мин, ди Гашыйк Гарип, ул моңнарны саз эченнән чыгарып, сезгә тыңлаттыра алам. Карчык ышанмый. Тылсым иясенең хикмәтле нәрсәләре күп була. Ә синең бернәрсәң дә юк бугай, ди. Гашыйк Гарип букчасын алып килеп күрсәтә. Букчаны капшап карагач кына ышана карчык — уйнап күрсәт, алайса, ди. Гашыйк Гарип чиртә башлый шуннан саз кылларына, үзе сазга кушылып җырлап та җибәрә. «Мин ил гизеп йөрдем бик озак еллар, күп нужа чиктем, туган якларыма әйләнеп кайткач, газиз әнием мине танымады...» — дип җырлый ул. Карчык елап җибәрә. Син минем йөрәгемне пәра-пәра телгәлисең, син минем улымның язмышын беләсең, әйтмисең генә, ди... Аннары тынычлана. Шәһәрдә хәзер зур туйлар бара, шунда барып җырлар идең, кешеләрнең күңелен ачар идең, бик оста җырлыйсың бит, ди. Нинди туйлар, дип сикереп тора Гашыйк Гарип. Хөршид бәк Мәһимөһригә өйләнә,

ишетмәдеңмени, ди карчык. Гашыйк Гарип ашык-пошык киенә дә башлый. Әби, зинһар, югалган улыңның сазын биреп торсана, ничек алып киткән булсам, шул көе кайтарып бирермен, ди Гашыйк Гарип, карчыкка ялына инде. Юк, юк, юк, өемнән алып чыгарга рөхсәт итмим, ди карчык, күтәрелеп кенә бәреләә. Алайса, минем белән кызың да барсын туйга, ул күз-колак булыр сазыгызга, ди Гашыйк Гарип. Сеңелесе дә әйтә, бирик, әни, мине дә алып бара бит Рәшит абый, үзем күз-колак булырмын, ди. Әнисе кызын битәрләп ташлый. Өйдә сукыр әнием берьялгызы кала, димисең, чит ирләргә ияреп туйга барырга атлыгып торасың, мәрхәмәтсез җан, ди. Шулай да ризалыгын бирә.

Башта боларны туйга кертмичә торалар. Гашыйк Гарип ишек сакчыларына алтын-көмешләр биргәч кенә кертәләр. Зиннәтле зур сарай эченә барып керә болар. Өстәл тирәсендә Хөршид бәкнең туганнары, дус-ишләре күңел ачып, кәеф-сафа кылып утыралар. Ә Маһимөһри үзенең дус кызлары белән чаршау артында. Бер кулында агу салынган җамаяк, икенчесендә хәнҗәр икән моның. Хөршид бәккә яр булмас өчен, үз-үзенә кул салырга карар кылган Маһимөһри. Ни бит инде, аны этиләре көчләп бирмәкче булганнар Хөршид бәккә.

Шуннан килеп кергәннәр болар туйга. Башта, нинди әләмәтрәкләр йөри, дип куып чыгармакчы булганнар боларны. Хөршид бәк әйтә, тимәгез, утырсыннар, бездә бөтен кешегә дә урын җитәрлек, ди. Болар утыралар килеп табын янына. Я, мосафир, ди, бераз аны-моны сөйләшеп утыргач Хөршид бәк. Сазыңны чиртеп, җырлап күрсәт инде безгә, рас, саз күтәреп йөрисең икән, ди.

Ялындырып тормый Гашыйк Гарип, саз кылларына чиртеп җибәрә, җырлый башлый. «Мин моннан җиде ел элек бәхет эзләргә чыгып киткән егет, юлдашым мине шыр-ялангач калдырып ташлап китте, чит җирләрдә мәхәббәтем миңа юлдаш булды, мең чакрым җирдән җан сөйгәнемне сагынып кайттым мин бүген. Хөзер галәйһеәссәлам мине канатлы Акбүзенә атландырып алып кайтты. Мең чакрым араны без күз ачып йомганчы үттек»,— дип җырлый Гашыйк Гарип.

Чаршау артында утырган Маһимөһри агулы җамаягын бер якка, һәнҗәрен икенче якка атып бәрә дә: «Минем Гашыйк Гарибем тавышы бу, минем Гашыйк Гарибем кайткан»,— дип, чаршау артыннан атылып чыга. Атылып чыга да Гашыйк Гарипнең кочагына ташлана. Табын янында Хөршид бәкнең эчкече, хулиган энесе дә утыра икән. Күп уйлап тормаган бу, кул астында яткан пычакны эләктереп алган да Гашыйк Гарипкә: «Ялганчы, үтерәм мин сине, ничек итеп мең чакрым араны күз ачып йомганчы үтмәк кирәк?» — дип кычкырган. Аның абыйсы Хөршид бәк арага кереп, тимә аңа, сүзе дөрес булса, безгә бер могҗиза күрсәтсен, аннары ышанырбыз, дигән. Алайса, дигән Гашыйк Гарип, моннан җиде ел элек сукырайган карчыкны алып килегез, мин аны күзле итәм, дигән. Моны ишетеп, Гашыйк Гарипнең сеңлесе өенә йөгереп кайткан да: «Әни, теге кеше минем үз абыем, синең югалган улың Гашыйк Гарип икән, тизрәк киен, ул сине күзле итә»,— дигән. Болар барып житкәннәр бер заманны Хөршид бәк йортына. Халык боларны көтә икән. Гашыйк Гарип куенына яшерелгән төенчекне чишеп, акбүз ат тоягы астыннан алган туфракны әнисенең күзенә сөрткән. Әнисе шунда ук күрә башлаган. Шуннан соң Хөршид бәк Маһимөһрине берсүзсез Гашыйк Гарипкә биргән. Маһимөһри чибәр, акыллы кыз, ләкин минем сеңелем дә аннан ким түгел, теләсәң, минем сеңелемә өйлән, дигән Хөршид бәккә Гашыйк Гарип. Хөршид бәк бик теләп риза булган. Менә шулай итеп ике туйны бергә үткәргәннәр болар...

— Әй, Рәсим алай булмаган ла инде,— дип, әсәрләнгән күзләрен челт-челт йомгалады Тәслимә.— Алай түгел ич инде, ахырын үзең уйлап чыгардың, әйт, үзең уйлап чыгардыңмы?

Рәсим Тәслимәнең саф, гөнаһсыз карашын күтәрә алмады, читкә борылды.

— Нишләп уйлап чыгарыйм. Лермонтов бер төрек картыннан язып алган аны. Хәтерлисеңме, алтынчы класста укыганда Лермонтовның бер шигырен синең альбомыңа да язып куйган идем.

Әгәр җилләр очырсалар,
Ялгыз, сары яфракны,
Аерылып калган чыбыгы
Кызганыр микән аны?

Әгәр язмыш кушып, егет
Читтә үлсә бер ялгыз,
Читтә үлгән яшь егетне
Кызганырмы матур кыз?..

Тәслимә кинәт учлары белән йөзен каплап, сулкылдап елап җибәрде. Ничек юатырга да белмәде аны Рәсим ул чагында... Ә хәзер юата белер иде микән? Мөгаен, хәзер дә белмәс иде.

Гашыйк Гарип читтә җиде ел йөргән, ә Рәсим биш ел. Гашыйк Гарип мең чакрым араны канатлы атта күз ачып йомганчы үткән. Рәсим берничә сәгатьтә кайтып җитәчәк. Әкият белән чынбарлык арасында аерма әллә ни зур түгел, димәк...

Хәтирәләргә бирелеп утыра торгач, сизми дә калган Рәсим — самолет инде, тизләгән киметеп, түбән төшеп бара икән. Сорау Сәләх янә «ләхәүлә»сен укып куйгач кына сизде моны Рәсим. Бераздан болыт таулары, айкалып-чайкалып, самолетка юл бирделәр. Түбәндә елгалар, юллар, урман полосалары, легендалар белән чуарланып беткән җир, давылга эләккән кораб палубасы кебек, әле бер, әле икенче якка янтайды. Тагын бераз төшкәч, тып-тын салонга моторлар үкерүе бәреп керде, самолет йорт-түбәләренә тияр-тимәс очып узды да күзне чагылдырып җемелдәшкән аэродром утлары арасыннан такыр асфальтка килеп төште. Берничә мәртәбә җиңелчә генә сикереп куйгач, менә бит мин, күктә генә түгел, сезнең җирегездә дә бик яхшы йөри беләм, дип һавалангандай, канатларын туп-туры тотып, аэровокзалга таба элдертте.

— Хикмәти хода! — дип авыр сулады Сорау Сәләх, самолет тиешле урынга килеп туктагач.— Бер мәртәбә тәүбә иткәнем бар иде, тагын утырырга язган икән аэропланга. Вакытсыз гүргә кертә инде бу малай мине. Син, энем, исемеңне оныттым, минем капчыкларымны күтәрешеп чыгарсың әле автобуска хәтле. Бер әйбер дә алмам, диган идем. Нәфес бит, ходай оргыры. Тегендә юк әйберләр монда очрый, монда юклары — тегендә... Үзебезгә кирәкми хәзер бер әйбер дә. Шул малайга булсын, дип җан атып йөрибез. Кайткач, кадерен белсә...

### Бишенче бүлек

Җил. Кар катыш яңгыр сибәли. Нәкъ салкын диңгез буендагы кебек. Вагон тәрәзәләренә бияләй-бияләй кар килеп сылана.

Үземә генә кайтырга туры килер, ахры, дип уйлый Рәсим вагондагы кешеләрне күзәтә-күзәтә. Поездга утырганда да танышлар очрамады, вагонда да күренми. Димәк, юлдаш-фәлән булмаячак. Ун чакрым юл пүчтәк кенә инде аныcы егет кешегә. Тик менә бураны бик ямьсез, юеш буран. Күзеңне дә ачып карый алмыйсың мондый буранда. Керфекләрең бозланып ката, бөтен киемнәрең лычма су була. Ә иптәш белән, юл сизелми, сөйләшә-сөйләшә акрын гына атлыйсың шунда.

Вагонда теттереп татарча сөйләшәләр.

Күкрәге диңгез буендагы кебек сызламый инде Рәсимнең, ара-тирә сулкылдап кына куя.

Каршыдагы утыргычта алсу махер башлыклы яшь кенә ике кыз бертуктаусыз чытлыкланып сөйләшәләр. Ара-тирә каш астыннан гына Рәсимгә дә караштырып алалар. Рәсимгә кызларның үзләреннән бигрәк сөйләшүләре ошый. Ни әйтсәң дә, Татарстан республикасы бит, тоттереп татарча сөйләшеп кайталар. Тау ягы акценты белән сөйләшүләре килешеп тора тагын үзләренә. Кычкырып әйтергә ярамаган сүзләрне бер-берсенең колакларына пышылдыйлар да, учлары белән авызларын каплап, рәхәтләнеп көләләр.

Сагындырган икән татарча сөйләшү, бик сагындырган.

Кызларның һәрбер сүзе Рәсимнең җанына сары май булып ята. Сүзләрнең мәгънәсе кирәк тә түгел Рәсимгә, ул кызлар сөйләшкән сүзләрнең мәгънәләре турында уйламый да. Ул бары тик татар сүзләренең көен һәм музыкасын тыңлый, балачактан ук таныш авазларның кан тамырлары буенча шифалы гөрләвек булып узуын тоя, шуннан рәхәтлек таба, шуннан ләззәт ала. Азмы-күпме шулай бер уңайга оеп барганнан соң, Рәсим сүзләрнең мәгънәсенә дә игътибар итте.

— Нәсимәне белми теге, беләсең син аны, бик яхшы беләсең, унбишенче цехта контролер булып эшләгән Нәсимә,— диде кызларның калынрак гәүдәлесе.

Юкарак гәүдәле, зуррак күзле кыз байтак кына уйланып торды, аннары гына:

— Ә-ә,— дип сузды.— Юл мастерына кияүгә чыккан Нәсимәне әйтәсең инде син, алайса.

— Хәстәрләп куйганнар ул Нәсимәгә кияү. Җаен-кышын вилвет чалбар киеп йөри торган Нәсимәне әйтәм мин.

— Ә-ә-ә, анысын әйтәсеңмени? Я, я, нишләгән, нишләгән?

— Радикның әнисе Маһруй апа күзәтеп йөри икән моны. Бик акыллы, инсафлы кыз, эшендә дә сынатмый икән, узганда-барганда карткорылар белән үзебезчә исәнләшеп уза, Радигыма менә дигән киләш булыр, аллаһы боерса, дип, күрше-тирәләренә дә сөйләгән. Нәсимә Радигын белә, әнисен танымый бит инде. Бервакытны Маһруй апа мунчада очраткан моны. Сөйләшеп киткәннәр. Маһруй апа җаен туры китереп Радикны мактарга керешкән. «Беләм мин ул егетне, дигән Нәсимә. Болай ничава егет күренә, өйләрендә кемнәре бар икән соң аларның?»— дип сораган. «Әнисеннән башка беркемнәре дә юк»,— дигән Маһруй апа. Ә беләсеңме, сердәш, Нәсимә, нәрсә дип әйткән?

— Нәрсә дип әйткән?

— Әнисе бармыни аның, белми идем! Шул паразиты булмасын ие шул аның, дигән.

Кызлар авызларын каплап икесе ике якка бөгелеп төштеләр.

Утыргыч аша гына бер кожанлы агай тирә-ягындагыларга мотоцикл турында сөйләп кайта.

— Монда гараж-фәлән юк бит инде, гараж ызба бәясе хәзер, үзегез беләсез. Так... авылга җизниләргә апкайтып куйдым. Так. Беркөннәрдә исереп чыгып киткән дәген, зажигание ачкычын сындырган. Никак алып булмый хәзер.

Вагонның ары башында калын шәлгә төренгән кызыл иренле апа авыл кешеләренә, аларның тормышына кызыгып кайта бугай, тел төбеннән һәрхәлдә шул сизелә.

— Шулай, кош карагангa да, тирес түккәнгә дә акча. Без үскәндә генә булмады. Хәзерге тормышын ташлап җүләр кеше генә китсә китәр авылдан...

Тәрәзә буенда аксыл йөзле, чаллана башлаган чәчле мөлаем хатын кофта бәйләп кайта. Кулы кулга йокмый. Туку станогы да болай тиз

тукымыйдыр тукыманы. Бармаклары житез мөлаем хатынның, телгә дә төшеп калганнардан түгел, ахры. Өтерен-ноктасын калдырмыйча апачык итеп сөйли...

Ә менә монысы Рәсимгә энисенең тавышын хәтерләтте. Юк, сузыбрак сөйләшсә дә, болай ук елак түгел энисенең тавышы. Карчык кеше булырга тиеш. Рәсимгә аркасы белән бер якка янтаебрак утыра. Каршысында каратут йөзле, «Москвич» якалы пальто кигән яшь кеше. Әбине тыңлыйдырмы ул, юктырмы, «Әй!», «Кит!», «Менә син», «Бигрәк инде» дигән җөпләү сүзләрен шул кадәр җиренә җиткереп, шул кадәр килештереп, җепкә төймә тезгәндәй тезеп баргач, тыңлыйдыр, күрәсең.

Рәсим әби сөйләгән сүзләрдән шәйләп алды: каратут йөзле ир-ат Фәрит исемле икән. Әби исә Фәриткә бавырына таш булып утырган кайгысын, иң ачы хәсрәтен сөйли:

— Менә шулай, Пәритем. Җыр да бар бит:

Яшь чагында күргән нужа
Уйнап-көлеп тә уза.
Картайгачтын күргән нужа
Көн саен елап уза.

— Биш балам тәгәрәп үлде ачлыктан, Сәлимәмне сигез яшькә кадәр имезеп кенә алып калдым үлемнән. Анысы да үләдерие. Битләре шешенә башлагание...

Вагон эчендәге халыкны күзәтеп, тирә-юньдәгеләрнең әңгәмәләренә колак салып кайта торгач, төшәсе станциясен узып китә язган түгелме соң Рәсим. Поезд кузгалыр алдыннан гына каударланып сикереп торды ул. Сикереп торды да, бушлат төймәләрен чишеп җибәргән көе, бер кулына чемоданын, икенчесенә бескозыркасын эләктереп, вагон буенча йөгерде. Ишекләрне тез белән төртеп ача-ача карлы баскычка чыкты да караңгы бушлыкка сикерде. «Сыйлаганнар морякны»,— дип көлеп калдылар аның артыннан тамбурда тәмәке пыскытып торучы ир-атлар.

Якты тәрәзәләре алтын чылбырга охшаган поезд буранлы төн эченә кереп югалды. Соңгы вагонның кызыл уты шактый гомер җемелдәп барды. Рәсим аны күмелгәнче карап озатты. Бәләкәй станциянең йокымсырап янган утларына таба китте. Вокзал бинасы буп-буш, шыпшыр иде. Хәтта ишеге дә ябылмаган. Караңгы өй түбәләрендә үкереп йөргән җил көенә шыгыр-шыгыр килеп ачыла да ябыла, ачыла да ябыла. Станциянең начальник бүлмәсе тәрәзәсеннән генә, ераклашып барган соңгы вагон уты кебек, дежур диспетчерның фуражкасы күренә. Этләр дә өрми. Рәсим утырып кайткан поезд инде үр артында шыкылдый. Аның шыкылдавы минут саен, секунд саен кими, зәгыйфьләнә бара.

Төн авышкач һава салкынаеп киткәндер, күрәсең — буран. Рәсим уйлаганча ук, юеш түгел икән лә. Керфекләренә кунган карлар тиз генә эреп бетми, аларны кул аркасы белән сыпырып төшерергә туры килә. Аяк асты да зарланырлык түгел. Өстен кар каплап китсә дә, юл катысы шәйләнә. Ни әйтсәң дә, чын кышка ерак шул әле, я тегендә, я монда каралып беткән кар кисәкләре күтәрелеп тора, печән бөртекләре, салам кисәкләре очрый.

Хәер, үзе генә кайтмый ич буранлы юлдан Рәсим. Тәслимәсе белән кайта. Дингездә алай түгел иде, туган якларына якынлашкан саен, Тәслимәне күрәсе килү теләге көчәя бара Рәсимнең күңелендә. Бәлки Тәслимә инде Рәсим хәтерендә саклаган Тәслимә түгелдер, үзгәргәндер ул, картайгандыр, ямьсезләнгәндер. Биш ел гомер аз гомер түгел бит, бигрәк тә кызлар өчен. Бәлки инде ул Әхмәт абыйсына кияүгә чыккандыр. Юк, чыкмаган, чыкмаган кияүгә Әхмәт абыйсына. Әхмәт абыйсы Олы Күлдән мәктәп директоры кызын, завклуб Мөнирәне алып киткән. Бу турыда Рәсимнәрне ерак походка җибәргәч үк әнисе язган иде. Әй гарьләнгәндер инде Тәслимә Әхмәт абыйсы башка кызга өй-

лэнгэч! Менэ сиңа офицер шинеле, менэ сиңа йолдызлы погоннар. Рэсимне тиң итмэгэн булган идең, шул кирэк сиңа! Менэ хэзер, нибуч, онытырсың инде Эхмэт абыеңны: хэзер башка төрлерэк сайрарсың! Элеккеге Рэсим түгел шул инде Рэсим дэ. Элеккеге кебек җебеп төшмэс ул аның каршында. Эйтэсе сүзен флоттагыча ярып салыр, эйтмэсэ... Эйтмэсэ, эйтмэс. Эйе, салкын гына исэнлэшер дэ, туктап та тормыйча, үтэр дэ китэр. Тэслимэ хэзер йоклап ятадыр инде. Ак калын толымнарын мамык мендэр өстенэ таратып ташлагандыр. Тэрэзэсенэ леп-леп килеп йомшак буран сырышадыр. Тын бүлмэдэ келт-келт итеп сэгать йөридер. Тэслимэнең күзлэре ачыктыр. Бэлки, ул да шушы минутта Рэсим турында уйлап ята торгандыр.

Артта калган кышларның берсендэ станциядэн утыртып кайткан иде бит Рэсим Тэслимэне. Нэкъ шушы юлдан. Ул чагында юлның ике ягында да эрэмэлек иде. Хэзер эрэмэлек күренми. Сөреп басу ясаганнар, мөгаен. Ул көнне Казан артистларын кечке поездга төшергэннэр иде Рэсимнэр. Дүрт ат, дүрт егет. Тэслимэнең Лопатиндагы туганнарыннан кайтып килеше иде бугай. Минем чанага утырмас, дип курыккан иде башта Рэсим. Егетлэрнең һэркайсы, эйдэ, миңа утыр, миңа утыр, дип сайрап тордылар чөнки Тэслимэ каршысында. Рэсим чакырмады Тэслимэне, чакыру түгел, хэтта күтэрелеп карарга да базмады. Э Тэслимэ җэлт — Рэсим чанасына керде дэ утырды. Рэсимнең башы күккэ тиде. Карлыгач та сөенеченнэн, башын тэртэ башына салып, бик дөрес эшлэдең, без сине салуларда кагылдырмый-сугылдырмый җайлап кына алып кайтырбыз, дигэндэй, акрын гына кешнэп куйды.

Кайтыр юлга беренче булып чыкканнар иде алар. Кайта-кайта егетлэрнең барысы да узып киттелэр. Билгеле, Рэсим аларга юл салып тормады. Атларын карга батыра-батыра, чыбыркы белэн кыйный-кыйный, карт олаучылар эйтергэ ярата торган тозлы-борычлы сүзлэрне яңгыр урынына яудырып уздылар алар. Иң соңыннан дилбегэ башын тегермэн урынына зырылдатып, үзен үшэн атының көлтэ койрыгы белэн кыйнаттырып, Гөрҗи Фэһиме узды. Атлар узып беткэч кенэ Тэслимэ:

— Синең Карлыгачың болай ялкау түгел иде лэ Рэсим, ни булган аңа? — дип эйтеп ташламасынмы.

Рэсим, сүзне ничегрэк башласам, оятка калмамын икэн, дип баш ватып бара иде, югыйсэ. Чана түрендэ килешле нэфис итекле аякларын сузып, кечке салкыннан алсуланып-кызарып, шэмэхэ-зэңгэр күзлэрен елтыратып сөйгэн кызың утыргач, башка атлардан алда кайттың ни дэ, артта кайттың ни? Арттан кайтсаң, яхшырак та эле. Йөзеңэ чыккан, менэ без нинди, дип кычкырып торган уй-хислэреңне, каушау-оялуларыңны берэү дэ күрми. Шуны да аңламыймы икэнни Тэслимэ? Аңлый. Барысын да аңлый ул барысын да сизэ. Көлэргэ тели ул Рэсимнэн. Беренче ат уза башлагач, бер сүз дэ эйтмэде. Э менэ хэзер, егетлэрнең барысы да узып киткэч, исэн генэ торасыңмы, кодагый, Рэсимнең Карлыгачы ялкау булып чыкты.

Алайга китсэ, алайга китсэ, Рэсимнең гадэтен белэсез... Карлыгачка чыбыркы күрсэтүнең хаҗэте юк. Дилбегэңне ныграк кысып, сызгырып кына җибэрэсе...

Карлыгач алдагы атларны «эһ» дигэнче куып җитте, Фэһим атының чанасына ыргылып менэргэ җитешеп юрта иде ул хэзер. Рэсим дилбегэне алуга, юлның текэрэк, кар азрак яткан ягына каерды. Карлыгач арттагы ике атны уйнаклап кына узды. Э менэ Тырыс Нэгыймнең яшь айгыры белэн шактый алышырга туры килде Карлыгачка. Үрэчэлэр үрэчэгэ бэрелде, тэртэлэр тэртэгэ ышкылды. Яшь айгырның сыртында бертуктаусыз Нэгыймнең алтыдан үргэн чыбыркысы сызгырды. Яшь айгыр кушаяклап чабарга тотынгач, Рэсим дэ дилбегэсен бушатты, үрэчэ бавына ябышып, чырулап җибэргэн Тэслимэгэ эһэмият бирмичэ,

дәртләнеп-дәртләнеп: «Әйдә, әйдә, малкай! Тагын бераз гына, тагын әз генә!» — дип кычкырды. Карлыгач — әле ярый Рәсим аны тәртә очына ук җиккән иде — сөлек кебек сузылып ике-өч мәртәбә генә сикерде, ак күбеккә баткан яшь айгыр, җәйге чиләдә салам башлы каралты түбәсеннән капылт кына ургып чыккан кара төтендәй, бер урында биеп калды. Алда ик.ез-чиксез карлы кыр, карлы кыр читендә авыл утлары ачылды.

— Мин шаяртып кына әйткән идем ич,— диде Тәслимә, Карлыгач каты юлга чыгып юыртырга керешкәч. Тавышы гаепле кешенеке төсле калтыранып китсә дә, Рәсим ни Карлыгачны яклап, ни Тәслимәне яклап бер сүз дә әйтмәде.

Шул хут белән авылга кайтып кердселәр.

Тәслимә кое тыкрыгында ук төшеп калды. Аның рәхмәтенә каршы Рәсим кырку гына:

— Юлда очраган кешеләрне утыртмыйча калган юк анысы, аллага шөкер,— диде.

Шуннан соң алар шактый вакыт бер-берсенә сүз кушмыйча йөрделәр.

Буран басыла төшсә дә, җиле үзәкләргә үтеп исә. «Кыш килә, тирән шомга чумган бар тирә». Диңгездә җилләр болай йөзне чеметтереп исми. Диңгез җилләре дымлы, куәтле. Диңгез җилләре хәрәмләшмичә көрәшкән пәһлевангa охшаган. Ә монда, тьфү, тегеннән чишелә, моннан. Бу яктан тарткалый, тегеннән китереп аяк чалырга маташа. Өстендә тельняшка белән бушлат кына дигәч тә, сезнең ише хәчтерүш җилләргә генә бирешми әле ул Рәсим абыегыз!

Бәрәңге бакчасында соңгы тапкыр очрашкан төнне ник кенә суырып үпмәде икән Рәсим Тәслимәне. Әхмәт абыеңны-чуртыңны белмим, мин сине яратам, миңа син булгач житкән, миңа бернинди дә Әхмәт абыең кирәкми, дип әйтергә кирәк иде. Кысып кочакларга да җибәрмәскә иде. Янында ут кебек кайнар кыз сайрап торсын да, син күктә йолдызлар атылганны карап утыр инде. Җүләр түгел, диген. Бәлки Тәслимә үзе дә Рәсимнең кысып алуын көткәндер. Югыйсә, Рәсимне үзе башлап үбәр идемени? Ах, алла! Нишләп соңарып килә соң әле бу мондый үзәк өзгеч уйлар. Ә бит Рәсим Тәслимәгә бер генә хат та язмады. Әхмәт абыйсына гашыйк булганы өчен кичерә алмады Рәсим Тәслимәне. Ничек инде, янәсе, Рәсим ничә елдан бирле җан атып йөрсен дә, Тәслимә аны санга сукмыйча, ниндидер офицер Әхмәткә гашыйк булсын. Адәм страмы!

Хәер, балачак дусты, күршесе Хәбирдән дә бер-ике генә хат килде Рәсимгә. Соңгы хатын армиядән кайткач та язган иде Хәбир. «Вакыт юк, парин, хат килми торса, үпкәләмә!» — диген юллары бик нык хәтергә сеңеп калган. Шулай инде, читтә генә вакыт муеннан була ул, туган якларга әйләнеп кайткач кына вакыт җитми башлый. Хәбир читтән торып авыл хуҗалыгы техникумында укый, дип язган иде Рәсимнең әнисе. Тагын ниләр майтарып ята икән, тана колак?..

Станциядән бирле озатып килгән тау сыртының борылган җирендә Рәсим бераз ял итеп алды. Моннан авыл башындагы ялгыз агач күренергә тиеш иде инде. Аяз түгел шул, аяз булса, күренер иде. Әнә бит, әнә, бер ут җемелди анда. Авыл читендәге салам түбәле ызба, Мирвәлиләр ызбасы, Мирвәлиләр уты... Мирвәли абзый үзе күптән дөнья куйган. Ә малайлары барысы да читтә. Салам түбәле йортта Мирвәлинең карчыгы Хәнифәттәй, Рәсим әнисе кебек, бер ялгызы яши.

Хәнифәттәй малайлары читтә йөргәндә өеннән сирәк чыга. Аның ни ашап, ни эчеп торганын да белгән юк. Терлек-туар асрамый, кибеткә бармый, күрше-аршыларына да бик сирәк керә. Җен зәхмәте кагылган, дип тә сөйләштергәлиләр авылда аның турында. Булыр да. Авыл ба-

шыннан шактый ерак китеп салынган йортта яшәп кара әле син. Ялан кыр уртасында яшәгән кебек бит ул.

Аның каравы, читтәге малайлары ялга кайткач, авылның биш урамын бер итеп йөри Хәнифәттәй. Очраган бер кешегә кабы-кабы белән чәй өләшә, бала-чагаларны борчак конфет белән сыйлый. Үзе бертуктаусыз малайларын сөйли. Сәгать ничәдә кайтып кергәннәр, ничек ишеткән капка тавышын Хәнифәттәй, ничек ачкан ишекне, ничек күрешкәннәр, ниләр сөйләшкәннәр — берсен дә калдырмый. Хәнифәттәйнең бизәкләре балан чугына да, бөрлегән сабакларына да охшаган зәңгәр сатин күлмәге, ап-ак йон оеклары, чачаклы-чуклы француз яулыгы — кече малае Ижаудан алып кайткан — авылның әле теге очында күренеп китә, әле бу очында.

Хәнифәттәй тәрәзәсе башта буран арасыннан куырган борчак кебек кенә саргаеп күренгән иде, тора-бара ачыкланды, яктырды. Юк инде, тәткәчем, керосин лампасы гына түгел бу, керосин лампасы һаман бер көе йокымсырап яна. Ә бу әнә ничек балкып-балкып китә. Баярак тау башыннан узганда сәер гүләү ишетелеп киткән иде лә Рәсимнең колагына. Шул булган инде, мөгаен, шул, электр баганасы булган. Телеграмм баганалары тыйнак кына гүли, ә монысы, мин сиңа әйтим, табанына шырпы кергән карт аю кебек үкерә.

Әнисе язган булыр иде, димәк, күптән түгел генә кертканнәр әле авылга электрны. Рәсимнең күңеленнән, ниндидер бер бәйрәмне йоклап үткәргән чактагы кебек, үкенечле хис узып китте.

Электр шул, әнә бит, Хәнифәттәйнең пәрдәсе корылмаган тәрәзәсеннән дә күренә лампочкасы. Рәсим бозланган чемоданына учы белән шап-шоп бәргәләп алды да тәрәзәгә якынрак килде. Хәнифәттәй танып булмаслык дәрәҗәдә картайган иде. Иреннәре сизелер-сизелмәс кенә кыймылдый. Хат укый дисәң — күзләре күкеле сәгатьтә. Дога укыйдыр, күрәсең. Шушы минутта тирән шахталарда күмер чапкан, ташкынлы елгаларда сал агызган, мәкерле себер трассаларында олы машиналар йөрткән малайларына исәнлек-саулык, хәвеф-хәтәрсез көннәр, озын гомер телидер ул. Әнә бит кулында — хат. Кайсы малаеннандыр хат килгән инде кичә. Хәнифәттәйнең ничәү соң әле малайлары? Альберт, Вәгыйзь, Нәсир, Сәлим, Илдус, Илнар, иң кечесе Нургиз. Анысы армиядә булырга тиеш. Күр әле син, берсе дә авылда калмаган. Хәнифәттәйгә кыендыр, бик кыендыр караңгы озын көзге төннәрне бер ялгызы үткәрүе.

Рәсим үзе Хәнифәттәй турында уйлый, ә күңелендә моңаеп-сагышланып әнисенең сурәте тора. Юк, Рәсим Хәнифәттәй малайлары кебек түгел. Өч ел гына читтә йөрде ич ул, ике елы — хәрби хезмәттә. Аннары әнисе бу кадәр картаймагандыр әле. Рәсимнең әнисе Хәнифәттәйдән яшь ич әле ул, күпкә яшь.

Зират яныннан узганда туктый-туктый атлады Рәсим. Җил зират агачларына ябышкан карны пыран-заран китерә. Каен тәлгәшләре ачынып сызгыралар. Сәрби куаклары гына бирешмиләр җилгә. Кар япмаларын башларыннан ук ныгытып бөркәнәләр дә кабер ташлары кебек тынып утыра бирәләр. Әле анда, әле монда кара калкулыклар — яңа каберләр күренгәли. Кемнәр мәңге кайтмаска китте икән авылдан, кемнәрнең йолдызлары тормыш күгеннән мәңгелекнең чиксез океанына атылды икән? Мәхәббәт утында янганнар да үлә. Тигезсез мәхәббәт белән гомер кичерүчеләр дә, мәхәббәтнең ни икәнен белмичә картаючылар да... Рәсимнең әнисе дөнья карчыгы турында сөйләргә ярата. Кеше күзенә бик матур, яшь, сылу кыз сурәтендә күренә икән ул дөнья карчыгы. Шуңа күрә яраталар икән аны кешеләр. Ә чынлыкта исә дөнья карчыгы бик ямьсез, ди. Тешләре төшеп беткән, авызы кыйшайган, аркасында бөкресе чыккан ди аның... Әллә мәхәббәт тә дөнья карчыгы кебек алдакчы бер нәрсә микән, югыйсә. Авылда ничә йорт бар, шул

йортларның күбесендә ир белән хатын яши. Һәркайсы мәхәббәт хисен кичердеме икән соң аларның? Кичерсәләр, кая киткән соң хәзер аларның мәхәббәтләре?

Тоташ стена булып сузылган сәрби куакларын узгач, Рәсим юка кар өстендә тайгак эзләр калдырып, зиратка барып керде. Монда каберләр беленми, агачлар да юк, анда-санда иске ташлар гына кабарып ята иде. Шушы ташларның берсе Рәсимнең этисе кабере булырга тиеш...

Кырык сигезенче елның язында Әдрәс суы гомер-бакый булмаганча ташыган. Авыл картлары белә-белештән аскы урам белән урта урамны тоташтырып торган агач күпер, баганасы-субайлары белән кубарылып, Хәдичә абыстайлар бакчасына дөбердәп керде дә, ташулар тынгач, шунда ишелеп ятты. Сәлмән бабайларның инеш буендагы мунчалары, асты-өскә килеп, Гурди болынына чаклы агып барды. Бозлы ташкында колхозның ике таңасы батып үлде, унөч сарыгы югалды. Ташу суы икенче көнне Әдрәс авыл башындагы текә ярларны өстәл зурлыгы бозлар белән бастырып куйды да, зиратны икегә бүлеп, олы урманга кадәр сузылган тауларга төшеп житәрәк, иске зиратка бәреп керде. Айкады болганчык ташкын, чайкалды, тамырлары зәгыйфьләнгән юанюан юкәләрне аударып ташлады, каберләрне тигезләде...

Су чигенгәч, жир белән тигезләнгән каберләрнең иңкүрәк урыннан яртылаш ләмгә чумып яткан эреле-ваклы ташлары күренде.

Рәсим этисенең дә кабере шунда иде...

Әллә чынлап та, Борһан әйткәнчә, бик явыз булдымы икән Рәсимнең этисе? Әллә берәрсенең каргышы төштеме икән?

Рәсимнең этисе председатель булып эшләгән чагында колхозга нинди дер йомыш белән милиция начальнигы килеп төшә. Беркемнән дә рөхсәт-фәлән сорамыйча, колхозның яшелчә бакчасына кереп китә. Ярты сәгать чамасы витаминлы ризыклар белән сыйланып йөри. Рәсимнең этисе бакчадан чыкканын сабыр гына көтеп тора да моның, идарәгә баргач, квитанция язып кулына тоттыра.

— Менә, фәлән иптәш, яшелчә хакын колхоз кассасына түләрсез,— ди....

Шундый сәер гадәтләре күп булган инде Рәсим этисенең, нихәл итәсең. Берәү дә фәрештә булып килми җиһанга. Фәрештә булып килсә дә, гомер буе фәрештә булып яши алмый адәм баласы. Дөнья бу. Күзеңне ачарга теләмәсәң дә, ачарга туры килә.

Кемдер, кабер рәвешенә китереп, туфрак та өйгән булган, ахры,— кабер урыннары калкыбрак тора. Әмма калку урыннарга ташлар куелмаган. Ташлар һаман да иңку урыннарда сибелеп ята. Кемнең ташын кайда куясын Әдрәс суы үзе белгәндер, кузгатмыйк, дигәннәрдер ул хәвефле елны авыл картлары.

Рәсимнең зират буенда утырып торасы, җанын бушатасы, төрле уйлар уйлыйсы килде. Кемнәрнеңдер этәче сузып-сузып: «Хәят малае Рәсим кайткан, уяныгыз, торыгыз, моряк Рәсим кайткан!» — дип кычкырмаса, утырып торган булыр иде ул. Кычкырды шул сизгер этәч, бөтен авылны уятырга теләгәндәй, өч мәртәбә рәттән сөрән салды.

— Хәзергә хуш, эти, тагын килермен әле мин синең янга!

Бу сүзләрне Рәсим тыкрыктан Тәслимәләрнең биек өйләре калкып чыккач әйтте. Тәслимә турында уйламас өчен юри зираттан тыкрыкка кадәр күңелендә саклап килде ул билгесез таш астында рәнҗеп яткан этисенә әйткән кадерле сүзләрне...

### Алтынчы бүлек

Сезнең һәркайсыгызның диярлек, азмы-күпме читтә яшәп, туган йортка әйләнеп кайтканыгыз бар инде. Хет әз генә, хет ике-өч кенә көн булса да туган йорттан еракка китеп торганыгыз бар. Әйе, «Алтын-кө-

меш чыккан җирдән туган-үскән ил якын»,— дип тикмәгә генә җырламыйлар. Китү һәрвакыт кыен, сагышлы, үкенечле. Туган йортыннан ераклашкан саен кешенең күңеле тарая, үзе кечерәя бара сыман тоела. Кайтканда кеше үсә. Кайтканда кешенең башы болытларга тия, күңеле дәрьялар сыярлык булып киңәя. Юлдан язган кешеләр дә кайчан да булса туган йортларына бер әйләнеп кайталар, кайтмаса да, кайтасы килә, кайтасы килмәсә дә, онытa алмый туган җирен. Туган әнисен онытканнар да туган җирен онытмый. Оныткан, дигәнгә ышанмагыз! Онытмый, беркем дә туган җирен онытмый. Караклар да, хыянәтчеләр дә, дезертирлар да, хәтта тормышка битараф кешеләр дә онытмыйдыр туган җирен. Ә менә туган җирнең хәтере кеше хәтере кебек түгел, туган җир үзенә лаек булмаган балаларын оныта, мәңгегә оныта, исемсез каберләр өстендә чәчелеп яткан ташларын онытмаса да, үзенә лаек булмаган балаларын оныта туган җир.

Рәсимне онытмадымы икән инде туган җире, туган нигезе, туган йорты? Онытмагандыр, онытмагандыр. Кыйшайган капка баганаларыннан балачак өннәре ишетелер идеме аның колагына, югыйсә. Бәсәргән бакча киртәләреннән илаһи яктылык бөркелер идемени? Искергән агач өйнең ноябрь бураннары туңдырган тәрәзәләре шулай җылы булып тоелыр идемени?..

Капка келәсе ватылган икән — өйдә ир-ат юклыгы әллә кайдан күренеп тора. Келәнең кирәге дә шуның чаклы гына икән, хәер. Капка чемодан башы орынуга ачылып китте. Ишегалды тип-тигез кар, сәйләнтәгәрәтеп уйнарлык. Абзар алдына таслап чыбык утыны өелгән. «Әни хәзерләдеме икән?» — дигән уй үтеп китте Рәсимнең башыннан. Хәбирләр ягындагы карга миләше исән-сау икән. Тулыланыбрак та киткән бугай әле хәтта. Урамда игътибар итмәгән иде, ишегалдына кергәч кенә игътибар итте Рәсим — патша сарае кадәр йорт салып куйганнар түгелме соң Хәбирләр. Бүрәнәләре барысы да бер иш, нарат бүрәнә. Түбәсе калай бугай, шуңа күрә кар да кунмаган. Молодец, Хәбир, булдырган. Бакча артындагы каен төбендә тагын бер каралты күренә. Әллә мунча да салып куйган инде Хәбир. Валлаһидыр, өр-яңа мунча. Күр әле син тана колакны, ә! Хат язарга вакыты булмаган да булмаган инде моның болай булгач.

Чолан ишеге төбендә дә эзләр юк. Әллә әнисе өйдә юк инде Рәсимнең?

Өйдә. Капкадан кеше кергәнне күптән сизгән инде ул. Ян тәрәзәдә ялт итеп ут кабынды, ишегалды буенча Хәбирләрнең яңа йортларына таба нур көлтәсе сузылды. Бераздан ишек биге чылтырады. Рәсимнең әнисе картайган булса кирәк. Келә күтәрелгәч тә әле ишек байтак кына ачылмыйча, ачылгач, ябылмыйча торды. Ниһаять, караңгы чоланнан тавыш ишетелде. Аз гына карлыккан булса да, бик тиз танып алды Рәсим бу тавышны. Аның өчен дөньядагы тавышларның иң ягымлысы, иң якыны, иң назлысы иде бу тавыш.

— Әллә синме, улым?

Рәсим башта аз гына шаяртып алырга да уйлаган иде. Ләкин тамак кимерчәген кытыклап торган ниндидер каты нәрсә аның сулышын кысты, күз төпләрен әчеттерде. Шуңа күрә чынлап әйткән сүзләре зәгыйфьрәк яңгырады бугай.

— Мин, әни, ач...

Менә әнисе, ак яулыклы, җитен чәчле, нурлы күзле, җылы бишмәтле, олы итекле әнисе Рәсимнең салкын кочагында. Менә әнисенең кытыршы булса да бик йомшак булып тоелган бармаклары Рәсимнең яңакларын капшый, кашларын, чәчләрен сыйпый, кипшенгән иреннәре гап-гади сүзләрне изге дога итеп пышылдый.

— Ходаем, ходаем, мең шөкер! Бу көнне дә күрәселәрем бар икән! Көтә башлаганыма ике ай була инде. Самавырымны торам да яңартам төнлә, торам да яңартам. Башка солдатлар синтәбердә үк кайтып беттеләр ич, улым, быел. Син нишләп болай озак тордың соң? Синең исәнлегеңне теләп аллага ялваруларым! Бәндә белми ул, сөйләмәгәч...

Рәсимнең тараеп калган тамак төбеннән тагын бер сүз кысылып чыкты:

— Әни!

— Үскәнсең, улым, тазаргансың. Солтанат буйлы егет булгансың. Керик, улым, туңгансыңдыр.

Рәсимнең карлы чемоданы, кайтып җитмәдекмени әле, дигәндәй, шылтырап куйды. Ябылып җитмәгән өй ишегеннән җылы чыгып торган ахры — караңгы чолан буенча бусага төбенә барып җиткән Рәсимнең маңгайлары, борын очлары тирләп чыкты.

Өй эче Рәсим киткән чактагы кебек түгел, шактый үзгәргән иде. Әнисе тагын бер карават алып куйган. Агач сәке урынында җыйнак кына диван кукыраеп утыра. Диван өстендә, сыртын ишеккә куеп, ваемсыз рәвештә соры мәче чайрап йоклый. Ак шнурга асылган лампочкалар Рәсимнәр өендә икәү генә. Берсе түр якта, икенчесе мич арасыннан почмак якта ялтырап күренә. Стеналар җиренә җиткереп, пөхтә итеп обойланган. Тәрәзәдә челтәрләр, челтәр астында читләре чигүле ак сөлгеләр. Караватларның икесенә дә алсу япма ябылган, анда ак мендәр кабарып утыра. Бүлем такталарына пар аккошлы кәгазь келәм алып ябыштырырга да онытмаган әнисе. Бер дә харап инде, туй буласы өйне дә болай ук бизәми торганнардыр. Әлмәледә күкеле сәгать модада, ахры. Календарь белән янәшә эленеп торган бизәкле сәгатьнең нәни тәрәзәсе ачылып, аннан бармак башы кадәрле генә кошчык башын чыгарды да, вакыт турында күкелдәп, нәни тәрәзәсен шартлатып ябып куйды. Катерда кок шулай, палубага башын чыгарып, өстәге хәлләрне карый иде дә камбуз иллюминаторын шулай тиз генә ябып куя торган иде.

Ике тәрәзә арасында бүселеп торган баганага соңыннан гына күзе төште Рәсимнең. Тәрәү түгелме соң? Әйе шул, тәрәү. Әнисе тәрәүне дә җөен җөйгә китереп обойлаган булган да... Әмма, нишлисең, бастырык юанлыгы агачны кәгазь белән генә томалап бетереп буламы соң?

Рәсим әлегә бу хакта әйтеп әнисенең кәефен бозмаска булды. Җае чыгар әле, сөйләшерләр. Андый четрекле мәсьәләләргә кагылу сүз арасында җиңелрәк була ул.

Рәсиме чишенеп юынган арада, Хәят апа почмактан самавырын яңартып чыкты, өстәлгә чынаяклар, төрле тәм-томнар тезгәндә, өйдәге һәр нәрсәне озаклап карый-карый, эченнән генә нидер уйланып йөргән улына күз аткалап алды.

— Матур гына яшәп ятасың икән, әни, күз тимәсен! — диде Рәсим юынып, киң сырлы тельняшкадан гына өстәл янына килеп утыргач.

Хәят апа үзе пешергән бодай күмәчен күкрәгенә терәп кисә-кисә тезеп китте:

— Аллага шөкер, улым, зарланмыйм. Пенсиягә чыктым бит. Колхозчыларга да пенсия бирәләр хәзер. Эшкә дә чыкмыйм әле. Болай урак, печән вакытларында җиңел эшләргә әйтәләр. Кәҗә асрыйм. Ике сарыгым бар. Икесенә дүрт тәкә үстерделәр быел. Әле икесен суймаган. Каз өмәләренә кайтып җитмәдең менә. Казым да уңды быел. Уникене чыгарды, уникене үстерде. Тавык-чебешем дә житәрлек. Иртәгә этәч шулпасы пешерербез, аллаһы боерса. Әйдә, ашый тор әле, улым, ачыккансыңдыр. Сәмәлүт белән кайттыңмы, чуен юлыннанмы?

— Казанга хәтле самолет белән, аннары поездга утырдым, станциядән җәяү кайттым.

— Ат-фәлән очрамаган икән бер дә. Ялга каршы түгел шул, ялга каршы булса, ат белән төшүче күп була.— Хәят апа өстәлдәге ризыкларның барысын да берәм-берәм Рәсим алдына этәреп бетерде. Май да, шикәр дә, варенье да, кыздырган ит тә, кабартма да бар иде табында. Рәсим әнисе пешергән кабартманы сагынган икән — сөтле чәйгә мана-мана ашарга тотынды.

Менә бит бәхет, менә бит тормышның камиллеге. Тышта буран, өйдә май кебек җылы. Электр уты балкып яна. Келт-келт итеп күкеле сәгать йөри. Ана белән ул ничә еллар аерым яшәгәннән соң, сый-нигъмәтләр тулы табын янында кара-каршы утырып чәй эчәләр.

Сылу хатыннарыгызны култыклап, Кара диңгез буйларында шифалы көньяк һавасын сулап йөрүче, шаулы рестораннарда бәллүр бокалдан кыйммәтле эчемлек эчеп утыручы ир-атлар! Сез үзегезне дөньяда иң бәхетле кешеләр, дип уйлыйсызмы? Уйламыйсыз? Уйламыйсыздыр, уйламыйсыздыр шул. Дөньяда иң зур бәхет ул, илләр гизеп кайткач, сине сагынып көтә-көтә күз нурларын коеп бетерә язган газиз әнисең белән бер табында сөтле чәй эчеп утыру!

Әнә соры мәче дә торып утырды. Сыңар күзен генә ачып Рәсимгә карап алды. Сыртын дугаландырып киерелде, диван башына барып шытыр-шытыр тырнакларын кайрады. Алсу тел очын күрсәтеп, йомшак кына мияулап куйды да идәнгә сикереп төште, Хәят апаның аякларына килеп сырышты.

— Кеше ашагач, синең дә ашыйсың килдемени, песикәем.— Балага эндәшкәндәй йомшак кына сөйләште әнисе.— Аша, бар, аша, савытыңа салган анда,— диде ул, кулындагы чынаягына өрә-өрә.— Иптәш бит шул да. Төнлә шылт иткән тавышка да уянып китә. Мин тәрәзәгә барып карасам, ул да тәрәзә төбенә сикереп менә, урамга карый. Әле быел яз көне нәрсәгәдер сискәнеп уяндым төнлә. Котым очып китте — караватка менгән дә бу шытыр-шытыр юрганымны тырный. Нәрсә кыланасың, мәйтәм, төртеп төшердем моны идәнгә. Ә бу мияулый-мияулый ишек катына йөгерде. Ишекне барып ачтым — чыкмый, бусага төбендә тик мияулап тора. Нәрсә бар, мәйтәм, нигә тавышланасың төн уртасында. Шул чагында колагыма кәҗә мекердәве ишетелеп китте. Өстемә ашыкпошык бишмәтне кидем дә, аягыма ката элеп, абзарга йөгердем. Монысы да, койрыгын тырпайтып, минем арттан чаба. Абзарга кереп, шырпы сызып карасам, кәҗә бәтиләгән. Чем кара ике бәти китергән. Бәтиләрнең әле күзләре дә ачылмаган иде, аяк өстенә торырга азапланалар. Мәчене әйтәм, хайван диген син, шуны сизгән, билләһи. Кәҗә бәтиләгәч, үзенә сөт буласын белә ул теге... Кәҗә бер дә яратмый үзен. Күзенә күренде исә, мөгезләрен тырпайта башлый. Тегесе әй юмаланган була инде кәҗә каршында, әй сырпаланган була. Кәҗә рөхсәт итсә, тоякларын ялар иде...

Әйе, әнисенә сөйләргә кирәк, барысын да сөйләргә, эчен бушатырга кирәк. Мәчегә сөйләсәң ни, сөйләмәсәң ни, ике тишек бер борҗа аңа, ә күрше-күләнгә барысын да сөйләп булмый. Шулай, бүген әле кәҗә, мәче, каз турында гына булачак сөйләшүләр. Бүгенгә шулары да җиткән. Бүгенгә әле ул сөенечләрен генә сөйли. Көенечләре калып тора. Сөенечләрнең дә өйдәгеләре генә, ятканда-торганда күзгә ташлана торганнары гына телгә алына бүген. Шулай да Рәсим сорамыйча түзмәде.

— Авылда нинди яңалыклар бар соң, әни?

Хәят апа бу сорауны көткән булгандыр, ахры,— сүзе әле генә өзелгәндәй, ялгап китте:

— Авылда, дисеңме? Авылда... Шул бер көе яшәп яталар. Сәүбән малае белән Камилә малае армиядән кайттылар да шәһәргә киттеләр. Председатель яңа бит хәзер, Кучкардан китерделәр. Тракторга утырткычы булган тегеләрне, якын да килмәгәннәр... Галимулла абыең мәктәптә хезмәт дәресләрен укыта. Тимур командасы оештырган безнең

мәктәптә. Малайлар, кызлар бергә жыелалар да карт-корыларга йорт эшләрен эшләргә булышалар. Әле безнең утынны да шулар турап китте. Гайнелхаят әбиең дөнья куйды. Нурислам да, авыр туфрагы жиңел булсын, машина белән капланып үлде. Кичтән бик каты эчкәннәр. Шул килеш иртән машинага утырып такта заводына киткән. Әллә йоклаган юлда, әллә йөрәге тоткан, брачлар ачык итеп әйтмәгәннәр... Правление урта авылда хәзер, мәктәп шунда, монда кечкенәләр генә укый.

Рәсим үзе әнисе сөйләгәннәрне тыңлый, үзе әнисенең ни өчен Тәслимә турында бер генә кәлимә дә сүз әйтмәвенә гажәпләнә. «Авылда нинди яңалыклар бар?» — дип әйткәч үк, сүзне Тәслимәдән башларга тиеш иде бит әнисе. Белми микәнни, аңламый микәнни? Юк, сизмичә калмагандыр теге елларда. Ана күңеле сизгер була. Уенлы-чынлы әйткәне дә бар иде ич. Ничек дигән иде әле. «Борһан Кукамайлар белән кода-кодагый буласыларым төшләремә дә кермәде»,— дигән иде. Әллә балачак мавыгулары гына булгандыр, инде онытќандыр, дип уйлыймы икән? Тәслимә турында үземә сорау килешмәс. Урап булса да, йомгакны икенче башыннан сүтә башларга кирәк.

— Хәбирләр яңа йорт өлгерткәннәр икән.

Хәят апа эчәргә дип күтәргән чынаягын кире куйды. Иске самоварның подноска чап-чоп тамып торган борынын ныгытыбрак япты. Рәсимгә карамыйча гына кистереп:

— Өлгерттеләр,— диде.

Хәбир турында нибарысы бер сүзме? Соң, Хәбир бит икенче Рәсим инде. Хәбир — Рәсимнең балачагы. Авылның Рәсим баскан сукмакларына Хәбир дә баскан, Рәсим коенган суларда Хәбир дә коенган, Рәсим менгән тауларга Хәбир дә менгән. Шуны белмиме икәнни әнисе? Үзе әйтмешли, я алла.

Рәсимнең чәй эчәсе килми иде, ләкин ул эчә, әнисенә туп-туры караган килеш әллә өченче, әллә дүртенче чынаягын эчә.

Әнисенең тамырлары зәңгәрләнеп чыккан куллары өстәл өстендә ята. Күзләре — самоварда. Соңгы чигенә житкереп ялтыратылган самовар йөзендә Рәсимнең яңаклары да, маңгай колаклары да, тельняшкасы да озынаеп, көлке бүлмәсендәге шикелле гарипләнеп күренә... Күкрәгендәге жөе ничек чагылыр икән самовар жизендә? Нишләп сөйләми соң әнисе Хәбир турында? Әллә бер-бер хәл булганмы күршегә? Әллә әнисе чирләп киткәнме?

— Нәфисәттәй исән-саудыр ич?

— Исән-сау, исән-сау, дөбердәтеп йөри.

— Хәбир бригадир булып эшлиме?

— Бригадир булып эшли. Безнең авыл бригадасында. Ызбаларын салып, каралты-кураларын корып бетергәч кенә керде әле бригадирлыкка. Башта теге, ничек әле, тәкли, тәчми, әй аты корыгыры, бар ич инде хәзер колхозларда тавыкны тимергә алыштырып йөрүчеләр.

— Кемнәр-кемнәр? — дип көлеп жибәрде Рәсим.

— Соң, теге ни инде, тавык төяп китәләр дә, машина тимерләре алып кайталар... Тәкмин этәче, тәкмин этәче.

— Ә-ә, тәэминәтче булып эшләдемени Хәбир?

— Шунда эшләде. Шунда эшләгән чагында, машина кулында булгач, бүрәнәсен дә апкайтты, калаен да...— Хәят апа самовар жизенә бармагын тидереп карады.— Эчәсең килгән икән, улым. Әллә тагын яңартабызмы?

— Булды, әни, рәхмәт.— Рәсим чынаягын читкәрәк этеп куйды. Чиста, йомшак тастымалга кулларын, авыз кырыйларын сөртте. Самовардагы гарип шәүлә дә, аны үртәгәндәй, ул ясаган хәрәкәтләрне кабатлады.

— Мин, улым, син җибәргән акчаларның бер тиененә дә кагылмадым. Кассага салып бардым. Теләсәң, кием-салым алырсың. Теләсәң ни ал.

— И, әни, нишләп алай иттең соң? Син ачлы-туклы яшәсен дип җибәрмәдем ич мин сиңа акча. Эшләр идем әле, баш бәясе түгел, табар идем...

— Әй, улым, акча белән нишлим соң? Сиңа инде барысы да, син яшисе хәзер, матур гына тормыш корып җибәрергә язсын иде ходай!

Рәсимнең чигәләренә кан йөгерде. Ниһаять, сүз Тәслимәгә якынлашты бугай.

— Колхозда эшләрсең микән инде, улым?

Юк, булмады әле. Тагын Тәслимәдән читкә китте сүз.

Рәсим әнисенең соравына җавап бирде.

— Эштән курыккан юк ла анысы. Аты булгач, камыты табылыр.

Ә ни булган? Тотарга да сорарга. Нишләп әнисеннән оялып торырга тиеш әле Рәсим? Бәлки әнисе Тәслимәгә булган хисләре турында бөтенләй дә хәбәрдар түгелдер әле. Авыл яшьләре, шул исәптән, кызлар турында да сорашырга хакы юкмыни аның. Кулешов әйтмешли, в конце да концов!

Политика кирәк, дипломатия! Каушама, Рәсим! Җай белән, рәте белән...

— Фирдәүсә һаман клубта эшлиме?

— Шунда.

— Кияүгә чыкмагандыр ич?

— Юк бугай әле, ул-бу ишетелми.

— Ә Гөлнур?

— Гөлнур чыкты. Күрше авылга. Тегермәнче Галләм малаена. Син аны беләсеңдәдер әле. Бер елны Кәвәли базарыннан кайтканда этисе белән безгә кереп кунганнар иде. Атаңны яхшы белә Галләм. Сугышка хәтле бергәләп балта эшенә дә йөрделәр. Әйбәт кешеләргә эләкте Гөлнур, бәхете бар икән...

Нишләп шулкадәр күп сөйли инде Хәят апа Гөлнур турында? Гөлнурның кирәге дә шуның кадәр генә бит Рәсимгә.

— Малае да, атасы кебек, эчми, тартмый, ди. Машина йөртә малае, шуфер.

Рәсим кипкән иреннәрен ялап алды, бусагага менеп утырган мәчегә күзләрен текәп, тәвәккәлләде:

— Тәслимә нихәл?

— Тәслимәме? — Хәят апа өстәл өстендәге савыт-сабаларны тиз генә шатыр-шотыр җыеп алып кече якка кереп китте, шунда ук әйләнеп чыкты.— Төтен исе килгән кебек булды, алла сакласын, утлы күмер төшеп калса... Бер елны Шәмгуннар бөтен каралты-куралары белән янып киттеләр шулай. Рамазан аенда. Телсез кызлары сәхәргә торып самавыр куйган...

Әллә Тәслимә турында бөтенләй онытты инде әнисе. Сорауны ишетмәде, дисәң, Тәслимәме, дип кайтарып сорады. Шаярта, дисәң, күзләре бик җитди. Инде шул гына җитмәгән иде,— авызын учы белән томалап иснәде дә:

— Йоклыйк, улым, син дә юлдан кайткан кеше, арыгансыңдыр, калганын иртәгә сөйләшербез, иртә кичтән хәерлерәк,— диде.— Сиңа караватка җәйимме урынны, улым, дивангамы?

— Миңа барыбер,— диде Рәсим, әнисенә туры карамыйча.

Онытмаган икән әнисе, Рәсим чишенеп урынга менеп ятканны гына көткән икән. Рәсим исләре балачактан таныш йомшак урын-җиргә кереп чумуга, Гөлнурлар, Фирдәүсәләр турында сөйләгәннән дә битарафрак тавыш белән:

— Тәслимә медпунктта эшли, Буада укып кайтты,— диде.

Рәсим, сагаеп, сүзнең дәвамын көтте.

Хәят апа ни өчендер бик кыенсынып кына сөйли иде Тәслимә турында. Рәсим моны сизде, әмма, инсаф йөзеннән, әнисен ашыктырмады.

Хәят апа өстенә бишмәт алып киде, бераз ишек төбендә таптанып торды да аны кире салды, чөйгә элеп куйды. Мич капкачын тотып карады, кулы белән караңгы мич башыннан нәрсәдер эзләде. Аннары мич арасына кереп китте. Мич арасыннан тагын Рәсим көтмәгән сүзләр алып килде:

— Электрны әйтәм әле, уңайлы да нәрсә икән. Этләнгәнбез икән элек крачин лампалары белән. Әле анысы бер хәер, чыра яккан заманалар булды бит... Йокламыйсыңмы әле?

— Йокламыйм әле, никтер йокы качты,— диде, Рәсим аңлаган кешегә аңларлык иттереп.

Ана күңеле сизмиме, аңламыймы соң инде? Хәят апа да барысын да сизә, барысын да белә, хәтта, Рәсим уйлаганга караганда күбрәк тә белә иде бугай әле ул. Һәрхәлдә караңгы мич арасында эш юктан эш ясап йөрүе Тәслимә хакында сөйлисе килмәүдән генә түгел микән әле аның?

Рәсим юрган читеннән генә күзләрен елтыратып ята, йокламый, дөресрәге, йоклый алмый, көтә.

Рәсимгә кыен, Хәят апага тагын да кыенрак, ахры — идәнгә, итекме шунда, әллә башка берәр каты әйберме, нәрсәдер дөпелдәтеп төшерде. Итек икән шул. Әнә кулына тотып чыкты, ләкин кияргә уйламый, саксыз гына ишек төбенә ташлады да мичкә сөялде.

— Мин аны акыллырак кыз булыр, дигән идем, бик иратай нәрсә булып чыкты тора-бара.— Тәвәккәлләде шикелле, ниһаять, Хәят апа, бер тотынгач-тотынгач, элеп алып, селкеп салырга уйлады кебек.— Әхмәтләр өйләнгәнне әйтеп язган идем, авылда калырга уйлаган булганнар. Ә бу имансыз нишләде? Һәр ходай бирмеш көнне, ахшам җиткәч, Әхмәтләр капка төбен каравыллады. Әтисе өйләнгән кеше артыннан сөйрәлеп йөрүеңне ташлыйсыңмы син, юкмы, дип чыбыркы белән ярып алып кайткан бер көнне. Шул чаклы затсызларча эзәрлекләгәч, ир кеше нишләсен, ир кешене аздыру кыен түгел ул бер дә. Әхмәтнең төнлә медпунктка кереп киткәнен күргәннәр малайлар. Хатыны кан-яше белән елады, ничек итсә итте, алып китте Әхмәтне. Әле Әхмәтләр киткәч, әйтә ди тагын: «Ничек итсәм итәм, барыбер эзләп табам Әхмәт абыйны, барыбер үземнекен итәм!» — дип әйтә ди.

Рәсим сүзсез-өнсез калып урынына сеңә барды. Ләкин мендәр кайнар, кысылган саен ут кебек пешерә бара иде. Нигә генә сорашты икән, иртән булса, ишегалдына, арт бакчага чыгып йөгерер иде, ичмасам, салкын карга йөзтүбән ятып торыр иде.

— Үзе аяусызланган инде, йөрәк даны бөтен авылга таралган, энисен картайта, бәрхәдәрсез. Әнисе Хәдичәне күрсәң син хәзер, җаны гына чыкмыйча калган. Шул иратай гына вакытсыз картайтты мескенне... Әхмәт абый янына китәм, дип эшен ташлап, котырып йөри башлады, атасы тагын бик каты каезлаган тегене. Син кем аңа хәзер, кемгә кирәгең бар, сөйрәлчек, кияүгә чыкмый каласың бит, гомер буе безгә җан көеге булып каласың,— дип такмаклый-такмаклый каезлаган. Үзең беләсең, Борһанның кулы каты, аңа эләксәң... Юк инде, ходай бирмәгән акылны кыйнап кертеп булмый, диләр бит. «Мин кияүгә чыкмыйммы, минме, мин беләсегез килсә, авылның иң шәп егетенә кияүгә чыгам, теләсәм бүген үк, чыгам»,— дип суккан саен үҗәтләнебрәк әрепләшә икән атасы белән.

Рәсим көчәнеп чыраен сытты. Шулай иткәндә елыйсы килгәндә дә еламыйча түзә торган иде ул. Әлегә ни өчен еларга теләгәнен Рәсим үзе дә белми. Тәслимә дә жәл, Рәсим үзе дә кызганыч.

— Йоклыйсың, ахры.

— Юк,— диде Рәсим, кысылган иреннәрен сүзе сыярлык кына кыймылдатып.

— Үз сүзен итте тәки, дивана. Шул төнне үк чыкты кияүгә.

Рәсим кинәт урын-җире белән салкын төпсезлеккә очкандай булды да шул секундта ук яңадан гадәти халәтенә кайтты. Салкын төпсезлектә, кайнар мендәргә йөз куеп ятуга караганда рәхәтрәк иде. Кабатлансын иде шул халәт. Йөрәктәме аның хикмәте, кан тамырларындамы, баш миендәме? (Нәрсә, юләр, дидеме әнисе?) Кияүгә чыкты, дидеме? Шаяртадыр әле... Онытмаган икән шулай да Әхмәт абыйсын, онытмаган икән, һаман ярата икән.

Рәсим капылт кына юрганын чөереп ташлады да идәнгә сикереп төште. Кече якка кереп — монда узышлый гына күз салып узган иде бит ул — ак шнурлы лампочкадан күзләрен алмыйча, капшанып кына сулы чиләкне эзләп тапты, чиләк авызыннан йотлыга-йотлыга салкын су эчте, иякләренә, муеннарына, манма су булып тәненә ябышкан тельняшкаларына агыза-агыза эчте.

— Чәй бар ич, улым, су салкын бит, тамагыңа тимәсен,— дип Хәят апа да улы янына кереп җитте.

— Син нәрсә дидең әни? Тәслимә кияүгә чыкты, дидеңме?

— Чыккан, әтисе белән тавышланышкан көнне төнлә өйләренә кайтмаган.

Рәсим, берни дә уйлый алмыйча, әнисенең авызына карап катты.

— Әллә кемгә чыкмады анысы. Хәбиргә чыкты.

— Кайсы Хәбиргә?

— Соң, безнең күршегә инде, Нәфисәттәң малаена.

Нәфисәттәң малаена... Рәсим мич арасыннан шәүлә кебек чыгып китте. Идән буенча барганда да идән такталарын шыгырдатмады. Урынына менеп ятканда гына, аягының әллә кайсы бармагы эләгеп, юрган чехолының бер читен ертып җибәрде... Нәфисәттәң малаена... Назаренко ничек әйткән иде әле? Хатын-кыз мәсьәләсендә намуслы булуы кыен, дигән идеме? Димәк, Нәфисәттәй малаена. Кем була инде ул? Ул — Хәбир була. Ничек була инде? Тәслимә Хәбирнең хатыны, Хәбир Тәслимәнең ире була. Шулай да буламы икәнни? Рәсим тагын төпсезлеккә ычкынып бара түгелме соң? Юк, алай булырга тиеш түгел, әнисе, мөгаен, шаярта гынадыр. Менә хәзер көлеп җибәрер дә, Рәсимнең янына килеп, юрганының читен ачып ташлар. Борчылма, улым, мин юри генә әйттем, Тәслимә һаман элеккечә, имин генә, матур гына, инсафлы гына яшәп ята, алмалы көянтәсенә бизәкле чиләкләрен асып су ташый, узганда-барганда Рәсимнең хаты юкмы, Хәят апа? Хат язганда миннән дә сәлам әйтерсең, дип сүз кушып, хәл белешеп уза, дияр.

Бу мендәрнең төне буе суынасы юк. Нишләп сүндерми инде әнисе утны? Сәгать күкесеннән дә ямьсезрәк тавышлы берәр кош бар микән бу җиһанда? Кычкыруы үзәккә үтеп керә, бавырга пычак булып кадала... Әле төн уртасы авышты гына бит, таң атканчы күзең күгәрер... Әнисенең керосины бардыр инде чоланда. Әйбәтләп керосин сибеп ут төртергә дә ызбаларына чыгып китәргә авылдан. Тик йөрсеннәр сукыр тычкан кебек төтенгә буылып. Рәсим белән Назаренкога гына янарга, димәгән... Йөрсә йөрсен иде Әхмәт абыйсы артыннан. Рас ярата икән. Ач хәлен тук аңламаган кебек, яраткан кеше хәлен дә яратмаган кеше аңламый. Анысына сүз дә әйтмәс идең. Тик менә Хәбиргә чыгуын ничек дип юрарга? Суга баттың — исән калдың, Рәсим, утта яндың — имин калдың. Өченчесендә көч! Монысы суга батыру да түгел, утта яндыру да түгел, монысы җәзалап, саргайтып киптереп үтерү. Суга батканда да, утта янганда да яшәү дигән, яшел алан уртасындагы Тәслимә үлемнән саклап калды сине. Ә хәзер?.. Бар да бетте, дөнья-

ның алсу пәрдәсе ертылды, тешсез авызын силос базы кадәр ерып синең каршыңа дөнья карчыгы килеп басты. Ярат инде шуны менә, иркәлә! Өлешеңә тигән көмешең...

Әнисе утны сүндерү белән Рәсим юрганын аяк очына тибеп очырды да мендәрнең астын-өскә әйләндереп салды, үзе дә чалкан әйләнеп ятты. Карлы тәрәзә каршысында асылынып торган лампочка ялтыр күзле, йомры башлы буар еланга охшап күренде аның күзенә.



## Җиденче бүлек

Назаренконың тавышы болай нәзек түгел иде ич? Әнисе тавышы лабаса бу, нишләп әле Назаренко Рәсимнең әнисе шикелле «улым» дип эндәшә.

— Улым, дим, улым!

Рәсим күзләрен ачты, урын-җирләр ап-ак. Госпиталь палатасы... юк, түгел, койка янында әнисе басып тора, йөзе алсуланган, бит җыерчыклары күренми дә. Өйдә бит инде Рәсим, бөтенләйгә кайтты бит ул.

— Яктырып беткәч саташып ятасың, улым. Инде уянсаң да ярыйдыр. Кыстыбый пешердем. Салкынайткан, аяк асты тайгак... Кемнедер бик каты орышып ята идең әле генә. Башта бусага төбеннән карап тордым. Вареньега-фәләнгә буялган микән соң, мин әйтәм, моның күкрәге? Якынрак килеп карасам, котым очты. Нишләттеләр сине, улым?

Рәсимнең бөтен мускуллары катерда аврал уйнаган чактагыча пружинадай кысылдылар. Ул ялт итеп муенына кадәр җыерылып менгән тельняшкасын рәтләде, юрганына төренде.

— Болай гына ул, әни. Чуан чыккан иде. Аза башлады да кистеләр. Күптән төзәлде инде ул. Юк өчен хафаланма.

— Җөе бигрәк яман бит, улым, җылырак киенеп йөр, тагын азып китмәсен. Адәм баласын бер дә жәлләп тормыйлар брачларны әйтәм... Мин суга барып кайтам. Чәй кайнаган, юынгычта су бар...

Ишек шыгырдап ачылды да тавышсыз гына ябылды.

Өйгә май исе чыккан. Кече якта самавыр җырлаганы ишетелә. Тәрәзәгә ябышкан карларны җил очырып бетергәнме, үзләре эрегәннәрме — ни генә булса да тәрәзәләр чиста калган. Рәсим, урыныннан калкынып, урамга карады. Ал бакчадагы сәрби куагында яшел каурыйлы песнәк тирбәлеп утыра, йоннары кабарган. Урамның теге ягындагы таллар ак яфрак ярганнар диярсең — бөдрәләнеп, чукланып-чачакланып оеп утыралар.

Китмәскә килде микәнни инде кыш? Җәйләр, көзләр үттеме икәнни? Рәсим, аягына киез итек киеп, ишегалдына чыкты. Әнисе инде сарыкларга печән салырга да өлгергән. Рәсимгә барысы берьюлы тасыраеп карадылар да сарыклар, комсызланып, янә печәнгә ябыштылар.

Кәҗә кайда соң әле? Сарыклар печән ашаганда ничек жаны түзә икән сакалбайның? Абзар түбәсендә ниндидер карамчык шәйләп, Рәсим карашын югарыга юнәлтте. Шул ристан. Рәсимгә күзләрен бер генә ялтыратып карады да түбәнең теге ягына сикерде. Тәмлерәк ризыкка юлыккандыр, күрәсең. Кәҗә дә булсын, сарыклар белән бергә сарык ашаган ризыкны да ашасын, имеш.

Хәбирләрнең биек йортына бер генә күз сирпеп алды Рәсим. Йортның бу ягы ишексез-тәрәзәсез булганга, ни өчендер, төрмә бинасы кебек күренде ул Рәсимгә.

Рәсимнәрнең үзләренең ызбасы да төнге матурлыгын, төнге серлелеген югалткан, бер яккарак кыйшаеп, кар каплаган түбәсе кышкы төссез һавада чак-чак кына күтәреп торгандай тоела иде.

Кайту турындагы уй башына кергәч, Рәсимнең якты хыялларына сизелер-сизелмәс кенә күләгә төшереп торган күңелсез истәлек — иске

ызба булса, туган авылына кайтып бер кич кунганнан соң, менә шушы салкынча, төссез иртәдә бөртек тә борчымады Рәсимне ызба мәсьәләсе. Искерсә соң, искерсен! Ишелеп төшми ич әле өсләренә. Ишелә башласа, тагын бер терәү куярлар. Түбәсе ябылган хәзер, яңгыр үтми. Рәсим тозлы җил куып йөргәндә, әнисе өйнең нигезен дә такта белән тектереп куйган әнә. Тәрәзәләре Рәсим киткәндә ничек калган булса, шулай сакланган. Буявы да купмаган хәтта. Капка баганаларын гына алыштырмыйча булмас. Юкса, берсе мәшрикъка караган, икенчесе — мәгърипкә. Урам яктан сыер-фәлән ышкынып узса, шартлап сынарга да күп алмаслар.

Кинәт Хәбирләр морҗасыннан ургып күгелҗем төтен күтәрелде. Рәсим, амбар ишегенә сөялеп, шушы минутта Хәбирләр өендәге кешеләрнең нәрсә эшләгәнен күз алдына китерергә тырышып карады. Ләкин күз алдына китерә алмады. Хәбирләрнең әле Рәсим кайтуы якка ачылганын белмәгән ишекләре турында уйлый башлагач ук, аның күзләре яшьләнде, фикере чуалды. Әллә Хәбирләрнең төтеннәре Рәсимнәр ишегалдына да төшеп җитә инде, каһәр? Шул яшьләндерә, мөгаен, Рәсимнең күзләрен, шул чуалта аның фикерләрен.

Ишегалдының бөтен җире аяк эзләре белән чуарланган. «Нишләп йөрде икән соң әнисе бу чаклы? Утын алып керде, ди, сарыкларга печән салды, ди, суга китте, ди? Ә тагын, тагын нишләргә тиеш кеше? Рәсим, аптырап, артына әйләнеп карады. Үзе йөри лабаса Рәсим ишегалды буенча. Читлектәге арслан кебек, ишегалдының бер почмагыннан икенче почмагына үзе йөри, яшь карны бер мәгънәсезгә үзе таптый. Амбар ишегенә сөялеп торган җиреннән нигә дип кузгаласы итте дә, кайчан кузгалып китте соң әле ул? Койма ярыгыннан кеше күрер инде. Бу нинди тиле йөри икән, диярләр.

Рәсим тагын бер мәртәбә Хәбирләр морҗасыннан ургылып чыккан төтенгә карап алды да ашыгып чолан ишеген ачты, итегендәге карларны да сыпырып тормыйча, ябулы ишек янына килде, салкын учындагы эсселекне бетерер өчен салкын тоткага ябышып торды...

Ул бусаганы атлап кергәндә сәгать күкесе, үртәшкән төсле, нәни тәрәзәсен ачып җибәрде. Ләкин күкелди башлаганчы Рәсим чоланга чыгып өлгерде. Тозлы каз исе, мәтрүшкә, бөтнек, тагын әллә нинди шифалы үлән исләре таралган караңгы чоланда басып торганда, аның күңеленә сәер уй килде: «Минем әти белән әни ничек яратыштылар икән, мәхәббәтләре булдымы икән аларның, әллә болай гына өйләнештеләрме икән?»— дип уйлады ул, салкын тоткага инде ике учы белән дә ябышып. Аннары үзе үк нәтиҗә чыгарды: «Мәхәббәтләре булгандыр, мәхәббәтсез генә өйләнешкән булсалар, әнисе тормышны шул кадәр яратып, тормышка шул кадәр ябышып ятар иде мени? Шушы искереп беткән өйдә бер ялгызы ничек дүрт ел яшәр иде ул кайнар йөрәген мәхәббәт җылытып калдырмаган булса?!».

Рәсим ишекне кинәт кенә ачып өйгә керде — нәни күке оясына кереп качкан, йомшак йонлы соры мәче диван култыксасына менеп утырган да, колакларын селкеткәләп, ишетелер-ишетелмәс кенә сызгырып, сәгать теленә карап утыра иде.

...Гашыйк Гарип Хөзер галәйһиссаләмнең канатлы атында мең чакрым юлны күз ачып-йомганчы узды, ди. Сукырайган әнисе Гашыйк Гарипне ташламады, ди. Шәһәрдә хәзер туйлар бара, Маһимөһри Хөршид бәккә чыга, дип, әйтте, ди...

Ә Маһимөһри чаршау артында бер кулына агулы касә, икенчесенә хәнҗәр тотып утыра икән. Гашыйк Гарип кайтып җитмәсә, үзенә кул салырга ниятләгән икән Маһимөһри...

Очраткач, Хәбирнең авызына сугып җибәрүдән ничек тыелып калыр икән инде Рәсим? Нишләп Хәбиргә сугарга тиеш әле ул? Патша заманы түгел ич, көчләп алып кайтмагандыр Тәслимәне. Тәслимәнең

дә Рәсимгә, сине көтәм, дип вәгъдәләр биргәне юк. Уйлап-уйлап торсаң, менә бит эшләр кая таба китә. Димәк, ничек булып чыга инде? Димәк, Рәсим үзе гаепле булып чыга. Дөньяны онытып, җибеп йөрсәң, менә шулай була ул. Хан малае бит син, китереп бирерләр сиңа яраткан кызыңны, көт! Бишәр ел кош теле чаклы хат кисәге язмыйча, читтә йөр дә. Тәслимәң синең кайтканыңны зар-интизар булып көтеп торсын, имеш. Көтәрләр, тот капчыгыңны!

Рәсим, идән буенча ишекле-түрле йөри-йөри, әнә шулай уйлады. Ләкин нәрсә генә уйласа да, хәле әйбәтләнмәде. Әллә күкрәгендәге җәрәхәте ачыламы, әллә шул әрнетәме аның җанын? Сулышын тыя төшеп, бер-бер җирем авыртмыймы икән, дип тынып та торды Рәсим. Ләкин бу минутта тәненең бер җире, бер генә күзәнәге дә авыртмый иде аның.

Урамнан дөбер-шатыр килеп чылбырлы трактор үтеп китте.

Нишләп озаклады икән әнисе, әллә кизләү туңып та өлгергәнме икән? Су юлында хатын-кызлар белән сөйләшеп торадыр әле. Улым кайтты бит, дип мактана торгандыр.

Нишләп болай тилемсә кебек киләп сарып йөри соң әле Рәсим? Моны «гражданка» диләр. Приказ көтеп торасы юк. Абзарларны арчып чыгарырга кирәк. Ишегалдындагы карны себереп алсаң да язык булмас.

Рәсим җиң сызганып ук булмаса да, бик каты җилләнеп эшкә тотынды. Тирес исе дә сагындырган икән, баксаң. Шәһәр кешесе, авылга кайткач, кыр-урман чәчәкләренең исен иснәгәндәй, рәхәтләнеп комсызланып сулады Рәсим абзар һавасын.

Озакламый әнисе дә кайтып җитте. Чынлап та, су юлында сөйләшеп торырга туры килгән икән Хәят апага. Очраган бер кеше Рәсим турында сораша, җавап биреп бетерәлми икән Хәят апа.

Өйгә кереп, чишенеп, табага таслап, майлап өелгән кыстыбыйны мичтән алып табын янына утырырга гына җыенганнар иде, капка шалтырады, ян тәрәзә турысыннан кара шәүлә чагылып узды.

— Хәбир бугай,— диде Хәят апа әле Рәсимгә, әле өстәл өстендә өелеп торган кыстыбый өеменә карый-карый. Аның тавышы, ни өчендер, эчкә киткән иде.

Рәсим каушамаска, үз-үзен кулга алырга тырышты. Чалбар каешын рәтләп куйды. Тельняшкасын сыпыргалады, көзге каршысына барып керпе энәседәй каты, кыска чәчләрен тарап алды.

Я, я, кер, Хәбир, нишләп бик озакладың? Әллә керергә куркып торасыңмы? Ашамый сине Рәсим, кер. Ерткыч түгел ул Рәсим, юлбарыс та түгел.

Акрын гына ишек ачылды, кара итек, аннары кара чалбар, шундый ук пинжәк, изүләре ачык ефәк күлмәк, йонлач күкрәк күренде. Гәҗиткә төрелгән озын әйбер тоткан шактый тупас кул барысыннан да алда кергән булган икән. Рәсим анысын күрми генә торган икән.

Хәбирнең тырпайган колакларын күргәч, Рәсимнең күңеленнән әллә нинди йомшак, кытыкны китерә торган җип-җиңел дулкын үтеп китте. Ләкин төчеләнеп торырга вакыт калмаган иде инде. Хәбирнең тагын да киңәеп киткән җәенке йөзендә, бераз куркыбрак, бераз ялагайланыбрак карап торган зур күзләрендә шатлык нурлары уйный иде.

— Малай,— диде, җылы кисәкләрдән тегелгән чәшке бүреген ишек төбендәге урындыкка ташлап.— Исән-сау гына кайтып җиттекме? Ну сагындырдың!— Хәбир кулындагы төргәген дыңк иттереп өстәл читенә утыртты.— Әйдә, күрешик.

Күрешкәч Рәсим Хәбирнең кулы шактый ныгыган, куәтләнгән булуын сизде, алай-болай көч сынашырга туры килсә, мондый кул белән алышуы, әлбәттә, ансат булмаячак иде.

— Мин кайтканга ике ел бит инде, парин, ике ел. Флотта хезмәт иткәнеңне узган ел гына ишеттем. Мин сине диңгездә һаман балык тотып йөрисең, дип торам,— дип сөйләнә-сөйләнә Хәбир өстәл янына килеп утырды, төргәкне җайлы гына сүтеп, ак башлы шешә тартып чыгарды, Рәсимгә егетләрчә мәгънәле генә күз кысып алды да, мич арасыннан ярты гәүдәсе генә күренеп торган Хәят апага эндәште:

— Ачуланмасаң, без күршенең кайтуы хөрмәтенә аз гына тамак чылатып алырыек, Хәят апа!

— Ниткән ачулану булсын, ачуланмыйм,— диде Хәят апа ашыгаашыга.— Өстәлдә барын ашый торыгыз анда. Мин хәзер итле бәрәңге кыздырып алам.

Хәбир, рюмка-фәлән эзләптер, ахры, өстәл өстен карап-күзәтеп чыкты. Тагын бер мәртәбә, эх, малай, дип Рәсимгә күз кысып алды, «мәскәүски»нең тимер бөкесен теше белән генә каерып атып, кырлы стаканнарга аракы койды.

— Ә бит корабка алмадылар, парин. Яр буенда, сапер булып хезмәт иттем. Беләсеңме кем булып? Хуҗалык бүлеге начальнигының ярдәмчесе булып. Строевойдагылар кырык градус салкында селәгәй агызып йөргәндә, җылы складта тушонка санап кыш уздырдым мин. Бер банка, ике, өч — монысын Петров отделениесенә, бер банка, ике, өч — монысы Ивановка... Менә шулай. Күңелсез эш, между прочим! Ну аның каравы, сәламәтлегемне сакладым. Армиядән кайтканда туксан ике кило идем мин, беләсең килсә! Хәзер генә бирештем, бераз.

Күрешкән чагында сизелмәгән иде, якынрак килгәч, Хәбирнең авызыннан күңел болгаткыч ис бөркелде. «Кичә, яки бүген иртүк эчкән бу»,— дип уйлады Рәсим. Хәбирдән мөмкин кадәр читкәрәк тайпылырга тырышып:

— Бөтенләйгә кайттыңмы, парин?

— Бөтенләйгә,— диде Рәсим сөйләшәсе килмичә генә.

— Колхозда эшләргәме исәп, әллә читкә китәсеңме?

— Карармын әле.

Хәбир кырлы стаканның берсен Рәсим алдынарак шудырды.

— Әйдә, тотып куйыйк. Исән-сау кайтуың хөрмәтенә.

— Рәхмәт, эчмим бит мин.

— Нәрсә, бөтенләйме?

— Бөтенләй.

— Әллә шаяртасың инде?

— Син эч, эч, миңа карама.

— И эчәм дә... Безнең эштә эчмичә булмый. Тавык та эчә хәзер. Заманасы шундый. Эч, түлке акылыңны югалтма. Син дә өйрәнерсең әле, тормыш өйрәтә ул.— Хәбир стаканны җәлт кенә каплап куйды, чеметеп кыстыбый капты.— Тартмыйсың дамы?

— Юк.

— Безнең частьта да бар иде берәү, Альфред исемле. Канатлары гына юк, канатлар куйсаң, Альфред первый сорт фәрештәгә әйләнә, дип әйтә торганнар иде аның турында. Бер караңгы төнне постта торганда урманда урман мәчесе сикергән моның өстенә. Сикергән, и, Альфредның бәхетенә каршы штык очына эләккән. Бавыры авыртуга чыдый алмыйча, чинап җибәргән мескен ерткыч, ә аннан да бигрәк яман тавыш белән Альфред акыра икән. Күрше посттагылар ишетеп килеп житкәннәр. Шуннан соң тотлыга башлады егет. Д-д-дядя, дип сөйләшә. Демобилизовать итәсе елны көненә бер пачканы «эһ» тә итми тартып бетерә иде, егетең. Тормыш өйрәтә ул, ие... Тормыш — ул муеныңны бормыш.

Хәбир, моңа каршы нәрсә әйтерсең икән, дигән кебек, Рәсимгә текәлеп торды. Әмма Рәсим бу минутта, Хәбиргә карамыйча, тәрәзә ар-

тындагы сәрби куакларыннан тавышсыз гына коелган карны күзәтә иде.

— Куркынычмы соң дингездә?

— Ә? Диңгездәме? Төрле чак була. Курыкканыңны күрсәтсәң,— куркыныч, күрсәтмәсәң, куркыныч түгел.

Хәбир әллә аңлап, әллә аңламыйча, ияк кагып куйды, өстәлгә Хәят апа китереп утырткан табадан ит кисәге алып капты.

— Күргәнсеңдер, ызба өлгерттек, мунча салдык, каралты-кураны рәтләдек.— Хәбир кызара башлаган күзләрен өй чатлары буенча әрле-бирле йөгертте.— Сиңа да кочәнергә туры килә инде, малай, кыенлашты хәзер ызба салулары, элеккеге кебек түгел. Пермь ягында бер бүрәнәгә яңа акча белән егерме сум сорыйлар. Бер бүрәнәгә бит ул. Бер ниргәсе күпмегә төшә инде? Йөзгә якын. Яңа акча белән почти мең тәңкә дигән сүз.— Хәбир иплэп бармагы белән мәзәк кенә иттереп яртылаш бушаган шешәгә төртеп күрсәтте.— Ә монсыз дөнья сансыз хәзер, малай. Нинди генә йомыш белән барсаң да, ярты буламы, дип кенә сөйләшә хәзер халык.

Рәсим әле кайчан гына борыныннан «юеше» күренеп йөргән Хәбирнең аракы турында шулай тәмләп, олыларча фикер йөртүенә аптырамады, киресенчә, көләсе килде аның. Назаренко әйтергә ярата торган сүзләр исенә төшмәгән булса, Рәсим, ихтимал, көлеп тә җибәргән булыр иде.

— Аракы — намуслының дошманы, намуссызның юлдашы,— дип әйтергә ярата торган иде Назаренко яшь диңгезчеләргә.— Эчкән кеше нинди дә булса шатлыктан яки кайгыдан эчми. Кайгыдан яки шатлыктан эчәм, дигән сүзләр тышкы ямау гына ул. Намус белән янәшә яшәү туйдырган кешенә. Намусыннан качарга, я намусын качырырга уйлаган кеше.

— Өй салам, дип, ярты картайдым инде, малай...— Монысы Хәбирнең үз сүзе түгел. Монысы Хәбирнең әнисе Нәфисәттәй сүзе. Хәбир әле урамга капка астыннан чыгып йөргәндә үк Нәфисәттәй: «Ярты картайдым инде бу малай белән, күлмәк-ыштан җиткерер хәл юк»,— дип сөйләргә ярата торган иде.

— Колхоз булышмадымыни өй салырга?

— Колхоз?!— Хәбир Рәсимгә, нәрсә, дөньяга бүген генә килдеңме әллә, дигәндәй, сәерсенеп карады.— Булышыр колхоз! Колхозның үзенә булышасы бар әле, бик беләсең килсә. Колхозлар кечкенә чагында карап бетерә алмыйларие хуҗалыкны. Хәзер, берләшкәч тә очына чыгар хәл юк. Ике председатель килеп китте инде. Килеп колхозны талыйлар да таялар, малай. Менә яңасын китереп утырттылар. Институт бетергән, дипломлы яшь белгеч, имеш. Төкерәм мин аның дипломына, арпадан бодайны аера белмәгәч.

— Сез үзегез сайлап куйгансыздыр ич? Юньлерәк кеше табалмадыгызмыни?

— Һәй, малай, дөньяга бүген генә килгән кеше кебек сөйлисең син. Без сайласак, Галимулла абыйны калдырган буладырие халык. Түбән авылда да яраталарие Галимулла абыйны. Юк бит, районнан килгән вәкил чат каршы торды. Фәлән мең гектарлы олы хуҗалык белән идарә итәр өчен махсус белемле кеше кирәк, имеш. Халык сизгер бит ул, кешенең кем икәнен килеп эшли башлагач ук белеп ала. Юашны да яратмый ул, усалны да. Усал булсаң, асарлар, юаш булсаң, басарлар, уртача булсаң, ил агасы ясарлар, дип тикмәгә генә әйтмәгән борынгылар.

Рәсим Хәбирнең телгә тәмам остарып җитүенә гаҗәпләнеп куйды. Башта ул, аракы сөйләндерә инде моны, сүзенең рәте-чираты булмас, дип тыңлар-тыңламас кына утырган иде. Тора-бара, Хәбир авызыннан

шактый гына акыллы сүзләр чыга башлагач, дикъкать беләнрәк тыңларга кереште. Шуннан артыгын эчмәскә, ахры, исәбе Хәбирнең — шешәнең бөкесен үк каплап куйды. Майланып, ялтырап торган авыз кырыен да сөртеп алса, өстәл янында шыр аек кеше утыра икән, дип уйларсың, билләһи.

— Безгә нәрсә,— дип дәвам итте Хәбир, тамагын туйдырып, алдындагы ризыкны читкәрәк этеп куйгач.— Без бәләкәй кешеләр, чабатачыларның чабатасы гына.

— Хуҗалыкны синең белән без, колхозчылар, аякка бастырырга тиештер ич инде. Алма пеш, авызга төш, дип бот күтәреп ятсаң, дию пәрие килеп эшләмәс синең эшеңне.

— Менә, менә,— дип ялгап китте Хәбир, сүзнең шундый борылыш алуын гына көтеп утыргандай,— дөп-дөрес әйтәсең. Хуҗалыкны без аякка бастырырга тиеш. Ә безнең хуҗалыкны кем аякка бастыра? Сиңа, менә бу нигезне бөтәйткәнче, каралты-кураларыңны адәм рәтенә керткәнче, беләсеңме, күпме нужа чигәргә туры киләчәк әле? Һи-и! Сызгырып күрсәтер идем инде мин сиңа, өйдә сызгырырга ярамый. Безнең авылда гына да йорт-җирләре тузган алтмыш хуҗалык бар икән. Беркөн авыл Советында санап утырдылар. Түбән авылда да шуннан ким түгел. Үз хуҗалыгы шундый хәлдә булгач, колхоз хуҗалыгына күңел бирәме соң инде крестьян, я?

— Ә колхоз кемнеке соң? Колхоз шул ук крестьяннныкы лабаса. Армиядә политзанятие дәресләренә сирәк йөргәнсең, ахры, күрше.

— Син авызыңны ерма. Мин сиңа дөресен сөйлим. Сүз белән тамак туйдырып булмый. Теге елларда өчәр, дүртәр йөз хезмәт көне эшләгән кешеләргә дә уңыш бүлгәндә ике-өч поттан ары икмәк тимәгәнен бик яхшы беләсең син. Колхоз синеке булгач, нишләп авыз тутырып ипи ашамадың соң син ул елларда, ә? Һәй, малай, читтән торып Авыл хуҗалыгы техникумында укып маташа бит әле абзаң. Әйе, әнә шул, Тутаев әйтә: крестьян психологиясен үзгәртер өчен мең еллар кирәк дип лаф оручы булды заманында, ди. Ә нигә үзгәртергә крестьян психологиясен, ди. Крестьян — җир кешесе. Ул кендеге белән җиргә бәйләнгән, җирдән башка яши алмый крестьян һәм яши алмаска да тиеш, ди. Крестьян психологиясен үзгәртсәң, аның җиргә булган мәхәббәте суына, ялкаулана крестьян, ә ялкау крестьяннан рәтле эшче дә, колхозчы да чыкмый, ди.

— Ә син үзең ничек уйлыйсың?

— Минме? Мин дә шулай уйлыйм. Кошлар җылы яклардан кайткач, иң элек оя кора, аннары гына сайрый белгәне сайрау эшенә керешә, сайрый белмәгәне корткыч бөҗәкләрне кыра.

— Алай,— дип сузды Рәсим.— Аңлашыла, ә менә син инде шәхси хуҗалыгыңны карагансың. Һәрхәлдә, йорт-җиреңнән канәгатьсеңдер. Синең бердәнбер максатың, иң изге бурычың — колхозны аякка бастыру булырга иеш инде хәзер.

Хәбир майланган авызын зур учы белән каплап пырхылдарга тотынды.

— Хәят апа, хи-хи, хи-хи! Хәят апа гаҗәпләнә торгандыр инде безгә. Идарә утырышына әйләндердек чистый иртәнге ашны... Миннән генә торса иде эш, Рәсим малай, мин болай да көн чабам, төн чабам. Бригадирның эшен беләсең. Не шути, хәзерге бригадирлар элеккеге председатель дәрәҗәсендә хәзер алар. Инде конкрет әйтсәмме, минем теләктән генә торса, мин колхозчыларга акчаны әзрәк, икмәк-курмыны күбрәк бирер идем. Дүрт күз белән көтсеннәр яңа уңышны. Әйбәт уңыш үстерәсең икән, акча да була сиңа, икмәк тә... Хәзер бит нәрсә? Боз сугып китә тоташ бер басуны. Юлдан узып барган чит кеше елый, ә шул басуның хуҗасы, шул басуны сукалап, чәчкән кеше төкереп тә бирми. Дәүләт бай, ач үтермәс әле, янәсе. Дәүләт бай!.. Бер коровник

салырга уйлаганнар. Мин армиядә чакта ук корып куйганнар нигезен. Инде мин кайткач та ике ел үтте. Нигез нигез килеш ята бирә. Коровникның стенасы үсми. Аның каравы, алабута бик шәп үсә. Башта проекты дөрес түгел дип, төземи торганнар, аннары колхозның акчасы бетеп киткән. Йөк машиналары, ашлама, тагын әллә нәрсәләр алырга кирәк булган акча. Менә сиңа крестьян психологиясе...

Рәсимнең әнисе чәй яңартып китерде дә, күксел бу чыгып торган чиләкне күтәреп, өйне кабыгын әрчемичә пешерелгән бәрәңге исе белән тутырып, ишегалдына чыгып китте.

— Мисалга шул ук бәрәңгене генә алыйк. Янгырлы киләме, карлымы, көз колхозның бер генә буразна бәрәңгесе дә җир астында калмыйдырые, безнең этиләр колхозда эшләгән чакта, шулай бит. Ә хәзер кара. Сәгать җидедә чыга халык бәрәңге басуына. И унбердә әбәткә кайтып китә дә сәгать икегә чаклы әбәт ашый. Аннары, мин сиңа әйтим, берзаманны шәһәрдән ярдәм килеп төшә. Кызыл тырнаклы кызлар, озын чәчле малайлар. Бер елны, шундый ярдәмчеләр булышып киткәннән соң, бәрәңге басуын сөргәннәр иде, малай, мәктәп укучылары шул җирдән алтмыш центнер бәрәңге җыеп тапшырды колхозга. Менә монысы да крестьян психологиясе...

Менә син әчкече дип уйла кеше турында, болагай дип уйла. Төптәнрәк фикер йөртеп карасаң, шактый гына дөреслек бар лабаса бу тана колакның сүзләрендә. Хәбир тәнкыйтьли. Кимчелекләрне күрсәтә. Ләкин ул кимчелекне бетерү ысуллары турында ләм-мим бер сүз әйтми. Рәсим эченнән генә Хәбир сөйләгән сүзләр белән килешә дә кебек, әмма шул ук вакыттаниндидер әчке тавыш Хәбир китергән мисалларның һәркайсын шик астына алырга куша Рәсимгә. Бәлки, Тәслимәдәдер хикмәт? Бәлки, сукыр дошманлык, көнчелек хикмәтедер бу? Хәбир ни генә сөйләсә дә, хаклы әйтмидер, үзенең белеме белән мактанырга теләмидер кебек. Нишләп, нишләп алай икән? Юкса, шактый төпле, дәлилле, ышандырырлык итеп сөйли бит инде үзе...

Хәбир тагын нәрсә хакындадыр сөйләргә уйлаган иде, ләкин, сәгатенә карагач, ашыгып урыныннан торды, калган аракысын бөкеләп кесәсенә тыкты, Рәсимгә күз кысып алды.

— Монысын калдырмыйм. Сезнең изге йортыгызны ямьсезләп тормасын. Идарәгә төш. Иркенләбрәк сөйләшеп утырырбыз. Яңа агроном китерделәр безгә. Шәһәр кызы. Мәдинә исемле. Бәхәсләшергә ярата...

Әллә исереп китте инде Хәбир, әллә әйтәсе сүзен онытты, башлаган сүзен әйтеп бетермичә кинәт телдән калды, бүреген башта дөрес итеп кигән иде, ни өчендер аның артын алга әйләндереп куйды, каш астыннан гына Рәсимгә карады.

Рәсим, кулларын чалбар кесәләренә тыгып, аның һәр хәрәкәтен дикъкать белән күзәтеп тора иде.

Бүреген төзәтеп кигәч кенә Хәбир башлаган сүзен әйтмичә кала алмаячагын аңлагандай:

— Безгә кереп утыр, дияр идем кич белән, өйдә булмыйбыз икән, бер җиргә чәйгә дәшкәннәрне онытып та җибәргәнмен,— дип ишеккә борылды.

Тәслимә турында бер сүз дә әйтмичә чыгып китәргә җыена түгелме соң бу? Сорарга уңайсыз. Юк, ишекне ачмады әле, нәрсәдер әйтергә чамалый бугай. Менә ул Рәсимгә ян беләнрәк борылды, имән бармагы белән ишек элгечен шалтыр-шылтыр китереп алды. Өстәл янынан торганда йөзе болай кызармаган иде әле аның, ә хәзер бүрек астына семафор фонаре тыгып куйганнар диярсең. Баядан бирле нәрсәдер әйтеп маташа икән иде Хәбир, Рәсим игътибар бирмичә генә тора икән.

— ...Мин, малай. Хәят апа әйткәндер...

— Ишетмәдем.

— Өйләндем бит мин малай.

— Кит аннан? Юк, әни миңа бернәрсә дә әйтмәде.

Бүрек астындагы «стоп-сигнал» тагын да кызара төште.

— Буйдак тормышы шәһәр кешеләренә генә килешә, дип әйтә торгание минем начхоз. Авылда семьясыз яшәп булмый, малай. Беләсеңме, кемне алдым?

Рәсимнең авызы кипте, теле кургашын кисәгедәй авыраеп калды.

— Фирдәүсәнедер инде?

— Түгел, Фирдәүсә белән борчак пешмәде безнең. Завклубка, үзең беләсең бит. Ярты төнгә чаклы клубта ихахай да михахай. Ни чуртыма миңа андый кәләш? Тәслимәгә өйләндем.

— Кайсы Тәслимәгә?

Рәсим таш кебек катты. Бу минутта диңгез мәктәбе бик нык ярдәм итте бугай аңа. Аның йөзендәге бер генә мускул да кыймылдамады. Күзләре дөньяда барган вакыйгаларга битараф рәвештә кысылганнар да ваемсыз гына ялтырыйлар.

Хәбир мондый ук ваемсызлыкны көтмәгән иде, ахры. Ишек төбендә байтак кына өнсез-тавышсыз торганнан соң гына телгә килде.

— Ничек инде кайсы Тәслимә? Борһан кызы.

— Ә-ә! Әйе бит әле. Борһан абыйның кызлары икәү бугай. Кайсысы Тәслимә иде әле аның?

— Әй,— дип җиңеләеп, рәхәтләнеп хихылдап алды Хәбир.— Артистланырга элек тә маһирыең. Хәзер дә ташламагансың икән шул һөнәреңне. Тәслимәне белмәскә син. Читкә киткәндә күзең төшеп йөргән Тәслимә инде. Кечесе Гөлфирә ич аның. Анысы да үсеп җитте, малай. Тәслимәдән дә чибәр. Теләсәң, таныштырам, баҗайлар булырбыз! Ха-ха...

Рәсимнең кулы җитәрлек урында гына артык урындык тора. Сузылып кына аласы, сузылып кына! Ә монда кешелеклелек, мораль, әхлак... Эшләгән эшең өчен кешеләр каршында гына түгел, үзеңнең намусың каршында җавап бирү кебек четрекле мәсьәләләр бар. Анысы дөрес: кеше — горур яңгырый. Әмма нинди кыен кайчагында кеше булып калулары.

Хәбир ишекне каты гына ябып чыгып китте. Бераздан аның ишегалдында Хәят апа белән кычкырып-кычкырып нәрсә турындадыр сөйләшкәне ишетелде.

## Сигезенче бүлек

Рәсим нәрсә уйлап утыра, дисезме? Уйлары менә болайрак аның. Миңа егерме ике яшь. Өйләнмәгән. Сөйгән кызым юк. Нишләргә тиеш инде хәзер Рәсим? Җиң сызганып эшләргә тиеш, әлбәттә. Яңа йорт салырга, өйләнергә, бала-чага үрчетергә, нәсел калдырырга, шулаймы? Шулай. Бабаларыбыз да, без дә шулай яшәргә тиеш, безнең балаларыбыз, оныкларыбыз да. Шулай, нәкъ шулай. Кешеләр климатка гына түгел, тормышка да җайлашырга тиешләр. Кешеләр тормышка гына түгел, бер-берсенә җайлашырга тиешләр. Бер-берсенә генә түгел, үз-үзләренә җайлашырга, ягъни йөрәге дулаган чагында аны тыя белергә, елыйсы килгән чагында көлә белергә, җаны әрнегән чагында аны юата белергә тиеш кешеләр.

Менә Рәсимнең авылга кайтканына да өченче тәүлек китте. Әле аның урамга аяк басканы юк. Так себя йөри шунда ишегалды тирәсендә, иртән торып гимнастика ясый, кар белән юына, кәҗә-сарыкларны ашата, эчертә. Болай да тап-тар амбарларны себереп чыгара, абзар чистарта, өйгә утын кертә. Әнисе: «Ял ит әле, улым, рәхәтләнеп, эшләргә өлгерерсең»,— дип тә әйтеп карый. Рәсим тик ятамы соң инде

энисе эшләп йөргәндә. Олы чиләкләр асып суга киткәндә дә кызганып кала әле ул аны. Бераз иләшсен дә менә авылга, үзе барачак Рәсим суга, энисен йөртмәячәк.

Диванда физика, алгебра, тригонометрия дәреслекләре чәчелеп ята. Өстәл өстендә дәфтәрләр, авторучкалар. Укырга тиеш Рәсим. Урта мәктәпнең программасын бер яки ике елда ерып чыгып, имтиханнарны экстерн гына тапшырырга тиеш. Чит телгә генә теш үтеп бетми, немец теле укытучысы Мәсәлия ападан ярдәм сорарга туры килер. Физика мәсьәләләрен, математиканы флотта су урынына эчә торган иде Рәсим. Онытмаган икән. Нәтиҗәләр һәрвакыт диярлек дәреслекләрдәге җаваплар белән тәңгәл килә. Төгәлсезлекләр дә булгалый, әлбәттә. Ноль бөтен меңнән өч урынына, мәсәлән, кайчакта ноль бөтен меңнән бер яки ике килеп чыга. Логарифм линейкасы юк шул Рәсимнең. Барысын да яттан исәплисе, күңелдән чишәсе.

Рәсим кайтканнан бирле Хәят апаның самавыры җырлаудан туктамый. Мичтә әледән-әле коймак чыжлый, кичен бөтен өйгә тәмле булып бәлеш исе тарала. Каз ите исе чыга.

Рәсим үзе урамга чыкмаса да, күрше-аршылар, таныш-белешләр кергәли. Мөнәвәрә апа килеп хәл белеп, чәй эчеп китте. Ә хәзер ул авыл Советында секретарь икән. Артык картаймаган. Маңгаендагы бер тотам ак чәчен санамасаң, түм-түгәрәк йөзле шул ук Мөнәвәрә апа.

— Әбәү, күз тимәсен, нинди дәү егет булгансың, энем. Бергә эшләгән чаклар бар ие, мин әйтәм,— дип Рәсимнең аркасыннан шапылдатып сөйде ул. Сүз арасында үз кайгысын да сөйләп алды.— Утырып эшли алмыйм мин, Хәят апа, эчем поша. Бригадир булып йөргән чакларымны сагынам. Басуларга чыгып китәр идем иртүк торып. Тургай сайрап каршы алыр иде үземне. Арышлар юлның ике ягыннан, башларын иеп, безне онытма, назга сусадык, иркәләп, сыйпап үтсәнә, дип торырлар иде.

— Эшләргә кирәк ие әле, Мөнәвәрә, үз эшеңдә, сәламәтлегең бар, син бит әле үз көчеңдәге кеше.

— Әй, Хәят апа, көчтә мени хикмәт? Басулар зур хәзер, яңа культуралар игәбез, перспективалы кадр кирәк, диделәр.

Рәсимнәрнең сул як күршеләре Мәчтүрә апа да озак кына утырып чыгып китте. Рәсимнәрнең үсмер вакытын, Хәбир белән бергәләп урамда гармун уйнап, җырлап йөргән чакларын искә төшерде.

Өченче көнне иртәнге чәйне эчкән генә иделәр, иртүк Галимулла абыйның мәктәптә укый торган малае килеп керде. Мунчага чакырырга килгән.

— Нихәл, Рәсим абый, исән-сау гына хезмәт итеп кайттыңмы?— дип олыларча ике куллап бөтен тәртибен туры китереп исәнләште. Яңадан ишек төбенә барып, култыгына кыстырган бүреген башына киеп куйгач кына, Хәят апаның: «Чәй эчеп алыр идең, Камил энем»,— дип өтәләнеп йөрүенә бөртек тә игътибар бирмичә, бер сулыш белән йомышын әйтеп ташлады.

— Әти чакырды сине, Рәсим абый. Алты яшьлек юлдан кайтса, алтмыш яшьлек хәл белергә килер, дип өметләнеп ятмасын, үзен көтәм мин аның, берәттән мунча да кереп китәр, озакламасын, юкса, минем характерны белә ул, диде...

Тагын берничә көн өй арасында гына йөрергә иде әле Рәсимнең исәбе. Булмас, өйдә утыртмаслар, ахры.

Урамга чыгудан курыкмый ла анысы Рәсим. Тик менә Тәслимә генә очрамасын. Югын юк, беткән инде Рәсим өчен Тәслимә. Яшьлек дигән яшел тугайда Тәслимә дигән матур чәчәк юк хәзер. Аны өзгәннәр, Рәсимне көтеп тормаганнар. Яшьлек дигән яшел тугай буенча Тәслимәне эзләп бармый хәзер Рәсим. Болай гына, бер максатсыз, так себ

бара. Күрәсе килми Рәсимнең Тәслимәне. Дөресрәге, курка ул аның белән очрашудан.

Нәрсә? Рәсим куркамы? Куркыр Рәсим, куркытырсың аны!

Әнә бит, киенеп тә куйды ул. Бушлат төймәләре ялтырый, ботинкалары көзге кебек. Пычак та пычак, чалбар сыры да пычак! Якын килмә — кулыңны кисәрсең. Бескозырка тасмалары, алтын якорьларын ялтыратып, җилсез дә җилфердәргә тора. Менә хәзер, хәзер мичманның көчле, кырыс тавышы яңгырар сыман:

— Становись! Равнение направо! Смирно! Дулкыннан катер дер селкенә, ә алар, тимер палубага ябышып үскән кебек, иңнәрен-иңгә терәп басканнар да приказ көтәләр.

Әллә медален дә тагып җибәрсен микән Рәсим? Кирәкмәгәнне, авыл халкы кыланып йөргәнне яратмый.

— Бигрәк юка инде өс-башың, улым. Акча барында кием-салым юнәтеп калырга тырыш инде.

— Туңмыйм мин, әни,— диде Рәсим, моңсу гына елмаеп.— Кыш көне кияргә туным бар, итек бастырып куйгансың, бүрегем әле өр-яңа. Тагын ни кирәк миңа?..

Рәсим, урамга чыккач, тегендә-монда күз салмыйча, туп-туры түбән очка төшеп китте. Аркаларына букча аскан бала-чага шау-гөр килеп узды аның янынннан. Рәсим үтеп киткәч, балалар тынды. Борылып карамаса да сизде Рәсим, сокланып, кызыгып, көнләшеп карап калдылар балалар аның артыннан. Шәмсиләр коесына суга баручы ике хатын да, сукмак уртасында шып туктап, кулларын каш өстенә куеп карый-карый озаттылар Рәсимне. Урам уртасын дөбер-шатыр китереп, чана таккан трактор узып китте. Тракторчысы кем булгандыр, әмма чанадагы кызларның берсен Гөлнурга охшатты Рәсим.

Клуб яныннан борылып узган юл медпункт яныннан да үтә. Уйлап-уйлап барды да, дөпелдәп типкән йөрәген тынычландырырга тырышып, борын астыннан гына:

— А моряки об этом не грустят... А моряки об этом не грустят,— дип кабатлый-кабатлый кибет тыкрыгына борылды егет.

Кибет тыкрыгында Рәсимгә Нури Гайфулласы очрады. Нури Гайфулласы үзе пароход мачтасы кебек озын, хатыны Язилә бик бәләкәй булып, Язилә апа турында халык, кучкардан шырпы алырга урындык куеп менә икән, дип сөйлиләр иде. Гайфулла абый бервакытны Кәвәл базарыннан кызмача кайтып кергән дә каршы алырга чыккан хатынына, алай каршы алмыйлар ирне, биттән үбеп каршы алалар, дип бәйләнә башлаган. «Ничек үбим соң, Гайфуллам, буем җитми ич»,— дигән тегесе уены-чыны белән. Озак уйлап тормаган Гайфулла, утын яра торган бүкәнне тәгәрәтеп китергән дә хатынын бүкән өстенә менгереп бастырган. Нишләсен, шартлар тудырылгач, ире кушканны үтәргә туры килгән Язилә апага.

Бүген дә кызмача бугай әле Гайфулла. Элек лесхозда эшли иде, бслай көпә-көндез чайкалып йөргәч, хәзер дә шунда эшли торгандыр.

Олы галош кидерелгән завод итеген чаңгы кебек шудырып килде-килде дә Гайфулла тайгак сукмак өстеннән юл сабарга ниятләгән Рәсимне озын куллары белән кочаклап алды.

— Син ич, Рәсим наныем? Танымый торам. Нихәл, исән-сау кайттыңмы? Ай-яй, адмирал килә, дип торам, елки-маталки. Килешә дә суң үзеңә флотский форма. Ай-яй!

— Отпускыга гына кайттыңмы, наныем, бетерепме?

— Бетереп, бетереп, Гайфулла абый,— диде Рәсим сукмакка сыеша алмыйча торган галошларны урап узарга ымсынып.— Ачуланма инде, Гайфулла абый, ашыгадырыем.

— Кайчан кайттың суң әле, наныем? Бүгенме, кичәме?

— Өченче көн төнлә, Гайфулла абый.

— Суң нишләп күренмәдең моңарчы кибет янында? Әллә жаның юкмы синең? Әллә кайтканыңа сөенмисеңме? Отмичать итмичә ярамый мондый вакыйганы, шту син, Рәсим наныем.

— Ярар, ярар, Гайфулла абый, очрашырбыз әле, сөйләшербез.

— Суң, сөйләшербез, дип, йомышы шул инде аның, Рәсим наныем. Кибет яныннан озатабыз хәзер кешеләрне, кибет янында каршы алабыз. Авылда рестораннар юк бит, үзең беләсең. Кибет ачылгач ук кил, без шунда булабыз...

Гайфулла галошларында шуа-шуа урта урамга төшеп китте. Рәсим исә, без дигәне кемнәр икән инде моның, дип баш вата-вата кибет тыкрыгыннан атлады.

Югары урам башка урамнарга караганда киңрәк тә, җиллерәк тә. Кыр ягыннан вакыты-вакыты белән җәяүле буран килеп керә. Килеп керә дә, урам уртасыннан узарга базмагандай, койма буйларына сырыша, капка асларында бөтерелеп тора, өй кыекларына менеп, бии, морҗа төтеннәрендә ак итәкләрен җилфердәтә.

Ничә еллар председатель булып эшләде, әллә ниләр кораштырып калдыра алмаган икән Галимулла абыйсы да. Капкасын ачкач ук Рәсимнең күзенә иске лапас чалынды. Лапас алдында Рәсимнәрнеке кебек үк чыбык утын турап өелгән. Лапасның бер ягында верстак тора, верстак өстендә ышкы, балта кебек эш коралы күренә. Лапас янындагы аралыкта мүкләк сыер күшәп тора.

Рәсим болдыр ягына килеп җитәрәк, чолан ишеге ачылып китте, Галимулла абыйның тап-такыр итеп кырылган башы ялтырап күренде.

— Я, кайттыңмы, герой! — дип бик үк нечкәреп китмичә, шулай да сизелерлек дәрәҗәдә гасабиланып күреште ул Рәсим белән. Өстендә элек кигән уңган гимнастерка иде аның. Ләкин ул элек ничектер килешеп, сыланып тора иде Галимулла абыйга. Хәзер ябык ат сыртына салынган иске ыңгырчак кебек шәлперәеп калган.— Инде мин синең турыңда, кайтмаска китте, ахры, бу, понимаешь, дип уйлый башлаган идем. Үскәнсең, тазаргансың, молодец. Ә менә без картаябыз.

— Картаймыйсың әле, Галимулла абый,— дип сөйләнде Рәсим, караңгы чоланнан узганда,— һаман да егетләр кебек әле син...

— Шулай дип юат инде.

Өйгә керделәр. Ак оекбашлы аякларын буяулы идән буенча күтәрер-күтәрмәс кенә хәрәкәтләндереп, Мәслихә түти дә килеп җитте. Мәслихә түтинең кулы Рәсим әнисенеке кебек түгел, бик йомшак һәм нәфис иде. «Ни әйтсәң дә, ирле кеше шул, нужа күреп яшәми, ирләр эшен эшләп»,— дип уйлап куйды Рәсим күрешкәндә...

Рәсим, әле генә чәйләп чыктым, дип кыстатып маташты, ләкин аны көчләп диярлек өстәл янына китереп утырттылар. Телемләп тураган каз ите дә, майлы сарык ите дә, тозлаган яшелчәләр, каклаган казылык та бар иде табында. Рәсим, бу тамашаны күргәч, әйтми түзмәде:

— Хәбир күрше белән сөйләшеп утырдык кичәгенәк. Зарлана, колхозның хәле әйбәт түгел, ди. Дәүләткә фәлән хәтле бурыч түлисебез бар, ди. Шуңа аптырыйм мин менә: колхоз ярлы, ә колхозчылар мул яши. Кемнең генә өенә барып керсәң дә өстәл тулы нигъмәт, өс-башлары да начар түгел, әле монда килгәндә түбән урамда да, сезнең урамда да байтак кына яңа йортлар күземә чалынды.

Галимулла абый шкафның буфет кебек җиреннән рюмкалар алып куйды, Мәслихә түти чоланнан «ярты» күтәреп керде.

— Кара,— дип тимер тешләрен күрсәтеп кеткелди Галимулла абый,— өстәл янында кемнәр утырганын сизде «шешәң», тирләп чыкты... Салкын бугай әле, сиңайтәм, җылы суга тыгып торасыңмы әллә?— Аннан Галимулла абый җәһәт кенә кулын селкеп алды.— Болай да батар, азрак кайнар су өстәрбез...

— Нәрсә, Галимулла абый, монсыз гына сөйләшеп булмас, дисеңмени?

— Сөйләшеп була да соң... Йоласы шул бит аның. Мин дә дус түгел бу нәмәрсә белән. Врачлар да кушмый. Картаям да бит андин ары. Ә синең кайту хөрмәтенә күтәрәм, ике дә уйлап тормыйм... Я, әйдә, тот!

— Мин эчмим бит, Галимулла абый, кыстама.

Галимулланың сирәкләнгән кашлары югары сикерде, яшькелт соры күзләре төссезләнеп китте.

— Бөтенләйме? Бер дә эчмисеңме?

— Бер дә эчмим.

— И эчкәнең дә юкмы?

— Эчкәнем дә юк?

— Бер дәме?

— Бер дә.

— Мәслихә! Мәслихә!

— Нәрсә бар, атасы, нигә чакырасың?

— Чык әле монда, сиңайтәм, бер әйбер күрсәтәм.

Кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә кече яктан Мәслихә түти чыгып житте.

— Ни булды тагын? Башыңа киттеме, әллә житеп житмәдеме?

— Мәслихә, карале син моңа!— дип, тәмәке төтененә ысланган бармагын Рәсимнең күкрәгенә үк терәп куйды Галимулла абый.— Карале син моңа!

— Әй, карт тиле, бераз эчеп алдымы, котыра башлый. Я карадым, ди.

— Беләсеңме бу кем? Бу — фәрештә. Бу изге кеше. Күктән төшкән бу. Вә-әйт, сиңа әйтәм, дүрт ел читтә йөреп кайткан кеше бер рюмка аракы эчми. Дөрес түгел бу, ышанмыйм мин моңа... Ә-ә, теге чакта авырыйм дип котымны алган идең, әллә һаман да шуның зәхмәтеме?

— Нинди зәхмәт булсын? — дип Галимулла абыйның бармагын читкә этәрде Рәсим.— Күрәсең ич, флотта хезмәт итеп кайттым. Авыру кешеләрне флотка алалар, димени?

— Анысы да дөрес, кичер мине, карт юләрне. Шулай да шаккатырдың бит әле син мине. Шундый бер мәзәк бар. Имештер, берәү әйтә икән иптәшенә: «Вәт, фәлән кешенең малае башлы дисәң дә башлы, кемгә охшап шул кадәр башлы булгандыр ул? Әтисе дә алай башлы түгел, нәсел-нәсәбе дә»,— ди икән. Иптәше сораган моннан: «Нишли соң ул шул кадәр башлы булып?»— дигән. «Соң, бүген иртән йөз грамм аракы салып биргән идем, эчмәде тәки, профессорның да башы житмәс шулай эшләргә»,— дип җавап биргән теге. Шуның шикелле, синдә дә баш бар икән, ай-яй! Әллә тартмыйсыңдамы?

— Юк шул.

— Менә монысы начар. Аракыны эчмәсәк тә, болдыр алдына чыгып икәүләп бер пошкыткан булыр идек.

Галимулла абый кеткелдәп көлә-көлә Рәсимнең иңбашына сугып алды.

— Ничә мәртәбә ташларга тырышып карадым шул мәлгуньне, булмый, көч житми. Сырлан белән бер, һич кенә дә арыныр хәл юк, бәдбәхеттән. Укырга уйлыйсыңмы, эшләргәме?

— Белмим әле, Галимулла абый. Читтән торып яисә үзлегемнән укып имтихан бирсәм генә инде. Әни ялгыз бит, әле дә күп йөрелде, әллә кая китеп йөреп булмас хәзер.

— Укырга кайчан да соң түгел, ниятеңдә булса, укырсың анысы, и укырга кирәк тә, укымыйча булмый бу заманда... Әле бая әйткән сүзләрең истән чыкмый. Ничек дидең әле син? Ни өчен колхоз ярлы, кол-

хозчы бай, диден. Шулай бит? Тач шулай ук булмаса да, шул мәгънәдәрәк әйтелде. Колхоз беркайчан да ярлы булмаячак хәзер. Ни өчен ме? Ә менә ни өчен. Шәһәргә баруы кыенмы хәзер? Кыен түгел. Шәһәрдә ипи бармы? Җитәрлек. Ипие булгач, авыл кешесенә ни кирәк тагын. Сөткә-майга аптырамый ул, сыер асрый. Итен сатып алмый. Күбесе үзләре сата. Шулар өстенә үрдәген асрый, казын, күркәсен.

— Соң, Галимулла абый, мал асрагач, аларны ашатырга да кирәк ләбаса.

— Ашатырга юк дип кемнең дә булса сыерын сатканын янсә кошкортын бетергәнен күргәнең, ишеткәнең бармы синең, понимаешь? Кайчан, кайсы авылда булганы бар андый хәлнең? Кайсы да булса колхозчының ашатырга җитмичә сыеры яки сарыгы егылып үлгәнен ишеткәнең бармы? Юк, ишеткәнең юк. Үзе ач торса тора, авыл кешеләре, әмма хайванын, күзенә мөлдерәп карап торган малкаен ачка гарыктырмый. Ә колхозда узган ел унҗиде сыер үлде. Я җитәр, җитәр, сөйләсәң — сүз чыга, төртсәң — күз чыга, ди, сүз белән бозау имезеп утырмыйк әле. Мунча өлгергән, Мәслихә түтиенә бөтнекле себеркә пешерергә кушкан идем... Бер дә ашыкмыйча иркенләп чабын. Мунча кереп чыккач, бераз нәфесең дә төшеп куяр, шәт,— Галимулла абый нәрсә булганын, нинди табынга эләккәнен төшенә алмыйча, өстәл өстендә аптырап утырган шешәгә ымлады.

— Юк инде, Галимулла абый, рәхмәт. Шайтанның фәрештәгә юлдаш булганын кайчан күргәнең бар?

Галимулла абый авызын ера-ера:

— Баш та бар икән үзеңдә,— дип кабатлады.

Галимулла абый Рәсимгә колхоз хәлләрен бәян итте, ә Рәсим үз чиратында йөргән җирләре, армия, флот, диңгез хәлләре турында сөйләде.

Рәсим аягүрә басты, иңенә Мәслихә түти күтәреп биргән кайры тунны салды, азрак уйланып торды да Галимулла абыйның бармак очларында биеп йөргән чынаягына карап сүз катты:

— Сыерлар үлде диден инде алайса, Галимулла абый. Син председатель чагында алай түгел иде бит, Галимулла абый?

— Ничек — түгел иде? Булды инде, Рәсим туган.— Галимулла абый бүген беренче мәртәбә Рәсимгә туган дип эндәште. Димәк, тиң итеп сөйләшә ул Рәсим белән.— Бездә дә булды. Бер елны унсигез бәрәнне бүре буып китте. Заоферма белән елмамадык кына. Иртүк уполномоченный килеп житте, дилбегә буе акт төзеде. Бәйләнәләр генә бит, понимаешь. Кайда бүре, күрмим мин бүрене, табып китерегез бүрене, ди. Бәрәннәрнең чәйнәлгән бугазларын күрсәтәбез. Бәлки үзегез чәйнәгәнсездер аларның бугазларын, дип ялтырата да тора күзләрен. Райкомнарга барып, бюроларда тикшерелеп көчкә котылдык...— Чынаягын каплап куйган Галимулла абый да аяк өстенә торды, бармак очлары белән өстәл өстендәге ипи валчыкларын чүпләп авызына капты.— Хәзер киләсе ел өчен генә кайгыртырга кушмыйлар бит. Перспектив планның нәрсә икәнен беләсеңдер инде син. Әнә шул перспективалы план буенча, Кодрәт болынын сукалап кукуруз чәчкәннәр иде өченче ел, тишелмәде, былтыр күпьеллык үлән чәчтеләр — тәмәке төпчеге кадәр калыкты да катып калды. Су кирәк икән баксаң күпьеллык үләнгә. Ел коры килсә, су сипмичә үсми икән ул, акыллырак житәкчеләр башта сугару җайланмасын алып куялар икән басуларына, понимаешь. Бар инде син, бер рәхәтләнеп чабынып чык. Сиңа әйтәм, сабыр-мунчала шундадыр ич?

— Шунда, шунда, әйдә, барсын... Бар инде, бар, Рәсим улым,— дип тавыш бирде Мәслихә түти кече яктан.— Камиле кая чыгып киткәндер тагын. Камил кайтса, арканны юып чыгар, җибәрермен.

— Кирәкми, кирәкми, Мәслихә түти, зинһар, мәшәкатьләнмәгез,— диде Рәсим, күкрәгенең йонлы турысын учы белән кысып,— без өйрәнгән инде.

Галимулла абый бүлдерде.

— Өйләнгәч кенә өйрәнәләр аны, Рәсим туган. Өйләнмәс борын борын күтәреп сөйләшмә әле син алай. Колхозларга да житәкче постларга соңгы елларда менә синең шикелле, без өйрәнгән инде,— дип сөйләшә торган яшь әтәчләр килде. Бар арада иple генә эшләп киткәннәре и тел тегермәннәрен тартудан узмаганнары да күренгәли. Телисеңме, ачуланмасаң, мин нәрсә әйтер идем, Рәсим туган. Тормышны белмисез, тормышны...

Өлкәннәр, бигрәк тә Галимулла абый шикелле житәкче постларда эшләп киткән кешеләр яшьләрне тәнкыйтьләргә яраталар. Бу кадәресен Рәсим белә иде, әлбәттә. Шуңа күрә бу очракта дәшмичә калуын әйбәтрәк булыр, дип фикер йөртте Рәсим. Ә ишек төбенә житәрәк, артына борылып, гарьлекләреннән ташып түгелергә житешкән рюмкаларга ымлап алды.

— Яшь әтәчләрне әнә тегенең белән күбрәк сыйламыйбыз микән, Галимулла абый? Шуның белән яшьтән үк тавышлары бозылмый микән?

— Дөрес әйтәсең Рәсимулла, бик дөрес әйтәсең... Узган сугыш безгә бик яман чир йоктырды. Үзебез генә авырсак бер хәер иде, гөнаһ шомлыгына каршы, балаларыбызга да йоктырдык бит яман чирне. Инде оныкларыбызны саклап каласы иде бу афәттән... Аннары аракы-зәхмәтен гасырлар буе эчеп җайлашкан халыклар бар. Мичкәсенә төшеп ятса да, аларга чорт та булмый. Ә безнең халык нәрсә, бөтен гомере буе чәй эчеп өйрәнгән халык. Йөзә белмәгән килеш дәрья уртасына илтеп ташласыннар әле сине, нишләрсең икән...

Диңгез портларындагы сәламәтлек комбинатларында, фин мунчаларында, пары тәнне кымырҗытып, мускулларны кытыклап, бертуктаусыз хәрәкәт итеп, сәгать угы уңаена җай гына әйләнеп, циркуляция ясап торган эксперименталь мунчаларда юынганы бар Рәсимнең. Алар әйбәт, сүз юк. Әмма Рәсим үзләренең авыл мунчасын сагынган бит әле.

Хәрби диңгез флоты корабларында гына була торгандыр мондый да чисталык, пөхтәлек! Чолан аулларына кадәр гәрәбә шикелле ялтырап тора. Утыргычларда йомшак җәймәләр. Эчсәң, теленне камаштырырлык салкын суы да шунда гына тора. Өсте ябылган, чүмече каплап куелган. Мунча ишеген ачып җибәрсәң, идәнгә басарга кыенсынып торасың. Чөйдә эленеп торган мунчалалар, элгечтәге кызыл башлы сөлге акрын гына җылы һавада тирбәлеп тора. Бөтнек исе, юкә, матрүшкә чәчәге, карлыган яфрагы исләре башларны әйләндерә, зиһенне чуалта.

Җылы салып җибәргәч, түшәмнәр күтәрелеп киткәндәй була. Тәндәге бөтен күзәнәккә, чәч төпләренә, керфек, каш араларына чемер-чемер килеп пар дулкынчыклары тула. Ул дулкыннар әле салмак кына агалар, кан тамырларына кадәр үтеп керә алмыйлар әле алар. Менә акрын гына каен җиле исә башлый, борыннарны ярып, сулыш юлларына пешкән яфрак исе бәреп керә. Пар инде синең кан тамырларыңны да чемердәтә. Каен җиле кискенли, эссе яфрак очлары инде тәнеңә орынып киткәли. Күзәнәкләргә сыеша алмаган пар мускуллардан тышка ыргыла. Ләкин дымлы яфраклар инде күзәнәкләрнең авызын ябып куйганнар. Пар кан тамырына үтеп керә. Кан тәнчекләрен урле-кырлы сикертә, тегендә чаба, монда йөгерә. Ахырда шашар дәрәҗәсе житеп ярсыган кан йөрәк клапаннарына барып бәрелә. Шул вакыт чабынучы шаукымына бирелгән кешеләрнең хәлләре китә, йөрәкләре кага башлый. Алар бүрекләрен, бияләйләрен салып ыргыталар да ләүкәдән төшәләр. Көч-хәл белән ишек ачып салкын карга чумалар яисә өсләренә бер чи-

ләк салкын су коялар. Пар молекулалары суына, кан тәнчекләре чистарып, сафланып кала, йөрәк яңа көч белән дәртләнебрәк эшли башлый.

Менә нинди мунча бар Рәсимнәр авылында!

Кар әле чыгып чумарлык ук түгел иде. Шуңа күрә Рәсим тәне күкрәгендәге җөе белән бер төскә кергәнче чабынды-чабынды да өстенә шатырдатып салкын су койды...

## Тугызынчы бүлек

Рәсим клубка барып кергәч шаккатты: ул киткәндә тездән ләпеккә батып ялан тәпи йөри торган малайлар, кызлар тәмам буйга җиткәннәр. Буйга хәтта Рәсимнән узып киткән егетләр бар. Рәсим клубка кереп киткәндә шундыйларның берничәсе болдырда тәмәке тартып калды. Сөйләшүләре дә үзгә, ирләрчә, калын тавыш белән сөйләшәләр, яшь механизаторлардыр, күбрәк телләрендә «скорость», «ДТ», «генератор» кебек колакны яра торган сүзләр генә. Кая киткән «камыш», «дилбегә», «йөгән», «тай» шикелле җанны иркәли торган сүзләр?

Эскәмияләрне сәхнәгә дыңгычлап тутырганнар. Читләре арыш башаклары белән бизәлгән кызыл такта эленеп тора. Аңа нәзек ак хәрефләр белән: «Хезмәткә — намуслы караш!» дип язылган. Зал шыпшыр, сап-салкын. Ишек төбендәрәк балык тозлый торган мичкә тора. Стенада пломбасыз янгын сүндергеч.

Бакча ягындагы олы тәрәзә төбендә — кечкенә чагында Рәсимнәр ул тәрәзәдән качып-посып кино карыйлар иде,— башына солдат бүреге чәпәп куйган агай тәмәке тартып утыра. Рәсим аны йөткерүеннән таныды: Печтер Имамы. Бернигә дә шаккатмый торган адәм. Элек колхозның яшелчә бакчасын каравыллый торган иде ул. Гомумән, бу як кешесе түгел ул. Әлмәлегә мари ягыннан килеп урнашкан. Балачагасы юк. Карчыгы да үзе шикелле. Өенә кайткач, бәрәңге бакчаларына чыга да тәмам караңгы төшеп күз бәйләнгәнче ялгыз шомырт төбендә көрсенгәләп утыра. Кеше белән аралашмыйлар, үзара да ачылып китеп гәпләшеп утырганнарын күргән кеше юк аларның. Мәхәббәт турында уйлый башласа, Рәсимнең күңеленә ни өчендер нәкъ менә Печтер Имамы һәм аның карчыгы Гайшәбикә әби килә торган иде. Аларның да яшьлекләре, мәхәббәтләре булгандыр бит инде. И-и дөнья!..

Кеше белән сөйләшергә яратмаса да, бер туйдан соң кемгәдер: «Минем болай йөрүемә әти белән әни генә гаепле, тәгәри-тәгәри янсыннар тәмугта»,— дип әйткән, ди, имеш, Печтер Имамы! Шуннан башка ләммим. Ни өчен шул кадәр рәнҗегән ул әтисе белән әнисенә, нинди төзәлмәс җәрәхәт ясаганнар ата белән ана балалары күңеленә, анысын, кем әйтмешли, бер ходай да Имам ага үзе генә белә.

Печтер Имамы янынннан күренмичә үтеп китәргә яхшысынмады Рәсим.

— Исән-сау гына яшәп ятасыңмы, Имам абый?— диде ул күршесенә кулын сузып.

Имам кулындагы тәмәкесен суыра, җыерылган йөзен төтен болыты артына яшергәч кенә кулын бирде. Аның каты кулы бозда яткан бәрәңге кебек салкын, кытыршы иде.

— Армиядән кайттым бит, Имам абый.

— Армиядән?

— Үзегез ничек яшисез соң, Имам абый? Гайшәбикә абыстай исәнсаумы?

— Исән-сау.

— Хуш, Имам абый, эчкә керим әле мин, яшьләр янына.

— Ярый.

Төтен дулкыннары арасыннан җыерчыклы йөз болганып чыкты, Печтер Имамы нурсыз күзләрен Рәсимгә түгел, ишек өстендәге билгесез ноктага төбәгән иде.

Аның каравы клуб эчендәгеләр шау-гөр килеп каршы алдылар Рәсимне. Шахмат уйнау онытылды, доминочылар да кулларындагы шакмакларын өстәлгә ташладылар. Почмактагы олы баян өстенә башын салып утырган бөдрә чәчле малай гына, аны-моны сизмичә, шалтыравык төймәләрне җан-фәрманга кыйный-кыйный «Умырзая» көен шыңшытып маташты.

— О-о, моряк кайткан!

— Югалган кеше...

— Исән-сау гына кайттыңмы, Рәсим энем?

— Олы юлда талап китсәң дә танырлык түгел.

— Казна ипие килешкән кешегә.

— Иртә белән Галимулла абыйлар капкасыннан бер ят кеше кереп киткәнне лә аны, син булгансың икән.

— Бөтенләйгәдер ич, Рәсим?

— Безнең авылдан моряк югые бугай әле.

— Ник булмасын? Мирзанур суң, Мирзанур.

— Мирзанур кайтканга егерме ел инде. Диңгезнең ни төсле булуын да оныткандыр.

— Ә Хәбир?

— Хәбир ярда гына служит иткән ич ул.

Рәсим сорауларның кайсысына башта, кайсысына ахырда җавап бирергә дә белми торды. Хәер, аны уратып алган шат чырайлы егетләр, кызлар, танышлар, таныш түгелләр аңардан җавап көтмиләр дә иде бугай. Иң кызыксындырганы — Рәсимнең кайтуы, аның клубка чыгып күренүе иде.

Күрешергә сузылган кулларның күбесендә алтын балдаклар, ике куллап күрешүчеләрдә алтын йөгертелгән ялтыравыклы сәгатьләр дә күренгәләп китә. Рәсим авылда чагында болар юк иде әле. Кичә Хәбирнең тел төбеннән: «Колхозчыны акча белән азындырмаска кирәк,—дигән шикеллерәк фикер аңлашылып калган иде. Нигә, әллә колхозчының алтын балдак киясе, алтын сәгать тагасы килмиме? Алтын кыйммәт хәзер. Кибеткә күкәй тапшырып кына алтын балдак алып булмый.

Иң соңгы сорауны бөдрә чәчле гармунчы малай бирде. Ул уйнаудан туктаган, әмма гармунын тезеннән төшермәгән, идән уртасындагы ыгы-зыгыны, курчак театры курчагы сыман, баян артыннан башын гына калкытып күзәтә иде.

— Рәсим абый, карале, Рәсим абый, диңгез Тигәли күле хәтле ике бармы?

Барысы да дәррәү көлеп җибәрделәр.

— Аптырама, Рәсим абый,— диде көлеп арыгач, шахматчы малайларның өлкәнрәге.— Ул Ибрай география дәресендә дә җыр чыгарып утыра, диңгез ни дә ана, елга ни, ике чабата — бер кием.

Бөдрә чәчле малай, Рәсим абыйсының җавабын көтеп тормыйча, шахматчы малайны әйләндереп салды:

— Кеше мыскыл итеп утырмасана, чучка бәбәк. Диктант дәфтәреңнән койрыклы «бишле»ләреңне сана башта.

Шуның белән күрешү тантанасы тәмамланды. Рәсим Элмәле клубының законлы әгъзасына әверелде. Игътибар үзәге баянчы малай белән шахматчы малайга күчте.

Фирдәүсә, Рәсим үзе керсен, дип, юри чыкмыйча утырган, ахры, китапханә ягында. Югыйсә, ишеткәндер инде, ишетмичә калмагандыр — ике арада төрле плакатлар ябыштырылган такта стена гына бит. Рәсим, керергә ярыймы, дип ишекне ачып җибәргәч, бик гаҗәпләнгән булды.

— Әнекәчем, әллә күземә күренәсеңме, Рәсим түгелме соң?— дип урыныннан сикереп торды да, өстәл өстендәге китаплар өемен идәнгә ишеп төшереп, ишек төбенә атылып килде, Рәсимнең муенына сарылды, хушбуй исе аңкып торган шома чәчләрен Рәсимнең иягенә терәп, тынып торды.

— Егетләр кайта хезмәт иткәч...

Җырның азагын Рәсим белә иде, шуңа күрә Фирдәүсәнең кызарып чыккан күз кабакларын сөртеп алуын көтеп торды да, үзе сүзгә кереште.

— Күрешергә дә чыкмыйлар, понимаешь, син монда җәһәннәм читеннән җиде диңгез кичеп кайтасың.— Бу «понимаешь» Галимҗан абыйсыннан йогып калган, ахры, Рәсимгә. Югыйсә, понимаешьсыз сөйләшә торган иде флотта.

— Әй, Рәсим,— диде дә Фирдәүсә артына әйләнеп карады. Анда, китап күче артына башын яшереп, пальто якасының күперен, елкылдап торуы беләнме, йөзенең дә, күзләренең дә түм-түгәрәк булуы беләнме, бохар күгәрченен хәтерләткән тагын бер кыз утыра иде.

— Исәнмесез,— диде ул, колакларына кадәр кызарынып. Рәсимгә бер генә мәртәбә карап алды. Йөз кызыллыгын яшерергә теләгәндәй, башын иеп, тавышсыз-тынсыз гына чыгып китте. Әллә тиде аның бәләкәй туфлиләре идәнгә, әллә юк.

Фирдәүсә Рәсимнең, нинди асыл кош бу, дигәндәй гаҗәпләнебрәк калганын күргәч, саксыз гына кулын селкеп идәнгә төшкән китапларына иелде.

— Авыл хуҗалыгы институтының практиканткасы. Авылда кеше саны тулмаган. Зоотехник, имеш. Сыер бозаулаганын күрсә, бер чакрымга йөгерә. Мәми авыз. Исеме дә бит аның Мөккәррәмәгөлдеррия.

Фирдәүсә, Рәсим көлсен өчен, юри «р» авазына басым ясап әйтте.

— Алай, элек фермада мөдир бар иде. Онытканда бер, күн сумка тагып, ат врачы Качугин килеп чыга иде. Хәзер инде, әнә, зоотехник Мөкәррәмәгөлдеррия... Әле китапханәче дә укып кайтачак, анысы үзебезнең авыл кызы,— дип, сүзне икенчегә борды Фирдәүсә.— Әле ике эшне дә үзем сөйрим. Бетереп кайттыңмы, Рәсим? Мин әйтәм, күренми, күрше авылда яши, ахры. Тавышың да үзгәргән. Син киткәндә туып кына калган балалар дүртне тутырды бит инде. Адәм көлкесе, шулай озак йөриләрме читтә. Хәят апа ничек түзгәндер, белмим. Ялгыз кешегә бер көне дә кыен бит дөнья көтүләре...

Рәсим Фирдәүсәнең йөзеннән үзгәрешләр эзләде. Юк иде үзгәреш Фирдәүсәдә. Ул киткән чакта ничек калган булса, хәзер дә шулай. Җыйнак гәүдә, беленер-беленмәс кенә калкып торган тыйнак күкрәкләр. Икегә ярылып торган шоп-шома чәч. Яңакларындагы алсулык кына җуелган сыман. Аннары кул селкеп сөйләшүләре, әй, дип ирен читләрен җыерып куюлары олыларча. Хәер, бөтен хәрәкәтләре, барча ымнары-ишарәләре килешеп тора тагын үзенә.

Күрешкәч сөйләшенә торганы сөйләшенеп бетте бугай, ниһаять.

Рәсим Фирдәүсәнең чекерәеп торган елтыр күзләре үзенә төбәлүен тойган хәлдә шүрлекләрдәге китапларны караштыргалап, озакка сузып актарынгач: «Кызыклы китаплар кайтамы? Китап укучылар күпме?»— дип сорады.

Фирдәүсә аның һәр соравына, имтиханда «бишле» алырга тырышкан бала кебек, җиренә җиткереп җавап бирә барды.

— Кызыклы китаплар кайта. Синең шикелле күп алмыйлар хәзер. Алганы да кешедә айлар буе ята. Син шигырь китаплары да укый торган идең. Шигырь китапларын хәзер халык аз укый. Кыз-кыркыннарына хәтле фантастика, я көлкеле китап, дип теңкәне корыта. Элек мәктәп укучылары күп укый иде. Үзәктә рус мәктәбе ачылганнан бирле алар да онытты китапханә юлын.

Рәсим мыегына чорнап куйды: әһе, «үзәк» дигән сүз юк иде элек. Хәзер авылда «үзәк» дигән җир дә бар икән. Фирдәүсә әңгәмә уңаеннан анысын да аңлатып китте.

— Чыршы авылын үзәк дип йөртәбез. Авыл Советы шунда, идарә, таш клуб шунда.

— Шигырь укымыйлар, дип читтән килгән кешеләргә сөйли күрмә тагын. Көләрләр. Менә Хисам Камаловның шигырьләрен алам. Монысы Фадеевның «Разгром»ы. Безнең Назаренко дигән бик әйбәт старпом бар иде. Һәр культуралы милләт үзе белән багланышта яшәгән икенче милләт телен, хәле җиткәнчә, һич югы, җырларының мәгънәсен аңларлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиеш. Шул чагында гына ул милләт буларак күршесенә дә, үзенә дә дөрес бәя бирә дип әйтә торган иде. Ә безгә җыр белән генә булмый, безгә күбрәк өйрәнергә, күбрәк белергә кирәк.

Фирдәүсә: «Татарча да яхшы бел, урысча да яхшы бел»,— дип көйли-көйли Рәсимгә яңа карточка тутырды. Рәсимгә кул куйдырды. Кул куйганда Рәсим күз чите белән генә Фирдәүсәнең почык борыны тирләп чыгуын, болай да юка иреннәре кысылып, яфрак калынлыгы гына калуын күреп алды. Эх, вакытында саубуллашып чыгып китмәде Рәсим. Нигә кирәк булды инде Фирдәүсә каршында: ах, мин менә нәрсә беләм, менә миңа нәрсә өйрәттеләр, дип мактанып торырга? Фирдәүсәнең характерын белмәгән кеше кебек. Мөкәррәмәгөлдөррияне утлы табага бастырганда, борын яфраклары болай күпермәгән иде бугай әле аның. Чыгып китәргә соң түгелдер әле, шәт. Шәт, түгелдер әле... Чыктың, чыгарыр Фирдәүсә коры килеш кенә. Әнә күзләреннән яшеннәр атып та җибәрде. Иреннәрен кыймылдатканы күренмәде, ә сүзләре бик ачык ишетелде:

— Сине дә әйтер идем инде, Рәсим...

География дәресендә җыр чыгарып утыра торган бөдрә чәчле малай баянын ныграк кычкыртсын иде, ичмасам. Шулай инде, шулай, дөрес уйныйсың. «Умырзая шыта, карагыз...» Ах, чәнчелгере малай. Уйнавын бөтенләй акрынайтты».

— Җиләк кебек кызны ычкындырдың...

Ни әйтәсең инде моңа каршы? Дөрес сүзгә җавап юк, дәшмичә сүзнең дәвамын көтәргә туры килә.

— Әле кемгә, диген. Бер селәгәй малайга, аракы мичкәсенә.

Әһә, ябышырга җеп очы булды. Бәлки, батмас Рәсим. Бәлки, исән-сау ярга йөзеп чыгар. Йөз-битләре кызармаган бугай әле. Димәк, Фирдәүсә һөҗүмен кире кайтарырга була.

Иң алдан плацдарм әзерләргә, ягъни тамак кырып куярга кирәк.

— Кһм!.. Кайчандыр, кемнәрдер ул аракы мичкәсе өчен җан атып йөргән дигән сүзләр йөри авылда. Разведка мәгълүматларына караганда, хәзер дә оныта алмыйлар ди аракы мичкәсен...

Кайберәүләр...

Контрһөҗүм уңышлы булды бугай. Һәрхәлдә Фәрдәүсә бер минут чамасы борын яфракларын тибрәндереп, аңына килә алмыйча утырды. Ләкин бу мәкерле тынлык булган икән. Рәсимгә ул кыйммәткә төште.

— Хәбир синең җан дустың, әйтсәм үпкәләмәссең микән, Рәсим? Әйдә, үпкәләмәссең әле, кунак түгел, үз кеше.— Ишектән ачык изүле балон плащын флаг комачыдай җилбәгәй җибәргән кызыл йөзле бер ят кеше башын тыккан иде, Фирдәүсә барып шарт иттереп ябып куйды ишекне. Теге мескен борынын чак кына кыстырмый калды.

— Кайсысы тарта анда, куып чыгарам хәзер барыгызны да! Җан көекләре. Гәзит-журнал укырга килмиләр клубка.— Фирдәүсә Рәсимгә күтәрелеп карамыйча гына урынына барып утырды, өстәлнең бу почмагындагы китапларны икенче почмакка күчереп куйды.— Кемнәрдер җан атып йөргән, дисең инде, алайса. Җан атып йөргәнмендерме, юктырмы, анысы минем эш, әмма ләкин мин барыбер ул пижа ябала-

гына кияүгә чыкмас идем. Гомерем буе ир чыраен күрмәсәм дә чыкмас идем мин аңа.. Әйтсәм әйтим, Рәсим, мәхәббәтнең нәрсә икәнен белми торган бәхетсез зат бит ул. Яшермим, бер заманны, әле армиягә алынганчы ук, мин аны яратып китә яздым. Ходай саклагандыр, тиз арындым җүләр чирдән. Син уйлама, Хәбир өйләнгән дә, бу шуңа үчләнә икән, дип. Ике ятып бер төшемә керми. Әле син ачуны китергәнгә күрә генә... Чит илләрдә өреп тутыра торган хатын-кыз карачкысын саталар икән. Резинадан ясалган диме шунда, пласмастанмы. Кайбер ирләр шуны алып кочып яталар икән. Хәбиргә дә менә шундый карачкы кирәк, чын хатын-кыз түгел... Әллә Тәслимә яратып чыкты, дип уйлыйсыңмы Хәбиргә? Юк, йөз кат юк, мең кат! Мин Тәслимәне синнән яхшырак беләм бит. Өзеп чыгарасың, бөтермә төймәнне... Хат язгалап кына торсаң хет. Ничек китәргә дә суга төшкән балык кебек югалырга мөмкин кеше шулай...

— Әллә мине яратадырмы, дип уйлыйсыңмы Тәслимәне, мине дә яратмыйдырмы ул,— диде Рәсим, Фирдәүсә тынып торган арада, кызып һәм гасабиланып.

— Синеме? Ничек телең бара? Икәү генә калдык исә гел син генә идең аның телендә, гел син генә. Урамда син уйнап йөргән көйләрнең барысын да исендә тота ул. Шуларны көйләп җырлап йөри иде. Гарип Гашыйк турындагы әкиятеңне әллә ничә тапкыр сөйләп бирде миңа. Чәчендә нинди приколка дип уйлыйсың син аның менә хәзер, менә шушы минутта? Мөрәле юлында тәгәрмәч астына эләгеп сынган иде бит. Син булавкасын капрон җеп белән чорнап биргән идең. Менә шул приколканы кадап йөри Тәслимә чәченә.

Булган иде шул, әйе, андый хәл дә булган иде. Ләкин боларны нигә сөйли әле Фирдәүсә Рәсимгә? Боларның нинди әһәмияте бар хәзер. Буласы булган, буявы сеңгән, узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да... Рәсимнең йөрәге таш, дип уйлыймы әллә ул? Шулай әйтергә, нәкъ менә шулай гына авызын томаларга кирәк Фирдәүсәнең... Әйтә алмый ләкин, әйтә алмый Рәсим. Әйтергә теле күтәрелми. Тәслимә турында һәрбер сүз, һәрбер вакыйга, һәрбер истәлек кадерле шул Рәсимгә, күздән яшь чыгарырлык дәрәҗәдә кадерле.

— Ихтимал, сиңа Әхмәт абыйга гашыйк булган иде Тәслимә, диярләр. Әхмәт абый өйләнгәч тә аның артыннан күсәк булып йөрде, диярләр.

Рәсим, сагаеп, сүзнең азагын көтте. Нәрсә ялганлар икән Фирдәүсә, тагын нәрсә уйлап чыгарыр икән. Әхмәт абыйсын яратуын Тәслимәнең үз авызыннан ишетмәсә, бәлки, гайбәт, дип уйлар иде Рәсим. Ишетте шул, теге елны, үз авызыннан ишетте.

— Ә мине, беләсеңме кем ярата? — дип бөтенләй көтелмәгән яктан китереп сукты Фирдәүсә. — Әйтимме, кешегә әйтмисеңме? Көлмә түлке. Мине Печтер Имамы ярата.

Рәсим шаркылдап көлеп җибәрә язды.

— Көләсеңме? Көлмә, дидем ич мин сиңа. Ни өчен төнге сәгать унберга хәтле салкын залда тәмәке пошкыртып утыра дип уйлыйсың син аны, ә? Мине күрү өчен килә ул клубка. Ә, беләсеңме, мине күргәч, йөзендәге җыерчыклары пәрәвез җепләре кебек беленер-беленмәс кенә кала аның. Бер күтәрелеп карый, икенче мәртәбә күтәрелеп карый алмый. Куллары да калтырый бит әле аның. Беркөннәрдә — кино буласы көн иде — иртәрәк килдем дә йозакны ача алмый интегәм. Имам абый әллә кайчан килгән иде, болдыр почмагында тәмәке тартып тора. Мин эндәшмәсәм, килмәгән дә булыр иде. Карт булса да, шундый оялчан ул. Булмый, Имам абый, ачылмый бит, дигән булам инде моңа.

Тәмәкесен карга атты да сүзсез генә килде. Салкын йозакны ике кулы белән кысып — мин шырпы яндырып торгач барысы да күренә — мәрткә китеп торды башта. Мин инде, йөрәге тоттымы әллә, дип кур-

кып-киттем. Беравык шулай тынып торгач, ачкычымны шалтыратырга тотынды бу. Шырпыны бармагым пешә башлаганчы тотам да яңадан сызам, кул бармагым пешә башлаганчы тотам да сызам. Шунда күрсәң, кулы бер тамчы калтырамый бит Имам абыйкәчемнең! Шаккаттым. Чылт иттереп кенә ачты да йозакны миңа бирде, тагын болдыр почмагына барып басты. Зал ягына бер-ике адым атлагач кына игътибар иттем — әле генә кулны өшетерлек иде йозак, инде тимер мич кебек җылынган. Исем китте шул чагында. Булса булыр икән карт күңелендә шул кадәр җылы!..

Фирдәүсә сөйләгәндә Рәсим үз-үзен кулга алып өлгерде. Фирдәүсә әйтер сүзен шундый шаян хикәяләрдән башлаган булса соң. Менә син, ә, иске авыздан яңа сүз... Гомер узар, уч табаны чаклы авылның ничек сулаганын белмичә үлеп китәрсең тәки. Туктале, кая калды соң бу Фирдәүсә.

— Ә син? — дип сорады кыздан Рәсим.

— Нәрсә мин?

— Син ничек җавап бирәсең инде Печтер Имамының кайнар мәхәббәтенә?

— Рәсим! Көлмә, дидем ич мин сиңа. Синең карт кешедән көләргә хакың юк!

— Я, я, ярар, көлмим. Әхмәт абыйның ни катнашы бар инде монда? Тәслимәнең ни катнашы бар? Әллә Әхмәт абыйны да Печтер Имамы шикелле бетешкән карт дип әйтергә уйлыйсыңмы?

— Минем бер гаебем дә юк, миңа алай усал итеп карама, Рәсим. Печтер Имамы — Тәслимә. Әхмәт абый — мин... Аңлашыламы?

Фирдәүсә, бик аз гына баян тавышына колак салып торгач, теге якка ымлап алды:

— Кара, ярыйсы гына маташтыра башлады бит теге кабак баш, ишетәсеңме... Юк, юк, үләсем килми, юк, үләсем килми, умырзая кебек боегып...

Юк, «Умырзая» көен рәтле-юньле уйный алмый иде әле егет. Моңа ирешү өчен, мөгаен, әле аңа тагын бер чалбар тезен туздырырга туры килер. Я алла, әллә Печтер Имамына гашыйк булган инде бу Фирдәүсә...

— Ярар, аңлашылды да, ди. Әгәр дә Печтер Имамы медпунктта фельдшер булып эшләсә, Фирдәүсә төнлә белән аның янына кереп йөрер идеме соң?

— Менә син нәрсә турында, менә син ничек уйлыйсың? — Фирдәүсәнең күзләреннән тагын яшьләр атылды. — Ә кергәм нәрсә булган? Керер идем, билләһи керер идем. Имам абыйны юатыр өчен, аның җанын юатыр өчен. Син, Рәсим, шушы китапханәдән китапларның барысын да диярлек укып чыктың, тегендә дә аз укымагансыңдыр... Гайбәтче хатыннар кебек сөйләшәсең, дисәм, гафу ит. Медпункт ике смена эшли бездә. Теләсәң, син дә керә аласың анда. Бүген какраз Тәслимә сменасы. Әле сәгать тугыз тулып кына килә. Унга кадәр эшли медпункт.

— Хаҗәте бар инде хәзер Тәслимәнең.

Монысы бигрәк тә балаларча. Алай әйтергә теләмәгән иде Рәсим.

Фирдәүсә усал, Фирдәүсә культура-агарту эшен алып бара, аннан да бигрәк кешенең психологиясен яхшы аңлый. Кайдан белер иде, югыйсә, ул Печтер Имамының үзенә гашыйк булганын? Хәтәр кыз Фирдәүсә. Моның янында сак булырга кирәк. Рәсим усаллана башлагач кына нишләп авыз ера әле ул? Китәргә кирәк моннан яхшы чагында. Ычкынырга кирәк.

— Рәсим.

— Мин туганнан бирле Рәсим.

— Онытмагансың икән бит син Тәслимәне. Син аны һаман да яратасың икән бит. Гафу ит, мин юри генә, сине сынар өчен генә сүз

кузгаткан идем Тәслимә хакында. Рәхмәт, Рәсим, син бер дә үзгәрмәгәнсең. Син һаман да шул ук Рәсим.

Алайга китсәме, алайга китсә, Рәсимнең дә мин-минлеге бар, алайга китсә, Рәсим дә төшеп калганнардан түгел. Каушамыйча-нитмичә, үзгенә үтәрлек итеп әйтергә кирәк, әлбәттә. Печтер Имамы, имеш, чурт-чурама, тагын әллә нәрсәләр уйлап табар әле бу. Тәмам артистланып беткән икән клубта эшли-эшли.

— Җитте, Фирдәүсә. Булды. Рәхмәтеңә рәхмәт. Ләкин син шуны аңла: мин Хәбир белән Тәслимә арасына керергә җыенмыйм. Беркайчан да. Аңладыңмы, беркайчан да. Сиңа Хәбир кирәк икән, мине катыштырма. Печтер Имамы түгел мин сиңа. Хуш...

Рәсим ишектән чыкканда Фирдәүсәгә борылып карады. Фирдәүсә калды. Өстәлдәге китаплар күче арасында, идәннән түшәмгә кадәрле сузылган китап киштәләре арасында үзенең мәхәббәт фәлсәфәсе, Печтер Имамы турындагы уйлары белән берьялгызы калды Фирдәүсә...

Шахматчы малайлар рокировка ясый белмиләр икән, китапханәдән чыккач, Рәсим аларны рокировка ясарга өйрәтте. Беркавым, доминочылар артына басып, аларның бөтен җаннарын биреп, азарт белән, йөзләренә чын борчылу, шатлык янсә үкенү галәмәтләре чыгарып, аратирә «менә без болай итәбез аны», «бусы ничегрәк була?», «әһә, берсе утырды», «тегесенең дә койрыгына басабыз аны», дип кычкыргалап уйнауларын карап торды. Ялангач имән өстәлдә бик шәп чыкылдыйлар иде домино сөякләре. Кабак баш инде икенче көйне шыңгырдатып маташа. Менә шулай яхшырак та булыр. «Умырзая»га барыбер төшең үтми. Биючесе булмаса да, «Бишле бию» көе күңелне күтәрә, уйларга да җиңел аннан соң.

Кеше-карага сиздермичә генә чыкты Рәсим клубтан. Бу юлы Печтер Имамы белән сөйләшеп тормады. Печтер Имамы, җыерчыклы йөзен бүрек колагәсенә яшереп, ярым-караңгы тамаша залын каравыллап калды.

Тышта салкын түгел иде. Шулай да Рәсим бескозыркасын кашларына ук төшереп киде. Клубтан ераклашкач, юл уртасында туктап, төнге тавышларга колак салып торды, сәгатенә карады. Вакыт бик акрын бара, әле ун туларга ярты сәгатьтән артыграк иде.

Тәслимә — Печтер Имамы, имеш. Ну, сөйләшеп тә күрсәтә соң Фирдәүсә. Нәрсә әйтергә теләде икән ул шундый чагыштыру китереп? Тәслимәнең Әхмәт абыйсына булган мәхәббәте Печтер Имамының мине ярату кебек үк өметсез мәхәббәт, нәтиҗәсез ярату, дип әйтергә телә гәндер инде, бәлки. Бик кызык килеп чыга бит әле бу, шайтан алгыры. Үзе яратмаган кешегә кияүгә чыга берәү, шуның белән яши, өметсез мәхәббәте турында уйлый. Ә Рәсим нишләргә тиеш инде бу очракта?

Туктале, нишләп һаман Тәслимә турында уйлый соң әле Рәсим? Аяк астында кар юк, шуңа күрә шыгырдамый да... Менә шул чакта да уйларга кирәк. Күк болытлы, караңгы. Менә шул чакта да уйлап була. Зират ягында нәзек тавыш белән бер эт улый. Менә шул хакта уйласаң да ярый. Куенындагы китапларны бүген үк укып чыгар ул, шәт. Әйе шул, иң яхшысы — китаплар турында уйлау.

Аннан ары, аннан ары... Нәрсә соң, кунак кадере өч көн, хәрби учетка утырырга да эш мәсьәләсен кайгырта башларга кирәк. Эш мәсьәләсе артыннан өй мәсьәләсе... Анысы акрынлап, җай белән. Кара, нишләде әле, элекке кебек борчылмый башлады Рәсим өй салу мәсьәләсендә. Салсак ни, салмасак ни, дип кенә карый түгелме соң ул бу мәсьәләгә? Матчаның бер очына Рәсимсез генә куйганнар икән терәүне, икенче очына Рәсим куяр. Менә бит нинди уйлар килә башка, уйларга тотынсаң. Әнисе дә аны-моны дәшми. Улым ул булган, кайткач, үзе карар дигәндәй, шыпырт кына йөри бирә.

Тагын нәрсә хакында уйларга мөмкин? Тагынмы, тагын... Башы рөхсәт бирмәгән килеш аяклары кая алып бара соң әле Рәсимне? Уй-

лап бакса, күптән медпунктка таба атлый икән инде Рәсим. Карак кебек, юлбасар кебек, үзеннән үзе качып, Тәслимә турындагы уйларны эт улавы артына яшереп... Ничек оят түгел сиңа, Рәсим? Тагын бер-ике адым гына атлыйсың да кире борыласың, ярыймы? Ирле хатын белән шаяртырга ярамый, ярамый, Рәсим. Я, тагын берне атладың, ди. Ә хәзер борыл инде. Медпункт тәрәзәсенә пәрдә корылган, барыбер бернәрсә дә күренми.

Ә медпунктка барса ни булган? Медпункт кешеләр килер өчен инде ул. Башың авыртса да барасың, эчең авыртса да. Борыл, Рәсим, егет кешегә килешә торган эш түгел. Үз-үзеңне алдама. Борыл яхшы чагында. Ярар инде, караса ни булган? Ашалып төшмәс әле медпункт тәрәзәсе. Тәслимәне кыз чагында күрде, хатын булгач та күрәсе килә ич Рәсимнең. Әнә, пәрдәсе тартылып бетмәгән җире дә бар. Йөзенә генә карый Рәсим аның, үзгәргәнме, нишләгән икән...

Рәсим өлгенең уч табаны кадәр ачык калган урынына күз сирпеп алуга ук таныды Тәслимәне һәм, аягы таеп, тәрәзәгә яңагын бәрә язды. Тәслимә үзгәргән иде. Ләкин бу үзгәрешнең нәрсәдән гыйбарәт булуын төшенер дәрәҗәдә түгел иде Рәсим бу минутта. Йөзе сулган дисә, элек тә шулай озынчарак иде. Тәслимәнең өстендә ак халат. Халат җиңнәрен сызганып куйган. Сыгылмалы нәфис куллары белән әллә дару болгата шунда, әллә чәй. Элек кечкенә колаклары куе чәчләр арасына керми дә торган иде. Хәзер чәчләрен күтәреп тараган Тәслимә. Шуңа күрәдерме, муены озынаеп киткән сыман. Монысы да килешле, монысына да бәйләнеп булмый. Әллә мыек та чыккан инде үзенә? Ут яктысы яннан төшкәндә генә шулай булып күренә икән, хәер. Керфекләре дә болай ук озын түгел иде ич аның. Әллә ут шулай алдыймы? Төнге күл өсте кебек зәңгәр хәзер аның күзләре. Сагышлы уйчанлык, әйтеп бетергесез тирән моң белән өретелгән бугай алар. Керфекләре сирпелгәндә Рәсимгә һәрхәлдә шулай күренде. Рәсим Тәслимәнең күкрәгенә карамады. Карамаса да күз алдында торды Тәслимәнең халат аша тыгыз булып беленеп торган күкрәкләре. Тәслимәнең озын ак муеныннан, алсу яфраклы кечкенә колакларыннан, сине үртәргә теләгәндәй, аз гына алгарак чыгып торган килешле иреннәреннән аерылгысыз иде шул Тәслимәнең яшь күкрәкләре. Карарга теләмәсә дә, хыялына үзләре йөзеп килделәр алар.

Китәргә кирәк иде. Угры кебек болай тору килешми иде. Китәргә кирәк иде. Ләкин пыяла артындагы сурәттән аерылу турында уйлау Рәсимнең бөтен барлыгын дер селкетеп узды. Баллы пыялага ябышкан чебен халәтендә хис итте Рәсим үзен... Тәслимә аның йөрәк тибешен ишетмәсә дә сулышын ишетер төсле иде.

Рәсим күзләрен чытырдатып йомды, ярдан торып көймәне дулкын эченә этеп җибәргәндәй, кулларын тәрәзә яңагына терәде, мускуллары киерелде. Йөрәген тынычландыру өчен кар өстенә ятып торасы килде аның. Юк, карга ятып кына тынычланмаячак иде аның йөрәге. Йөрәкне тынычландырыр өчен Рәсимгә эткә әверелергә һәм зиратның артына чыгып айсыз-йолдызсыз караңгы күккә карап таңга кадәр уларга кирәк иде.

### Унынчы бүлек

— Мунчадан соң, суык тияр, улым, кар яумыйдыр ич, карга буялып беткәнсең,— дип каршы алды Рәсимне әнисе.

Күр әле, чынлап та, карга ятып аунамады бугай ич Рәсим? Медпункт кыегыннан да кар коелганы сизелмәде. Әйе бит әле, каеннардан, зират каеннарыннан коелды кар. Юлны озынайтыр өчен, юри зират артыннан әйләнеп кайтты Рәсим.

— Кеше-фәлән юктыр ич, әни?

— Ят кеше юк, Нәфисә күрше генә. Чүпрә сорарга кергән.

Рәсим Нәфисәттәй чыгып киткәнче, тагын бераз урамда йөреп ке-

рергә уйлаган иде дә, әнисеннән яхшысынмады. Өс-башын каккалап өйгә керде. Урамда бер исәнләшкәннәр иде инде Нәфисәттәй белән, бу юлы инде кул биреп күреште.

— Кулларың боз кебек булганчы кайларда йөрдең болай, үскәнем,— дип телләнеп каршылады аны Нәфисәттәй.— Карап-карап торам да тагын бер карап куям. Гернадир кебек булдыгыз бит, сөбеханалла. Әтиләрегез генә күрмәде шул, әтиләрегез генә.

Йомшак йон оегына килеп сырпаланган песине Нәфисәттәй читкәрәк тибәрде.

— Өйләндермә әле, Хәят, малаеңны, рәхәтләнеп йөреп калсын, егет чаклар ике килми. Армиягә киткәнче еллар ябык булды, ачлы-туклы яшәп баш күтәрми эшләделәр.

Рәсим кече якка кереп чуеннан аш салып алды. Сәке читенә утырып, күпереп пешкән арыш ипиен килеп алды да өрә-өрә аш капты. Итләре җимеш кебек суырылып кына керә иде авызга. Күпереп пешкән арыш ипие капкан саен кабасын китерә иде. Рәсим, аны-моны уйламаска тырышып, ризыкның тәмен белеп кенә ашарга тотынды. Аны-моны уйламаска тырышса да, әнисе белән Нәфисәттәй сөйләгән сүзләр бик ачык ишетелә һәм уйланырга мәҗбүр итә иде аны.

— Ашыкты шул, ашыгыбрак ташлады. Әйттем үзенә. Әле өй арасында эшләрлегем бар, бер-ике ел рәхәтләнеп йөрим, кана, дидем. Тыңламады. Шул Борһан Кукамай нәмәрсәсен сөйрәде дә кайтты берконне. Йөргәннәре дә ишетелмәгән ие, белмим ничек кенә булгандыр.

— Маңгайларына шулай язылган булгандыр инде, Нәфисә күрше. Нихәл итмәк кирәк, маңгайларына шулай язылган булгандыр. Әйбәт торалармы соң болай?..

— Торалар, дисәм, ялган булыр, тормыйлар, дисәм, ир белән хатын. Малай бик каты эчә башлады соңгы вакытта. Эчкәнен яратмый тегесе. Хәзер күркә кебек кабарынып китә. Малай да үпкәле аннары. Кул күтәреп сукканы юк болай.

— Таза нигезгә бирде инде Борһан кызын. Әйбәт кенә яшәсеннәр ие дә, кана. Нихәл соң, сиңа каты түгелме килен?

— Миңамы? Ни, күрше, әйттең сүз! Миңа каты булып ни кыла ала ул? Икесен дә пырылдаттырып кудым чыгардым булыр. Минем ачуымны китерсәләр... Йортны мин җыйган акчага салдылар. Әнә, мунча аларга! Шунда чыгып торсыннар, сыеша алмасалар...

Бераздан теге яктан пышылдап сөйләшүгә күчтеләр. Рәсим колагына «җитди», «ничә ай», «менә син», «медпункт», «бишек» кебек аерым сүзләр генә килеп кергәләде.

Нәфисәттәй дә булсын, пышылдап сөйләшергә дә риза булсын! Шактый ерак араны йөгереп үткәндәй, мыш-мыш килеп торды да ярып салды.

— Ишетсен ишетмәгәнен. Авыл җирендә абзар артына чыкканын да яшереп булмый. Булса булырга вакыт инде бик. Өйләнешкәннәренә сигезенче ай китте... Әй, Хәбир... Кечкенә чагында, тукта үстерим, кеше итим, дип чиләнәсең. Инде үсеп җиткәч тә тынычлык юк, ишшү хуҗы үсеп җиткәч. Ашыктырма, күрше, ашыктырма, малаеңны өйләндерергә...

Авылга кайткач беркая да чыкмыйча, әнисе белән генә сөйләшеп, тыштагы хәлләрне тәрәзәдән генә карап утырырмын, дип уйлаган иде Рәсим. Хәтта зимагур кәҗәсен дә сагынды ул. Өчәр-дүртәр тәүлек давыллы диңгезләрдә чайкалганда, исән-сау әйләнеп кайтсам, печәннән өзелдермәс идем, дип адарынган чаклары да булды. Бактың исә, кәҗә иң арткы планга калып бара. Хәер, үзе дә бик өнәп бетерми кара киемле ят кешене. Болдыр алдында Рәсимнең шәүләсе күренүгә, бөтен хуҗалыгын сарыкларга тапшыра. Утын әрдәнәсенә сикерә, аннан

лапас түбәсенә менеп китә. Сакалындагы боз шөлдерләрен җем-җем китереп, күзләрен алартып, кайсыдыр мүкләгенә сабак укытканда мөгез очына эленеп калган йон учмасын җилфердәтеп, өстән Рәсимгә карап тора. Шәт, син яхшы кешедер, шәт, син миңа тимәссең дә, ләкин мин ничек сиңа ышаныйм соң, күзгә кереп торган гаепләрем булмаса иде, ул чагында мин сиңа ышаныр да идем, дигән мәгънәне аңлата сыман аның урыныннан купкан күзләре.

Кәҗә ышанмый Рәсимгә. Сарыклар ышана. Ләкин сарыкларның төссез яшел күзләрен үзе ошатмый Рәсим. Ниндидер җансыз күзләр, салкын күзләр. Суйган чакта да үзгәрми хәтта сарыкларның күзләре. Әллә суючыга карый ул шунда, әллә күккә карый. Курку да юк ул күзләрдә, җан газабы якынлашуын тоеп ярсу да, газаплану да юк. Мәгез, теләсәгез нишләтегез мине. Алай дисәң, бәрәннәрен ничек яраталар алар. Бәрәннәре олыгаеп бетә, үзләре кадәр була, әнисенең корсак астына сыймый башлый. Шулай да мекер-мекер килеп имезәләр алар «сакаллы сабыйларын». Сарык дигән хайван бик куркак та бит әле аннан соң. Дөньяга битараф җан иясе куркак була аламыни? Куян да куркак, ләкин куянның күзләре матур.

— Улым, әллә син йоклап киттеңме анда, тавышың-тының ишетелми.

Рәсим бүлмә тактасына сөялеп утырган көенчә хисап җыеп алды.

— Юк, әни, укып утырам, йокламыйм.

Нәфисәттәйнең чыгыйм инде, йоклагыз, ял итегез, арыгансыздыр, дигәненә дә шактый гомер узды. Әмма һаман чыкканы күренми әле. Һаман леңгер-леңгер сөйләшәләр. Сөйләшсеннәр, Рәсимнең барыбер бөртек тә йокысы килми. Нәрсә сөйләшәләр, нинди серләрен уртаклашалар ике күрше, ирсез үстергән малайлары буйга җиткән ике карчык.

Минем өчен син юк инде хәзер,
Синең өчен мин дә югалдым...

Китапны кулына алгач ук Рәсимнең күзләренә әнә шул юллар килеп кадалды. Нигә чыгып китми инде бу Нәфисәттәй, нигә? Әнисе дә Нәфисәттәйне озатырга чыгар иде бәлки. Шул чагында Рәсим башын мичкәгә тыгып, үкереп елар иде. Үзе артыннан утка кереп күзсез калган Назаренконы кызганып елар иде, ә сарыклар өчен, сарыклар өчен... әлбәттә, еламас иде. Нигә сарыклар өчен елап торырга? Күзләре тормышның бәйрәмнәренә дә, фаҗигаләренә дә битараф карый торган сарыклар өчен елап тора ди мени кеше?

Авылда бердәнбер якын дусты бар иде Рәсимнең. Ул — Хәбир иде. Нишләп ике, өч булмады икән соң Рәсимнең дуслары? Берсе югалса, берсе калыр иде. Дөнья кайгылары азрак булгандыр, күрәсең, балачакта. Дуслар турында уйланылмагандыр...

Рәсим сәкедә тезләрен чәнчеп утырган җиреннән дерт итеп сискәнеп китте, идәнгә шуып төште, кулындагы китабын мич катына куеп, түр якка атылып чыкты, чыккан уңайга тиз-тиз киенә дә башлады. Карчыклар, тынып, Рәсимгә текәлделәр.

— Дворга... барып кайтам әле,— диде Рәсим киенгән уңайга, сүзләрен өзеп-өзеп.— Йокы да килми барыбер.

— Анда Гыйззәтулла карттан гайре җан иясе дә юктыр инде,— дип, Рәсимнең әнисеннән алда Нәфисәттәй сүзгә кушылды.

— Ә атлар?

— Атларны җан иясе чутына керткән кеше дә юк аларны, эш тә юк аларга хәзер, аш та,— дип элеп алып китте Хәят апа.— Күздән үк

авызларын коры шүрлеккә эләләр. Ябагалары белән кабыргалары гына чыга язга.

Рәсим ишек төбендә бераз уйланып торды да, кече якка кереп, бер кыерчык ипи кисеп алды. Кесәсенә берничә шакмак шикәр салды.

— Карлыгачыңны,— дип каршы алды аны әнисе ишек төбеннән үтеп киткәндә,— Нурулла малае Искәндәр җигеп йөрде. Язган идем бугай. Ул да качты инде авылдан. Тыңлаталмыйча аптырыйдырие, мескен. Карлыгач безнең турыга җитүгә, каера да керә капка төбенә, каера да керә...

Рәсим аны-моны дәшмәде, ботинкасын шнурлап бәйләде дә, ишек-капкаларын тавышсыз гына ачарга тырышып, урамга чыкты. Хәбирләр йорты тагын да биегрәк булып, коймалары исә адәм үтеп керә алмаслык стена булып, каралты-куралары ныгытма почмакларындагы манараларга охшап күренә иде салкын декабрь төнендә. Тәслиманең шул караңгы йортта, шул биек койма артында яшәвенә күңеле ышанырга теләми, ышанасы да килми иде Рәсимнең...

*Кулъязма шушында өзелә. Аны матбугат өчен Эльмира Шәрифуллина әзерләде.*

*Пицунда.*
*Сентябрь, 1982 ел.*

## Разил Вәлиев

### Безнең иман

Бәхет даулап изге яуга кердек,
Үтәдек без намус кушканны.
Күңелләрдә бер сүз бары: Җиңү —
Без җиңәргә тиеш дошманны.

Безнең сүзне бүлдерергә теләп,
Шашып сукты Рәсәй чаңнары...
Янды алда, Кызыл байрак булып,
Киләчәкнең алсу таңнары.

Ирек даулап чапты аргамаклар,
Ялкынланды кызыл яллары...
Шушы ялкын кайнар теле белән
Яңа туган җирне ялады.

Күтәрелде күккә Кызыл кояш,
Күтәрелде томан — Җир буы.
«Көзге җил»гә кушып җырладык без
«Кузган, уян!..» дигән җыруны.

Океан артларыннан, бармак төртеп,
Көлде дошман: «Бәхет шушымы?»
...Яраларны тотып җырладык без,
Безнең җырга илләр кушылды.

Качты патша: тик җан исән булсын.—
Янсын иле. Бетсен тәхете...
Ә без — монда, без мәңгегә монда —
Без Ил белән генә бәхетле.

Шушы бәхет өчен яуга кердек,
Без үтәдек Ватан кушканны.
Безнең иман — Унҗиденче елгы,—
Без җиңәргә килдек дошманны.

### Кошлар кайта

Яшьле күзен мөлдерәтеп
Кыш карап тора.
Уйный-көлә язлар килә
Кош канатында.

Бар тереклек кулын суза
Кояшка таба.
Җир әйләнә яшел кошка,—
Җир канатлана.

## Көз офыгы

Көз әле алтынсу биләүдә —
Мин инде җәйләрне сагынам.
Сагышның мәйданы киңәя —
Офыклар киңәйгән чагында.

Соңгы кат сеенеп калыйм дип,
Каеннар таң белән торганнар.
Күңелгә көз моңын иңдереп,
Каңгылдый һавада торналар.

Яңгырый хушлашу авазы
Күкләрдән, таулардан — бар яктан,—
...Йөрәгең өзелер бер мәлдә —
Агачтан өзелгән яфрактай.

Тик һаман кошларга ияреп
Талпына күңелем югары.
Бәхетнең үзенә илтә күк
Күктәге кошларның юллары.

## Елмайсын сабыйлар

Агара, чалара әнием чәчләре...
Агармый тик кайгы карасы.
Мәйданда мәңгелек ут яна,
Ул — минем йөрәгем ярасы.

Мин беләм: бары тик бер адым
Кайгылар, бәхетләр арасы.
Менә шул мәңгелек арада
Сулкылдый йөрәгем ярасы.

Бәхетләр ягына йөз тотып,
Безгә бит әле күп барасы.
Сабыйлар елмайса дөньяда,
Төзәлер йөрәгем ярасы.

## Авылга кайту

Ашыктырып этә иңнәремнән
Туган якка буран.
Өянкеләр авыл башынача
Каршы чыгып торган.

Карт өянке, давылдандыр инде,
Каерылган, сынган.
Күтәрелеп килә алсу кояш,—
Җир йөрәге сыман.

Ал кояшка таба йөзне тотып,
Күпме юллар үттем!
...Дөньяда тик безнең авылдадыр
Ипи исле төтен.

Олы хисләр, олы омтылышның
Туган якта башы.
Шушы җирдә туган хыялларым
Шунда чыңга ашты.

Туган авыл — соңгы станция...
Кайтам сине уйлап,
Ике рельс кебек ялтыраган
Чана юлы буйлап.

## Туган җирем

Озын юллар узган көннәремнең
Офыктадыр инде бер башы.
Таң шәфәгы сүнде, төш тә узды...
Баш күтәреп эзлим кояшны.

Талган йөрәк,
Чык суларын эчеп,
Кояш нурын җыеп туяр да,
Пешкән җимеш сыман, ашыгыр ул
Җылы җиргә башын куярга.

Туган җирем, йөзең алсуланган...
Яңа таңнар сине уяткан.
...Төзәтелгән иске сәгать сыман,
Күке тавышы китми колактан.

Мин ышанмыйм хәзер күкеләргә.
Санамыйм да... күпме калганын.
Начарлыклар юрап куркытты да,
Яз һәм сөю биреп, алдады.

Ерак түгел, җирем, бәйрәм көнең,
Бүләк итим сиңа ни генә!?
Йортлар салмыйм, текмим киемнәр дә,
Һәм үстермим кырда игеннәр.

Тик хезмәтнең беләм чын бәясен,
Тормыш серен аңлыйм, төшенәм.
Бу киемне, йортны, ипине дә
Бүләк итте миңа кешеләр.

Ә мин, җирем, син еласаң — елыйм,
Син шатланган чакта — гел көләм...
Ил алдында олы бурычымны
Түләрмен мин шигырь, җыр белән.

## Туган көндә

Сорамагыз аннан яшен бүген,
Юрамагызниләр көтәсен.
Тәрәзәдән ташып аксын шатлык,
Күлүеннән кайгы үртәлсен.

Көнләшүдән, күзен чекерәйтеп
Тәрәзәдән йолдыз карасын.
Шундый кичләр якынайта бугай
«Бүген» белән «Бәхет» арасын.

Очар кошлар күздән качып китте,
Чәчәкләр дә бетте бит сулып.
Ә ул һаман яз гөлләре төсле,
Тамчы да юк анда моңсулык.

Ул беләдер дус һәм туганнарның
Бар афәттән аны йоласын.
Күз аенда туган кеше өчен
Күзге яңгыр әнә еласын.

Илнең генә түгел, Җир шарының
Аңлый алган уен, бар гамен...
Ул кояшы төсле шушы йортның,
Ул — шатлыгы шушы дөньяның.

Сорамагыз аннан яшен бүген,
Юрамагыз ниләр көтәсен.
Бөтен дөнья бүген, бәхет теләп,
Аның өчен бокал күтәрсен!

## Кайт син миңа

Өмет кебек ап-ак көймәләрне
Гөрләвектә бергә агыздык.
Язлар килсә, чыгам урамнарга...
Гөрләвектә ага ялгызлык.

Йөрәкләрдән уртак ялкын алып,
Учакларны бергә кабыздык.
Учак булып янды безнең сөю...
Көле булып калды ялгызлык.

Шатлыклар да күрдем, кайгылар да,
Күрмәдем тик синнән явызлык,
Ә нигә соң каргыйм үткәннәрне —
Явызлыкмы әллә ялгызлык?!

Синең күзләр төсле сагышлы төн,
Синең шәүләң кебек ялгызлык.
Кайт син миңа. Уртак ялгызлыкны
Гөрләвектә бергә агызыйк.

## Ватан калыр

Арсак, талсак сиңа сыенабыз,
Агачларың саклый яңгырда...
Хәл җыябыз ятып туган җиргә,
Көч җыябыз... алга барырга.

Тузан кунган аякларны сыйпый
Чәчәкләрнең ап-ак күбеге...
Изге мизгел, авыр мизгел көтеп,
Зәңгәр килеш саклыйм күгемне.

Бу мизгелнең аты — Тормыш, Яшәү...
Без калырбыз җирдә уй булып...
Балаларга ачык китап кебек,
Ватан калыр, ташка уелып.

## Театр

*Әйләнә карусель, әйләнә...*
*Карусель корылган хәйләгә.*

Мостай Кәрим

Әйләнә, дөньялар, кешеләр,—
Кышларым язларга әйләнә.
Шаккатып, онытып торам мин
Йөрәгем ярасын бәйләргә.

Әйләнә авыллар, шәһәрләр,
Кайгылар шатлыкка әйләнә.
Чуалган, таралган уйларым
Тезелә шул вакыт сәйләнгә.

Сәхнәгә чыктисәм, һәрвакыт
Нигәдер телләрем бәйләнә.
Әйтерсең, язмышым шушында
Түгәрәк бәхеткә әйләнә.

Бу залга керүгә бар кеше
Иң яхшы кешегә әйләнә,—
Кайгысын калдырып урамда
Кергән күк илаһи бәйрәмгә.

Патефон табасы шикелле
Театр сәхнәсе әйләнә.
Елата, җырлата, юата,—
Театр корылган хәйләгә.

## Ирек хакына

Байракларны горур тоткан килеш
Киләчәккә таба узганда,
Утлы хәреф белән
Күңелләрдә
«Теләктәшлек» дигән сүз яна.

Шул сүзне без иманыбыз иттек,
Шул сүз белән кердек ялкынга.
Без — теләктәш барча яхшылыкка,
Безнең көрәш — Ирек хакына.

Май җилләре бар кыйтгалар буйлап
Бәйрәмнәргә дәшеп узганда,
Халыкларның күңел түрендәге
Өмет тулы хисләр кузгала.

Балкый өмет май кояшы булып,
Кошлар булып оча югары.
...Байрак итеп
Биек күтәрдек без
Җиңүләрдән торган елларны.

Сугыш, диеп, түгел, уңыш, диеп,
Домналарда койдык корычны.
Күңел домнасында
Корычтан да
Чыдам итеп койдык:
«Тынычлык».

Дуслар өчен — ачык колачыбыз,
Дошман өчен — безнең кылыч нык.
Илем байрагында өч сүз балкый:
Теләктәшлек, Хезмәт, Тынычлык!

## Мансур Вәлиев

# ДУЛКЫН

ПОВЕСТЬ

*Я*
*существую*
*на бегу!*
*Не на бегу*
*я*
*не существую!*

«Волна». М. Икбал.

Без аның белән бер бүлмәдә яшәдек.

Тәрәзәсе диңгезгә карап торган — җыйнак кына, ике кешелек кенә бүлмә иде ул...

Ял йортларында билгеле инде: кызыклы дуслар, җанга якын әңгәмәдәш табып, вакытны күңелле үткәрергә тырышасың. Ял икән, ял булсын инде, дисең...

Ә менә минем быелгы ялым бик үк әйбәт башланып китмәде. Ни өчен дисәгез... баштагы көннәрдә бүлмәдәшем бөтенләй диярлек сөйләшмичә аптыратты.

Соң, үзегез уйлап карагыз инде: иртән йокыдан торгач, мин аның белән сөйләшеп китмәкче булып берәр сүз кушам. Ә Әхнәф — бүлмәдәшем — кырт кына кисеп, кыска гына җавап бирә дә... Һәм инде шуның белән вәссәлам! Син аннан бүтән сүз көтмә инде. Ул сине оныта. Ул каядыр үз уйларына чума.

Икенче көнне мин тагын аны кузгату өчен:

— Йә, бүген нишлибез соң инде?— дип, мәсьәләне кабыргасы беләнрәк куеп карыйм.

Күршем исә битараф кына тавыш белән:

— Белмим бит!— ди дә, тагын әңгәмәдән ычкына...

Баштагы көннәрдә ике-өч мәртәбә шундыйрак хәл кабатланды.

Аннары түзмәдем, мин моннан туп-туры сорадым:

— Гафу ит, Әхнәф... Син һәрвакыт шулай аз сүзлеме??!

Минем бу сүзләремне ишеткәннән соң ул, «нәрсә дисең?» дип кайтарып сорагандай, үзенең зур зәңгәр күзләрен тутырып, акыллы, озынчарак йөзен тагын да уйчанландырып, озак кына итеп текәлеп карап торды. Чынлап та, минем нәрсә хакында соравымны аңлап җитәргә теләде, ахрысы.

Ә аннары... шактый гына вакыт үткәч, менә ни диде ул:

— Мин сезгә барысын да сөйләрмен, аңлатырмын!.. Тик әз генә... Әз генә сабыр итегез, яме...

Мин тагын да аптырый төштем.

Ни өчен сабыр итәргә кирәк?!

Ни өчен хәзер сөйләшми, сөйләшергә теләми Әхнәф минем белән?!!

...Беренче көннәрне әнә шулай аптыратты мине бүлмәдәшем.

Ә соңрак... Ә бер кичне...

Ул көнне — кич булып тәмам караңгы төшкәч кенә һәм үзендә моңарчы сизелмәгән, күренмәгән әллә нинди бер дәрт белән, сәеррәк бер ашкыну белән кайтып керде ул.

Кайтып керде, сүзсез генә ишекле-түрле йөренеп алды. Бераз утырып торды. Аннары тагын торды. Тагын бер әйләнде бүлмәне... Ә мин, аның хәзер нәрсәдер әйтәчәген сизеп, көтәм.

— Сез мине тиргәп бетергәнсездер инде... Иң әшәке кеше урынына куеп сүккәнсездер инде... Бер бүлмәдә яшәп тә җүнләп, кеше төсле сөйләшмәгәч...— Әнә шундый гафу үтенүчән, юаш тавыш белән башлап китте Әхнәф үзенең сүзен.— Ә мин бит... Мин бит үзем бер дә андый кеше түгел! Юк, һич тә андый түгел мин!

Әхнәфнең бу сүзләреннән соң хәзер инде минем үземә уңайсыз булып китте. Аңа каршы ни дип тә әйтергә белмичә, югалып калдым. Ә ул, тагын да җанлана төшеп, сүзен дәвам итте:

— Бу арада бик гыйбрәтле хәлләр кичердем мин... Әнә шулар һич башымнан чыкмый. Көн дә, төн дә шулардан аерыла алмыйм!

Бүлмәдә тынлык урнашты. Әхнәф балкон ишеге янына барып баскан. Диңгезгә таба караган. Ә мин аның әйтеп бетергәнен көтәм.

— Шул уйларымнан арынып булмасмы дип, әзрәк кенә ял итә алмаммы дип тауга менәм мин.— Биеккә, бик биеккә күтәреләм. Ә күземә таулар күренми! Чөнки күз алдымда гел теге хәлләр тора!... Аларны онытыйм дип диңгез буена төшәм. Анда бик озак йөрим. Суга чумам, әллә кайларга хәтле диңгез эченә кереп китәм. Әмма... Әмма — каршымда һаман шулар! Һаман теге вакыйгалар күз алдында! Бүлмәдә булганда да, сез миңа сүз кушып караганда да — колагым сезнең сүзне ишетә, ә башыма барып җитми ул сүзләрнең мәгънәсе. Чөнки анда — үзем белән ияреп килгән уйлар өермәсе! Алар, тимер кыршау белән кыскан сыман, мине ычкындырмыйлар, җибәрмиләр!

Әхнәфнең мондый хәвефле сүзләре мине аптырашка салды.

— Ни булды соң шул хәтле өзгәләнерлек?— дип сорадым.

Ул тирән итеп көрсенеп куйды. Байтак кына вакыт нидер көтте, кулын кая куярга белми йөдәде. Аннары, шактый озын итеп үстергән чәчләрен туздырып, кинәт кенә миңа таба борылды да — ниндидер бер зур бүләк әзерләп сөендерергә җыенган кеше төсле елмаеп:

— Сөйлимме барысын да?!— диде.— Сөйлимме?!.

Бу минутта ул — җәядән ычкынган ук, буасын ерган ташкын иде! Юк, ул минем тыңларга ризамы, түгелме икәнемне дә сорап тормады. «Сөйлимме» дип сүз әйтүендә үк инде күңеле белән бу бүлмәдән чыгып киткән булуын сиздем мин аның.

— Ләкин мин сезгә баштан ук сөйлим... Барысы да аңлашылсын өчен, тәртибе белән сөйлим.

Һәм ул ашыгучан, кайнар, рухланган тавыш белән, мине үзенең сөйләү сәләтенә гаҗәпләндерә-гаҗәпләндерә, матур-матур күренешләрне, башыннан кичкән хәлләрне берсе артыннан берсен шундый ипле итеп тәзә-тәзә сөйләп китте.

Әле менә хәзер дә күз алдымда...

Бүлмәдә инде караңгы. Мин аның йөзен, күзләрен, сөйләгән чактагы кул хәрәкәтләрен күрә алмыйм. Алар барысы да бер шәүлә сыман гына шәйләнә... Бу үзе үк төнгә ниндидер серлелек бирә, аны бүтән кич-

лардан аерып куя... Житмәсә әле ай да күренмч, шуңа күрә төн тагын да караңгырак тоела.

Минем алда — әнә шул төн караңгылыгы, диңгезнең бер көйгә салмак кына гүләве һәм Әхнәф тавышы.

Үземне ниндидер сәеррәк, әкияткә якынрак бер хәл белән очрашкандай итеп тоям. Төш белән өн арасындагы кызык кына бер халәттә утырам...

Ә Әхнәф миңа игътибар да итеп тормый. Ул үзенең күңел ташкынына инде тәмам чумган. Калган дөньяны бөтенләй дә оныткан. Сөйли дә сөйли...

Ул кичне — Әхнәфнең ачылып китүенең беренче кичендә — мин менә нәрсәләр ишеттем. Әнә шул кичтә ишеткәннәремнең барысын да түкми-чәчми сезгә сөйлисем килә.



## Беренче төн

— Менә сез шундый хәлне аңлый, күз алдына китерә аласызмы икән... Мин, Татарстанның гап-гади бер авылында туган булуыма карамастан, әле хәзер дә үземне ниндидер бер зур диңгез буенда туып, балачагым, үсмер чагым шунда үткән кебек хис итәм. Бәләкәй чагым гел зур су, ажгырып торган көчле дулкыннар, менә-менә батам дип барган көймәләр белән истә калган минем. Без, малайлар, көннәр буена, күбесенчә кичләрен дә, кайвакытларда исә төннәрен дә — гел су буенда, су янында идек. Бу инде, бүтән авыл малайлары кебек су кереп, комда кызынып яту гына түгел иде. Без үзебезнең, ә үзебезнеке булмаса күршеләрнең, яисә туганрак тиеш кешеләрнең көймәләрен алып «дошманнар»га каршы һөҗүмгә борынгы сугыш кораблары сыман бара идек, язын су баскан җирләрне айкап йөри торгач, билгесез яңа утраулар ача, үзебезне әллә нинди зур сәяхәтчеләр кебек итеп тоя идек.

Болай иркенләп йөрерлек нинди зур су икән соң ул Татарстанда диярсез, бәлки. Камага килеп кушылучы гап-гади бер елга иде ул безнең авыл яныннан аккан су. Боз китеп бераз торгач, ул бик нык ташый һәм тирә-якны каплап ала иде. Мондый чагында аның киңлеге өчәр-дүртәр чакрымга хәтле җитә. Ул бөтен урманнарны, болыннарны баса, безнең авылга да бик якын килә. Кайберәүләрнең бакчаларына үк керә. Бик бәләкәй малайлар да үзләренә кунакка килгән шул суда ялгаш белән йөриләр, сал ясыйлар, диңгезчегә әвереләләр.

Елганың әнә шулай язгы ташуын, ул ташуның да тыныч, акмый торган чагын бездә «яшут» диләр...

Зур су, диңгез стихиясе, минем күңелгә генә түгел, ә бик яшьләй үк бөтен яшәү рухыма да сеңә барган шикелле. Ничектер, минем җанның бер өлеше булып әверелгән сыман ул диңгез... Зуррак су күрсәм мин хәзер дә әллә кайчангы бер якын дустымны очраткандай, күптән сагынган ахирәтемне тапкандай сөенеп, канатланып китәм. Андый чакларда мин үземнең җаныма иң килешә торган, иң үземчә яшәү булган, иң ипле бердәнбер мөхитне тапкан кебек тоям... Су яныннан озак, бик озак китә алмый торам. Ни туры килсә шуңа утырып, я басып минем тирәк су өстенә кереп китәсем, тирәк әнә шул җанга якын стихиянең уртасында буласым килә. Әгәр чыннан да моңа ирешә алсам — миңа бик-бик рәхәт, бик-бик җиңел була. Үземне бәхетнең җиденче катында итеп тоям мин ул чак... Кайчакларда, төннәрен шәһәр урамнарында йөри-йөри, мин яр буйларына килеп чыгам, анда чылбырлап куелган көймәләр күрәм. Кайбер кичләрдә мине көймәләрнең берниндн йозагы, бигедә туктата алмый — мин аларны, ничек булса да бер җаен табып, бәйдән

ычкындырам. Әнә шул вакытларда, көймәләр белән бергә, мин үзем дә ниндидер бәйдән, чылбырдан ычкынган шикелле тоелам. Үземне иркенлеккә, үз диңгеземә, үз стихиямә чыккан сыман сизәм. Кайчакларда мин берүзем төннәр буе кап-караңгы су өстендә йөрим. Күңел булганчы, куллар талганчы ишәм дә ишәм. Аннары гына, шактый ара киткәч кенә «мин кая икән?» дип, дөньяга бер күтәрелеп карыйм...

Мондый кичләр, мәхәббәт кичләре сыман, мине тагын да дәртләндеребрәк, тагын да ашкындырыбрак җибәрә...

Миңа су, диңгез стихиясе сеңеп калуның тагын икенче бер сәбәбе дә бар бугай.

Безнең әти әнә шул киң, көчле дулкынлы суның теге ягында маллар көтә һәм ул көн саен көймә белән өйгә кунарга кайта иде. Ә үзегез беләсез — зур суның тыныч вакыты бик аз, сирәк була. Шуңа күрә, көн саен диярлек, кич җитә башласа: «Бүген дулкын ничек микән инде?», «Җил басылса ярар иде инде...», «Исән-имин генә чыга алсалар ярар иде...» кебек сүзләр безнең өйдә бик еш кабатлана иде. Алар миндә — бәләкәй кешедә — әлеге су, диңгез стихиясен тагын да көчәйтәләр, тирәнәйтәләр иде...

Әтинең төнге караңгыда, лычма чыланган брезент кожаннан кайтып керүе гел күз алдында. Кәрәчин лампасы белән сүрән генә яктыртылган кечкенә өйдә бу вакыт яңадан су, көймә һәм юеш кожан исе тарала иде...

Белмим, сезгә бәлки болар кызык та түгелдер, әмма мин үземнең шәхесемнең, характерымның башын, җеп очын әнә шуларда күрәм. Күрүдән дә бигрәк, алар белән үзем арасында сүз белән әйтеп бирүе кыен булган ниндидер нечкә, серле бәйләнеш тоям.

Беләсезме, минем хәзер бу хакта үземчә фәлсәфәм дә бар. Табигатьне һәм, гомумән, авыл тормышын бик оста, акыллы тәрбияче дип саныйм мин. Ни өчен? Чөнки авылда, табигать эчендә кеше бәләкәйдән үк бик күп төрле катлаулы бәйләнешләр эчендә яши. Табигый чынбарлык аңа бик күп төрле юллар белән секунд саен, минут саен тәэсир итеп тора, кеше кечкенәдән үк әнә шундый табигый чынлык рухында тәрбияләнә, калыплаша. Бу аны ниндидер бер тарлыктан, дөнья хакында өстән һәм җиңел генә фикер йөртүдән саклап кала.

Менә үзегез уйлап карагыз: авыл җирендә бала тәпи йөри башлау белән йомшак яшел үләннәр, яфраклар, кешене иркәләгәндәй генә кагыла торган куак-агачлар дөньясында яши. Аларның йомшаклык, матурлык тараткан һәр хәрәкәте, лепердәве кечкенә кешедә ирексездән шундый ук йомшаклык, иплелек тәрбияли бит... Ә ташлар, каты-каты корпуслар, кискен һәм ашыгыч хәрәкәтләр, табигый булмаган көчле тавышлар арасында үскән шәһәр баласына, билгеле, кечкенәдән үк икенче төрле яшәү рухы сеңә, шул көчәя анда. Башында акыл, фикер йөртү сәләте тиз үсә, ә эчке табигате дөньяның сүз белән әйтеп бетереп булмаган олы бер чынбарлыгыннан ниндидер күзгә күренмәгән киртә белән аерылган була.

Шәһәр тәрбиясенең бик тирәнгә яшеренгән әнә шундый тарлыгын, бер бик кирәкле бәйләнеш җебеннән мәхрүмлеген шактый зур эшләр эшләгән атаклы гына кешеләрдә дә күргәнем бар минем. Алар — акыллары белән ничек кенә тырышсалар, омтылсалар да дөньяның олы табигыйлеге белән табигый рәвештә тоташа, аның белән бер җан булып яши алмыйлар. Һәрчак тырышулары гына тырпаеп кала. Ә табигый ялгану үзе килеп чыкмый. Табигать белән табигый берлек, бербөтенлек килеп чыкмый...

Әйткәнемчә, минем бәләкәй чак күбесенчә су, урман, болын арасында үтте.

Аннары аңа шундый ук көчле икенче ташкын килеп кушылды. Аныcы китаплар, әдәбият дөньясы иде. Мин мәктәпкә кергәнче үк укырга

өйрәндем. Авыл клубы янында олыларның көлә-көлә миннән кино афишасы укытулары истә калган. Әдәбият дөньясына чуму, кулыма эләккән бөтен китапны рәттән укый башлау, алардан аерыла алмау мине — моңарчы табигать кочагында, аның тәрбиясендә үскән кешене — тагын да баетты, күңелемне тагын да үсендерде. Үзем укыган китаплардагы бик күп яхшы кешеләр, аларның тормышы, аларның якты гомере минем күз алдымда чын-чыннан якты маяк сыман булып балкый башлады... Әйе, әйе — алар мине бик нык тәрбияләделәр!

Ләкин менә тагын бер кызык кына хәл. Кышын укуга никадәр нык чумган булсам, җәй җитү белән шулай ук ашкынып колхоз машинасына чаба идем. Без, классташ малайлар, май ахырлары җитүгә, инде үзебезгә машиналар бүлә башлый идек. Кем кайсы машинада йөкче булып йөриячәк, ягъни... Бу безгә колхоз эшләренең иң ошаганы иде.

Йөк машинасында җиңел түгел, билгеле. Анда бик авыр йөкләр ташырга да туры килә. Карьердан зур-зур ташлар, урманнан озын-озын бүрәнәләр, амбардан авыр-авыр капчыклар ташу — һәммәсе дә була. Әмма машина, барыбер, безнең йөрәкләрне җилкендерә, ашкындыра иде. Кирәкле йөкне тиешле урынга илткәч, кайткан чагында, машина әрҗәсендә бик зур эш кырган кыяфәттә, горур төстә кайтулар бик нык хәтеремдә минем. Менә әле дә күз алдымда: машина кызу тизләктә алга оча, җилләр уйный! Ә син, кабина өстенә чыгарып куелган тотынгычка чытырдап ябышкансың да, шулай ук алга очасың! Мине кеше күрә микән, дип як-якка да карап аласың... Бәхет иде, бәләкәй чакның иң зур бәхете иде безгә мондый көннәр, айлар!

Менә хәзер, искә төшергәндә, шуны уйлап куям. Җәйләрен зур тизлектә чапкан әнә шул машинада җилдерүләр дә, язларын диңгез булып ташыган су эчендә көймәдә йөрүләр дә — болар һәммәсе дә минем йөрәкнең ниндидер бер олы ашкынуын канәгатьләндерәләр, шул ашкынуга җавап бирәләр иде!

Әнә шул вакытларда, әнә шул чакларда мин ниндидер үзгә бер бәхет — канатлы булу бәхетен татыдым бугай! Канатлы булу — очу һәм йөзү бәхетен татып калдым бугай...

## Икенче төн

Үзенең кичә сөйләгәннәре белән Әхнәф мине бер ташкын эченә алып кереп киткән шикелле булды. Гүяки мин дә аның сыман зур су буенда туганмын да, гүяки мин дә үземә диңгез рухы, давыл рухы — мәңгелек тынгысызлык рухы сеңдергәнмен...

Икенче кичне Әхнәф сүзен дәвам итте.

— Авыл табигате минем күңелгә канатлы хисләр, якты тойгылар салып кына калмады. Ул мине әйбәт кенә итеп баянда уйнарга да өйрәтте...

Җәй көннәрендә без, малайлар, яшьләргә ияреп колхоз печәнен чабарга Каманың аргы ягына чыга идек. Печәннән куышлар корып, бер айга якын шунда яши дә идек. Иә ат белән чүмәлә тарттырабыз, янсә шунда сәнәк тотып күбәләрне берләштерәбез... Бусы көндез, эш вакытында... Ә кичләрен безнең куыш яны фантастик әкиятләрне хәтерләткәндер!

Безнең куышлар Кама буена утырган. Егерме биш-утызлап куыш. Чын бер авыл кебек... Кич белән ашап-эчкәч, караңгы төшкәч, учак тирәсендә түгәрәк уеннары кызып китә. Мине теләсә каян эзләп табалар

да, гармуным белән бергә арбага китереп утырталар! Шундагы печәнгә утырып төн буе уйна син! Кайчагында гына алмаш баянчы табыла да, җиңел сулап куясың, яшьтәшләрең янына ычкынасың...

Әй, ул кичләр!

Әй, ул җәйге кичләрдә бездә кайнаган хисләр! Аларны әйтеп кенә, сөйләп кенә бетереп буламы соң?!!

Озак кына күңел ачкач, яшьләр төрлесе төрле якка таралыша. Әбез — малайлар, яшүсмерләр — төнге Кама яры буенда үзебез генә калабыз... Үзебезгә өр-яңадан учак ягабыз! Ләкин инде бусын су буена ук китереп ягабыз... Һәм әнә шул учак янында, гаять киң дәрья янында, бик озак утырабыз... Төнге Каманың тынлыгын бозып, ял-якты пароходлар узып китә. Алар узганда без бар дөньябызны онытып, илаһи бер күренешкә тап булгандай әсәрләнеп, тып-тын калабыз. Ул минутларда безнең йөрәкләр әллә нинди билгесез җепләр аша әнә шул якты пароход, якты могҗиза белән бәйләнеп өлгерә! Төн караңгылыгын әкрен генә ерып барган ул якты пароход — үзе белән безнең күңелләрне дә алып китә... Еракка, әллә кайларга алып китә. Безнең каядыр китүебезне, каядыр йөзүебезне раслагандай, тирә-юнебездә дәрья дулкыннары чупылдаша, алар тавыш бирә. Без инде тәмам олы дәрья эчендә итеп тоя башлыйбыз үзебезне, аның уртасында итеп!

Шулай әсәрләнеп озак, бик озак утырабыз...

Аннары инде әкренләп җиргә төшәсең... һәм үзең әле генә тойган, сизгән каядыр йөзү, очу хисен югалтырга теләмичә — шул бөек бәхеттән аерылырга теләмичә — гармуныңа тотынасың! Чөнки, эчебездәге хисләр туктап калырга, тик торырга теләми! Алар ярсый-ярсый алга омтыла!

Кама исемле әнә шул олы дәрья яры буйлап, төн караңгылыгында, инде без, яшүсмер малайлар, җырлый-җырлый атлыйбыз:

Су өстендә дулкын ничек —<br>Безнең шундый чагыбыз!

... Менә шул баян белән торган саен ныграк җенләнә бардым мин. Шуның буенча укырга да кердем. Казанга, культура институтына. Мәктәптән соң ике ел армиядә булып кайткан идем, укырга керү әллә ни кыен тоелмады анысы...

Ә инде студент чак — иң якты елларым минем!

Әллә нинди зур-зур эшләр уйлап чыгара, оештырып җибәрә һәм гадәткә кертә идек без!

Менә хәзер мин кайта-кайта, кабат-кабат уйлап карыйм: укыган елларда боларның барысы да кирәк булдымы икән? Башкача, бүтәннәр кебек — укып һәм күңел ачып кына яшәп булмас идеме икән ул чак? Искә төшерәм һәм янә дә шуңа ышанып куям: юк, ул вакытта янып, дәртләнеп, ашкынып яшәмәгән булсак — бездән бөтенләй икенче кешеләр, тиешле сәгатьне эшләү белән дөнья һәм кеше кайгысын оныта торган затлар чыккан булыр иде!

Авылда яшәгән чагында көймәдә йөрүләр, машинада җилдерүләр мине ничек канатландырган булса, студентлык чоры, югары белем алу — ул канатларны үстерде, ныгытты.

Ә соңгы курста көтелмәгән хәл килеп чыкты.

Диплом яклап йөргән көннәрнең берсендә группа җитәкчебез мине чакырып алды да:

— Яшьләр газетасында эшлисең килмиме? — диде.— Культура бүлегенә кеше кирәк аларга.

Аяз көнне яшен яшьнәгән кебек тоелды бу миңа. Газетада сирәк-мирәк мәкаләләр бастыргаласам да, һич уйлаган нәрсә түгел иде бит!

Ә группа җитәкчебез күзгә карап тора. «Әйдә, тиз уйла, син егет кеше — тиз хәл итәргә тиеш!» — дип, салпы якка салам да кыстыра.

Тәки килештем бит мин бу тәкъдимгә! Институт белән саубуллашкач, эшли дә башладым.

Әмма...

Ярый, алайса, бусын да үз тәртибе белән сөйлим инде.

Ул болай булды. Безнең редакциягә бер авылның яшьләреннән хат килде. Гадәттәге һәм шактый еш очрый торган хат иде ул. Яшьләр үз авылларында клуб, китапханәнең начар эшләвеннән зарланалар, безнең берәр төрле ярдәм итүебезне үтенәләр. Редакция андый хатларны тикшереп чара күрү өчен күп чагында район җитәкчеләренә җибәрә, алардан җавап көтә. Чөнки бөтен хатны да урынга барып тикшереп йөрергә редакциянең кешеләре дә җитми, һәр хат газета өчен яңа материал да бирә алмый.

Ә бу очракта исә журналистларның ул районда байтактан булмавы ачыкланды. Барырга кирәк иде, чөнки районнар белән элемтәне өзмәү— һәр редакциянең иң беренче бурычы. Командировкага мин киттем.

Бардым, авылның күп кенә егет һәм кызлары белән сөйләштем, җитәкчеләрен күрдем. Хатта язылганнар, чыннан да, дөрес иде. Клубта да, китапханәдә дә олы яшьтәге апалар эшли. Алар инде билгеле, дәртләнеп йөрмиләр, теге-бу сәбәп чыкса, күбрәк өйдә булу ягын карыйлар. Яшьләрнең: «Кичен кая барыйк?» — дип борчылулары инде алар өчен бармы-юкмы диярлек...

Мин барганда колхоз председателе үзе өйдә юк иде, ә аның урынбасары әллә нинди: бүгенге көн бурычларын бик өстән генә аңлаучы булып тоелды миңа. Ул ике сүзнең берендә күргәзмә агитацияне телгә ала. Әйтерсең, аның белән генә барысын да хәл итеп була?! Клуб та, китапханә дә менә дигән итеп бизәп куелган, ә кешеләр белән җанлы эш бармый, клуб үзе бик сирәк ачыла. Шулай булгач, ул күргәзмә агитациянең кешеләргә ничек тәэсире булсын инде... Һәм ничек авыл яшьләре канәгать яшәсен?!.

Казанга кайткач, үземнең шушы уйларымның барысын да кертеп газетабызга зур гына мәкалә яздым. «Яшьләргә ни җитми?» дигән исем белән ул озакламый басылып та чыкты.

Мәкалә дөнья күреп берәр атна чамасы вакыт үткән иде — редакциягә теге районның комсомол райкомыннан хат килеп төште. «Сезнең мәкаләгез һәм анда күтәрелгән мәсьәләләр комсомол райкомы пленумында тикшереләчәк. Авторның катнашуын сорыйбыз», — диелгән иде анда. Бу инде безнең өчен гадәти булмаган, сирәк очрый торган күренеш иде. Үз мәкаләсе буенча район күләмендә җыелыш үткәрелү— һәркем өчен бик зур шатлык. Мин дә үземә бер төрле горурлык хисе тоеп киттем ул районга.

Пленумны, чыннан да, зурдан җыйганнар иде. Районның күп кенә җитәкчеләре чакырылган, партия райкомының икенче секретаре да килгән.

Әмма, оештырылуы шулай зурдан булса да, баштагы чыгыш ясаучылар мәсьәләнең бик эченә кермичә, бөтен кешегә билгеле фикерләрдән, теләкләрдән узмыйча — шома гына чиратларын уздырдылар...

Ә бит, чынлап карасаң, райондагы бик күп эшнең нинди хәлдә булуы нәкъ менә шушы кешеләрнең үзләреннән тора! Алар исә кемдер бүтән берәү хәл итәргә тиеш төсле сөйлиләр. Ачык кына итеп берсе дә үзенең ни эшләячәген, нинди конкрет өлеш кертәчәген әйтми.

Әлеге мин язган колхозның председателе генә башта ук үгезне мөгезеннән алып сөйли башлады. Ничектер, бер күрү белән мин бу кешегә ышандым. Шулай була бит ул: кайчак бер күрүдә кешенең кем икәнен аңлап аласың, аның нинди адым ясый алу мөмкинлеген чамалыйсың, аннан нинди яхшы һәм начар эшләрне көтәргә һәм көтмәскә мөмкин икәнен беләсең...

Юк, ул минем мәкаләне мактамады. Кайбер җитәкчеләр судан коры

чыгу өчен үтемле хәйлә кулланалар, авторны мактыйлар. Ә автор тө-зәтергә теләгән төп мәсьәлә андый вакытта бер читтә кала.

Мин ике колагымны торгызып бик игътибар белән тыңлап утырган-да, ул һич көтелмәгән сүзләр әйтте:

— Безне менә шунысы борчый — өйрәтүчеләр күп, ә менә алынып эшләр кеше юк... Шунда җиткәч, көймә килә дә терәлә! Инде мин үзем дә аптыраган: нишләргә, кемне куярга?

Председатель әлеге соравыннан соң тынып калган иде, шул арада партия райкомы секретаре үз сүзен әйтеп куйды:

— Иң зур колхоздан бер кеше таба алмау — бик гаҗәп!

— Болай карасаң, кешесе дә бар инде аның, Кәрим Сөнгатович... Тик менә күңеле шул эшкә ятып торганы юк бит, нишләтәсең... Аның бит кайбер җирләрдә «җене кагылган» кешесе була, бөтен эш шул бер кеше аркасында җанланып, гөрләп китә...

— Менә син үзең шундый бирәү бул! Тик колхозыңны да тарт, яшь-ләр белән дә эшең гөрләп торсын!

Бусын секретарь ачулырак итеп, кырыс тавыш белән әйтте. Аңа каршы председатель бернинди дә җавап кайтара алмады.

— Я, инде нәрсә дибез? Әнә, журналист иптәш бик дөрес язган — кешенең күңел дөньясын һич тә онытырга ярамый. Без, хуҗалык эшлә-ре белән бергә, ул турыда да кайгыртырга тиеш!

Райком секретареның бу сүзләрен әллә ничек, үземә төрттерү сы-манрак кабул иттем. Әйтерсең ул: «Язуы җиңел дә аны, ә менә кем эшләр, хәлне кем төзәтер?» — дип сорый иде... Колхоз председателе әле бая гына әйткән сүз дә искә төште — «өйрәтүчеләр күп ул...»

Болар барысы да мине бик кыен хәлгә куйды. Үземнең ни өчендер кызара баруымны тойдым. Ниндидер бер ялганда, дөрес булмаган эштә тотылган кебек күренде миңа үз хәлем. Әле аңарчы мондый авыр хәлдә калганым юк иде шикелле...

Шунда, үзем дә ныклап уйлап, алдын-артын үлчәп өлгермәстән, президиумда утырган урынымнан сикереп тордым да, кирәгеннән артык ук кычкырып — анысы, күрәсең, эчтән бик киеренке утыруым нәтиҗә-се булгандыр:

— Үзем барам! — дидем. — Үзем эшлим шунда!!

— Туктагыз әле... Сез бит Казанда эшлисез, редакциядә... Сез — безнең карамактагы кеше түгел...

Көтелмәгәндә килеп чыккан бу хәлдән райком секретаре бер мәлгә үзенең дәрәҗә саклап сөйләшүен дә онытып җибәрде сыман. Аның тавышы гади кешенеке шикелле акрын гына чыкты һәм җылырак бу-лып ишетелде.

Бернинди алдан уйлап кую, әзерләнү булмаса да, мин үземнең дө-реслегемә, үз күңелем кушу буенча эшләгәнемә нык ышанган идем. Шуңа күрә әз генә тынычрак тонда, инде бераз сүрелә төшеп:

— Ничек енә булса да әлегә мин үземә үзем хуҗа,— дидем.— Теләгән эшемне эшли алам дип уйлыйм.

Комсомол райкомының беренче секретаре да минем сүзне ныгытып куйгандай итте:

— Кәрим Сөнгатович... Әгәр дә... Әгәр дә журналист иптәш әлеге сүзләрен чынлап, барысын да уйлап әйткән икән... Ул чагында без аны бик шатланып культура йорты директоры итә алыр идек!

Аннары, тагын күпмедер вакыт сүзсез генә басып торгач:

— Нигә, Кәрим Сөнгатович, әгәр дә кеше үзенең сүзен эш белән ныгытырга тели икән — бу бит бик яхшы! Минемчә, бик шәп теләк бу! — диде.

Кәрим Сөнгатович елмайган иде аның шул сүзләреннән соң...

Хәзер күп нәрсәне яңадан искә төшереп, күп нәрсәне кабаттан уй-лап карыйм... Чыннан да, газетада үзем язган әйбер басылып чыккач

миңа еш кына, бик еш кына нәрсәдәндер уңайсыз була иде... Мактап язылган мәкалә булса — син кеше эшләгәнгә кул чабып кына йөрисең кебек тия, үзең җиң сызганып шул эшне эшләргә тиеш идең сыман тоела... Тәнкыйтьләп язсаң — шулай ук, иң башта үзең шул өлкәдә кеше күзенә күренерлек эш майтарырга кирәктер шикелле...

Әлеге пленумда мине аяк өсте бастырып, үзем дә көтмәгән сүзләрне әйттергән көч, мөгаен, үз-үземә ныклап ышанасы килү, бер җиң сызганып эшләп аласы килү булгандыр, дип уйлыйм мин бу турыда хәзерге акылым белән...

Хәтерлисезме икән, мин сезгә үземнең бәләкәй чагымнан ук килгән бер омтылышым, гадәтем хакында әйтеп үткән идем... Зур сулар күрсәм, аңа кереп китәсе килә, шул стихиягә кушыласы килә дигән идем... Биредә дә шулай булды, ахрысы... Күңелемә күптән үк якын булган ташкын — эш ташкыны әнә шулай үзенә суырып, тартып алды сыман мине... Мин рәхәтләнеп, үземдәге зур сусауны канәгатьләндерүдән ләззәт таба-таба, бик тансыкланган әлеге диңгезгә, яңа ташкынга кереп киттем...



## Өченче төн

Әхнәфнең сөйләгәннәре мине бер яктан сокландырса, икенче яктан аңлашылып та җитми, гаҗәпләндерә дә... Чыннан да, аның тынгысыз күңеле, гел эшкә, гел хәрәкәткә ашкынган йөрәге — миңа бик аңлашыла, миңа бик якын тоела. Ә менә Әхнәфнең бик тиз арада үз тормышын шундый нык үзгәртердәй карар кабул итүен мин тиз генә аңлый алмадым. Бу нәрсәнең төбендә, нигезендә ни ятканын тиз генә төшенә алмадым...

Әхнәфнең өченче хикәятен мин әнә шундыйрак халәттә тыңлый башладым.

— Күптән түгел минем йөрәк авырта башлады. Бу мине бик курыктты. Әйе, әйе, яшермичә һәм ихластан әйтәм — бик курыктым мин моңа. Ул миңа әллә нинди бер кисәтү, куркыныч бер янау булып тоелды. Һәм шул көнне мин, бөтен ашыгыч эшләремне баштан чыгарып ташлап, аларны күпмедер вакытка үз өстемнән атып бәреп, үткәннәрнең барысын да искә төшереп, уйлап утырдым. «Нишләп? Нәрсәдән? Ни сәбәпле?» Шул сорауларга җавап эзли-эзли мин шактый еракка барып чыктым. Бик күп вакыйгалар минем күз алдымда әкренләп бер җепкә тезелделәр.

Мин гомерем буе диярлек әллә нинди — йөрәкне гел борчый, тынгысызлый торган нәрсәләр белән мавыкканмын икән...

Менә хәзер кызык та, көлке дә кебек тоелган, ләкин минем яшәүне аңлатырдай мәгънәгә ия бер генә нәрсә: башлангычта укыганда беркем әйтмәстән, өйрәтмәстән, үзебезнең оч бала-чагаларын җыеп, безнең алма бакчасында зал һәм сәхнә ясый идек тә — концертлар, спектакльләр куя идек... Ә кыш көне — өйдә. Безнең өй түрендә оик зур сәке бар иде. Бер стенадан икенчесенә чаршау тартып куясың да — чын клуб була! Безне карарга бөтен күрше хатыннары җыела иде.

Ә үсә төшкәч, мәктәптә үзеннән-үзе комсомол эшенә чумылды. Ничектер, мин бөтен шундый мәшәкатьләргә үзеннән-үзе барып кергәнмен... «Нәрсә бу, нинди сыйфат бу?» — дип уйлыйм мин хәзер еш кына. Яхшы нәрсәме бу, әллә ниндидер көчәнү, ясалмалык бармы монда? Ни өчен мин гади генә булып, тыныч кына йөрмәгәнмен? Алай итсәң, мөгаен, үзеңә әйбәтрәктер бит?!

һәм әнә шул «әйбәтрәктер» дигән сүздә шикләнеп, яңадан туктап калам. «Әйбәтрәктер...» Ничек итсәң ни төсле әйбәт буласын һәм ул «әйбәт»нең чынлыкта ни дәрәҗәдә әйбәтлеген каян, нәрсәгә карап белеп була соң?

Әллә кешенең бәләкәйдән үк башланган, шуннан ук сузылып киткән үз юлы буламы икән? Кеше әллә шул юлга башта ук килеп эләгеп, аннары бөтен гомере буена алга таба атлый гына микән? Әллә кешеләрнең канында ук аларның гомер юлларының башы, очы салынган була микән? Кеше үзенең акыл хөкеме белән генә аны үзгәртә алмый микән әллә?

Унынчыда укыганда классташларымны оештырып, мәктәптә Чайковский, Есенин, Такташ кичәләре үткәреп йөрүләр... Авыл җирендә аларның әсәрләрен табып, изге бер дога ишеткәндәй, онытылып тыңлап утырулар... Музыка һәм сихри тынлык тәэсире... Шигърияткә мөкиббән китеп тын калу... Юк! Болардан башка мин бөтенләй икенче кеше булыр идем. Яшьлектә болар миңа канат булган икән! Әнә шулай үткән һәр матур көн безне югарырак күтәргән икән!

Аннары, мәктәпне бетергәч, армиядә дә бу эш белән миңа тынгы булмады. Рота комсоргы итеп куйдылар. Тагын көн-төн чабарга туры килде. Кызыклы чаралар башымда бер-бер артлы туып кына тора, ә аларның һәммәсен үтәп чыгу өчен никадәр көч салырга кирәк! Ләкин егетләрнең армиядәге кырыс тормышын күңелле итәсе, авыр хезмәтен җиңеләйтәсе килү барысын да онытгыра. Аларның җылы карашын да сизсәң, тагын да дәртләнеп китәсең!

Беләсезме, мин үземдә шундый кызыклы бер үзенчәлек барлыгын сизәм. Мин болай, гадәти шартларда кешеләр белән авыррак аралашам, бу миңа кыенрак бирелә. Ә менә нинди дә бер олы эш, олы хәрәкәт вакытында кешеләр белән бик нык якынаеп китә алам... Белмим, моның сере нәрсәдә? Әллә бу, гомумән дә, кешеләргә хас нәрсәме икән? Әллә эчке тормышның активлыгы арту кешеләрне бер-берсенә ныграк якынайта микән? Югарырак күтәрелгән саен кешеләр нинди дә бер уртак матурлык ноктасына якыная төшәләрме икән әллә?

Менә мин сезнең белән дә көндез бөтенләй аралашмыйм, сөйләшмим, диярлек. Чөнки сөйләшер сүз таба алмыйм, нәрсәдән тотынып башларга белмим... Монда, ял вакытында берсе дә әһәмиятле түгел сыман, кызык түгел шикелле. Аннары көндезге әрсез яктылык миндәге эчке кыюсызлыкны тагын да арттыра, минем ачылырга, күренергә ымсынган нечкә, йомшак омтылышымны куркыта... Ә төн, караңгылык миңа үзенең ипле акырынлыгы, ашыкмау-каударланмавы, артык ачыклык, конкретлык таләп итеп кешене кыенсытмавы, аптыратмавы белән үз һәм якын тоела... Төн ул кеше эчендәге акыл аңлап җитмәгән хасиятне дә ача бугай...

Сүземне йөрәк авыртудан башлаган идем. Менә хәзер уйлап куям: гадәти кешегә бик үк хас булмаганча, ашкынулы хәрәкәттә генә ачылып, шул стихиядә генә үз булып, шунда гына иркенләп яшәвем нәтиҗәсе микән әллә бу? Кеше бит алай яшәү өчен яралмаган! Мин табигатьнең, җир кешеләре тормышның нинди дә бер канунын боздым микән әллә болай яшәвем белән?

## Дүртенче төн

Әхнәфнең сөйләгәннәре миңа торган саен кызыклырак тоела бара. Күбесе үземнең дә күңел түрендә йөргән уйларга килеп ялгана. Еш кына мин эчемнән Әхнәфкә кушылып китәм, аның белән бергә уйлана яки бәхәсләшә башлыйм.

Кайвакытларда мин бу егетнең бүгенге тормыштагы олы бер вазифасын да күргән төсле булам. Аңа кешеләр көткән, алар өчен кирәкле

булган бер мөһим эш тапшырасы килеп китә. Әнә шул эш аның күңелендәге бөтен уйларын тормышка ашырыр, аның үзенә иң олы канәгатьләнү китерер һәм безгә дә аның кем икәнен, нинди көчкә ия икәнен ачык күрсәтер шикелле...

Әхнәф үзенең әнә шундый — мин уйлаганга якын эшкә тотынуын әйтсә дә, әле бу турыда сөйләргә ашыкмады... Башта үзе килгән колхозның председателе белән таныштырып үтүне кирәк санады ул.

— Председатель Назыйм абыйга беренче күрүдә үк игътибар иттем мин... — дип сөйли башлады ул. — Әйе, әйе, ул бүтәннәрдән шактый аерылып тора иде... Нәрсәсе, кайсы ягы белән? Мөгаен, башта ул мине үзенең бүтәннәр кебек шома сөйләмәве белән җәлеп иткәндер. Әйткән идем бит: теге пленумда мәсьәләгә конкрет якын килүче дә ул булды.

...Ә безнең беренче сөйләшүне күрсәгез икән сез! Юк, әлеге пленумда түгел — мин авылга баргач...

Казанга кайтып, хәлне аңлату һәм эштән китү әллә ни күп вакытны алмады.

Мин үземнең чемоданымны күтәреп Назыйм абыйлар колхозына — Җиләкле авылына килдем. Көн кичкә авыша башлаган иде инде. Шуңа күрәме, колхоз идарәсе бушабрак калган. Ләкин Назыйм абый минем киләсене онытмаган. Бухгалтерлар бүлмәсендә нидер исәпләп утыручы апа, минем кем икәнне белү белән:

— Әй-әй, җаным, кем киләсе бар икән дип торабыз... Назыйм абыең шул хәтле дә кайгыртты синә әйбәт фатир табу өчен... Аңа тегесе дә ошамый, бусы да бармый. Сайлый да сайлый инде менә...— дип сөйләп китте. Ә үзе күзен дә алмыйча мине тикшерә, мине күзәтә. Минем кем икәнне, нинди кош икәнне белергә тели. Ә мин нишлим инде — тик торам елмаеп һәм хисапчы апаны тыңлыйм...

— Сайлый торгач, тәки таптык бит менә дигән фатирны. Нәгыймәттәйне таптык. Назыйм абыең берсүзсез килеште... Хә-ә-зер сине шунда алып барам...

Чынлап та, бик тыныч, әйбәт апа булып чыкты Нәгыймәттәй. Ул мине үз улы кебек күреп дигәндәй каршы алды. Соңыннан да безнең аның белән бер-беребезне борчыган, ачуландырган чагыбыз булмады.

Назыйм абый кичен, нәрәт азагында, идарәгә килергә кушкан икән. Хисапчы апа шуны әйтте дә, саубуллашып чыгып китте.

Нәгыймәттәйнең өе зур гына, бер почмагы чаршау белән бүлеп куелган. Чишенеп, әзерәк ятып тордым... Ә Нәгыймәттәй үз алдына сөйләнә-сөйләнә, өй эшләрен карап йөри:

— Бигерәкләр дә берьюлы башлады шул Назыйм. Барысын да берьюлы башлады... Әкрен-әкрен генә үзгәртсә булмас не микәнни соң ул. Болай үзенә кыен бит бигрәк. Үзенә авыр бит балакайның...

Мин дә иплән кенә сүз кыстырып куям:

— Бер тотынса берәгәйле тотына торган кешедер инде ул алайса...

Нәгыймәттәй арлы-бирле йөри-йөри генә сөйләшсә дә, минем сүзләрне дә колагыннан ычкындырмый икән:

— Шулай шул, шулай шул... Шундый тынгысыз нәсел инде алар! Атасы мәрхүм дә гел иң авыр эштә булыр иде...

Әйе, Нәгыймәттәй дөрес әйтә — без барыбыз да үсә барган саен үзебезнең әтиләребезгә охшаганлыкны ныграк сизә, тоя барабыз. Зур бер эчке горурлык белән тоябыз без ул хисне!

... Кышкы көн озакка бармый инде ул. Тиздән караңгы төште. Авыл өйләрендә ут алдылар. Әзрәк торгач Нәгыймәттәйнең ашы да пешеп җитте. Ашап алдык та, идарәгә киттем. Ләкин иртәрәк килгән булып чыктым. Әле нәрәт бирү башланмаган да иде.

Коридорда бер төркем ир-ат басып тора. Араларында Назыйм абый

да бар. Ул кара материя белән тышланган калын тунын ычкындырып җибәргән, бүреге кирәгеннән артык арткарак авышкан, ләкин башында нык утыра, нык итеп басып киелгән... Гәүдәгә уртача гына буйлы. Бүгән председательләр төсле бик үк калынаерга да өлгермәгән әле...

Мин килеп кергәнче ул нәрсәдер сөйләп торган ахры — бөтенесе дә аңа таба караган иде.

Ул мине ишектән керү белән үк күреп алды. Сөйләп торган җиреннән туктап, елмая-елмая миңа таба килде.

— Менә, хәзер безгә Казан үзе ярдәм итә башлады инде! — диде.

Елмайган йөз, ачык чырай белән әйтсә дә — бу сүзләргә зур мәгънә салуын, минем колхозга килүемә бик зур әһәмият бирүен аңладым...

Гадәттәгечә, ничек килүем турында, ничек урнашуым хакында сорашып алды ул.

Алданрак, нәрәт башланганчы килүем дә бик ошады аңа:

— Тагын да шәбрәк! Безнең нинди эшләр белән кайнашканны беләерсең! Ә культура ул — башка зур эшләр белән бер фронт итеп алып барылса яхшы! Шулай бит? — Үзе ихластан елмая, килешәме-юкмы икәнне беләсе килеп миңа карый, шул арада бригадирларга да күз йөртеп ала.

Шулай түгелме соң! Әлбәттә, шулай! Тик бу кадәр халык алдында бераз югалыбрак калуымны сизепме, Назыйм абый тагын үзе дәвам итә:

— Менә синең армиядә булганың бар бит?

Мин: «Каян белгән ул моны?»— дип эчтән гаҗәпләнәм дә:

— Әйе, бар!— дим нык иттереп.— Хәрби өйрәнүләр әле дә истә.

— Алай булгач син бик яхшы беләсең: һөҗүмгә барганда фронтның бер флангысы арттарак калса яисә йомшаграк булса, ул бүтәннәргә дә шундук сизеләме?

— Сизелә билгеле... Әле шуның аркасында, алга бара-бара чолганышта калуың да бик мөмкин!

— Менә культура мәсьәләсе дә шулайрак, егетләр: аның артта калуы бүтән эшләрне алга җибәрергә тырышканда шундук сизелә!

Назыйм абый сәгатенә күз төшереп алды. Күрәсең, нәрәтне башлар вакыт җиткән иде — ул тунын салып, элгечкә элде. Башкалар да чишенделәр. Мин дә өсне салдым.

Колхоз идарәләрендәге нәрәт бирү — тәмәке төтене белән тулган бүлмәдә утыручы ир-атлар булып хәтердә калган. Биредә дә шундыйрак хәл күрермен кебек иде. Әмма, председатель кабинетына кереп, барыбыз да өстәл янына утырышкач — мин бөтенләй башка нәрсә күрдем. Өстәл тирәсендә пөхтә һәм культуралы итеп киенгән, кирәк булса дип кесә дәфтәрләрен алып куйган җитди эш кешеләре утыра иде.

Назыйм абый үзе түрдә, өстәлнең икенче башында тыныч кына блокнотын актара... Менә ул бер биткә тукталды. Шул битне яхшылап ачып, үз алдына салды.

— Алайса, башлыйбыз, иптәшләр...

Председательнең әлеге сүзләреннән соң, ул үзе сөйли башлый инде дип торсам, көтмәгәндә, аңа якынрак, түрдәрәк утырган абый аягүрә басты да кыска гына, конкрет җөмләләр белән сөйләп китте:

— Кичә бирелгән нәрәт буенча беренче бригадада түбәндәге эшләр эшләнде... Алма бакчасын әйләндереп алу өчен җитәрлек санда бетон баганалар алып кайтылды, тиешле урыннарына бушатылды. Тимер челтәр белән тоткарлык килеп чыкты әле — анысы бүгенгә булмады... Яшелчә бакчасының коймасы төзәтелде, бүтән ремонт эшләре дә башкарылды. Кичә басуларга билгеләнгән күләмдә ашлама чыгарылды. Нормадан ун гектар артыграк мәйданда кар тотылды...

Бригадир шулай итеп тагын байтак эшләрне санады.

Аннары икенче бригадир торып, хәрбиләрчә кыска хисап бирде.

Өченче һәм дүртенче бригадалар эше дә тыңланды. Мин шушындый эшлекле сөйләшүгә сокланып утырдым. Кара син ә, нинди шәп форма! Кичә сөйләшенгән сүзнең чынга ашуы менә ничек конкрет тикшерелә. Җаваплы иптәш үзе үк шул хакта хисап бирә...

Тыңлап утыра-утыра мин шуңа игътибар иттем: бу идарә утырышында минем өчен ятрак тоелган, ничектер без укып-ишетеп иялэнмәгән эшләр турында сүз бара иде. Без бит колхозларны күбрәк кырчылык һәм ферма белән генә шөгыльләнә дип уйларга күнеккәнбез.

Ә биредә мин нинди эшләр турында гына ишетмәдем! Якындагы тау битендә алма бакчасы булдырырга карар кылынган икән — әлеге бетон баганалар, тимер челтәрләр шуны әйләндереп алу өчен икән!

Җиләкле авылы бик матур су буена утырган. Былтыр шул суны да будырган икән колхоз. Буага балыклар җибәрелгән. Җаваплы кешеләре билгеләнгән. Утырышта ул хакта да сүз чыгып алды.

Умарталыкка ярдәм хакында да киңәшеп алдылар. Анда ремонт эшләре бара икән.

Бригадалар хисап биреп бетергәч, Назыйм абый миңа тагын бер күз салып алды да, әле моңарчы сөйләмәгән бер егеткә мөрәҗәгать итте:

— Безнең культура йорты кайчан өлгерә инде, Сәлим?

Сәлим дигән әлеге егет колхозның төзүчеләр бригадиры булып чыкты. Үзенең исемен ишетүгә, ул армиядәгечә җәһәт кенә торып басты, бөтен гәүдәсе белән Назыйм абыйга таба борылды һәм:

— Яңа елга өлгертергә дип тырышабыз инде, Назыйм абый,— диде. Бу егетнең сүзләреннән мин аның Назыйм абыйны бик хөрмәт итүен һәм әнә шул хөрмәтен эштәге тырышлык белән белгертергә теләвен чамалап алдым... Әйе, мондый эшчән һәм намуслы егетләргә үзе дә нык таянадыр Назыйм абый... Юкка гына колхоз зур-зур төзелешләр башлап җибәрмәгән шул... Бик зур культура йорты да, җылы гаражлар да, кунакханә дә...

Назыйм абыйдан ерак түгел креслода утырган икенче бер кешегә күзем төште. Бу — теге килүемдә танышкан кеше — Хәкимуллин иде, Назыйм абыйның урынбасары. Аның үз-үзен тотышы мине шул көнне үк бик гаҗәпләндерде. Нәрәт бара бит инде — колхозның зур-зур эшләре турында бергәләшеп киңәшү, план кору бара. Ә Хәкимуллинга бу бармы-юкмы! Ниндидер бер брошюра караштырып утыра. Мин моны күргәч шаккаттым! Ничек шулай битараф утырырга мөмкин! Ә аның исе дә китми — юан гәүдәсе белән бөтен креслоны тутырып кереп чумган да, күтәрелеп тә карамый! Хет әллә нәрсәләр булсын, кузгаласы түгел!

Тагын бераз киңәшеп алганнан соң иртәгесе көнгә нәрәт бирелә башлады. Бусы тагын бик күп яңа эшләр ачты миңа. Юк, яңа эшләр дигәч — барысы да рәттән яңа түгел инде ул. Колхозның гадәти, көндәлек эшләре мәҗбүри рәвештә нәрәткә кертелә бара, үзеннән-үзе. Ә менә шулар арасына мәсәлән күрше колхоз белән чаңгы ярышы да килеп керә. Колхоз яшьләре иртәгә алар белән ярышырга тиешләр икән. Сөйләшүдән шул аңлашылды: бу эшнең дә башлаучысы Назыйм абый булган. Уйнапмы, чынлапмы — үзем дә катнашам, дип тә ычкындырды әле хәтта. Мин ышанырга да, ышанмаска да белмәдем...

Ә нигә, катнашса, моннан председательнең укасы коеламы әллә?! Чыннан да, булдырасың икән — колхоз яшьләрен нигә шәхси үрнәгең белән дәртләндермәскә ди! Аның ише эшләр коллективны, киресенчә, ныграк берләштерә генә бит ул!

Нәрәт беткәч Назыйм абый минем белән дә таныштырып алды. Аның шундый сүзе бик истә калган. Минем эшем турында:

— Колхозның бригадиры яисә агрономы кебек үк җитди эш эшли торган, халык белән эшли торган пост ул! Шуңа күрә, үз арабызга тагын бер актив көрәшче итеп алабыз без сине!— диде ул.

Башкалар иртәгесе көнгә бәйле сорауларын хәл итеп бетергәч, таралыштылар. Алар белән бергә үк Хәкимуллин да чыгып китте.

Без бүлмәдә икәү генә калдык. Назыйм абый торып, башта ишекле-түрле йөреп килде. Графиннан бәләкәй чәйнеккә су агызып, электр белән генә чәй куеп җибәрде.

— Менә шулай иткәч, баш ачылып китә минем...

Ә мин... әле генә тикшерелгән шундый зур эшләрдән соң шушы бүлмә эченә кайтып җитә алмыйча утырам. Гәүдәм генә монда. Ә күңел дигән нәрсә һич тә бүлмә эченә төшеп утыра алмый, әле телгә алынган зур эшләр дулкынында йөри...

Назыйм абыйның чәе тиз кайнап чыкты. Сул ягындагы шкаф тартмасыннан сәйлүн чәе алып, аны пешерергә куйды, үзе һаман сүзен дәвам итте...

— Безнең сүзләр әзрәк колагыңа кергәндер бит инде синең...

Мин үземнең нинди халәттә утырганны әйтергә ашыктым:

— Әзрәк кенәме соң!! Алар мине тулысынча биләп алды, Назыйм абый! Әле менә үземне чәй исе килеп торган шушы бүлмәгә кайтара алмыйча утырам.

Назыйм абый чәйне ике чәшкегә бүлеп, йомшак кресло алдында торган тәбәнәк өстәлгә куйды, мине шунда күчеп утырырга чакырды.

— Зур эшләр белән дәртләнә, рухлана алу бик шәп сыйфат ул! Менә безнең биредә утырган иптәшләрнең барысында да шул булсын иде әле... ул чагында, беләсеңме, ничек җиңел булыр иде алар белән аңлашу! Юк шул, арада төрлесе бар... Нишлисең — тормыш!

Назыйм абый, үзалдына текәлеп, әкрен генә өрә-өрә чәен суыта... Иплән кенә мин дә сүзгә катнашып киттем:

— Бик зур эшләр башлагансыз шул, Назыйм абый... Чынлап та, авырдыр...

Ул миңа таба борылмыйча гына:

— Әйе-е, җиңел түгел!— диде. Бераздан тагын кабатлады: — Җиңел түгел! — Аннары ул зур-зур итеп йотып алды, миңа таба борылды һәм:

— Ә бүтәнчә ярамый бит!— диде.— Моңа хәтле сузганнар икән ул эшләрне, хәзер барысын берьюлы эшләргә туры килә. Шулай кирәк! Алар барысы да кирәк! Бик тиз кирәк!

Мин үзем өчен тагын бер нәрсәне ачыклап калырга уйладым:

— Әле сез үзегез күптәнме соң... бу эштә?

— Председатель булып бишенче ел инде. Ә аңарчы агроном идем... Байтак кына вакыт узды шул! Ул бит вакыт дигәнең синнән сорап тормый — үтә дә үтә... Байтак кына эш тә эшләдек, билгеле. Әнә, син берәзын ишеттең дә...

Назыйм абый, кулына чәшкә белән чәй тоткан килеш, бүлмә буйлап йөреп китте.

— Әмма иң күп эш, иң зур эшләр алда әле безнең! Алда!

Бу сүзләрне ул нигәдер туктап һәм тәрәзә аша караңгы урамга карап (гүяки, ул үзенең күз карашы белән урам караңгылыгын тарата ала иде), үз-үзенә үтә дә нык ышанган тавыш белән әйтте. Мин аның эчендә олы уйлар кайнаганын сизеп, дәшми генә көттем.

— Беләсеңме, Әхнәф, әллә нинди планнар бар бит әле минем! Һәм аларның барысын да эшкә ашырып булыр кебек! Ни өчен дисәң— алар бит барысы да нәкъ менә шушы җирдә, нәкъ менә шушы тырыш һәм әйбәт күңелле кешеләр өчен эшләнергә тиешле нәрсәләр!

Менә мин гел шуны уйлыйм: нишләп әле кышын авыл кешесе сүлпән яшәргә тиеш? Бу бит үзе әйбәт күренеш түгел! Сүлпәнлекнең начар нәтиҗәләре бик күп аның! Аракы белән шаяру да әнә шуңа килеп ялгана бит... Моңа каршы без, беләсеңме, нишләргә уйладык?! Менә тыңлап тор!

Үзебезнең Җиләкледә дә, күрше-тирә авылларда да бик күп яңа өйләр салынамы? Салына. Аларның тәрәзәләренә наличниклар кирәкме? Кирәк һәм бик күп кирәк. Бик матур кирәк! Халык каян алырга белми йөри... Бусы бер. Тагын, моның өстәвенә, үзебезнең колхозга ук ел саен әллә ни хәтле ат чанасы, арбасы, тәгәрмәч тугымы, камыты, дугасы кирәк булып торамы? Кирәк була һәм безгә генә түгел, күрше колхозларга да! Ә бөтен районыбызга әнә шуларның барысын да эшли торган берәр мастерской бармы? Юк! Көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың, юк! Шулай булгач... Шулай булгач — шулай дидек тә, бер иске амбарыбыз бушаган иде — тоттык та шуны мастерской иттек! Хәзер анда станоклар куеп яталар әнә... Кышын ирләр шунда эшләячәк. План булачак, эш булачак аларга!

Назыйм абый сөйләгән саен кыза, үзе әйткән эшләр белән торган саен ныграк дәртләнә барды:

— Менә без, иптәшләр белән киңәшеп, шушы дүрт ел эчендә генә дә байтак эш кузгатып җибәрдек. Зур гына алма бакчасына нигез салдык — биш-алты елдан колхозчыларга чиләкләп-чиләкләп алма да булачакбез... Умартачылык элек бик сүлпән бара иде — хәзер без аңа бик нык игътибар итәбез. Чөнки безгә бал бик кирәк! Умартачылар санын да арттырдык. Авылда аңа әвәс кешеләр бар бит ул! Әнә шуларны куйдык. Семьялары белән куйдык! Балалары да өйрәнеп үссен бу нәзберек эшкә!

Аннары менә бүген ишеттең: бик яхшы итеп буа будык. Юк, бүтәннәр сыман бульдозер белән балчык иштереп кенә түгел. Андый буаны беренче көчле яңгырлар ук алып китә аны... Ә без элек картлар буганча иттереп будык. Машина-машина чыбык-чабык салдык, шәпләп таптаттык, тыгызлаттык. Улагын да кирәгенчә көйләп була торган итеп ясадык. Көчле яңгыр вакытларында безнең улакны зур итеп ачып куеп була, су аннан иркенләп ага. Ә буа исән калачак... Чөнки ул буада балык үрчи. Балык — шулай ук колхозчылар өчен! Артса дәүләткә дә сатарбыз — яңа тотылган балыктан кем баш тартсын! Бөтен кешегә дә кирәк бит ул!

Әле бит безнең яшелчә бакчасы да бар... Анысы, аллага шөкер дигәндәй, электән дә әйбәт кенә уңыш биреп килә. Ни өчен дисәң, яшелчә бригадирыбыз — нәкъ шул эш кешесе, җаны-тәне белән бирелгән кеше. Безнең Кәрим абзыйның тирә-якка даны таралган инде аның! Менә шул... Мин агроном вакытта да аңа гел ярдәм итәргә тырыша идем. Инде хәзер бәләкәй трактор да, атлар да бирдек. Кешеләре дә җитәрлек. Яшьләрдән дә болайрак дәртләнеп эшли әле Кәрим абзаң! Менә бит ул яраткан эш нишләтә!

Назыйм абый сөйли-сөйли йөренгән җиреннән туктап, үзе дә куанычыннан елмая, миңа карап тора. Яшермим — үз эшеннән шулай дәртләнгән кешене күрү миңа да бик зур бәхет бирә, аның белән бергә мин дә бәхет кичерәм!

Ә үзем эчемнән генә уйлап утырам: «Хәзер бик күп колхозлар оныттылар шул алма бакчаларын, яшелчә бакчаларын, умарталыкларны... Ә буа буып балык үрчетү турында инде әйткән дә юк...»

— Беләсеңме мине тагын нәрсә борчый, Әхнәф?! Әле безнең тагын бик зур резервыбыз бар. Юк, резерв кына да түгел ул... Ничек дөресрәк итеп әйтергә соң сиңа? Безнең уртак тормышның бер тармагын җанландыру турында әйтмәкче булам мин... Конкрет әйткәндә — мәктәп хакында сүз...

Бүгенгесе көндә анда ике йөз дә сиксән алты бала укый. Менә шуның кадәр зур көче булган коллективның физик хезмәт ягыннан пассив яшәвенә эчем поша минем. Юк, колхозга эш куллары җитмәгәнгә генә аптыравым түгел бу! Алар бит эштән аерылып, физик эш тәрбиясе алмыйча үсәләр! Атнага ике-өч кәрә торган хезмәт дәресе генә бу ким-

челекне төзәтә алмый. Кешене эшкә, хезмәт итәргә өйрәтү өчен — даими рәвештә барган һәм күпмедер шәхси җаваплылык белән бәйләнгән эш кирәк!

Менә мин шундый уйны иптәшләр белән киңәшергә җыенам әле: нигә әле безгә шушы кадәр көче булган мәктәпкә зур гына мәйданда җир бүлеп бирмәскә, техника бирмәскә! Һәм тагын бер бәләкәйрәк ферманы алар карамагына тапшырмаска!

Кешене җаваплылык тойгысы бик нык үстерә, ныгыта! Безнең балалар акыл ягыннан гына түгел, физик хезмәт итү ягыннан да кечкенәдән үк актив булып үсәргә тиешләр! Бүтәнчә һич тә ярамый. Югыйсә, без мәктәптән сакаллы сабыйлар гына чыгарачакбыз.

...Әнә шундый искиткеч зур уйларын ачты миңа ул кичне Назыйм абый. Ул алар эченә тәмам чумган иде. Әйе, һич арттыру булмас — ул алар белән яна иде!

Ә мин, аның сүзләрен бик бирелеп тыңласам да, һаман сүзнең үзем көткән якка борылып китүен, минем конкрет эшемә күчүен көттем.

Шулай бик озак сөйләшкәннән соң, бер мәлне ни күрим — Назыйм абый иплəп кенә җыена башлады, өстәлдәге әйберләрен урнаштырырга тотынды. Гаҗәпләнүдән күзләрем маңгайга менгәндәй булды. Ә минем эш?! Ә бүген мин көткән сөйләшү?! Ул кая?!

Шул сүзләремне әйттем:

— Назыйм абый, ә минем эш турында...

Ләкин минем сүзләр аны гаҗәпләндермәде. Әллә онытканмы дип уйлаган идем — алай булып чыкмады. Назыйм абый мин уйлаганга караганда хәйләкәррәк икән. Беләсезме нәрсә диде ул миңа:

— Менә син, Әхнәф, безнең колхозның бик зур эшләр башлап җибәрүен ишеттең. Әкренләп үзләрен дә күрерсең син ул эшләрнең... Ә мине бик сөендергәне: син безнең эшләр белән дәртләндең, мин моны синең күзләреңнән, утырганда тыныч кына кала алмаган йөзеңнән күрдем, сиздем... Безнең биредәге киңәшү сине әкренләп үз эченә алып кереп китте. Мин әнә шуңа бик канәгать... Әле син иртәгә авыл, колхоз белән тагын да ныграк танышырсың. Бик күп уйларың үзеннән үзе диярлек туар... Аннары, кирәк дип тапсаң, ныклап тагын киңәшеп алырбыз... Синең башыңда идеяләр күп булырга тиеш ул!

Әнә шундый сүзләр әйтте миңа ул кичне Назыйм абый. Аның ничек акыллы эш иткәнен мин менә хәзер генә тулысынча аңлап життем бугай әле... Шул кичне үк тегесен-монысын өйрәтә башласа, ул мине гади бер йомыш үтәүче итеп кенә калдырган булыр иде бит. Ә ул минем үз көчемне, үз инициативамны уятырга теләде! Минем үз башым белән уйлап, колхозның зур-зур эшләрен белеп, шуларга тиң эшләр белән шөгыльләнүемне теләде. Һәм ничек матур итеп китереп чыгарды ул моны! Яшермим, кешегә ышану — аны нык үстерә, һәммә яктан, бар яктан! Мин дә үземә мең канат куелгандай сиздем ул кичне!

## Бишенче төн

Беренче төнне сөйләгән сүзләре белән үк Әхнәф мине бер ташкын эченә алып кереп китте дип әйткән идем бит... Әнә шул ташкынның торган саен көчәя, кызулана баруын тойдым мин. Юк, аның сөйләү рәвеше генә торган саен дәртлерәк, ашкынулырак була бармады — Әхнәф атаган вакыйгалар, эшләр дә һаман зуррак һәм һаман мөһимрәк була бара иде.

Үзендә балачактан бирле зур ашкыну хисе тоеп яшәгән яшь Әхнәфнең шундый энергияле, инициативалы председатель белән очрашуы

да бик мөһим иде. Эшкә, хәрәкәткә ашкынган яшь күңелнең зур эш кешесе белән конкрет очрашуы иде бит бу!..

Бишенче кичне тагын да кызыклырак хәлләр сөйләде миңа Әхнәф.

— О-о, колхозда Назыйм абый башлап җибәргән үзгәрешләрнең колачын күрсәгез иде сез! Ул матур үзгәрешләр сизелмәгән бер генә тармак та калмагандыр! Мин аларны торган саен күбрәк күрә бардым, бу колхозга кергән авыллардагы яңарышны торган саен тирәнрәк тоя бардым.

Назыйм абыйны бүгенге колхозчы тормышының бөтен ягы да уйландыра иде. Һәм әнә шулай уйлана-уйлана, белгечләр белән киңәшә-киңәшә, ул әллә нинди кирәкле проблемаларга килеп чыга иде...

Менә бер генә мисал. Сугышка хәтле Җиләкле халкы үз көче белән үзәк урамга таш җәйгән булган. Хәзер ул әкренләп туза башлаган, күп җирендә чокырлар хасил булган иде...

Җәйгә чыккач, чираттагы бер утырышта Назыйм абый шул хакта сүз кузгатты.

— Алар ат белән дә күпме таш ташыганнар. Ә безнең егерме дүрт машинабыз бар! Оят түгелме безгә!— диде.

Байтак сүз булып алды ул көнне. Шикләнүчеләр дә табылды. Әмма карар кабул ителде: алдагы шимбә, якшәмбе көннәрне колхоз буенча өмә ясарга! Авыл кешеләре машина, техника ярдәмендә урамнарга таш җәяләр!

Таш үзебезнең колхоз җирендә үк чыга иде. Шимбә, якшәмбе көн халык, барлык техника купты! Мәктәп балалары да җыйнаулашып килде. Соң, үзләренең туган авылларын матурлау өчен бит! Моңа, моның ише изге эшкә, кем генә каршы килә алсын да, кем генә риза булмасын соң?! Мин дә булыштым, малай чактагыча үз кул көчем белән катыштым: карьердан кайткан ташны бушатыштым.

Ике көн буе җан-фәрман эшләдек. Эшнең күзгә күренеп алга барганын сизү безне тагын да дәртләндерде. Алдагы ике ялны да өмә игълан иттек.

Шулай итеп, ул җәйне тәки Җиләкленең урамнары таш юлга әйләнде... Аннан соң асфальт җәю турында кайгырта башлады Назыйм абый. Аның баштагы нияте үк асфальт җәю булган икән. Башта ул аны әйтми генә торган.

Бу — бөтен район өчен вакыйга булды инде! Килеп карамаган кеше калмагандыр... Ә башлаганда күпләр ирония белән елмайганнар гына иде. Шулай инде — күңел курка, кул эшли, дип юкка гына әйтмәгән бит безнең халык!

Колхоздагы зур вакыйгаларны сөйләп, үземнең төп эшемне онытып торам икән әле. Культура йорты, чынлап та, Назыйм абый әйткән срокка — Яңа елга өлгереп җитте. Халык өчен бик күңелле булды. Ә мин бу йортның зурлыгына, анда бөтен мөмкинлекләр булуга сөендем бигрәк. Нинди генә заллар, бүлмәләр юк иде анда!

— Яшьләр теләгән барлык спорт секцияләре булырга тиеш безнең!— диде Назыйм абый.— Авыл яшьләре шәһәрнекеннән ким яшәмәскә тиеш!

Анисының да җае чыкты тагы. Мин килеп бер ярты ел үттеме-юкмы — культура йортында минем белән бергә эшләүче апаның пенсия яше җитте. Ә аңарчы, Казанның физкультура институтында укучы дус егетем белән безнең арада хатлар йөри башлаган иде инде. Өч-дүрт хаттан соң Вәкилне тәмам күндердем мин. Бу колхозда эшләрнең нинди темпта баруын яздым, Назыйм абыйның перспектив планнарыннан берничәсен атадым, белгечләр өчен квартиралар да салынып ятканын әйттем — һәм шулар җитте.

Вәкил читтән торып укуга күчте. Тагын бер карават куйдык Нәгыймәттәйнең кунакчыл өенә.

Дустым спорт секцияләрен үз кулына алды. Мәктәп балаларыннан алып картая баручы абзыйларга хәтле безнең культура йортына йөри башлады.

Ә мин музыка буенча түгәрәкләр оештырдым. Тора-бара авыл яшьләреннән зур гына бер хор да килеп чыкты. Ул хор белән соңрак Казанга да килдек әле...

Ләкин Назыйм абыйның хыялы аңа гына да канәгать түгел иде әле. Бер сөйләшеп утырганда аның болай дигәне бик истә калган:

— Менә без телевизорны бик еш карыйбыз. Шунда күрәбез: атаклы музыкантлар чыгыш ясый. Тыңлыйбыз без аларны. Ләкин безгә үзебезгә дә әнә шундый атаклы музыкантлар тәрбияләргә кирәк бит! Кирәк, бик кечкенәдән үк кирәк... Без тотабыз да: баланың музыкаль слухы юк, дибез. Ә бит ул — булдырып була торган әйбер. Аның күктән төшкәнен көтеп ятарга ярамый!

Шундый сөйләшүләрдән соң ул авылда музыка мәктәбе төзи башлау идеясен тыкырдатырга тотынды!

Аның алма бакчасы, умарталыгы, буада балыклар үрчетүе, мастерской ачып наличниклар ясата башлавы, авыл урамнарына асфальт җәйдерүе — алары бик яхшы эшләр иде инде, аңлашыла. Боларынын авыл кешесенә кирәк булуы ачык. Бирелә бәхәс юк иде. Ә менә музыка хакында, чынлап әйтәм, бик зур бәхәс барды идарә утырышларында. Бик каты барды! Чөнки бит әле андый нәрсә район үзәгендә дә юк иде!

Бу фикергә Назыйм абый, беләсезме, ничек дип җавап бирде:

— Безнең районда юк, ә менә бүтән республикаларда андый мәктәпләр барын мин беләм! Ул безгә дә кирәк!

Назыйм абыйның үзе нык ышанган мәсьәләдә ахыргача принципиаль булуы, әнә шул сокландыргыч сыйфаты аңа биредә дә җиңү китерде. Ахыр чиктә идарә членнарының күпчелегенең яклавына ирешә алды ул!

Шулай итеп, башта фантастик кебегрәк тоелган фикер дә идарә утырышы карары булып кабул ителде. Әкренләп төзелеш материаллары кайтарыла башлады...

Әйе, эшләр киң колач алды.

Авылның, колхозның күп почмакларында яңа төзелешләр җәелеп китте.

Төзелә торган йортларның да матур булуын, һәркайсының авылга ямь биреп торуын таләп итте Назыйм абый. Аның район архитекторы белән дуслыгы да бар иде, шуннан да бик әйбәт файдаланды ул. Архитектор безнең колхоз өчен индивидуаль проектлар эшләде, яисә типовой проектларның кайберләрен безнең шартларга яраклаштырды.

Әле аның белән генә дә калмады Назыйм абый. Һәркемнең йорты, капкасы матур итеп бизәлгән булуын, урамга ямь биреп торуын таләп итә башлады. Каралты-курасы каралмаган, төзәтелмәгән хуҗалыкларга, гомумән, авылда көн калмады. Мастерскойда ясалган тәрәзә челтәрләренең дә бер-берсен кабатламавын, һәркайсының үзенчә булуын таләп итте...

...Менә бу хәлләрнең барысы да мин Җиләкле авылында эшләгән ике ел ярым вакыт эчендә булды. Әйтәм бит: алты елдан аз гына артыграк гомер эчендә — аның ике елы минем күз алдында узды — авыл тормышын астын-өскә китерердәй эшләр эшләнде анда!

Әмма... Әмма әнә шулай күтәрелеп, җанланып киткән уртак эшкә эчләре пошучылар да була икән бит ул. Хәтта ачулары килүчеләр дә була икән!

Мин әнә шундый кешеләр турында еш кына уйлыйм. Безнең илебездәге тормышта, намуслы кешеләргә генә йөз тотылган җәмгыятьтә, каян чыгалар алар — шундый кешеләр? Каян киләләр алар?

Уйлый торгач, ныклы нәтиҗәгә килгәндәй булам. Мөгаен, алар — уртак эш өчен көч түкми генә, рәхәт яшәргә омтылучылардыр. Аларга кайберәүләрнең ил, халык мәнфәгате дип янулары, тырышулары ошамыйдыр. Чөнки бу бит аларны тынгысызлау, кыймылдарга мәҗбүр итү була!

Ни өчен мондый сүзләргә кучтем соң әле мин?

Ни өчен дисәгез — соңга таба Назыйм абый өстеннән төрле-төрле урыннарга хат язулар күренгәли башлады. Ул хатларның кайберсендә төзү материаллары дөрес юл белән табылмады диелгән була, кайберсендә бу хәтле төзелеш колхозга кирәк түгел, юкка акча түгелә, дип языла. Назыйм абыйның үзенә гаеп ташлаулар да ешайды. Кыскасы, биредә эшкә таяк тыгарга маташу, Назыйм абыйга аяк чалырга теләү ята иде.

Мин үзем бу әшәкелекләрнең барысында да Хәкимуллин һәм тагы бер-ике кеше кулы уйный дип сизендем. Аларның районда нык кына тәрәкләре дә бар иде. Ни өчендер безнең Назыйм абыйның райисполком председателе Сулимов белән борчагы пешмәде.

Бу хакта авылда инде мин килгәндә үк төрле сүзләр йөри иде. Янәсе, бервакыт райбашкарма комитетында колхоз председательләренең зур гына киңәшмәсе җыелган. Кыш көне булган бу. Ә кыш көне, үзегез беләсез инде, сүз күбрәк сөт турында бара. Сөт савуны арттыру хакында. Райисполком председателе үзенең чыгышында матбугатта күтәрелгән бер алымны мактый, малларны шулай ашатырга кирәк, ди. Бу алымның гыйбәт нәтиҗәләре безнең районда да бар, иптәшләр, дип, ул Назыйм абыйның колхозын телгә ала. Җыелышта Казаннан килгән җитәкче дә катнашкан булган. Шуңа күрә, билгеле, райисполком председателе ул хакта бик зурлап, ул фактка көчле яңгыраш бирергә тырышып әйткәндер.

Әмма Назыйм абый нәкъ шул чагында әллә башка нәрсә уйлап утырган, әллә ишетеп тә ул сүзләрнең ни өчен әйтелгәнен, аларның мәгънәсе кая таба барганын аңлап, серенә төшенеп җитмәгән — кыскасы, тәҗрибә уртаклашу өчен дип үзенә сүз бирелгәч, ул чынлыкта ничек эшләсәләр — шуны сөйли дә бирә! Бернинди алдынгы алымны да искә алмый!

Әйтүләренчә, үз колхозының башкаларга караганда сөтне күбрәк савуын шулай аңлаткан Назыйм абый: көздән азыкны мул әзерләп куйган идек, хәзер шуны фураж белән кушып бирәбез, дигән. Байтак колхозлар саламнарын да яндырдылар бит, аларның азык белән хәле кыенрактыр, дигән.

Үзенең чыгышыннан соң шушындый сүзләр ишеткән райисполком председателенең хәлен күз алдына китерәсездер инде! Назыйм абый бит аны республика җитәкчесе алдында хурлыкка калдырган! Сүзен ялганга чыгарган! Мөгаен, аның бу эшен бер дә онытa алмагандыр иптәш Сулимов! Әле ул моны юри, үзенә каршы төшү өчен эшләгән эш дип тә уйлагандыр, бәлки...

Назыйм абый исә мондый хәйләле эшләрнең җаен, рәтен белми иде. Ул үзенчә бара бирә, ашкынып эшли бирә иде. Ә кайберәүләр аның эчкерсез адымнарын үзләренә каршы төшү дип кабул итәләр һәм аңа каршы йоннарын кабарталар... Назыйм абый еш кына моның сәбәбен дә белә алмыйча аптырый иде...

Менә бит ул ничек! Без бер яктан газеталарда, җыелышларда эш кешеләрен күкләргә чөеп мактыйбыз, аларны иң зур хөрмәткә ия кешеләр итеп күрсәтәбез — ә икенче бер урында, гел эш турында гына уйлап йөреп, синең һәм минем кәеф белән исәпләшеп торырга вакыт тапмаган кешеләргә кырын карый башлыйбыз. Хәтта, кайчагында, алардан «дошман» ук ясап куябыз!

· Ә бит, акыл белән уйлап караганда, кешенең эшләгән эше нигез булырга тиеш бәһа биргәндә... һәрвакыт шулай булырга тиеш!

Назыйм абый белән Сулимовның мөнәсәбәтләрен тагын бер мәсьәлә бик куертты. Мин килгән елларны бу районда вак авылларны күчерү күбәеп китте. Үзәк авыллар, зур авыллар белән берләштерү ешайды. Сизүемчә, бу эшнең идеясе күбрәк райисполком председателеннән чыга иде. Әлеге мәсьәләдә ул бигрәк тә, хәтта артыгы белән активлык күрсәтә иде. Минем күз алдында гына да әллә ничә мәртәбә:

— Ну, Чишмәгә кайчан тотынасыз инде? — дип сораганы истә калган аның.

Чишмә — безнең колхозга кергән иң бәләкәй авыл иде. Сулимовның уенча, Назыйм абый иң элек әнә шул авылны күчерергә тиеш иде шикелле.

Белмим, әйтүен ничек дип әйткәндер, нинди җавап биргәндер, әмма чынлыкта Назыйм абый бу хакта уйламады да! Киресенчә, ул аның урамнарын рәтләттерә, каралты-кураны төзәттерә, кешеләренә ярдәм иттерә иде. Чишмәдә һәрвакыт электр януын, радио сөйләвен, телефон төзек булуын таләп итте ул. Кибетләре искергәч, колхоз ярдәме белән бәләкәй генә кибет тә салынды.

Соң, акылы бар адәм шушындый матур урынга утырган авылны күчерәме соң инде?! Чишмәнең бит урыны шундый гүзәл! Табигате искиткеч!

Аннары бит әле ул авылда, бәләкәй авыл булса да, шул бригаданың басу-кырларын карап, эшкәртеп торучы колхозчылар яши! Гомер-гомергә шушы җирдә тир түгеп эшләгән халык яши! Аларны ни йөзең белән кузгатмак кирәк...

Назыйм абый, әлбәттә, боларның барысын да уйлагандыр. Җиде кат үлчәгәндер...

Моның да бер серен әйтмичә ярамый тагын: Чишмә — Назыйм абыйның туган авылы иде. Әнә шуны белеп, райисполком башлыгы бигрәк тә үчләште бугай Чишмәгә... ул үткәндә дә, сүткәндә дә кереп Назыйм абыйның каефен кырып чыга иде шушы авырткан әйбер белән...

Назыйм абый ничек түзгәндер — әмма Чишмә барыбер кузгалмады. Халкы да читкә, бүтән авылга китмәде, тузмады. Болар барысы да, билгеле, Сулимовны эчтән ярсыткандыр инде... Кыскасы, Назыйм абыйның аның белән мөнәсәбәте, дипломатик тел белән әйткәндә; киеренке, бик тә киеренке иде...

Әле житмәсә, бик тә теңкәсенә тигәч, Назыйм абый түзә алмыйча, Сулимовка авыр сүз әйтеп ташлаган дип тә сөйләделәр... Идарәдә аларның сөйләшкәннәрен ишетеп калучылар булган, ахрысы...

Колхоз эшләренең алга баруын, халыкның уртак эшкә дәртләнебрәк тотынуын сизү белән бергә, шул ук вакытта, кайбер нәрсәләрнең хәвефле төс ала баруын да тоймый кала алмадым мин...

Үземдә әнә шул хәвефле тойгы көчәйгән чакларда минем күз алдында гел Сулимов һәм үзебезнең Хәкимуллин шәүләләре пәйда була иде...

## Алтынчы төн

Күптән түгел Әхнәфнең холкын тагын да ныграк аңларга ярдәм иткән бер хәл булды. Әйткәнемчә, без бит диңгез буенда гына яшибез. Диңгез безнең тәрәзә каршында гына. Шушы бер-ике көндә ул бик каты давыллап алды. Бөтен көченә котырынды!.. Минем диңгезнең төрле чакларын күзәткәнем бар, әмма бу кадәр дә куркыныч давылны күргәнем юк иде әле диңгездә! Хәтта бүлмә эченнән, ял йортыннан карап торганда да куркыныч иде ул көннәрдә диңгез!

Аның яры буйлап кына үткәндә дә киемнәрең манма су була! Дәһ-

шәтле көчләрен тыя алмыйча дулаган дулкыннар синең өстеңә ташланып һәм изеп китәр шикелле тоела!

Бер миңа гына түгел, бөтен кешегә дә әнә шулай куркыныч иде диңгез. Аның кырыена беркемне дә якын китермиләр.

Мин шулай дип уйлый идем. Шуңа ышана идем.

Әй Әхнәф... Әй Әхнәф бөтенләй бүтән булган икән... Әнә шул көнне котырынган диңгез кочагына керде бит ул!!!

Юк, мин аның ничек итеп кереп киткәнен күрмәдем. Ул моны соңыннан үзе дә сөйләмәде. «Әй ничек күрдең соң?» — дисезме? Бу хәл миңа болай булды...

Шул кадәр дәһшәткә сокланып та, куркыбрак та тәрәзәдән карап тора идем. Бер заман күрәм: ярдан әллә ни ерак түгел, маяк тирәсендәрәк, ниндидер кызгылт әйбер тирбәлә! Нәрсә микән бу дип текәлебрәк карасам — Әхнәфнең һава тутырылган матрасы! Ул аны бирегә килгәч тә прокатка алган иде. Күзләремә ышанырга да, ышанмаска да белмим. Кызыл ятак миңа аермачык күренә, ә менә Әхнәф бармы-юкмы аның кырыенда — һич күренми. Биек-биек дулкыннар һава тутырылган матрасны төрле якка чөяләр, күздән югалталар. Мажаралы кинода моның ишене күрсәтсәләр, мөгаен, арттыралар дисең инде. Кеше мондый дулкынга ничек түзсен, дисең! Ә ул көнне Әхнәф нәкъ әнә шундый көчле гарасатның уртасына килеп эләккән иде! Үз теләге белән әле җитмәсә!

Бик текәлеп күзәтә торгач, ниһаять, үзен дә күрдем мин аның. Матрасына ябышканмы, кочаклап ук алганмы шунда... Дүртәр-бишәр метрлы дулкыннар гарасатында икәүләп арлы-бирле атыналар. Дулкын аларны аерырга теләгәндәй, китереп-китереп бәрә. Бер мәл икесе дә күздән югалалар. Кая инде болар дип торганда, яңадан калкып чыгалар.

Нишләп керде икән соң Әхнәф мондый көнне диңгезгә?! Мине чынчынлап курку биләп алды. Хәзер матрасыннан аерылса, бетә, бата бит инде бу! Әле ныклап йөзә беләмикән соң? Хәер, су буенда үстем диде — анысын булдырадыр инде. Тик бу бит диңгез, бөтенләй башка нәрсә! Син су кереп үскән елга түгел!

Аптырагач, яр буена йөгереп төштем. Әйтәм бит, якын килерлек түгел су буена! Ләкин эчтә кеше җәфаланганда, ничек бармыйсың инде?! Кием чыланса чылана инде дип, мөмкин булган хәтле бардым ярга табарак. Һәм күрәм: теге, чынлап та, ярга таба якыная алмыйча аптырый икән бит! Аны дулкын ярга һич җибәрми. Шулай күпме азапланды микән соң инде Әхнәф?! Ул бит тәмам арыган булырга да мөмкин? Менә сиңа бәла! Тик торганда! Авырткан башка тимер тарак дигәндәй... Хәзер ничек ярдәм итәргә соң инде моңа?

Чынлап та, хәле мөшкел иде аның... Нишләргә дә белми әзрәк торгач, башыма бер уй килде. Моннан ерак түгел коткару посты бар бит! Алар берәр чарасын тапмый калмас! Тиз генә шунда йөгердем. Мышмыш килеп, бүленә-бүленә хәлне аңлаттым. Ә тегеләрнең, әллә инде үз күзләре белән күрмәгәнгә, бик исләре китми. Ашыкмыйлар. Стенада эленеп торган озын бауны алдым да кире йөгердем. Анда бит һәр секунд санаулы!

Әхнәф турысына килеп җитеп, бауны аңа ыргыттым. Тик кая ул — беренче дулкын аркылы да үтә алмады бау! Шундук дулкын астында калды! Бер аттым, ике аттым. Җитми генә бит Әхнәфкә хәтле!

Яңадан ату өчен бауны урап кына бетергән идем, берәү кискен генә итеп кулымнан тартты да алды. Борылып карасам — теге коткаручы егетләр килгән икән. Берсе нәрсәдер ачуланып кычкырды миңа. Дулкын шавына ишетмәдем. Аннары читкә этеп җибәрде. Үзе ыргытырга җыена икән бу! Мин читкәрәк киттем.

Оста ыргытты бу бауны. Коткару бавы Әхнәфкә барып җитте, ләкин

Әхнәф аны эләктереп өлгерә алмады. Теге егет тиз генә яңадан ыргытты. Бу юлы каптырды бит Әхнәф! «Ах, молодец!» дип торам мин дә.

Тартышырга мин дә булыштым. Әхнәф бауны эләктерү шатлыгыннан матрасын ычкындырган икән... Хәер, бу дулкында ничек итеп икесен дә тотмак кирәк! Билгеле, бау мөһимрәк инде!

Шулай итеп, туңып, күгәреп беткән Әхнәфне ярга көчкә тартып чыгардык! Чыкты да — аягына да баса алмыйча ауды. Ярга чыгып җитүенә шатлану идеме бу, әллә чыннан да бөтенләй хәле беткән идеме аның — озак ятты Әхнәф. Мин теге егетләрне ял йортында тавыш чыгармаска, Әхнәф өстеннән әләкләмәскә көч-хәл белән күндердем. Бүлмәгә кереп тиз генә «җылынып» та чыктык.

Ә Әхнәф һаман шунда иде әле...

— Инде беттем дип торам...

Мин аны тәмам коты чыккандыр дигән идем. Ә бу елмайган килеш әйтә бит әле монысын да! Минем ачу килеп китте. Кешегә күпме мәшәкать ясады, борчыды — әле җитмәсә елмаеп утыра!

— Әйе, мин күреп алмасам — елмаер идең хәзер су төбендә!

Сүзләремнең ачулы тонына исе китмәде аның. Гын гына торды елмаеп... Ә бераздан әйтеп куйды:

— Менә хәзер инде чын диңгезне күрдем дип әйтә алам мин! Хәзер аның нинди икәнен беләм инде! Югыйсә, тыныч чагында диңгез мени ул? Андый вакытта ул бит үзенең чын холкын, чын характерын яшергән кеше кебек... Ә менә бүген ул чынлап та үзе иде! Мин аның үзе белән очраштым бүген!

Әхнәфнең бу сүзләре инде минем ачуны гына кабарта иде.

— Ярар! — дидем дә, аның үзен генә калдырып китеп бардым.

Менә шундый хәл булып алды бездә. Тик Әхнәфнең үзенең моңа әллә ни исе китмәде. Гүя ул аны бөтенләй онытты. Ә минем өчен... Минем өчен һич тә онытырдай вакыйга түгел иде ул... Әхнәфне тагын да ныграк аңларга ачкыч кебек булды ул миңа...

...Аның төнге хикәяләренә инде әкренләп ияләнеп киләм шикелле. Көннәребез исә һаман аерым үтә — мин үземнең иптәшләр белән йөрим, ул ашау вакытында гына күренеп ала да, шулай ук каядыр китеп бара. Кайчагында ашауга да соңарып кайта...

Алтынчы төнне Әхнәф миңа председатель урынбасары Хәкимуллин турында сөйләде.

— Хәкимуллин ишеләр, чын эштән курыксалар да, башка якка бик маһир булалар бит. Хәкимуллин да үзен бүтәннәр арасында зур, югары итеп куярга тырыша иде.

Шушы сыйфатны минем күп мәртәбәләр сынаганым бар. Кайда гына очратмыйм — эш өчен исе китмичә, күбрәк тел белән алдырып йөрүче кеше үзе турында артык күп уйлаучан, артык нык борчылучан була. Нишләп алай микән ул? Тегеләрнең — гел эш турында, аны гел алга җибәрү өчен тырышып йөрүчеләрнең — үзләре хакында уйларга вакытлары калмый микән? Алар үзләренең кешегә ниндирәк булып күренәчәкләрен артык мөһим нәрсә түгел дип саныйлар микән? Бу алар өчен — кыйммәтле вакытны юкка әрәм итү кебегрәктер...

Мин колхозда эшли башлагач, Хәкимуллинны тагын да ныграк аңларга булышкан бер хәл булды. Хәкимуллин бер вакыт ике комбайнчы егеткә штраф салдыртам дип ду килеп йөрде. «Ни өчен?» — дигәч, «Әйткәнне эшләмиләр, сүзне тыңламыйлар...» — ди гомуми төстә генә.

Ә комбайнчылар үзләре икенче көнне бу хәлне болай сөйләп бирделәр.

Авылдан ерак түгел генә басуда урып яталар икән. Урак бетәргә

инде күп тә калмаган, ләкин һавасы да сәгатьләп, минутлап кына ачылып китә, вакыт бик кадерле. Шуңа күрә егетләр ашыга-ашыга уралар. Шулай да, бер әйләнгәндә Хәкимуллин белән зоотехникның мотоциклга утырып елга буена төшеп китүен искәртеп алалар. Ә елга буе — шәһәр кунаклары кайтып ял итә торган урын инде! Анда кешенең нигә төшкәне билгеле!..

Ачулары килсә дә, күрмәгәнгә сабышып, үз-үзләрен тынычландыра-тынычландыра ура бирәләр. Ә бераздан тегеләр кайтып килә. Кишәрлекнең аргы башыннан килгәндә егетләр күрә — мотоциклларын туктатып, боларның килгәнен көтеп тора тегеләр. Янәсе, аларны күрү белән егетләр комбайнны туктатып йөгереп килергә тиешләр.

Әмма егетләр бу кишәрлекне бүген ничек тә бетерәсе иде дип тырышалар, халыктан кыенсынмыйча күңел ачып йөрүчеләргә ачулары да килә. Туктамый болар! Кишәрлекне әйләнә бирәләр! Ә басу читендә ике начальник боларның бер әйләнгәнен карап тора, икенче мәртәбәсен көтәләр. Ләкин комбайн өченчесендә дә туктарга уйламый!

Шуннан соң болар нишли?

Мотоциклларын бөтен газына үкертеп камыл өстеннән бәреп чыгалар һәм мотоциклны комбайн каршына бастырып та куялар! Инде туктамый хәлең юк! Комбайнчы егетләрне аска чакырып төшерәләр дә берсен-берсе бүлә-бүлә сүгә башлыйлар. «Молокосослар! Кем булдыгыз! Безне күрмисезме?! Санга сукмыйсызмы?! Штраф икегезгә дә — унар сум!»

Аракы исе аңкып торган ике авыздан яшь егетләр әнә шундый сүз ишетәләр ул көнне.

Кичкә хәтле алар әйбәт кенә эшлиләр. Үзләренең әйткән кишәрлекләрен бетерәләр.

Ә икенче көнне берсе дә эшкә чыкмый. Колхоз председателе чакырта боларны, «Нәрсә булды?» — ди. Егетләр комбайнга таба аяк та атларга теләмиләр. «Безнең тынычлап эшлисебез килә, Чаллыга китәбез, инде чемодан тутырылган», — диләр...

Көч-хәл белән алып калды аларны председатель.

Менә бит ул ничек! Имеш, Хәкимуллинның горурлыгына көч килгән! Ә шул урында эш өчен көеп йөргән кеше булса — бөтенләй бүтәнчә итәр иде бит. Ул урактагы егетләрнең яныннан китмәс иде, алар әйбәт кенә эшләсен өчен җанын да җәлләмәс иде! Хәтта шәхси үпкәсен, теге яки бу сәбәптән әзрәк кәефе кырылуын бик тиз онытыр иде ул!

## Җиденче төн

Әхнәфтән аермалы буларак, мин үземнең бөтен гомеремне шәһәрдә үткәргән кеше. Шәһәрдә тудым, шунда үстем. Хәзер дә бер төзелеш идарәсендә инженер булып эшлим... Моны шуңа күрә әйтәм —Әхнәфнең авыл, колхоз хәлләрен сөйләп китүе башта бер дә кызык булмас кебек иде. «Газеталардагы күңелсез очеркларны укып та туеп беткән инде!» — диебрәк кенә уйлаган идем мин башта... Әмма аны тыңлыйтыңлый фикерем үзгәрде. Әхнәф сөйләгәннәр колхоз турында түгел, ә кешеләр турында икән бит! Аларның бер үк тормышта, бер үк социаль шартларда төрле идеалга табынып, ике төрле полюс кешеләре булып яшәүләре хакында икән бит!

— Беләсезме, авылда үсүем һәм әдәбиятны бик күп уку миңа кешеләр белән ихлас, эчкәредән аңлашуда нык ярдәм итә шикелле... Ничектер, алар миңа кеше йөрәгенә үтүнең иң дөрес юлын табып бирәләр сыман... Кеше күңелен куркытырдай, сагайтырдай һәм аны ачылмый-

ча тотардай сүзләрдән, кыланышлардан, адымнардан саклыйлар сыман алар мине...

Шулай итеп, эшкә чумдык без. Эш ташкыны мине инде беренче көннән үк билэп алган иде. Мин инде тулысынча шуның иркендә идем.

Көнделәге планнардан, ниятләрдән төнлә дә йоклап булмый! Төнлә сикереп торам да, онытылмасын дип фикеремне язып куям. Утны сүндереп әз генә вакыт үтә — тагын да кызыклырак уй башка килә, тагын утны кабызам... Әле ярый үземнең почмак бар иде. Югыйсә, бу хәтле бимазалауга Нәгыймәттәй чыдый алмаган булыр иде!

Ә аннары инде, иртән тору белән мәктәпкә чабасың. Анда иң актив ярдәмчем — пионервожатый Хәлимә эшли. Ул эшкә иртә килә. Төн буе уйлап, сызгалап яткан планнарыңны аның белән киңәшәсең...

Киңәшеп, сөйләшеп алгач, үз-үзеңә ныграк ышана төшәсең бит ул— шуннан соң инде ниятеңне тормышка ашырырга дип чаба башлыйсың.

Без башта ук иң мөһиме дип беләсезме нәрсәне куйдык? Яшь кешенең үзен ялгыз итеп, аерым итеп сизмәвен, шул күңелсез хисне тоймавын. Бүгенге авылның бик күп проблемалары әнә шуннан башлана кебек тоелды безгә. Һәм ул минемчә дөрес тә. Мин хәзер дә шулай саныйм. Чөнки яшь кеше авылдан ни өчен китә? Күңеллерәк тормыш, аның рухына, эчке ихтыяҗларына җавап бирердәйрәк тормыш эзләп, шуны шәһәр җирендә табуны өмет итеп китә. Үзенең шәхесенә киңрәк, югарырак яшәеш эзләп китә ул. Авылдагы беркатлы, үтә гади кебек тоелган, барысы да аермачык кебек күренгән тормыш канәгатьләндереп җиткерми бугай аны...

Яшьләрне авылдан җибәрми генә икенчерәк, югарырак, күңел өчен матуррак булган тормыш белән яшәтеп булмый микән соң?— дип уйландык без. Уйлый торгач, әкрен-әкрен җае табыла икән. Иң башта колхоз радиосы аша «Комсомолия» дигән яшьләр тапшыруы оештырып җибәрдек. Матур итеп, күңелле, дәртле музыка белән башланып китә иде ул! Аннары колхоз яшьләре тормышыннан яңалыклар яңгырый, хезмәттәге яңа җиңүләр халык алдында җылы итеп, зурлап, мактап әйтелә. Бер карауга әллә ни зур күренмәгән әйберләргә дә бик игътибар бирергә тырыша идек. Чөнки үзебезнең яшьтәш егет һәм кызлар турында сөйлибез бит! Бу сүзләрнең алар тарафыннан ничек кабул ителәсен дә белеп, сизеп торабыз! Җылы сүз — җан азыгы ләбаса! Бигрәк тә радио аша ишетелгән, музыка белән бергә яңгыраган сүз!

Бу турыда сөйләгәндә бер җырчы егет язмышы искә төшә. Бик матур, моңлы тавышлы егет иде ул Җәүдәт. Үзе дә әйбәт, чиста күңелле егет иде. Тик, ничектер, авылда ул үзенә пар табып, вакытында гаилә корып кына җибәрә алмады. Һәм нигәдер авылдан да китеп бара алмады ул. Аның тирән сагышлы тавышы кичләрен караңгы авыл урамында еш кына ишетелә торган иде. Әнә шул җырын тыңлаганда ул әллә ничек, минем күңелгә кадерле дә, кызганыч та булып китә иде. Аның тавышында ниндидер зур бер кайгы авазы ишетеләдер шикелле иде... Күрәсең, шушы олы дөньяда үзенең ишен таба алмаган йөрәкнең әрнүе, нәрсәгәдер, кемгәдер рәнҗүе, үпкәләве булгандыр инде бу...

Көчкә үгетләп, ялынып без аны үзебезнең радиотапшыруда җырларга күндердек. Ул җырлаган кич безнең концертларның иң шәбе, иң онытылмастае булды. Күздән яшь китерердәй итеп, үзәккә үткәреп, нәкъ менә синең карагандай — күңелеңнең иң төбенә үк үтеп, үзе дә йөрәгенең әллә нинди нечкә җепләрен авырттырып өзә-өзә, өзелә-өзелә җырлады ул җырны...

Тапшыру үткәннең икенче көнендә иртән идарәдә очрашкач Хәкимуллин әйтә миңа:

— Безнең яшьләр хәзер шул исерек тавышына мохтаҗмыни инде? Шуннан ямь табабызмыни инде?

Мин аптырап калдым. Соң шундый моңны да аңлый алмаган кеше-

гә нәрсә дип әйтә алыйм инде?! Зур сүзләр сөйләп торырга, һәр талантның халык байлыгы икәнен кабатларга, аны саклау кирәклеген аңлатырга мыни инде?!!

Әйе, бу — Хәкимуллин шул инде... Аны тиз генә үзгәртеп булмый...

Җырчы егетсбезгә, күрәсең, Хәкимуллин сүзен житкергәннәр. Ул безгә бүтән җырламады. Бары тик авыл урамнарында гына, тәмам караңгы төшкәч, яшьләр клубтан таралган чакта, аның тагын да моңлырак кебек тоелган тавышы ишетелә иде.

Карар инде,
Карар инде
Кара күзләре белән...

Моңлы кешенең гомере кыска була, дигән сүз бар халыкта... Моң кеше йөрәген шундый да нык ашый микәнни соң?! Шулай ук нык яндыра микәнни соң аны моң дигән ул ут, моң дигән ул ялкын?!

Җәүдәт тә озак тормый әрәм булды.

Аның язмышы хәзер дә минем күз алдымда тора. Тавышы һаман колакта ишетелә сыман... Әллә нинди серле бер эчке каршылык өзгәләгән кеше булып яшәп калган ул минем күңел түрендә.

Авыл! Безнең барыбызның да туган жиребез ул. Барыбызның да бик күп югалткан нәрсәләребезне эзләп кире кайтачак төбәге әле ул... Әнә шуннан гомергә китә алмастай егетләр бүген ниндидер эчке каршылык кичерәләр... Аларны авыл бик нык тота, жибәрми. Чөнки болар авылсыз тора алмаячаклар, югалачаклар — тимер һәм таш урманнарына кереп китеп, кешеләргә хәтле барып чыга алмыйча, адашачаклар алар. Шуны алдан ук сизеп, авыл үзенең кайбер балаларын жибәрми, үз кочагыннан ычкындырмый. Ләкин ул балалар канына инде әллә нинди замана «жене» кергән. Хәзер шул тарткалый аларның бөтен барлыгын, бөтен жанын, рухын...

Чорыбыз йөкләгән бөтен җаваплылыкны тоя идек кебек без үз эшләребезне планлаштырганда... Төп максатыбыз — матур, дөрес яшәүдә яшьтәшләребезгә чын күңелдән ярдәм итү иде.

...Иртә-кич ашаган вакытларда өйдә, Нәгыймәттәй белән колхоз эшләрен, авыл яңалыкларын тикшереп алабыз. Нәгыймәттәй үзе Назыйм абый башлаган олы эшләрне ихлас күңелдән яклый. Ике сүзнең берендә: «Алла ярдәм бирсен инде балакаема...» дигән теләген әйтми калмый... Алланың ярдәменә ышанмасак та, мин дустым Вәкил белән Нәгыймәттәйнең ниятен хуплыйбыз. Чөнки алар, олылар, дөрес сизә— Назыйм абыйның бөтен тырышканы колхоз өчен, халык өчен! Изге ниятле кешене исә халык тиз аңлап ала.

Беренче көнне Нәгыймәттәйнең авызыннан: «Атасы мәрхүм дә шундый иде аның...»— дигән сүз ишеткәч, ул сүзне хәтер түренә салып куйган идем. Икенче бервакыт җаен табып, ныграк та кызыксындым...

— Күпме гомер итеп, әтәсенең дә, әнәсенең дә бер генә кыек эшен дә хәтерләмим... Бик ярдәмчелләр иде икесе дә, изге күңелләләр... Урыннары оҗмах түрендә булсын... Кемнән генә сорасаң да шулай диер...

Нәгыймәттәй утырып сөйләшергә яратмый — гел аягүсте сөйләшә. Бу юлы да шулай, самавыр куеп йөри. Мин тагын әңгәмәне үземә кирәк якка борам, һаман Назыйм абый турында сораштырам...

— Аңа да рәхәт туры килмәде инде... Бик яшьтән үгез җигеп үсте. И-и-и, чиләнәләр иде инде ул кире хайван белән... Балакайларым үзләре генә беләләр! Төн уртасында торып, салкын кыш көннәрендә Иделнең аръягына печәнгә чыгып китәләр иде бит... үзләре бот буе малайлар... Күрделәр инде алар да, күрделәр...

— Аннары нинди эштә эшләде соң?

— Кем, Назыйммы? Соң, нинди эш дип... Шул инде... Тракторга укыды аннары, тракторга! Бик алда бара дип сөйлиләр иде... Кәртечкәсен тактага куялар иде гел дә...

— Ә аннан соң?

— Әй-й, балам — тынгысыз кешене, тынгысыз җанлы адәмне үзең беләсең бит инде! Бер генә дә тик тора алмый бит ул! Аңа гел ни дә булса җитми, аңа гел ни дә булса кирәк!.. Назыйм да шундый бит ул, атасы мәрхүм...

— Шулай шул...— дип куям мин Нәгыйматтәйне тагын да дәртләндерергә теләп.

— Тракторда озак эшләде ул, бик озак эшләде... Төгәл генә елын белмим, бик күптер. Әнисе мәрхүмә сөйлидер ие, киемендәге караны юып бетерер хәл юк дип. Икешәр-өчәр кат юам дип.

— Ә-ә-ә...— дим мин дәшми калмас өчен генә...

— Яшьтән үзе эшләп үскән бала шул... Шуңа күрә эшләгән кешенең кадерен белә... Ул механизаторларны, сыер савучыларны кара — ничек хөрмәтли ел саен! Өрмәгән җиргә дә утыртмый бит!

Бусы дөрес. Бу кадәресен мин дә беләм, күреп торам... Шулай да минем бит әле тагын да күбрәк беләсе килә Назыйм абый турында... Тагын җайлап кына сораштырам...

— Укыды ул аннары, укыды... Биш ел укыды! Биш ел! Казанда укыды!.. Ничек кенә укыгандыр анда, өйдән дә бик ярдәм итә алмадылар бугай инде. Ул чакны үзең беләсең бит, тормышлар хәзергечә түгел ие... Бутәнчәрәк ие!.. Җәй саен кайтып эшлидер ие инде! Анысына тырыша ие. Әйтәм бит: эшкә дигәндә алар нәселенә куш инде син!

— Шуннан соң агроном булдымы инде ул?

— Кем, Назыйммы? Соң, шуннан соңдыр инде, шуннан соңдыр... Әйе, әйе — ул вакытны Шәймәрданов бездән киткән ие бит, урыны бушаган ие. Назыйм шунда кайтты, агроном булып. Шул елны кайтты...

Калганын инде үзем дә беләм. Кайткач та җиң сызганып тотынган ул эшкә! Аларын миңа сөйләделәр инде аның... Колхозның бөтен эшен фәнни нигезгә куйган ул. Мине биш ел буе хөкүмәт юкка укытмады, дигән! Менә шушы басуларның уңышы күтәрелсен, халыкка икмәк күбрәк булсын дип укытты мине хөкүмәт, дигән ул!

## Сигезенче төн

Әхнәфнең гадәт-холкына инде күнегеп җитәм дигәндә генә, көтелмәгән бер-бер хәл белән ул мине яңадан гаҗәпләндереп куя. Кичәге сөйләшүдән соң аны бүгенге яшь энтузиаст, яшьләр вожагы итеп күз алдыма китерә башлаган идем. Инде шул яктан ачылуын көтә идем. Бу төнне ул тагын бик күп эшләре турында сөйләр дип уйлаган идем.

Ләкин ул, мине аптыраштa калдырып, бөтенләй икенче нәрсә турында сөйләп китте.

— Әллә нинди бер гадәт бар миндә, үземне дә куркытып куйган сыйфат — ничектер, тормышны бөтен киңлегенә иңләп барасы килә минем кайчак! Һәммә нәрсәне эшләп, барысын да үзем дигәнчә үзгәртеп, матурлап, үзем уйлаган тәртипкә салып барасы килә! Әллә бу минем фантазиянең шулай, реаль чикләрне онытып котырынуы, әллә үзем дә аңламаган бүтән көч, бүтән нәрсә бу?

Колхозга килеп, председатель Назыйм абыйның ничек дәртләнеп эшләп йөрүен күрү белән миндә шундый теләк туды: аның нинди кеше икәнен халыкка күрсәтергә, аңлатырга! Мондый кешеләрнең әле бездә шактый сирәк очраганын әйтеп, аларга ышанырга чакырып язасы килә иде минем. Аны Хәкимуллин ишеләр арасында күрү бу теләкне бигрәк тә көчәйтә, Назыйм абыйны яклап чыгуны тагын да мөһимләштерә иде.

Күпмедер вакыт фикер туплап йөргәч, «Безнең заман герое» дигән

зур гына очерк яздым. Иң башта Назыйм абыйны кеше буларак ачарга тырыштым. Аның халык өчен, колхоз өчен җан атып йөрүен югары кешелек сыйфатлары нәтиҗәсе итеп күрсәттем. Һәр җитәкченең иң башта югары кешелек сыйфатларына ия булуы бүген бик кирәк икәнен басым ясап әйтергә тырыштым.

Бүгенге тормыш һәм көннең чын геройлары хакындагы бик күп уй-фикерләрем керде ул язмага. Чын геройларны яклаган ялкынлы сүзләр күп иде анда. Әнә шул очерк аша мин тормышның үзем дөрес дип тапкан һәм Назыйм абый ише җитәкчеләр күргән үсү юнәлешен расларга тели идем. Кешеләрне шуңа ышандырырга тели идем!

Язманы элек үзем эшләп киткән редакциягә җибәрдем. Җибәрдем дә дулкынланып көтә башладым. Андагыларның фикере ничек булыр? Алар ни дияр?

Болар барысы да минем өчен хәзер бик әһәмиятле иде. Хәзер бик зур мәсьәлә хәл ителә иде. Бу геройны кабул итә алырлармы? Ул үзенә ышандыра алырмы? Аның бүгенге тормыш өчен кем булуын, нинди көч булуын аңлый алырлармы?

Җавап озак торып, көттереп кенә килде. Күрәсең, үз кеше — үпкәләмәс әле, дигәннәрдер инде... Фикерләрен язып җибәрергә ашыкмадылар алар. Ә бәлки мине бераз суынсын, язганы турында аек баш белән рәк уйлансын дигәннәрдер...

Бүлек мөдиренең миңа язган хаты мондыйрак иде. «...Безне онытмавыңа сөендек. Очеркыңны да бик күпләр укыды, сорап алып, кая әле нәрсә тапты икән, дип укыдылар. Менә мин сиңа уртак фикерне язам дип уйлыйм. Безнеңчә, син геройны артыграк ялтыратып җибәргәнсең, фантазияңне җәлләмәгәнсең. Шуңа күрә ул синең тормышчан ук булып җитмәгән...»

Әйе, алар Назыйм абыйның заман герое булуын аңлап, бәяләп җиткермәгәннәр иде. Ул чагында аларның мондый җавабы минем башыма да сыймаган иде. Ә менә хәзер бу җавапның нинди җирлектән чыгуын беләм сыман. Алар очерктан моңа кадәр үзләре күреп ияләнгән гадәти председатель табарга тырышканнар. Бер карасаң, аларны аңлап та була шикелле... Ләкин Назыйм абый кебек кешеләрне, бүгенге тормышта шулай ук бик реаль булып, халыкның бик күп ихтыяҗларына җавап биреп яшәгән, эшләгән җитәкчеләрне кая куясың?! Дөрес, әлегә алар күпчелек түгел, артык күп тә түгел әле алар — сирәк очрыйлар. Әмма тормыш тарафыннан никадәр таңсыкланган, ничек көтелгән кешеләр бит алар! Минемчә, җәмгыятебезнең бүгенге, бигрәк тә иртәгәге үсеше күп дәрәҗәдә шундый шәхесләрдән торачак!

Элекке коллегаларым бу геройны аңлый алмадылар. Аларга бүген күпчелекне тәшкил иткән җитәкче образы кирәк булып чыкты... Ә минем өчен бу — кешенең алгарак карый алмавы, якын киләчәкне күрмәве иде.

Инде заман сәхнәсеннән китеп баручы «бүгенге»ләр белән артык мавыккан алар, дип уйладым мин. Тормышны перспективада, хәрәкәттә күрә алмау бәласе иде ул, минемчә...

Назыйм абыйның яшәү һәм эшләү рәвешен аңлый барган саен, бу кешенең көченә, киләчәгенә ышанычым арта төшә иде. Аны шундый зур итеп «заман герое» дип атау мине һич тә шикләндерми иде. Редакциядән килгән җавап та ышанычымны какшата алмады. Ничектер, бераздан ул хатка ис тә китми башлады.

Назыйм абыйны яклау, саклау теләге миндә сүнү генә түгел, үз эшем белән бертигез дәрәҗәдәге максатыма ук әверелде. Әйтәм бит, хәзер инде ул ният—үз идеалымны саклап калу өчен көрәш кебек иде!

Бер көнне, үзем дә уйламаганда, башыма шундый фикер килде. Минем бик яратып укый торган газетам бар —«Комсомольская правда». Ә нигә әле шуңа җибәреп карамаска!

Тиз генә дәфтәремне эзләп таптым, русчага әйләндереп яңадан язып чыктым һәм... җибәрдем дә!

Алар миңа җавап биреп тормадылар. Ә беләсезме, нишләделәр? Минем ул очеркымны «Аның беренче хикәясе» дип басып чыгардылар. Мин күләргә дә, еларга да белмәдем. Болай барысы да минекечә, бераз кыскартылган гына... Әмма ул бит «хикәя» дип басылган, уйлап чыгарылган әйбер булып! Ә Назыйм абый бит — чын кеше, чын председатель! Анда язылган бөтен эшләре дә чын бит аның!..

Әйе, бүгенге дөнья аның чынлыгына ышанмаска бик нык тырыша, теше-тырнагы белән каршы килә иде! Бу ниятем минем әнә шулай, ярым-ярты хәлдә генә тормышка ашты. Шуңа күрә ул миңа әллә ни канәгатьлек тә китермәде. Күпләр күрми дә калгандыр әле аны. Зур шатлык китермәгәч, мин дә мактанып, күрсәтеп йөрмәдем.

Бары тик комсомол райкомының беренче секретаре гына бер баргач: «Укыдык, укыдык!»— дип куйды. Тик минем нинди максат белән язуны белмәгән кешегә аны хикәя итеп, хыял җимеше санап укуның ни кызыгы булсын соң!

Ул язмам үзем теләгәнчә басылса, Назыйм абыйга күрсәтеп бераз мактанып алырга да исәп бар иде барын. Ә болай, хикәя булып чыккач, киресенчә, аннан көлү сыман дип таптым. Шуңа күрә күрсәтеп тә тормадым... Минем әле аны яклап тагын ниндидер бер зур эш эшлисем бардыр шикелле иде ул чак. Аны һәрчак кемдер яклап, саклап торырга тиеш сыман тоела иде миңа...

## Тугызынчы төн

Ял йортына көн саен диярлек яңа кешеләр килә, ә вакытлары тулганнар диңгез белән саубуллашып, кайтып китә торалар... Миндә дә бу арада ялдан, эшсезлектән туюга охшаган нәрсә тоела башлады. Башта бик күңелле, кызык кебек тоелган дусларның күбесе туйдырды, аларның минем өчен ачыласы яклары калмады сыман. Ә кайберләре исә, үзләре сөйләгән кыска анекдотлар кебек, вакыт узу белән күз алдында тоныкландылар.

Элекке дусларымның шулай итеп кызыгы кимегән саен, үз бүлмәдәшем белән кызыксынуым арта барды. Юк, аның башкаларга охшамавы гына үзенә тартмагандыр мине дип уйлыйм... Аның рухына ялгенгән көчне, сәләтне тора-бара күрә, аңлый башладым бугай мин.

Әйе, анда — Әхнәфтә — безнең күбебездә булмаган бер көч, бер сыйфат бар иде. Ул сыйфатны ничек дип әйтергә? Үз-үзеңә нык ышану, таяну дипме? Үзеңдә тормышның вак-төяге генә җиңә, сындыра алмастай җегәр, көч, яшәү суты тою булдымы икән ул? Әнә шуннан туган олы ышаныч идеме икән ул?

Чыннан да, Әхнәфнең тормышта ниндидер, без белмәгән бер зур тотанагы бар төсле иде. Үзенең эчке ныклыгыннан килгән, шуннан туган көчлелек, хәтта әйтергә мөмкин — хөрлек сыман иде ул.

Ә ул үзе, бу нәрсәгә һич тә игътибар итмәстән, сөйли бирде, тагын да ачыла барды...

— Минем дәртләнеп сөйләүгә карап, сездә «бик җиңел бирелгән икән моңа барысы да...» дигән тәэсир калмасын тагын. Бу эшләр хакында мин, чыннан да, тыныч кына, битараф тавыш белән генә сүз алып бара алмыйм. Чөнки... чөнки, дәртләнмәсәм, гомумән, эшли дә алмыйм мин. Мине эш белән нык дәртләнү, рухлану гына йөртә. Ә болай, тыныч кына эшли алмыйм мин, ахырга хәтле барып чыгарга минем еш кына түземлегем җитми... Ә хәзер сөйли торганнар алар барысы да яратып, дәртләнеп башкарган эшләр.

Колхозда яшьләр тормышына җан кертү, яңача оештырып җибәрү дә җиңел булмады. Без һәркем турында кайгыртырга тырыштык, дигән идем. Шуның дәвамы итеп тагын бер зур бурычны алга куйдык. Һәр яшь кеше колхоз һәм яшьләр тормышы белән кызыксынсын, гомуми эшнең ничек торышы, ничек барышы хакында уйлансын, җитәкчеләр кушканны үтәүче генә булып калмасын, дидек. Чөнки үзегез дә беләсездер — кеше кушкан эш ул еш кына бик күңелсезгә әйләнә, тиз туйдыра. Ә без яшьләрнең үз инициативалары буенча эшләүләренә омтыла башладык. Киңәшеп, сөйләшеп эшләү турында сүз бара, билгеле...

Ахыргача алып барып чыга алган тәкъдирдә бу — бик көчле стимул. Бу инде коммунизм принципларының берсе дигән сүз. Чөнки кеше әкрен-әкрен үзе, кемдер кушмыйча һәм мәҗбүр итмичә эшли башлый!... Әнә шуның матур гына чаткылары, чалымнары күренә сыман иде бездә. Яшьләр уртак тормыш мәнфәгатьләре тирәсенә тартыла, туплана башлаган иде. Аларда ниндидер күләмдә кызыксыну барлыкка килгән иде.

Шушы урында бер вакыйга искә төшә.

Мин килеп инде шактый эшләгәч, яшьләр белән бик кызыклы бер сөйләшү үткәрдек без. Аның көн тәртибе дә бик яңа иде. Ничек дип уйлыйсыз? Юк, сез аны беркайчан да белә, таба алмыйсыз! Ул көн тәртибе — «Әгәр мин председатель булсам...» дип атала иде. Билгеле, мин аны башта Назыйм абый янына кереп шыпырт кына киңәшеп чыктым. Ул моны ишеткәч тә, төшенгәч тә кычкырып көлеп җибәрде. Аннары мин аңа аңлаттым. «Безнең иң төп максатыбыз — яшьләрне колхоз тормышы белән ныграк кызыксындыру, колхозны тагын да үстерү өчен яңа идеяләр тудыру»,— дидем. Соңрак үзе дә: «Тыңларга мин дә кереп утырсам...»— дип кызыгып киткән иде, ләкин «Юк, яшьләр кыенсынырлар, мин барында барысын да әйтмәсләр...» — дип кире уйлады тагын.

Ул җыелышның бөтен барышы яңача, моңарчы күреп өйрәнмәгәнчә иде. Иң башта бригада комсорглары җыелышка рапорт бирделәр. Үткән җыелыштан бирле үзләренең оешмасы нәрсәләр башкарган, шуны әйтеп чыктылар. Бу — эшлеклелекне арттыру, яшьләрнең җыелышка ышанычын ныгыту өчен бик кирәк иде. Соңрак та без гел шулай эшли торган булдык.

Аннары яшьләрне әңгәмәгә алып кереп китү өчен сүз әйтеп җибәрүче кирәк иде. Гадәттә, бүтән урыннарда мондый керешне колхоз җитәкчесе әйтә. Әмма биредә Назыйм абыйның булуы кыенсыну тудырыр дип уйлагач, кереш сүзне Хәкимуллин әйтеп җибәрергә тиеш иде. Тик минем бик күп мәртәбәләр сынаганым бар: сүзне башлап җибәрүче җанлы, кызыклы фикерли белми торган, гомум билгеле нәрсәләрне кабатлаудан уза алмаган кеше булса — теләсә нинди үткен һәм кайнар мәсьәләнең дә тыңлаучы өчен кызыгы калмый, күңелсез вакыт уздыру гына килеп чыга. Шуңа күрә без яшьләр өчен аеруча мөһим дип уйланылган чараларга үзләре шәхес буларак кызыклы булган кешеләрне генә тартырга тырыша идек.

Сүз уңаеннан әйтеп үтим — менә шәһәр җирләрендә дә яшьләр өчен дип әллә нинди кичәләр үткәрелә. Тик кызганыч, аларда яшь егетләр-кызлар бик әз була. Ни өчен? Чөнки ул кичәләрне бүгенге яшьләрнең ни теләгәнен, тормыштан, дөньядан ни көткәнен үз күңеле, үз җаны белән тоеп, аңлап яшәмәгән кеше оештыра кайчак...

Бергәләп киңәшкәч, без Хәкимуллиннан котылу җаен таптык. Башка шундый бер фикер килде. Элек, сугышка хәтле елларда, бу колхоз якын-тирәдә данлыклы, бик бай булган икән. Ул республика күләмендә шаулаган, дип сөйлиләр. Шул чордагы колхоз председателе әле дә исән, авылда яши икән. Башлап сүз әйтү өчен аны чакырырга карар кылдык без үз җыелышыбызга!

Хафиз абзый без яшьләрнең өметен аклады. Инде нык картайган

булуына карамастан, ул чакта ничек эшләүләрен искиткеч дәртләнеп, канатланып сөйләде. Аның өчен чын романтика булган икән бу эш, дип уйлап утырдым мин ул сөйләгәндә.

Хафиз абый онытылып китеп сорауларга үзе уйлаганча җавап бирә башлады, секретарь кыз исә тәкъдимнәрне язарга тотынды. Аңа Назыйм абый: «Берсен дә төшереп калдырма!»— дип кисәтеп әйткән иде, башын да күтәреп карамый, яза да яза...

Үзебезнең эш планын раслагач, соңыннан, таралышыр алдыннан тагын шундый уртак фикергә килдек: китапханә ишек төбенә бер кечкенә тартма элеп куярга — кызыклы тәкъдимнәр өчен! Анда — яшьләр тормышына һәм колхоз хәлләренә кагылган бөтен уй-фикерләрне язып салырга!

Яшьләрне әнә шундый дәрәҗәдә активлыкка китереп җиткерү эшнең башы өчен бик әйбәт иде. Инде шуннан соң күп нәрсә җитәкчелектән торырга тиеш иде...

Җыелышның икенче көнне үк мине Хәкимуллин үз кабинетына чакырып алды. Башта: «Кәефләрегез ничек?» — дип сорашып алган булды.

Нишләптер, бу сорау минем гел көләсене китерә. Аны ишеткәч мин һәрвакыт аптырап калам: «Нәрсә соң әле ул кәеф? Минем кәефем кайда соң әле ул? Ничек, нинди соң әле ул?»

Мин генә шулай гаҗәпләнәм микән соң бу сорауга? Гел ашыгып, кабаланып йөреп минем генә кәеф турында уйлаган юк микән соң?.. Әллә башкалар да шулай аптырый микән ул сәер сорауга?... Белмим, һәрхәлдә, ул миңа гел мәзәк, буш сүз сыман тоела. Минемчә, кеше бик күп нәрсәне әңгәмәдәшенең йөзенә бер карау белән белә бит инде... Ә калганын, эчтәгесен кеше аңа тиз генә әйтеп бирер микәнни?! Аның ашык-пошык кына бирелгән соравына. «Кәефең ничек?» дип сорау белән: «Менә шулай-шулай минем кәеф, иптәш Хәкимуллин!» дип, тиз генә әйтеп бирер була микәнни соң ул?!.

Бу юлы да мин, ирексездән, берни уйламыйча гына елмаеп куйдым бугай. Ә ул елмаю Хәкимуллинга бер дә ошамады. Тавышына ук чыккан ризасызлык белән китте бу алып:

— Эшегез әллә ни шәптән булмаса да, кәефегез шәп күренә, сорап та торасы юк икән!

Болар минем өчен бик үзәккә үтә торган сүзләр иде.

— Нигә... Начармыни?.. — дидем мин бөтенләй югалып калып.

— Кичәге сөйләшүдән мин бер дә канәгать түгел. Сездән — укыган, югары белемле кешедән һич тә моны көтмәгән идем! Юк, моны көтмәгән идем!

— Ә нәрсә ошамады соң сезгә? — дип сорадым мин аны чын-чынлап аңларга, ни өчен шундый бәя бирүен белергә теләп.

— Житди түгел! Җыелышка охшамаган! Тәртип юк! Әгәр шунда райкомнан килгән берәрсе булса?!. Кем нәрсә тели — шуны әйтә бит. Берсен-берсе бүлә-бүлә сүз башлау дисеңме, басып та тормыйча, урыннан гына тәкъдим әйтү дисеңме!

Бу — минем иң куанган, уңышым дип иң шатланган нәрсәм иде. Бу — колхоз яшьләренең җыелышка ышанып, үз эчләрендәгене әйтүе, димәк, уртак эш өчен кайгырта башлаулары иде. Шуңа күрә мин бу мәсьәләдә һич шикләнми, икеләнми идем. Мин бу ышанычым өчен бәхәсләшергә, көрәшергә әзер идем!

Тик менә телгә килгән сүз генә артык кискен булды бугай:

— Ә алар сезнең җыелыштагыча авызларына су кабып утырсалар янсә алдан ук язып килгән, сез кат-кат карап, тикшереп чыккан кәгазьне укып кына төшсәләр, әйбәт булыр идемени?! — дидем мин ярсый төшеп. — Ул чагында сөйләшү нигә кирәк соң? Күз буяу өчен генәме?!

Халыкны җыю, кешеләрнең һәм үзебезнең бу заманда бик кыйммәтләгә әйләнгән вакытыбызны бушка алу нигә кирәк соң алайса?!

— Энем, сиңа политик белем җитенкерәми, ахры... Җитдирәк булырга кирәк иде, җитдирәк! — дип кенә куйды ул, минем сүзгә туры җавап бирмичә, гадәтенчә, гомуми сүзләр белән. Аның тавышында ниндидер янау төсмере яңгырагандай тоелды миңа.

Шул сөйләшүдән соң аның миңа булган мөнәсәбәте сизелерлек салкынайды, сөйләшүе тагын да корыланды. Моны күреп мин: «Шулхәтле нәрсә булды соң әле?..» — дип аптырап кала идем. «Чыннан да, әллә бер-бер зур ялгыш җибәрдемме?»

Хәкимуллинның миңа мөнәсәбәтендәге зур үзгәрешкә шул гына сәбәп булу бик гаҗәпләндерә һәм, яшермим, елмайта да иде. Чөнки Хәкимуллин инде күптән тарих чүплегенә себереп түгелгән иске чиновник кыяфәтендә күренә иде миңа ул вакытта! Тик тормыш әле без уйлаганга карап кына барысын да себереп үк түкми икән! Ул әле алай үк ашыкмый икән! Анда әле күп, бик күп кала икән үткәннең җимешләре!

Ул чагында, Хәкимуллин белән булган әлеге сөйләшүдән соң: «Ничек инде шундый ачык хакыйкатьне дә аңламаска мөмкин!» — дип, үземә нык ышанган хәлдә эчтән елмайган идем мин.

Ләкин Хәкимуллин үзенең елмаюын ахыргарак калдырган икән шул... Соңыннан көлгән кеше әйбәтрәк көлә, дигән сүз бар. Бу да иң соңыннан көлде шикелле.

Миннән дә, хәтта Назыйм абыйдан да соңрак елмайды ул...

## Унынчы төн

Чыннан да, Әхнәф мине бик гыйбрәтле хәлләр эченә алып кереп китте бит әле... Хәзер инде үзем дә ул сөйләгән хәлләр эчендә йөрим, шуларда катнашам кебек. Колхоз председателе Назыймның күмәк эш өчен җан атып йөрүен үзем күрәм шикелле... Еш кына: «Эх, бөтен җирдә дә шундый энтузиастлар булса иде!..» — дип тә куям... Әхнәф үзләренең эше белән тәмам мавыккан иде. Аның һәр сүзеннән диярлек мин әнә шуны сиздем...

— Эшләр әйбәт кенә бара иде безнең, — дип сөйләп китте Әхнәф бу кичне. — Назыйм абый колхоз эше өчен үзе дә ут кебек бөтерелә, башкаларның да шулай йөрүен таләп итә иде... Ә Хәкимуллинга исә колхоз эше бармы-юкмы — шулай үз көенә йөри бирде ул вак-төяк нәрсәләр белән шөгыльләнеп...

Районнан Сулимов килгән чакларда гына Хәкимуллин аны чәй эчәргә чакырырга онытмый иде. Әйтәм бит, ни өчендер аларның борчаклары пешә иде. Уртак тел тапкан иде алар...

Сулимов колхозга килгән саен Назыйм абыйның вак-төяк кимчелеген таба торды, шуның белән кәефен кыра торды. Аның юлына аркылы төшүне үзенә максат итеп куйганга ошый иде ул. Миңа шулай тоела иде...

Ә бервакыт Назыйм абыйга чынлап бәйләнергә җай чыкты.

Колхозның ветврачы яшь кенә бер егет иде. Ул әле Назыйм абыйның сынау срогын үтә иде. Аңа ышанасы килә иде шикелле Назыйм абыйның... Әнә шуңа ышанырга теләве, ышануы аркасында үзе кыен ашады да инде ул...

Һич көтелмәгән хәл булды. Йогышлы авырудан колхозның дистәдән артык савым сыеры үлеп китте. Бу — бөтен район өчен гадәттән тыш хәл иде. Тикшерә башладылар. Теге ветврач егет йогышлы авыруга

каршы алдан укол ясамаган булып чыкты. Ә үзе Назыйм абыйны алдаган, «ясадым» дигән. Сизелмәс, болай гына үтәр дигәндер инде. Ләкин ул «ЧП» болай гына үтмәде. Аның тавышы зурга, артык зурга китте!

Райисполком председателе Сулимов үзе җиң сызганып тотынды бу эшкә. Партия райкомының беренче секретаре авырып Казанда больницада ята иде, шуңа күрә Сулимов үзен тулы хуҗа һәм хөкемдар итеп сизде ул көннәрдә. Райком вәкиле белән колхозга килеп, шундук җыелыш җыйдырды. Колхозчыларның гомуми җыелышын. Аңа бер генә мәсьәлә — Назыйм абыйны председательлектән алу мәсьәләсен куйдырды.

Хәкимуллин һәм тагын берничә кеше аның беренче булышчылары булдылар. Алар җыелышта да, берсе артыннан берсе чыгып, Сулимов фикерен куәтләделәр, артык зур булмаган кимчелекләр санадылар, шуларны күперттеләр. Ә савым сыерлар белән килеп чыккан күңелсез хәлне инде ничек кенә итеп аңлатмадылар!

Назыйм абыйны яклап чыгучылар да булды.

Комсомол җыелышларында һәрвакыт иң кирәкле мәсьәләләр күтәреп чыга торган тракторчы егет бар иде. Ул бик кызып сөйләде. Хәтта: «Монда утырган кешеләр арасында колхозга Назыйм абый хәтле бирелгән берәү дә юк! Мин моны нык ышанып әйтәм! Ә сез шул кешене эшеннән алырга дисез! Утызынчы елларда моны, мөгаен, кулак коткысы диярләр иде! Чөнки — колхозга каршы эш бу!» — дип үк әйтеп ташлады.

Өлкәннәрдән тагын берничә кеше: «Әллә ашыкмаска кирәк микән соң?» — дигәндәйрәк, председательне яклап сүз әйттеләр.

Мин бу җыелышта сөйләми кала алмый идем. Бу җыелыш минем өчен үз гомеремдәге иң зур сынау иде! Мин ул җыелышта Назыйм абыйны гына түгел, ә үземне дә, үз идеалымны да, тормышка булган олы бер ышанычымны да яклый идем кебек. Шуның өчен көрәшә идем шикелле!

— Кайсыбер басуларда әрләннәр бик күп була, — дип, чагыштырудан башлап киттем мин сүземне. — Ә әрләннәрне үзегез беләсез: ул барысын да бары тик үз оясына ташый! Комсызланып, мәңге туймас кебек булып, оясында мөлкәте күбәйгән саен нәфесен тагын да узындыра-узындыра көн дә, төн дә мөлкәт ташый ул оясына!

Әнә шул әрләннәр үз оясына мөлкәт ташыганда аларга каршы төшкән һәркем, һәрнәрсә — зур дошман була!

Алар — каршы очраган, комачаулаган һәркемгә җан ачуы белән тешләрен ыржайталар! Назыйм абый һәм аның эш стиле — әнә шул әрлән басуына килеп кергән үткен төрән иде! Ул аларның җайлы, рәхәт тормышларын бозды! Ул колхозны алга җибәрү турында гына кайгыртты! Бүтәннәр сыман, иң башта үз йорты өчен борчылмады! Менә ни өчен кайберәүләргә ошамый ул! Менә ни өчен кайберәүләр аннан котылырга тели!

Әрләннәр күбәйгән басуда тагын — үлән, чүп үләне мул үсә. Әнә шундый куе үлән әрлән ояларын каплап тора.

Хәкимуллиннарның эш стиле — куе үлән сыман: ул әрләннәрне матур-матур сүзләр дулкыны астында яшереп, иркәләп үстерә! Эшкә бернинди файда бирми торган гомуми сүзләр теге әрләннәргә яшеренү өчен бик әйбәт тирәлек! Бик яхшы урын! Чөнки андый куелыкта аларның кем икәне күренми! Алар, ул әрләннәр, курыкмый яши алалар анда!

Ә ахырдан, турыдан-туры залга мөрәҗәгать итеп, болай дидем:

— Иптәшләр! Сез белсәгез иде үзегезнең бүген нинди мөһим эш эшләгәнегезне! Сез бит, менә хәзер, менә бүген үзегезгә ике юлдашның берсен сайлыйсыз! Сөң уйлап карагыз: аларның кайсы сезнең өчен

ышанычлырак юлдаш соң? Кайсысы сезнең өчен ныграк тырышты моңа хәтле һәм аларның кайсысы моннан соң сезнең өчен тагын да күбрәк эшләячәк?

Ә мин үз фикеремне ап-ачык итеп әйтәм: Хәкимуллин кебек җитәкчеләр безнең арада очраклы гына, вакытлы гына! Килер бер вакыт — һәм без аларга аермачык итеп, инде бүтән һич тә, беркем дә, беркайчан да шикләнмәслек итеп тамга сугарбыз! Бөек Ленин исеме белән раслап тамга сугарбыз без аларга! Аларның эшен һәм яшәвен Ленинның эш стиле белән чагыштырганнан соң сугарбыз без ул тамгабызны!

Сулимов үзенең йомгаклау чыгышында «яшь иптәшнең бик томанлы ишарәләре» дип кенә кагылып узды минем сүзләргә... Хәер, мин аннан башканы көтә дә алмый идем...

Назыйм абыйны эшеннән алдылар.

Кешеләр җыелыштан ниндидер бер ярамаган эш эшләгән төслерәк таралыштылар. Күрәсең, салкын акыл сүзен тыңлап эндәшмәгән күпләрнең күңелләре үз урынында түгел иде...

Сүз уңаенда әйтим: ә мин, гомумән, күңел дигән нәрсә кешене дөресрәк алып бара дип саныйм...

Назыйм абыйның эшеннән алынуы минем өчен бик көтелмәгән хәл иде. Шуның хәтле бирелгән кеше эшләргә дә эшләргә генә тиеш дип уйлый идем мин. Тракторчы егет әйткәндәй, бу колхозда хәзер андый җитәкчене көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың бит! Әнә шундый председательне эштән алдылар... Нәрсә дигән сүз соң бу? Әллә артык яхшы кеше ярап бетми микән соң кайчак? Әллә күпләр, гомумән, бу кешегә ышана алмый, аның чынлыгына, ихласлыгына инанып бетми микән соң? Үзләренчә яшәмәгән кеше әллә аларны шикләндерә, куркыта микән?

Акылым әлеге җыелыш турында белсә дә, күңел һич тә аны чын күренеш итеп кабул итә алмый иде. Ул миңа ниндидер, киләчәктә мөмкин булган бер хәл сыман гына тоела иде һәм шуңа күрә, уйлап эшләгәндә әле аны булдырмый калу да кулдан килә шикелле иде.

Җыелыштан соң бер көн үтте. Ике көн дә үтте. Күңел тынгысыз иде. Ул үз урынында түгел иде. Нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Мин аны якларга, хакыйкатьне өскә чыгару өчен барысын да эшләргә тиеш идем! Бу бурыч хәзер минем өчен иң мөһимгә, иң кирәклегә әйләнде. Чөнки үз күз алдымда эшләнгән ялган белән килешеп калып, шуннан соң миңа яшьләр күзенә күренү, аларны ниндидер матур эшләргә өндәү оят булачак иде! Яшьләр күз алдында мондый нәтиҗә белән тәмамланган эш булмаска тиеш иде. Алар бик тырышып йөргән кешенең санга сугылмыйча, эшеннән чыгарып ташлануына шаһит булмаска тиешләр иде! Эшкә бирелгән кешенең тормышы яшьләр күз алдында болай бәяләнмәскә тиеш иде!

Әлеге җыелыш карары дөрес калса — ихлас күңелле эш кешесе шулай бәяләнсә — мин кемне нинди эшкә өнди, ышандыра алам соң?! Безнең сүзләргә аннары кем ышансын!

Ике көн буена уйлангач, мин райисполком председателе янына барырга булдым. Анда әләгүе бик кыен икән. Көч-хәл белән, ялынып-ялварып кына, биш кенә минутка кабул итүенә ирешә алдым. Миннән алда кергән кеше белән ул бик күңелле сөйләшкән, ахры, көлү чаткылары йөзендә әле дә саклана иде. Аның уйлары мине борчыган мәсьәләдән бик еракта иде. Бу мине сагайтып калдырды. Нәрсәгәдер шикләнеп куйдым. Шунда гына кылт итеп исемә төште: «Тукта әле, бу бит республика җитәкчесе алдында Назыйм абый тарафыннан оятка калдырылган кеше! Бу бит Сулимов! Назыйм абыйга бик ачуы килгән кеше. Шулай булгач, аңа сөйләвем дөрес булырмы?».

Ләкин, бирегә кергәч, инде сөйләми чыгу мөмкин түгел иде. Мин ул

биләгән бик югары урынга, аның гадел һәм кешелекле булырга тиешлегенә ышана идем.

Хәлне тиз генә аңлаткач, сүземне бер генә сорау белән бетердем.

— Фанатикларча эшкә бирелгән кешене тел бистәләре белән алыштыргач — без авыл хуҗалыгын ничек күтәрербез соң?!

Бу сүзләрдә минем бөтен борчылуым да, озак вакытлар эчемдә йөрткән уйларым да, һәм, яшермим, үз язмышымның хәл ителүен көтү дә бар төсле иде... Мин инде байтактан бирле Назыйм абый белән икебезнең юлларыбыз бер, юлларыбыз уртак дип йөри башлаган идем... Моны Сулимов та сизеп алды.

— Күрәм, сез дә аның шәкерте булып киткәнсез...— диде ул әлеге шат чыраен яшерүне кирәк тә санамыйча. Аннары кинәт кенә җитдиләнеп китте һәм бер дә көтмәгәндә миннән:

— Казан сагындырмыймы соң? — дип сорап куйды.

Аның теле миңа әнә шул сорауны бирде, ә күзләрендә мин башка сүзләр укыдым...

...Димәк ... Димәк...

«Тукта әле, шулай ук Хәкимуллиннар кирәгрәк булып чыга микәнни соң?»

Бу сорау минем башыма соңрак килде. Мин аны Сулимовка биреп өлгерә алмадым. Ул икенче кешене кабул итеп, аны тыңлый башлады...

Мин әкрен генә чыгып китәргә мәҗбүр булдым...

Машинистка бүлмәсен дә үттем, әмма бу бинадан тиз генә чыгып китә алмадым мин. Юк, бер кеше әйткән сүзгә карап кына минем бу йорт турында фикерем үзгәрәчәк түгел! Аңа булган ышанычым какшаячак түгел! Чөнки күңелгә бик нык сеңгән ышаныч ул!

Ләкин, шунысы бар — мин инде хәзер нәрсә эшләргә икәнен төгәл генә белмим...

Әйе, күңелемдә, йөрәгемдә олы өмет яши, мин аны һәр минут тоеп торам, сизеп торам. Ләкин менә хәзер, чынлыкта нишләргә? Кем миңа ярдәм итә ала?

Ул көнне мин аптырап, кая барырга белмәгәннән генә, комсомол райкомының беренче секретаре, үземә бик җылы карый торган егет янына кердем. Бер нәрсә дә сөйләп тормадым. Кердем дә аның почмактагы тирән креслосына чумдым. Бүлмә хуҗасы үзе кәгазьләр белән мәш килә. Мин күзләремне йомдым да, әллә нинди бер сөер халәткә киттем — кинәт башымда бер генә сорау да калмаган шикелле булды...

Күпме утырганмындыр, белмим, мине секретарь егетнең тавышы гына исемә китерде.

— Диңгез буена бик шәп путевка ята! Күргәнең бармы әле диңгезне?.. Булмаса, әйдә — гуляй!

Диңгез? Нинди диңгез?..

Ә-ә, диңгез...

Кинәт кенә ул миңа бик кадерле, бик сагынылган урын кебек тоелып китте! Мин нәкъ әнә шунда барып бик күп әйберне ачыкларммын, күп сорауларга җавап таба алырмын шикелле иде!

Күңел теләгенә буйсынып, риза булдым.

Назыйм абыйны яклау өчен хәзер күп чабу түгел, ә тагын бер кат төптән уйлау кирәк иде шикелле.

...Бирегә килгәннән бирле әнә шул хәлләрне җентекләп барлап чыктым... Беләсезме, уйлаган саен мин Назыйм абыйның дөреслегенә ныграк ышана барам. Кайбер ялгышлары булуга карамастан... Бүген шундый җитәкчеләр кирәклеген тулырак аңлый төшәм. Бөтен алган белемем, тормышның бүген сизелеп торган зур ихтыяҗлары шуңа ышандыра мине. Хәл ителүне көтеп, алга килеп баскан бөтен мәсьәләләр шуңа ышандыра!

Әмма, инде ничә көн уйлап йөрүемә карамастан, минем әле «нишләргә?» дигән сорауга җавап таба алганым юк. Табылганнарының берсе дә дөрес һәм ышанычлы булып тоелмый... Ә миңа иң дөрес җавап барыбер кая да булса бардыр кебек тоела...

Менә ничә төн буе мин сезгә сөйлим, ә үзем күңелдән әлеге җавапны эзлим. Ул җавап көтмәгәндә килеп чыгар да, мине тынычландырыр сыман...

Тик шунысын әйтим — биредә диңгез үз-үземә булган ышанычымны тагын да арттыра төсле. Ул миңа үземнең күңелдәге көчкә, омтылышка ныграк таянырга куша сыман. Бирешмәскә куша сыман!

...Хәтерлисезме икән — мин үземне диңгез буенда тугандай хис итәм дигән идем... Менә хәзер мин, чынлап та, диңгез буенда. Тормыш мине әнә шул тойгыдан алып, бүгенге чынлыкка хәтле китереп җиткерде. Арада, урталыкта да диңгез сыман — әлеге стихия, замана ташкыны кайный...

...Кайбер көннәрне мин бирегә, диңгез буена ял итәргә килгән кешеләргә карап торам. Алар шул хәтле рәхәтләнеп ял итә алалар — ирексездән көнләшеп куясың...

Әнә шундый вакытларда мин үзем күптән югалткан бер халәтне күреп алган кебек булам... Аларга карыйм һәм уйлыйм... «Назыйм абый да, мин дә алар кебек гап-гади генә яшәгән булсак соң?! Шулар сыман артыгын борчылмыйча, үзеңә кирәкмәгән, кагылмаган нәрсә өчен баш ватмыйча, үз-үзеңне тынычсызламыйча гына... Үз бәхетеңне алда йөгереп йөргән балаңнан һәм шат йөзле хатыныңнан гына табып...»

Нигә, болар да кеше өчен аз бәхет түгел бит! Бу да — зур һәм чын бәхет бит!

Көньякның җылы кояшында кызынып яткан ганиләләргә карагач, еш туа миндә мондый уйлар... Андый чагында алар кеше ирешә алган бәхетнең, ләззәтнең шактый югары ноктасында булып күренәләр.

Ләкин шул ук вакытта, онытылып аларга сокланганда, үземдә кызык бер кичереш тә сизәм: әйтерсең, мин кысыла-кысыла бер кеп-кечкенә матур кабырчык эченә кереп барам. Кергән саен, торган саен бәләкәйләнә-бәләкәйләнә... Кайчагында ул тойгы шундый көчле була — мин чынлап та куркып китәм! Чыннан да, бер бөҗәккә әйләнеп китәрмен сыман!

Әнә шунда гына үземне кайчак кызыктырган әлеге халәтнең минем өчен инде мәңгегә югалган икәнен аңлыйм. Минем бәләкәйлегем белән бергә югалган икән ул...

Хәзер андый бәхеткә ия булу өчен һәм шуннан гына канәгатьләнеп яши алу өчен миңа яңадан бәләкәй булу кирәк икән...

Андый вакытларда бер яраткан шагыйремнең шигыре еш искә төшә. Дулкын турындагы, аның бары тик хәрәкәттә генә яши алуы хакындагы бик тирән мәгънәле шигырь ул.

Дулкын тынмый —
дулкын тукмый,
дулкын катмый,
суыкка ядрә атя,
бозларны бәреп вата,

— дип яза шагыйрь анда... Ә ахыры, беләсезме, ничек бетә ул шигырьнең?! Дулкынның үз-үзенә, үзенең төп хасиятенә хыянәтен шагыйрь менә ничек тасвирлый:

Эшеннән канәгатьләнә,
ачуы бераз кайта,
әкерен генә тынычлана,
ял итәргә дип ята...
һәм
ката!

Дулкын булып, давыл булып — тынгысыз йөрәк белән яшәргә яратылган кешеләрнең язмышын күрәм мин бу юлларда! Аларның бүтәнчә яши алмавын белдергән хакыйкатьне күрәм мин анда! Тынычлану — сезнең өчен һәлакәт, дигән зур кисәтү ишетәм мин бу шигъри әсәрдә!

Һәм... һәм мин ул кисәтүнең дөрес икәнен, бик тә урынлы булуын да аңлыйм! Бик тә нык аңлыйм!.. Назыйм абый, мәсәлән, бүтәнчә яши аламыни соң?!! Юк, бүтәнчә яши алмый ул!

## Унберенче төн

Бүген көндез Әхнәфкә ашыгыч телеграмма килеп төште.

«Борчылма, эшләр уңайга бара. Назыйм абыең!»— диелгән иде анда. Ул тиз генә әйберләрен җыйды да, самолетка чапты... Әле аның тагын бер атнага якын вакыты бар иде.

Шулай итеп, уйламаганда очрашкан, танышкан кебек — без аның белән тиз генә, көтмәгәндә генә аерылыштык та. Кем белә, бәлки бүтән бер дә, гомергә дә очрашмабыз...

Менә бу төнне мин бүлмәдә ялгызым гына..

Ярым ачык калган балкон тәрәзәсеннән көндәгечә диңгез исе, диңгез һавасы кереп тора. Бер дә тынып тормаган дулкын шавы ишетелә...

Бүген бүлмәдә Әхнәфнең ашкынулы, ярсу тавышы яңгырамый. Аның урынына Әхнәфнең бөтен сөйләгәннәре тулы булып күз алдыма килә, уйларымны били, игътибарымны тарта... «Үземне диңгез буенда туып үскәндәй хис итәм»,— дигән сүзләре һаман колак төбендә...

Диңгез... Дулкыннар... Гел хәрәкәт, хәрәкәт...

Әнә шул тынгысызлык рухы, активлык рухы Әхнәфнең сөйләгәннәрен тагын да ныграк аңларга ярдәм итә. Мин үз алдымда кечкенәдән үк зур һәм якты омтылышлар белән үскән яшь замандашыбызны күрәм. Аның көчле яшьлек омтылышларын, ашкынулы йөрәген бүгенге олы эшләргә китереп ялгый алган колхоз председателе Назыймны күрәм. Минем күз алдымда бу ике кешенең тормышы бергә кушылып китә. Минем өчен алар икесе бер кеше булып күренә башлый.

Шуңа күрә менә хәзер дә аларның икесен бер исем, бер сүз белән атыйсы килә. Күңелемнән әнә шундый бер сүз эзлим... һәм бераздан ул бер сүзне табам. Тапкач — дөрес микән дип, аны тагын бер кат күңелемнән үткәрәм. Ул сүзнең дөреслегенә тагын бер мәртәбә ышанасым килә. Аннары инде, үз эчемнән кат-кат тикшергәннән соң, зур ышаныч белән һәм тәрәзә аша диңгезгә карап ул сүзне пышылдыйм:

— Фидакарьләр... Әйе, әйе... Алар, чыннан да — фидакарьләр!!!

...Назыйм кебек, Әхнәф шикелле әнә шул фидакарьләрнең тынгысыз күңеле, ярсу йөрәге булып, минем күз алдымда әле һаман диңгез шаулый.

Минем күз алдымда диңгезнең ярсу дулкыннары әле һаман ярга ташлана, күккә сикерә!

Әйе, безнең иң әйбәт замандашларыбызның йөрәге дә әнә шундый бит!

БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

## Роза Хафизова

# УРАК ӨСТЕ

**хикәя**



Чияле тау итәген тәмуг кызуы баскан. Кояш нәкъ безнең баш өстенә менеп кунаклаган да тик тора, кадаклап куелган диярсең. Утлы озын-озын нурларын безнең өстә уйната, хәлләрне ала, үрти, мыскыл итә. Нәни генә күләгә булсачы! Алда, күз күреме җирдә, тук башакларын җиргә иеп утырган арыш басуы. Һай арышы да арышы! Бер-бер сабагы бармак калынлыгы. Минем учка унлап кына сыя. Сәкинә апага охшатып, уракны каерып-каерып та эләктермәкче булып карыйм. Юк, булмый. Куллар бәләкәй шул әле безнең. Әнә, минем кулдаш Фәйрүзә дә әллә ни алдыра алмый. Шулай да сынатасыбыз килми. Апалар зур-зур учмалар алып, уракларын салмак кына йөретеп эшләсәләр, Фәйрүзә белән без, кәҗә кәбестә кимергән кебек, вак-вак учмалар ясап, кызу-кызу урабыз. Безнең урак тавышы чаж-чож, чаж-чож гына итеп тора. Их, кулымда тылсымлы урагың булсын иде ул! Иген кырына якын китердеңме, син урганны көтми, бинбии ура башласын иде. Нигә, булырга мөмкин андый урак. Әнә, бер табышмак та бар ич: «Бәләкәй генә бөкере, бөтен кырны бетерде». Андый урагым булсамы? Мин иң элек Фәйрүзә белән икебезнең аланны урдырып чыгар идем. Аннары Сәкинә апаларныкын. Аннары үзебезнең бригаданыкын, аннары бөтен колхоз кырын урдырыр идем. Айлы төндә бер ялгызың басуга чыгасың да, уракны арыш сабагына терәп: «Ур, ур, урагым, саплы, затлы коралым»,— дип пышылдавың була, урагың кулдан ычкынып, бөтен басуны кыркып чыга. Кырда бөрмәле тун кигән түтәйләргә охшаган көлтәләр генә кукраеп кала. Мин үзем берәр чүмәлә төбендә тик күккә карап, йолдыз санап ятам. Хыялга атланып, әтиләр сугыша торган Дон елгасы буйларына барып, әтине күреп кайтам. Әтинең күзенә күренмим. Кызу эш вакытында, урак өстендә, минем шулай эшсез трай тибеп йөргәнне яратмас ул. Сугышка киткәндә кистереп әйткән соңгы сүзе: «Кызым, житте, син зур инде, эшләргә кара, әбиеңә булыш, безне каршылаганда йөзең ак булсын»,— диде. Дөрес инде, уникe яшь уен эш түгел. Әти минем тылсымлы урагым барын белми ич ул!

Беләсе иде, башка уракчылар да тылсымлы урак турында хыяллаНалармы икән? Юктыр, мөгаен. Әнә, Сәкинә апаларны гына алыйк. Алар сугыштагы ирләре турында уйлыйлардыр, мөгаен. Сәкинә апаның өч яшьлек малае бар янында. Миндинә апа мәнә бигрәк тә кызганыч. Сугыш хәбәре безнең күрше Сибай абый белән Миндинә апаның туй өс-

тәленә кара таракан булып төште. Бик озак йөреп, яратышып өйләнешкәннәр иде. Ул чакта Миндинә апа миңа туй бүләге итеп зәңгәр тасма биргән иде. «Мә, үскәнем, күзләреңә пар булсын», дигән иде. «Сайлый белде кызны Сибай, затлы нәселдән алды»,— дип куанды әби ул чакта. Икесе дә бигрәк чибәрләр иде шул.

Сибай абый кебек өздереп гармунда уйнаучы илдә юк, үзе тагы терекөмеш кебек җитез иде. Туйда биегәндә аягы җиргә тими. Миндинә апа аның янында күбәләк кебек бөтерелгән иде. Күбәләгем, күбәләк тә, әби әйтмешли, канатлары бик тиз көйде шул.

Сибай абый сугышка китеп ярты ел да үтмәде, «похоронка»сы килде. Почтальон Миндинә апага бу кайгылы хәбәрне ирештергәнне мин күрмәдем. Күргән кешеләр гаҗәпләнеп сөйләделәр: конвертны ачып, кәгазьне укыган да, кулын корт чаккан кебек, тиз генә кире почтальонга биргән. «Юк, юк, дөрес түгел. Сибаем исән, ялгышлык бу, ялгышлык!» — дип кат-кат кабатлаган. Ары сугылган, бире сугылган. Көчкә тынычландырганнар үзен. «Похоронка»ны алмаган.

Миндинә апаның эчтән янганын гел сизеп тордым. Кара көйде, ябыкты, сулыкты. Бу кайгылы хәбәрдән соң күп тә үтми, кайнанасы Хәтимә әбине җирләде. Кыр кебек өйдә япа-ялгыз торып калды.

Кышкы озын төннәрдә ул үзенә иптәшкә мине кунарга алып чыга иде. Сукыр лампа яктысында дәресләремне карап бетергәч, без икәү бик озак кич утырабыз. Йон язабыз, фронтка җибәрергә дип оекбаш, бияләй бәйлибез. Шундый кичләрне Миндинә апа миңа Сибай абый турында сөйли. Ничектер, бик ачылып, матур итеп сөйли. Сибай абыйның исемен дә ул үзенчә, йомшак итеп әйтә. «Син, нәнәм, ышанма, исән Сибай абыең, исән. Күңелем сизә. Телә, нәнәм, исән-сау кайтуын телә. Син гөнаһсыз сабый әле, теләгең кабул булыр. Нәзерем шул: Сибай абыең исән-сау кайтса, сабантуйга үзеңә бала итәкләп матур күлмәк тегеп бирермен. Телә, нәнәм» ди.

Телим, бик телим мин Сибай абыйның исән-сау әйләнеп кайтуын. Яңа күлмәк өчен генә дә түгел. Бик кызганам Миндинә апаны. «Похоронка» килгәннән бирле кешеләр алдында ул беркайчан Сибай абыйны телгә алмас. Башкалар да аның ярасына кагылудан куркып, бу турыда сүз кузгатмыйлар. Хәзер ул, гомумән, бик аз сөйләшә. Бар белгәне— оекбаш, бияләй бәйләү. Хәер, апалар барысы да биш минутлык ялга утырган арада да бәйләмгә керешәләр. Әллә ничек, читләтеп кенә, без мәгънәсенә төшенмәслек итеп кенә ир-атлар турында сөйләшеп алалар. Ара-тирә җыр сузалар. Миндинә апаның тавышы бигрәк матур, күкрәктән чыга, башкалардан аерылып тора.

Телеграмм баганасын
Санылсым калган икән.
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән.

Җырны тәмамлыйлар да икенчесен башлаганчы озак кына тынып торалар. Кайберләре сиздерми генә күз яшьләрен сөртеп ала. Кызык инде бу апалар. Берсе дә әтиләре турында уйламый. Барысының теләндә ирләре, егетләре. Ә мин әтиемне сагынам. Бәләкәй чакта киреләнгән, тыңламаган чакларым исемә төшә дә күзләремә яшь килә. Хәзер кайтса, авызына гына карап торыр идем, бер дә каршы әйтмәс идем.

Тукта әле, уй белән мавыгып, Фәйрүзәдән калыштым түгелме?! Бер адым алга киткән! Ник болай сынаттым соң әле мин?! Тагын әйтер: «Син миннән бер яшькә яшьрәк шул»,— дияр!

Бар көчемне җыеп, уракны кысам. Тизрәк, тизрәк, кызурак эшләргә кирәк. Яшең җитмәгән, безнең рәттән торып эшли алмыйсың, диючләре бар. Әтигә ни әйтермен? Өйдә ике энем сыерчык балалары кебек

авызларын ачып ашарга көтеп торалар. Эти кайтканчы йортны ничек тә тартырга кирәк.

Уф! Фәйрүзә көлтә бәйләгән арада аны куып җиттем. Маңгайдан шабыр тир ага, авыз кипкән, эчәсе килә, бил авырта. Әби әйтә, яшь кешенең биле булмый ул, ди. Дөрес әйтми, минем бил бар. Бар гына түгел, урак урганда, утау утаганда, бәрәңге күмгәндә, идән юганда, инештә кер чайкаганда гел авырта. Ярый, анысына гына ничек тә түзәрмен. Бил бер миндә генә түгел, һәркемнең дә авыртадыр.

Инде тәмам хәлдән таеп, күз алларым әлҗе-мөлҗе килә башлаганда, бик күптән зарыгып көткән чаң авазы ишетелде. Кыр станында биек колгага тимер кисәге элгәннәр. Төш җитеп, аш өлгергәнне Сафура апа шул тимер кисәгенә бәреп кенә хәбәр итә. «Чың, чың, чың!» — ди тимер кисәге. Миңа ул «кил, кил, кил!» дигән кебек ишетелә. Чыңлавын да чыңлый, тик эш бетмәгән шул әле. Урагымны яртылаш тулган көлтә өстенә кадыйм да көлтә бәйләргә керешәм. Көлтәгә батырылган урак сыртын кабарткан ата мәче кебек тырпаеп тора. Бигрәк авыр быел көлтәләр. Берсе-берсе минем буе бар. Өстерәп бара-бара хәлләр бетә. Төшкә хәтле урганны хәзер җыймасаң, кичен бигрәк авырга килә. Әнә, бөтен басуны бетереп чабулый-чабулый көлтә җыялар. Сәкинә апалар үзләренекен җыеп та бетергәннәр инде. Фәйрүзәнең дә бетеп килә. Бөтен басуда бер үзем калырмынмы икәнни?! Ашыгудан, кабаланудан тәмам хәлем бетә, үрсәләнәм, җылыйсыларым килә. Әнә, Сәкинә апалар чишмә буена төшәргә җыеналар инде, тик нигә алар безнең янга киләләр соң әле?

— Күршеләрнең хәлен белик,— ди Сәкинә апа килә-килешкә. Үзе ике кулына ике көлтә күтәреп, чүмәлә янына илтә.

— Кара нихәтле урганнар бит! — ди Миндинә апа, безнең кишәрлек уртасында туктап.— Булдыргансыз. Күз тимәсен, кырт иттереп куйгансыз. Бер башак әсәре юк. Яле, безнең өлеш тә әзрәк керсен.

Миндинә апа да икешәр көлтәне берьюлы күтәреп, җыешырга булыша. Минем түбә күккә тия. Елмаясы, көләсе килә. Арганлыклар онытыла. Әйбәт булды әле, кешедән калышмадым. Куанычым эчемә сыймый. Авыз гел ерылып тора.

Станга бик вакытлы килеп җиттек. Сафура апа зур колхоз торыпшасын җиргә җәеп, аның уртасына шакмаклы ашъяулык каплаган иде инде. Бер кулына чүмеч тотып, казан янында кайнаша.

Салкын чишмә суын эчеп, юынып алгач, хәл кергән кебек булды. Хатын-кызлар, җиңнәрен сызганып, яулыкларын төзәткәләп, артык сүз куертмый гына, табын янына утырыштылар. Мин Сәкинә апа белән Миндинә апа арасына туры килдем. Кашыкларны кулга тотып, табынга зур агач табак белән аш кунаклавын көтәбез. Тик нигә әле Сафура апа бүген болай көттерә? Гадәттә, без утырышуга ук табынга аш куела торган иде. Табак урынына ул өсте ашъяулык белән ябулы куна тактасы күтәреп килә түгелме? Кыяфәте дә серле кебек. Әнә, куна тактаны ипләп кенә табын уртасына куйды һәм өстен ачты. Ипи! Яңа ипи! Исе борыннарны ярып керде. Авыздан сулар килде. Уракчылар «аһ» итте. «Кеше башына өчәр йөз граммнан персидәтел үзе җибәрде,— диде Сафура апа тантаналы итеп.— Персидәтел әйтте, уракчыларга көн дә шулай ипи булачак, диде».

Табындагылар куанычтан шаулашып алды. Мин үз өлешемнең кырыеннан чеметеп бер-ике валчыгын тел өстенә салдым. И сугышка хәтле кибеттә сатыла торган кызыл билле прәнник тә болай тәмле булмагандыр! Ипи валчыклары авызда эреп китте. Яңа урган арыштан пешергән ипидән әз генә әрем тәме килүчән була. Бу ипидән дә шул тәм сизелә. Их, авыз тутырып, ашаплар куясы.

Табынга, хуш исләрен бөркеп, табагы белән аш килде. Куе арыш чумары. Тәмле, туклыклы. Башымнан яулыгымны салып, аңа ипине

тордем дә читкә алып куйдым. Минем тамак монда да үтә. Өйдә анда ике малай белән әби бар. Алар бәрәңге шулпасы эчкәндә, ипиләп чумар ашау корсакка килешмәс.

— Әзрәген авыз итәр идең, үскәнем,— ди Миндинә апа, ипине төреп куюымны күргәч.— Син бит бик авыр эштә, ашау кирәк.

Аңа җавап бирер вакыт юк. Мин агач кашыкны тотырып, уртак табактан чумар ашыйм. Ай-һай тәмле, ашы да ашы! Тизрәк капкаларга да табынга чәй әзерләгән арада, әз генә читкәрәк китеп, черем итеп алырга кирәк. Чәй дә суына төшсен, суык чәйне яратарак төшәм мин.

Уракчылар ара-тирә берәр шаян сүз кыстыргалап куялар. Тик уенкөлке белән маташырга берсенең дә хәле юк. Мәзәк эзләп кенә йөргән урта урам Фагыйлә дә, кашларын җыерып, бик җитди кыяфәт белән ашый. Алай кыстатып тормасак та, Сафура апа күңел өчен генә «Ашагыз, аша»,— дигән булып, зур чүмеч белән әледән-әле табынга аш өсти тора. Уф, шәп булды бу!

Аннары, табындагыларның күзенә бәрелми генә артка шуышып, урынымнан кузгалдым һәм яшь каен төбенә башымны төрттем. Калганын хәтерләмим. Әнием иркәләп кенә чәчемнән сыйпап уята: «Тор, нәнәм, тор, эшкә керешергә вакыт, без генә калдык»,— ди. Әниемнең куллары йомшак, алардан тәнгә рәхәт җылы йөгерә. «Әйем лә»,— дим юри киреләнгән булам һәм шул мәлдә башымны көйдереп: «Әниемнең үлгәненә ике ел булды ич!» — дигән уй уза. Миңа бик кыен булып китә. Никтер, җылыйсы ук килә. Күзләремне ачам. Миндинә апа уята икән ич мине. Уракчылар инде таралышып баралар. Сафура апа савыт-саба җыештырып йөри. Миндинә апа минем өскә иелгән: «Әйдә тор, нәнәм. Менә эчеп җибәр, чәең суынды».

Мин, аның кулыннан калай кружканы алып, йотлыга-йотлыга үлән чәе эчәм. Тизрәк эшкә керешергә кирәк. Фәйрүзә инде дөнья хәтле ургандыр, тагын артка калырмын.

Уткүз кояш бер генә дә миннән калышмый, иярепме ияргән. Их, кодрәтеңнән килеп әнә теге офыкка тәгәрәтәсе иде дә соң үзен! «Тылсымлы» урак очы белән эләктереп, түбән тартсаң да кызык булыр иде. Кире кәҗә тәкәсе кебек аяк терәп тартышыр иде кояш, ә мин бирешмәс идем. И кызык буласы икән.

«Тылсымлы» урагымның тәмам хәле беткәч кенә кояшны офыкка «тартып төшердем». Көндез яхшы ашагач, әйбәт эшләнде тагы. Фәйрүзәдән адым да калышмадым.

Бүген никтер бригадир Идрис абзый килмәде. Үзебез генә сутый, чыгаргандай иттек. Көлтәләрне җыеп чүмәләләр куйдык. Кайтырга чыктык. Апалар юкны-барны сөйләшәләр, көлешәләр. «И малакайларым, үкенепләр бетә алмыйм, клубтан озата кайтканда, Фатихым ни сорады куна керергә, келәттә генә йоклый идем бит. Ник шунда кертмәскә»...— дип сөйли б[illegible]лый Фагыйлә апа. Фәйрүзә белән без, оялып, арткарак калабыз.

Уф, бигрәк тә авыр аяк атлаулары! Берәр тылсымлы әрекмән яфрагы табасы иде дә, шуның өстенә басып, очып кына йөрисе иде. Нәкъ үзебезнең ишегалды уртасына выжт итеп кенә очып төшәр идем. Әби шаккатар иде. Энеләремнең түбәсе күккә тияр иде...

Тегермән тавына җитеп килә идек инде. Шулчак безгә таба җан фәрман чаптырып килгән энеләремне күреп алдым. Үзләре йөгерәләр, үзләре кул болгыйлар. «Сөенче, сөенче!» — дип кычкырган тавышлары колакка керә, Мин аларга каршы йөгерергә телим, аякларым тыңламый. «Әти кайткан!...»

Малайлар сулышлары кабып килеп җитә-житешкә: «Миндинә апа, сөенче, Сибай абый кайтты!» — дип кычкырып, аңа ташландылар. Апалар «аһ» итте. Әти түгел икән шул әле...

Миндинә апаның йөзе ап-ак булды, ул баскан җиреннән лып итеп җиргә утырды. «Ие, ие, Сибай абый кайтты. Миңа каешын бирде, Шакирга пилоткасын, әнә йолдызы да бар!» — дип тәтелдәде Фәрит.

«Уң кулын өздергән. Шикәр дә бирде әле»,— диде Шакир.

«Һи, бер кулсыз да яшәп була ул! — дип искитмәгән кыяфәттә кулын селтәп куйды Фәрит.— Түше тулы орденнары, медальләре...»

Малайлар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә бу көтелмәгән яңалыкны сөйлиләр. Безнең авылга әллә ничә «похоронка» килде, сугыштан кайткан кеше юк иде әле. Апалар бер мәлгә өнсез калдылар. Аннары Миндинә апаны күтәреп диярлек торгыздылар.

— Миндинә апа, сөенчегә нәрсә бирәсең? — дип аңа сарылды Фәрит.

Миндинә апа малайларның икесен дә кочаклап үпте. Кулларыннан каеш белән пилотканы алып, битенә каплады да җылап җибәрде.

— Сөенче сезнеке, күгәрченнәрем, кайтып кына җитик,— диде, күз яшьләрен сөртә-сөртә.

Малайлар бик канәгать иде. Безнең янда инде аларга кызык түгел, кәҗә бәтиләре кебек теркелди-теркелди алдан йөгерделәр.

...Сибай абый безне үзләренең капка баганасына сөялгән килеш каршылады. Мин аны башта танымадым. Ябыккан, йөзе ниндидер күгелҗем, күз төпләре кара янган. Гимнастеркасының уң җиңен бил каешына кыстырган. Миндинә апа, талпынып, аңа таба атлады һәм никтер туктап калды. Сибай абый аңа текәлеп карап тора иде. «Менә мин шундый, кабул итәсеңме?» — ди иде кебек аның карашы. Әнә, ул әз генә елмайгандай итте, иреннәре дерелдәп китте. Миндинә апа шул мәлдә аның күкрәгенә килеп капланды. Һәм үксеп елап җибәрде. «Синме бу, Сибаем, синме?!»

Сибай абый: «Я, булды, алтыным, булды»,— дип кабатлый.

— Менә шулай, туганнар, кайттык...— Сибай абый һәммәбезгә исән кулын биреп күрешеп чыкты. Аннары капканы тутырук ачып: — Әйдәгез, әйдә, барыгыз да өйгә рәхим итегез! — диде.

Фәрит өйгә керергә җыенган Миндинә апаның итәгеннән тартты: «Матур апа, ә сөенче?»

Барысы да көлеп җибәрделәр. «Әй, сөенчене онытып торам икән бит. Хәзер, үскәннәрем, бераз гына сабыр итегез».

Миндинә апа энеләремнең икесенә дә берәр янчык чикләвек чыгарып бирде. Янчыкларына канәфер, роза чәчәкләре чигелгән.

Сибай абыйларга бик керәсем килсә дә, кермәдем. Олы кешеләр янында бала-чаганың буталып йөрүе ярамас. Бала итәкле яңа күлмәк болай да минеке. Миндинә апа сүзендә тора ул!

Без шатланып, куанышып, өйгә кайтып кергәндә, әби инде кичке ашка өстәл әзерләп йөри иде. «Кайттыңмы, балам, бик арымадыңмы?» — дип каршылады ул мине. «Комачауламагыз тутагызга, ул эштән кайткан»,— дип энеләремне кисәтеп тә куйды. Мин төенчегемне чишеп, күчтәнәч ипине әбигә суздым. «Көндезге ашка бирделәр. Уракка чыккан кешегә һәр көнне бирмәкчеләр икән. Ашы да тәмле иде. Бусын сезгә алып кайттым».

Әби ипине ике куллап бик зурлап алды.

— Рәхмәт, балам,— диде, иреннәре кыймыл-кыймыл итеп куйды.

Энеләрем Сибай абый биргән бүләкләр белән мәш киләләр, чикләвек яралар. Өйгә ипи исе керде. Әби өстәлгә табагы белән кайнар бәрәңге китереп утыртты. Ипине үзе чеметеп кенә кабып карады да өч кисәккә бүлеп безнең алга куйды: «Ашагыз, оланнар, ашагыз. Миңа карамагыз. Ипи чәйнәргә тешләрем юк минем».

Өебез тулы куаныч, өмет иде бүген. Сибай абый кайткач, шәт, безнең эти дә кайтыр. Ипи дә бик тәмле. Әби генә яулык чите белән әледәнәле күзләрен сөртеп ала. Кайгы килгәндә беркайчан еламый ул. Каралып кына китә. Бүген менә күзеннән яшь ага. Куанычтандыр инде...

# Нәҗип Мадъяров

## ТУГАН ЯК МОҢНАРЫ

### Кешелек ул кайда?

Әнә шундый гади генә сорау
Ни өчендер мине сагайтты.
Уйга чумдым. Җиңел түгел икән
Бу сорауга табу җавапны.

Дөрестән дә кайда икән соң ул?
Йөрәктәме? Әллә күздәме?
Дус-ишләрнең күңелен күтәрергә
Теләп әйткән җылы сүздәме?

Ә бәлки ул әрсез кешеләрнең
Чикләүдәдер кыңгыр эшләрен?
Дөреслекне яклаучының әллә
Ныгытуда микән көчләрен?

Тугры булып, сөю, мәхәббәтне
Саклауда да булмый калмас ул.
Хаксызлыктан рәнҗетелгәннәрне
Яклауда да булмый калмас ул.

Ялкаулыктан аны табып булмас,
Килми аңа үчлек якын да.
Гайбәтче дә аны сата алмый,
Сатып ала алмый алтын да.

— Кешелек ул кайда?— дисең, дустым,
Ул бит минем, синең яныңда.
Әмма аны яулау җиңел түгел,
Ә саклавы — кыен тагын да.

❁

Авылымның
Иң зур көзгесенә —
Инеш буасына
Карап уйга чумам.
Тәэсиреннән шуның,
«Галәм күкрәгендә
Иң кечкенә көзге —
Ул, дим, тын океан».

Таң нурлары төшеп тоташканнар
Төн сафлыгы сеңгән чыкларга.
Сандугачлар бер сайрауга сайрый,
Ашыкмыйлар һаман йокларга.

Ургып аккан чишмә тавышы да
Хәсрәтләрдән җанны дәвалый.
Шушында бит гомеремнең башы
Һәм шушында аның дәвамы.

Уй-хисләрем тарлыклардан чыгып
Старт ала алга — киңлеккә!
Гүзәллеккә тәмам әсир төшеп
Йөрүгә ни җитә иректә!

## Июль

Басуларга июль килеп керде,
Йомшак кына җилен йөгертеп.
Ахрысы, ул аксыл сулыш өрде,
Арышларга үзен белгертеп.

Барысын да үз дигәнчә көйли,
Күп хәлләр бар искә алырлык;
Яфракларга ул җиңеллек бирә,
Башакларга өсти авырлык.

Кул куйдырып тормый ведомостька,
Ышанычын тәмам ныгыткан,
Игеннәргә өлгерерлек көчне
Алып бирә җирдән, болыттан.

...Өлгертергә, тизрәк өлгертергә!
Нурларны да шуңа көйләгән.
Тәэсиреннән шуның инде әнә
Арпалар да мыек җибәргән...

Килеп керсәң урман залларына
Гүзәллектә һаман шәп чаклар.
Кул чабалар кошлар концертына
Әле дә анда җырчы яфраклар.

Сыерчыклар көтүләре белән
Нигә күчте икән бирегә?
Балалары очу имтиханын
Җыена, ахры, монда бирергә.

Наратларның иңнәрендә исә
Җәй уртасы балкып тибрәнә.
Чыршылардан усак балалары
Инде урман маршын өйрәнә.

Яшел сафлык дөрли, буйсындырып
Урманын да, болын, кырын да.
Изри дөнья, кыш киләсен онытып,
Мәрхәмәтле июль куенында.

Тукайның 100 еллыгына

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

**Күңелемдә көн һаман аяз — һаман да яз,**
**Шагыйрь күңлендә кыш булмый да, кар яумый.**

Г. Тукай. «Шагыйрь», 1908.



Иске клиника ишегалдындагы йорт. 1907 елда Уральскидан Казанга күчеп килгәч тә, Г. Тукай шушы йортта туктала һәм анда ике елга якын яши.

Татьяна Зуева рәсеме

# БЕЗГӘ КАДЕРЛЕ ЙОРТ...

Бу рәсем безгә күп нәрсәне искә төшерә.

Иске клиника ишегалдындагы бу йортны без дустым апабыз Маһирә Әпсәләмова торган йорт иде дип искә алабыз. Заманында бу йортка Габдулла абый Тукай да, Габдулла Кариев тә, Камил абый Мотыйгыйлар да төшә иде. Без дә, Казанга килдек исә, дустым апабыз дип шушы йортка килеп төшә торган идек.

Дустым апа — мәрхәмәтле, матур тормыш белән яшәп килгән, акыллы, сабыр кешеләрнең берсе иде. Һәркайсыбыз аңа дустым апабыз дип эндәшә идек.

...1907 елда Габдулла абый Тукай белән Габдулла абый Кариев Уральскида типография ябылгач, Казанга килеп, әтиемнең киңәше буенча, икесе дә Маһирә дустым апаларга тукталалар. Кариев шуннан үз авылына эш эзләп кайтып китә. Габдулла абый Тукай Маһирә Әпсәләмоваларда торып кала. Әмма Габдулла Кариев үз авылында эш таба алмагач, кире Маһирә апаларга килә һәм Уральск аша икенче шәһәрләргә эш эзләп чыгып китә.

1909 елда Уральск шәһәрендә яшәүче Камил абыйдан кече абыебыз Мөхәммәтгариф (Мөхәммәтгариф исемен әтиебез үз дустының шәрәфенә куйдыра) мәдрәсә тәмамлап Казанга укырга килә. Габдулла абый аны пристаньга төшеп үзе каршы ала һәм туры Маһирә апаларга китереп төшерә. Дустым апаларда ике үсмер егет бик тә якын булып байтак кына шунда яшиләр.

Уральскидан, әниләрдән килеп торган посылкаларны, почтага барып бергә алып кайталар, аны бергә ачалар, күчтәнәчләрне бергә ашыйлар. Хосусән, әниләрдән килгән посылка «Апуш белән бергә» дип аталып җибәрелгән була.

Апуш белән Мөхәммәтгариф посылканы алып кайту белән, ашамлыкларны өстәлгә җәеп, сөенә-сөенә ашыйлар. «Мине дә чакыралар, көлешә-көлешә, бергәләп утырып ашыйбыз», — дип дустым апа да, үз дустына гел язгалап, хәбәр биреп тора.

Янә бер көн, әниләрдән килгән посылкадан ике пар оекбаш, ике пар бияләй килеп чыккач, Апуш абыйсы күреп ала да, «Гариф, тукта, өлкән размеры булса, минем аякларга булыр, мин бит синнән өлкәнрәк», — дип, алдан әйтеп өлгерә. Тиз-тиз генә аякларын чишенеп ташлап, киеп карасалар, икесе дә бер размерда булып чыккач, «каян белгәннәр бу кадәр безнең аякларның бер чама икәнлекне», — дип, Маһирә апаларын эндәшеп, көлешә-көлешә сөенгәннәр. Уралдан килгән күчтәнәч белән бергә чәй эчеп, күңелләре күтәрелгәч, рәхмәт белдереп, Уральскига хат та язып җибәрәләр. Әниләрдән посылка бер генә мәртәбә килмәгән, әлбәттә...

Остазыбыз Фатыйх Әмирхан да миңа, театр техникумында укыткан вакытта, шулай ук аларның күңелле чакларын сөйләгәне бар иде. Фатыйх Әмирхан дустым апаларга Габдулла Тукайны күрергә килә торган була.

1909 елның көз башында Габдулла абый, дустым апаларда Гариф абый белән берничә ел торганнан соң, Болгар номерларына күчәргә була. Ләкин Габдулла абый белән Мөхәммәтгарифның аралары еракләшмый. Алар гел бергә булып, бер-беренә йөрешә торган булалар. Мөхәммәтгариф абый югары педагогия мәктәбенең рус бүлегенә имтиханнар тапшырганнан соң да, Габдулла абыйсына Уральскидан килгән посылкаларны күтәреп бара.

Соңгы елларда (1911—12 еллар) Габдулла абыйның хәле начарлана башлагач, Мөхәммәтгариф абый аның язуларын күчереп бирергә булышам дип әтисенә хәбәр иткәли.

Габдулла абыйның елдан-ел сәламәтлеге начарлана. Хәле өметсезләнә үк башлагач, Габдулла абыйны «Клячкин» больницасына салалар. Шул хакта әтиләргә хәбәр биргәч, әнием белән җиңги (Камил абый хатыны) тиз арада Казанга килеп җитәләр. Габдулла абыйга ярдәм нияте белән.

Әниләрнең Габдулла абый янына барып хәлен белеп китүләре бер генә тапкыр булмый. Вафатына айдан артык калгач та алар дустым апаларга төшеп торып китәләр.

Габдулла абый 1913 елның 2 апрелендә вафат була. Әниләрем күмүне оештыруда күп көч куялар. Мәһирә дустым апаларда Габдулла абыйның өчесен укытып китәләр. Уральскига кайткач, җидесе үткәрелә. Әтиемнең яраланган йөрәгенә янә дә кайгы-хәсрәт арткannan-арта. Әтием Габдулла абыйны чиктән тыш ярата иде.

1913 ел. Мөхәммәтгариф абыйга, Габдулла абыйсының үлү кайгысын кичергән елында, зур кайгылы елда, укуын тәмамлап, Уральскига кайтып китәргә туры килә. Мәһирә дустым апа белән Хафиз абый, Мөхәммәтгарифны күз яшьләре белән озатып калганда, Габдулла Тукай белән бергә яшәгән чаклары һәм бергә Габдулланы җирләп йөрүләре — бары да күз алларына килеп, онытылмас авыр фаҗига булып исләрендә кала.

1923 елда мин дә — Габдулла Тукай, Габдулла Кариев, Камил абыйларның тәрбиясен күреп, алар традицияләре буенча үсеп җиткәч — әдәбият-сәнгать юлын сайлап, Әдһәм абыем, Әминә апаларым белән бергә Казанга театр училищесына укырга килдем. Шул ук Мәһирә апа, Хафиз абыйларга килеп төштек.

Иң әүвәл, әти-әниләр амәнәтен үтәү бурычы дип, дустым апа безне татар зиратына алып барды, Габдулла абыйның каберен күрсәтте. Аның кабере янына тукталып, Габдулла абыебыз дип, аның баш очында бик озак басып тордык, аны искә алдык.

Мәһирә апа аның авырган вакытларын сөйләде. Без күз яшьләребезне түгә-түгә тыңладык, ата-аналарыбызның кушкан амәнәтләрен тапшырдык.

Янә Габдулла абый кабереннән ерак түгел, Г. Кариев каберенә килеп, аның каршында да бик озаклап тордык, аның авыр язмышын искә алып, баш идек.

Ике көннән театр техникумына кабул ителүебез билгеле булгач, дустым апаларда бер-ике атна чамасы тордык та, тулай торакка күчеп киттек.

**Галия КАЙБИЦКАЯ.**

**Рәшит Гәрәй**

# ЫК БУЕНЫҢ «ЯҢА ЮЛ»Ы

Ил-көнгә муллык һәм куаныч алып килгән 1983 елгы көзнең, үз кадерен, үз дәрәҗәсен белеп, иңеннән-иңенә яшел хәтфә түшәлгән уҗым басулары куенына сыенып, сихри бер рәхәтлеккә талган чагы иде. Район үзәгеннән Тауасты Байлар авылына мин юри җәяүләп чыгып киттем. Үземә бөләкәйдән үк таныш булган ул авылның Түбән Кама сусаклагычы төзелү уңае белән, яңа урынга күчеп утыргач, иң беренче нәүбәттә тышкы яктан нинди үзгәрешләр кичергәнлеген ерактан ук ашыкмыйча гына күзәтә-күзәтә барасым килде.

Якын-тирә авылларда яшәүчеләр телендә Хәмәкәй урманы һәм Әтәч Шәех чокыры дип йөртелә торган урыннарны узуга, уң кул яктан — Ык ярлары буендагы әрәмәлекләр, сул яктан Мияш урманнары белән каймаланып алынган иген кырлары башлана. Бодай инде күптән җыеп алынган. Аның хуш исле саламы озын-озын эскертләргә өелгән. Әлеге басуларда мондый ыспай эскертләрне минем беренче тапкыр гына күрүем түгел. Хәтта: «Бу хуҗалыкта эскертләү осталарын алдан махсус билгелиләр»,— дигән сүзләрне дә ишетергә туры килгәне бар.

«Яңа юл» колхозының Мулланур Бәдретдинов, Нәүбәт Гатин, Ирек Галләмов, Әхмәт Мәхмүтов, Фарсил Хафизов, Миңнулла Биҗанов кебек уңганнары бу эшкә маһирлыклары белән елның-елына макталып телгә алыналар. Эскертләр басуларны ышыклау өчен утыртылган урман полосаларына барып тоташа. Бер-берләренә елышып үскән каеннар, наратлар, ерактан караганда, өсләренә ак кофта һәм яшел итәк кигән зифа буйлы яшь кызларны хәтерләтәләр.

Соңгы елларда гына салынган Минзәлә — Боерган юлыннан уңга борылып бераз баруга, чирәмле киң урамнары, ике яклап тезелеп киткән һәм заманча итеп җиткерелгән калай түбәле йортлары белән яңа авыл үзе күз алдына килеп баса. Кәрнизләре күк зәңгәргә буялган, тәрәзә төпләрендә чәчәкле гөлләр балкый, ишегалларында — чәчәк түтәлләре. Рәшәткәле бакчалардагы чия, алма, кура җиләге, кара миләш, карлыган, шомырт, баланнардан хуш ис бөркелеп тора. Бирердә җиләк-җимеш бакчасыз бер генә йорт та юк бугай. Гомер-гомергә Ык буенда көн иткән, болын-әрәмәлекләрдәге сыйларның кадерен белеп яшәгән авыл халкы, яңа урынга күчкәч тә, һәр урамга агачлар утырткан. Колхоз биләмәләренең кайсы гына ягына юл тотма, яшь урманнар кочагына барып керәсең. Хәтердә Антон Павлович Чеховның: «Әгәр һәр кеше җирдә үзенең кулыннан килгәннең барысын да эшләсә, безнең җиребез нинди гүзәл булыр иде»,— дигән сүзләре яңара.

Түбән Кама ГЭСы төзелә башлагач, икенче җиргә күчеп утырган авыллар аз булмады. Әмма алар арасында Тауасты Байлар авылы төзеклеге, чисталыгы, яшеллеге белән аерылып тора. Монда хәтта көтүне дә урамнан йөртмиләр. Мал-туар өчен каралтылар артында аерым капка булдырылган. Шәхси хуҗалыкларның бәрәңге бакчалары — авыл читендәге басуда. Ганлә башлыкларының әйтүенчә, ул участокларда бәрәңге уңышы әйбәт икән, шулай да бу урында колхозчыларның бер гозерен әйтеп китмичә булмый. Шәхси хуҗалыкларның бәрәңге җирләре хәзер шактый кечерәеп калган. Монда менә нәрсәне исәпкә алып җиткәрмәгәннәр шикелле. Авылның проекты моннан күп еллар элек «перспективасыз» дип саналган авылларны бер урыннан күчереп, агро-шәһәрчекләр төзү чорында ясалган. Инде тормыш үзе бу фикернең

һәр җирдә дә акланмавын раслады. Күпчелек колхоз һәм совхозларның үзәк утарларыннан читтә урнашкан кечкенә авыллар илдә азык-төлек муллыгын арттыру өчен үзләреннән бик зур өлеш кертәләр. Әшчәнлекләре өчен мөмкинлекләр тудырылган ул авыллар, үз урыннарында калган хәлдә, теге яки бу хуҗалыкны үстерү өлкәсендә потенциаль көчкә ия булып торалар. Моның шулай икәнлеген ниндидер катлаулы исәпләүләр ясап исбатлап торасы юк. Мисалга «Яңа юл» колхозы составындагы Мияш авылын ук алырга мөмкин. Монда әле күптән түгел яңа абзар төзелгән. Анда шәп токымлы таналар асрыйлар. Цех яңа ысул белән эшләп, көтүне тулыландыруда бик файдалы булачак.

Мияшләләр һәйбәт көтүлекләре, уңдырышлы җире, табигый сулыклары булган менә дигән урында көн итәләр. Аларны, ата-бабалары нигезеннән аерып, икенче урынга күчерү зур хата булыр иде. Колхозның иң зур авылы Дәвек турында инде әйтеп торуның да кирәге юк.

Ул авылларны күчерәбез дигән булып, бәрәңге бакчаларын кечерәйтү, безнең уебызча, һич тә бүгенге көн таләпләренә җавап бирми. Шәхси хуҗалыкларда терлек үрчетүгә, бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерүгә тиешле шартлар тудыру турында Азык-төлек программасында да күрсәтелде. Тауасты Байлар авыл советы мәгълүматларыннан күренгәнчә, бу авылларда яшәүчеләр узган елда гына да дәүләткә 600 центнер урынына 716 центнер сөт, 100 центнер ит, 27 центнер йон, планда каралган 120 тонна урынына ике тапкыр артыграк бәрәңге сатканнар.

Ә гомумән, авылны генераль план нигезендә төзегәндә, кешеләр ихтыяҗын мөмкин кадәр тулырак канәгатьләндерү күз уңында тотылган. Колхоз идарәсе һәм парткомы, авыл советы һәм элемтә бүлеге, профсоюз комитеты һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комплексы урнашкан ике катлы Культура йорты, сигезьеллык мәктәп, фельдшерлык-акушерлык пункты, укытучылар өчен җиткерелгән кирпеч йортлар салынган. Шулар янәшәсендә яңа өйләр төзелеп ята. Боларның бөтенесе дә колхоз исәбенә эшләнә.

Авылны яңарту өчен Татарстанның атказанган агрономы, колхозда егерме ел председатель булып эшләгән Мизхәт Гайфуллин күп тырышкан. Халык мәнфәгате өчен янып йөрүче коммунист бернинди киртәләр алдында да туктап калмаган. Кыенлыклар туганда, ул үзенең сугышчан һәм хезмәттәш якташларының иңенә, авыл коммунистлары һәм аларның җитәкчесе Шакирҗан Закиров ярдәменә таянган.

Җилләр генә хакимлек иткән шыр ялангa көчеп китәргә берәү дә ашкынып тормаган. Шәхси үрнәк күрсәтеп, бүгенге авыл урынына сугыш ветераны Равил Мосавиров, тракторчы Кәрам Сафин, ат караучы Шәйхенур Нуретдинов, комбайнчы Рәшит Гыймадиев, урман белгече Рафак Хәмидуллиннар белән бергә иң элек председатель үзе нигез кора башлаган. Халык бу энтузиастларга олы рәхмәтле. Чөнки авыл матураеп үсә, үзенең иртәгесе көненә зур ышаныч, якты өмет белән карый.

* * *

Беркөнне Культура йортында яшьләрне армиягә озату үткәрелде. Кичәгә егетләрнең әти-әниләре, туганнары һәм остазлары, сугыш һәм хезмәт ветераннары да чакырылган иде.

— Без,— диде Культура йорты директоры Роза Логинова, кичәне ачып,— колхозыбызның алдынгы механизаторлары, төзүчеләре һәм терлекчеләреннән сайлалган Рафаэль Хәйретдинов, Марсель Гыйльфанов, Нил Вәлиев, Фарсил Гыймадиев, Фәнил Гыйлаҗев, Расил Сабирҗанов һәм Илдар Билаловны Совет Армиясе сафларына озатабыз. Алар ярыш маяклары гына түгел. Күбесе үзебездәге «Яшьлек» җыр һәм бию ансамблендә, драма һәм хореография түгәрәкләрендә дә катнаша. Кешеләр белән тиз аралашалар, хезмәт яраталар, гадиләр һәм тыйнаклар, әйткән сүзләрендә торалар безнең егетләребез. Өсләренә солдат шинеле кигәч тә алар шундый ук булып калырлар, Ватаныбыз, халкыбыз алдында биргән антларын тапламаслар. Хәрби хезмәтләрен тутыргач, без аларның колхозга әйләнеп кайтуларын көтеп калабыз...

Өстәлдә чем-кара туфрак салынган пыяла савыт тора. Сүз Татарстанның атказанган зоотехнигы Рәисә Сәлимовага бирелә.

— Сез, бишектән төшеп, шушы туфракка аяк бастыгыз,— дип башлый ул үзенең сүзен, җир җылысы бөркелеп торган туфракны кызыл ситсыдан тегелгән кечкенә янчыкларга саклык белән генә сала-сала.— Барыгыз да әти-әниләрегез шушы туфракта иккән икмәкне ашап үстегез. Изге бурычыгызны үтәү юлына чыкканда сезгә шул туфракны биреп җибәрәбез. Ул ата-бабаларыгызның эзләре уелып калган буразналарны оныттырмыйча, һәркайсыгызны кабат шунда алып кайтсын.— Рәйсә ханымның үз кырында утыручы улы Нилнең башыннан сыйпап әйткән бу сүзләренә залны яңгыраткан көчле алкышлар кушыла.

Авылның аксакалы, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары ветераны персональ пенсионер Шәйхи ага Гыймадиев чыгышы күз алдына өлкән буыннар кичергән тарихи вакыйгаларны китереп бастырды. Шәйхи ага сүзен:

— Сез бәхетле! — дип, гади генә итеп башлады.— Безгә унҗиде-унсигез чакта илебез утлы боҗра эчендә иде. Безнең баштан сүз белән сөйләп бетерә алмаслык авырлыклар узды. Әмма безнең өметләр якты, ачык иде. Киләчәк буыннарның, менә сезнең бәхетегез, имин тормышыгыз өчен көрәшүебезне без бер генә минутка да истән чыгармадык. Өлкәннәр яулап алган матур тормышны саклау хәзер сезгә тапшырылды. Без, ветераннар, сезгә иң изге фатихабызны бирәбез.

Мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире Таһир Миргаязов егетләргә колхоз идарәсе, партком, профсоюз һәм комсомол комитетлары исеменнән бүләкләр тапшыра. Рафаэль Хәйретдинов барысы исеменнән дә Ватанга турылыклы хезмәт итәргә, аннары туган якка әйләнеп кайтырга сүз бирә.

Армия хезмәтеннән соң аларның, бәхетне читтән эзләмичә, туп-туры үз колхозларына кайтачакларына тулы нигез бар. Аларга үрнәк булырдай колхозчылар да күп монда. Әйтик, Фәннур Билалов. Ул мәктәптә укыганда ук җәен комбайнда эшли. Унынчы классны тәмам иткәч, гамәлдән чыккан иске машинаны ремонтлап, руль артына утыра, армиягә киткәнче шул машинадан төшми. Десант гаскәрләре сафында ике ел хезмәт итеп, ул яңадан авылга кайта. Фронтовик әтисе Флүр аганың, әнисе Тәзкирә апаның дөрес тәрбиясе эзсез калмый. Хәрби киемнәрен салып куюга, атна тулар-тулмас, Фәннур үзенең элеккеге эшенә керешә. Менә бишенче ел инде ул колхозга ягулык һәм майлау материаллары ташый. Фәннурның колхоз экономисты булып эшләүче хатыны Лузия Казан финанс-экономия институтының соңгы курсында читтән торып укый. Флүр абый белән Тәзкирә апа киленне гел мактап кына торалар. Хәер, «Яңа юл» колхозында мондый тату гаиләләр байтак. Киләчәктә әле алар тагын да артачак, узган елны урып-җыю чорында җиде мең центнерга якын ашлык суктырган комбайнчы Альберт Вәлиевне, тракторчы Шамил Нуретдиновны, механизаторлар Рифгат Нуриев, Нәҗип Гыйльметдинов, Камил Хисамиев, Фәнул Хәмәдиевләрне, терлекчеләр Васил Шәехов һәм Хәсән Гәрәев кебек ир-егетләр, төрле тармакларда эшләп, ихтирам казанган Рәҗибә Гыйззәтуллина, Римма Хәмидуллина, Афина Нуретдинова, Сәрия Муллахмәтова кебек кызлар булганда, «Яңа юл» колхозының киләчәге турында авыз тутырып сөйли алабыз.

* * *

Авылның аргы башыннан Ык ярларындагы биек-биек тау тезмәләре күкселләнеп күренә. Иске авыл шул таулар итәгенә, тирән казан төбенә төшеп утырган иде. Язгы-көзге көннәрдә урамнар тоташ сазламыкка әйләнә иде. Таулардан менә алмыйча яткан машиналарның саны-хисабы булмады.

Хәзер колхозара юллар барысы да күтәрелгән. Минзәлә районындагы юлларның торышы бик үк мактанырлык булмаганлыктан, аның бер колхозы өчен бу җәһәттән шактый эш эшләнгән диясе килә. Дөрес, безнең бу фикеребез белән килешеп бетмәүчеләр булачагын да белеп торабыз. Моннан нибары унике-унөч еллар элек кенә нигезе салына башлаган авылны һәрьяктан җитешле итү өчен киләчәктә дә әле күп көч түгәргә кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла. Һәм бу юнәлештә байтак кына чаралар тормышка ашырыла.

Колхозның үзендә унике кешелек төзү бригадасы бар. Бригадиры — коммунист Флүр Шәйхетдинов. Хуҗалыктагы яңа төзелешләрнең бөтенесе дә диярлек балта осталары Габделхак Кәрамов, Муллахмәт Гәрәев, Әгъзамнур Хафизов, Рәфыйк Кә-

римов, Гыйззәтулла Галиев, Хәниф Ризатдинов, Әхнәф Хәлиуллин, Дәүҗәт Мәрданов, электр белән эретеп ябыштыручы Рәшит Гаязов, сылаучы Зәһинә Билалова составындагы шушы бригада көче белән сафка баскан. Төзүчеләр арасында тракторчы, комбайнчы, слесарь һөнәрен белүчеләр дә бар. Язгы чәчү һәм урып-җыю вакытында алар да — икмәк язмышы хәл ителгән урында, басуларда.

Бригаданың прорабы Хәмит Гыйлфанов кечкенәдән үк шул һөнәргә тартылган булган. Яшьтәшләре аның мәктәптә уку елларында ук агачтан, таштан, калай кисәкләреннән төрле уенчыклар, йорт кирәк-яраклары ясап мавыгуы турында сөйлиләр. Еллар үтә. Хәмит Түбән Кама һәм Брежнев шәһәрләрен салышуда, Мәскәүдә Олимпия комплексын төзешүдә катнаша. Польша Халык Республикасына барып, анда берничә ел эшләп кайта. Кайда гына булмасын, ул һичбер кайчан да үзенең туган авылын онытмый. Авыл яңа урынга күчәчәк дигән хәбәрне ишеткәч, бөтенләй тынычлыгын югалта. Үз авылының яңа нигездә тагын да күркәмрәк булуын тели ул. Авыл төзүчеләренә ярдәмгә ашыга. Яңа үсеп чыккан объектларның проектларын төзүдә, күп кенә биналарны бизәүдә катнаша. Аның кулы тигән һәр нәрсәдә барыннан да элек халыкчанлык, гадилек, пөхтәлек, нечкә зәвык сизелеп тора. Башкалар аннан өйрәнүне үзләренә мәртәбә санийлар, аның кебек булырга телиләр.

— Хәмит бездә эшли башлаганнан бирле, төзүчеләребез арасында тәртип бозу, юк-бар сәбәп табып, эшкә килми калу, вакытны исраф итү очраклары бетте,— ди колхоз председателе Мулланур Сабиров.— Ләкин шунысы бар, авылга ул вакытлыча гына, ярдәм итешергә генә кайтты. Гаиләсе — шәһәрдә. Халык аның авылда бөтенләй калуын бик тели дә бит...

Шулай да Хәмитнең авылда үзенә менә дигән йорт та салып куюы бу барыбер кайтмый калмас дигән өмет уята. Хәмит Гыйлфановтан аерыласылары килмәгән төзүчеләр дә шундыйрак фикердә торалар. Күмәкләшеп эшләгән җирдә уен-көлке дә күп була. Андый сүзләрнең иясе һәрчак — аларның үз араларында.

— Хәмит китә-нитә калса, мине менә нәрсә үкендерәчәк, егетләр,— дип сүз башлый төзүчеләрнең берсе.— Янәшәсендә күпме гомер бөтерелеп йөрсәк тә, прорабыбызны тәмәке көйрәтергә өйрәтә алмадык. Шуның аркасында «перекур»га да тукталмый идек. Бөтенләй кайтсамы, мин эшне Хәмит дустыбызга тәмәке тартуның тәмен аңлатудан башларга торам...

Уйнап кына әйтелгән шул сүзләрдә дә авылдашларының Хәмитне яратулары да, аның кул астында эшләүнең рәхәтлеге дә чагыла. Тауасты Байлар халкы, гомумән, бердәм, тату, ихлас һәм ачык күңелле. Бер-берләренә ярдәмләшү, шатлык-кайгыларны уртаклашу, күмәк хуҗалык мәнфәгатьләрен бер үк вакытта үзенең шәхси эше итеп кабул итү аларның канына сеңгән. Әйтик, районның Күзкәй урта мәктәбендә хезмәт укытучысы булып эшләгән Вил Абдуллин, пенсиягә чыккач та, тыныч кына яшәп ятарга теләмәгән. Төзүчеләр салган яңа йортларның веранда һәм капкаларына матур-матур бизәкләр, челтәрле кәрнизләр, рамнар ясарга алынган.

Тауасты Байларда салынган һәр объект башыннан алып соңгы кадагын какканга кадәр төзү бригадасының үзенә йөкләтелә. Төзелеш өчен кирәкле материалларны хәзерләү дә, аны ташу да төзүчеләргә тапшырылган. Кайчак эшләрне кайбер оешмаларның материалны үз вакытында бирмәве генә тоткарлый. Төзүчеләр, мәсәлән, шифер җитмәү аркасында, кыенлыклар туудан зарланалар. Бу зар район төзү оешмалары җитәкчеләренә ишетелсен иде! КПСС ҮКның декабрь (1983 ел) Пленумында бу хакта нык итеп әйтелде.

Заман безнең авыллар алдына искиткеч зур таләпләр куя. Шундыйларның берсе — авыл халкының торак, көнкүреш һәм социаль-культура шартларын тамырдан яхшырту. «Яңа юл» колхозы бу өлкәдә дә матур нәтиҗәләр күрсәтә. Махсус уку йортлары тәмамлап, шушы колхозга эшкә җибәрелгән белгечләрнең, армиядән кайткан яшьләрнең «Яңа юл»да нигез корып, гомерлеккә төпләнеп калырга теләүләре үзе үк — әнә шуңа дәлил.

* * *

Эреләндерелгән кайбер колхозларда үзәк утардан читтәге авылларга үгисетебрәк карау — беркемгә дә сер түгел. «Яңа юл» колхозында мондый килешсез гадәткә

беркайчан да юл куелмады. Вак хуҗалыклар берләштерелгәнгә кадәр һәр икесе аерым колхоз булып саналган Мияш һәм Дәвек авылларында яшәүчеләрнең тормыш-көнкүреш, социаль-экономик шартларын яхшырту турында колхоз җитәкчеләре даими кайгыртучанлык күрсәтәләр. Утыз алты йортлы Мияш авылында бу нәрсә күзгә аеруча нык ташлана. Авыл һәртөрле төзелеш материалларына һәм җиләк-җимешкә бай урман куенына сыенган. Калмаш суы ярларына утыртылган наратлар да куерып урман булып үсеп киләләр һәм Мияшнең ямен тагын да арттыра төшәләр. Елганы буып ясалган сусаклагычта балык үрчетелә. Колхозда, гомумән, сусаклагычлар булдыруга, үләннәр чәчелгән мәйданнарны сугаруга зур игътибар бирелә. Үзәк утар янында гына Чыкырт күле җәелеп ята. Анда оя-оя казлар, үрдәкләр йөзә. Авылның әйбәт клубы, бай кибете бар. Хәтта колхозның үзәк утарындагы фермаларны да Мияштәге корылма су белән тәэмин итә. Күп кенә йортларга су кертелгән.

Элек тә үзенең җыйнаклыгы белән күңелләрне тартып торган Мияш авылы соңгы вакытта тагын да төзекләнә, яңара, матурая бара. Бәрәңге бакчалары артында, койма-киртә белән әйләндереп алынган әвеслекләрдә печән кибәннәре кукыраеп утыра. Мияш халкы терлекне күп итеп асрый. Бу якта мал-туарсыз ишегалдын элек-электән кысыр далага тиңлиләр. Кыскасы, зур авылларның бер тыкрыгына сыеп бетәрлек Мияш авылы тормышның бөтен рәхәтен тоеп яши. Кешеләре үзләрен шул тормышның чын хуҗалары итеп сизәләр. Гомеренең кырык бер елын мәктәптә балалар укытуга багышлаган Хөсәен Мусин, Мәскәү яныннан алып Прагага чаклы сугыш юлы узган, аннан соң бөтен көчен үз колхозын үстерүгә биргән, хәзер дә механизаторга ярдәм итеп торучы Галимҗан Кәримов, балта остасы Хәниф Ризатдинов кебек сугыш һәм хезмәт ветераннары, Әгъзамнур Хафизов, Рәфыйк Кәримов, Әхнәф Хәлиуллин, Габделхак Кәрамов, Дәүҗәт Мәрдәнов шикелле төзүчеләр, Муллахмәт Гәрәев, Мөбәрәкҗан Хафизов, Рафис Ибраһимов, Наил Гарипов, Ринат Гыймаев кебек комбайнчылар һәм шоферлар, савымчылардан Римма Газизова, Хәлимә Ибраһимова, Тәнзилә Гайсина һәм нәселле терлекләр үрчетү буенча зоотехник-селекционер Фәннур Хамматов белән сөйләшкәндә, аларның һәркайсының, иң беренче чиратта ил һәм халык мәнфәгатен кайгыртып яшәгәнлекләрен аңлыйсың, үзеңне рухи яктан тагын да баебрак киткәндәй хис итәсең. Бирелә илебезнең Азык-төлек программасын өйрәнү буенча махсус дәресләр оештырылган. Аңа тәҗрибәле пропагандист Хөсәен Мусин җитәкчелек итә. Ул дәресләргә хуҗалыкның җаваплы белгечләре дә актив катнашалар, аерым темаларга чыгышлар ясыйлар. Мияш терлекчеләре хәзер үз авылларында яңа гына төзелгән абзарда эшлиләр. Моңарчы исә алар берничә чакрым ераклыктагы Тауасты Байлар фермасына барып йөргәннәр. Ял итәргә, китап укырга, колхоз үзәгендәге Культура йортына килә торган артистларның, язучыларның чыгышларын тыңларга, концерт һәм спектакльләр карарга бөтенләй вакытлары калмаган. Ә инде авылның кечкенә булуын үзләренчә нигезле сәбәп итеп, Минзәлә һәм Казан артистларының Мияш авылын гел-гел читләп узуларын һич тә аклап булмый.

Ә бит заманында Минзәлә театрын оештыруда турыдан-туры катнашкан атаклы артист Шункар бу авылдагы колхозда председатель булып эшләгән. Авылыгыз да, клубыгыз да бәләкәй сезнең дип тормаган ул. Анда яшәүчеләрнең теләкләрен искә алып, аларга концертлар һәм спектакльләр кую өчен районнан сәнгать осталарын чакыртып китерә икән. Безнең көннәрдә исә бу матур гадәтне дәвам итү һич кыен булмас иде.

* * *

Колхозның икенче бригадасын тәшкил итүче Дәвек авылында да сигезьеллык мәктәп, культура йорты, китапханә, элемтә бүлекчәсе, медпункт, таштан җиткерелгән зур кибет һәм балалар бакчасы эшли. Олы юл буйлап Боерган ягыннан килеп кергәндә, авылның аргы читендәге киң мәйданга хуҗалык корылмалары — терлекчелек фермалары, механикалаштырылган ындыр табагы, машина-трактор паркы, ягулыкнан саклау сарае, силос һәм сенаж, бәрәңге һәм яшелчә базлары, ягулык саклау, такта яру җайланмалары, гараж һәм мастерскойлар урнашкан. Шунда ук — авыл халкын

ут, газ һәм су белән тәэмин итү объектлары. Су димәктән, авыл урамнарына колонкалар куелган, сиртмәле һәм чыгырлы коелар казылган, күпчелек йортларның үзенә үк су кертелгән. Хәзер монда газ плитәсе урнаштырылмый калган йортларны да бик сирәк очратасың. Халыкны бу арзан ягулык белән даими тәэмин итеп тору бурычы Фаяз Гыйләҗев һәм Мансур Нуруллинга йөкләнгән.

Бригада йортында ашханә дә бар. Механизаторлар көндезләрен, ел тәүлеге буена диярлек, шунда тукланалар. Төш җитүгә, аларга берәр мәзәк сүз әйтеп, тел чарлап алырга да сәбәп табыла.

— Әйдә, Әлфия Афзалованы тыңлап, күңелне күтәреп чыгыйк!— ди арадан берсе, янындагы иптәшенә мәрәҗәгать итеп.— Безне бүген ул нинди рәк җыр белән сыйлар икән.— Читтән килгән кешегә бу сүзләр башта бераз гаҗәбрәк тоела. Аның мәгънәсен соңрак, пешекчеләрнең берсе Әлфия исемле икәнлеген белгәч кенә аңлыйсың. Бу пешекченең исеме генә түгел, фамилиясе дә яраткан артисткабызныкы кебек — Афзалова икән.

Терлекчеләр өчен ара-тирә ял итеп алу өчен иртәнге якта да, өйләдән соң да чәй кайнаталар. Пенсиягә чыкса да, фермадан аерылырга теләмәүче Зөһрә Мәхмүтова белән комсомолка Рәүсә Латыйпова корган чәй табынын терлекчеләр бик яраталар.

Рәсми күрсәткечләр, узган еллар белән чагыштырганда, шактый үскән саен бу уңышта терлекчелектәге эшләрне дөрес көйләүнең дә роле зур.

Терлекләрне җәйләүгә чыгару һәм кышлатуга хәзерләү чорында бригаданың Лотфрахман Лотфуллин, Муллахмәт Миңнеәхмәтов, Зәфәр Яруллин, Хәким Ногманов һәм Сабир Латыйпов кебек тәүчеләре ярдәмгә килә. Кызганычка каршы, матди-техник база такыррак булу сәбәпле, балта осталары барлык ихтыяҗларны да канәгатьләндереп җиткерә алмый әле. Инеш аша салынган күпернең җимерек хәлдә ятуы гына да урап йөрүчеләрнең күпме кадерле вакытын һәм төрле машиналардагы никаклы ягулыкны җилгә очыра.

«Яңа юл» колхозы заманында тирә-юньдә үзенең җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары белән дан тота иде. Соңгы елларда бу тармакта әллә ни алга китеш сизелмәде. Моңа барыннан да бигрәк зәмһәрир суыклы кышлар сәбәп булды. Дәвеклеләр күбрәк бәрәңге, азык чөгендере игә башладылар. Районның бәрәңге игүчеләре арасында Мәгъсумҗан Махиянов гел макталып тора. Монда безнең телгә, «бригадный подряд», дип кереп бара торган ысул да үзенең бик уңай якларын күрсәтә. Махияновныкылар, колхоз идарәсе белән ике арада төзелгән килешү нигезендә җитештерелгән продуктның күләменнән чыгып, хезмәт хакы алалар. 1981 елда бер кешенең сәгатьлек эше 35 килограммлап бәрәңге булып әйләнеп кайтса, 1982 елда ул 56 килограммга җиткән.

КамАЗ зонасы ихтыяҗларын мөмкин кадәр тулырак канәгатьләндерүне күздә тотып, Минзәлә якларындагы кайбер колхозларда суган үстерә башладылар. Былтыр «Гигант», «Яңа юл», «Искра», «Алга», Вахитов һәм Тукай исемендәге колхозларда суган 350 гектар чамасы мәйданны биләде. Ш/ның 120 гектары «Яңа юл» колхозына туры килә. Бу яңа тармак районда нәкъ менә шушы колхозның Дәвек бригадасы җирлегендә туды. Аны агроном Фәрит Локманов башлап җибәрде. Суганнан колхоз һәр елны ике йөз — ике йөз илле мең сум саф табыш ал... килде. Фәрит Локманов Тауасты Байлар авыл советы башкарма комитеты председателе итеп сайлангач, суганчылар звеносына җитәкчелеккә Шәйхенур Латыйпов билгеләнде. Суганнан югары уңыш алуда Шәйхенурның читтән торып техникумда укуының да хикмәте бардыр, мөгаен. Узган елны уңыш хәтта складларга гына да сыеп бетмәгән. Аны ачык урынга җиргә мәҗбүр булганнар. Күп көч түгеп үстерелгән һәм бик зур киенлек белән җыеп алынган суганның дәүләткә тапшырылмыйча тау-тау булып өелеп ятуы колхозчыларны чарасыз калдырган. Колхоз төзегән килешүләр нигезендә, Брежнев шәһәренең җиләк-җимеш һәм яшелчә торгы — 4500, Минзәлә хәзерләүләр конторасы 1500 центнер суганны үз транспортлары белән 1 октябрьга кадәр басудан ук ташып бетерергә тиеш булган. Кызганычка каршы, оешмалар вәгъдәләрен бозганнар. «Яңа юл» колхозыннан Брежневка озатылган суганны кабул да итмәгәннәр хәтта. Олы байлыкны болай кадерсезләүне аңлап та, аклап та булмый. Ишетүебезчә, җитештерелгән суганны дәүләткә сату мәсьәләсендә башка колхозлар да интеккәннәр. Шул

рәвешле, суган игү файда түгел, киресенчә, зыян китерүче тармак була башларга ихтимал. Алдагы елларда аның мәйданын арттыру, суган үстерүче хуҗалыклар санын ишәйтүнең мәгънәсе бармы икән?

Һәр карышының көчен тиешенчә файдаланмаган, аны исраф иткән өчен Җир беркайчан да беркемгә дә рәхмәт әйтмәс. Суган үстерүнең серләренә төшенеп килүче «Яңа юл» колхозына бу җәһәттән һәрьяклап ярдәм итү, аның дәрәҗәсен күтәрү кирәк.

* * *

Район күләмендә алдынгылыкны һәрвакыт үз кулында тоткан Калинин исемендәге колхоз председателе Касыйм Гафиятовның, уенын-чынын бергә кушып, моннан берничә ел элек әйткән сүзе хәтергә кереп калган.

— Түбән Кама сусаклагычы төзелгәч, Ык буендагы болынлыклар һәм әрәмәлекләр су астында калгач, яр кырына аякларын салындырып утырып, Муса Җәлил исемендәге, «Ярыш», Вахитов исемендәге «Искра», «Кама» һәм «Яңа юл» колхозлары җитәкчеләренең бер-берләре белән аһ-зарларын бүлешәчәкләрен мин хәзер үк күз алдыма китерәм. Моңарчы әле алар болынның нинди зур байлык икәнлеген аңлап җиткермәгәннәрдер. Ул колхозлар терлекләргә гомер-гомергә хуш исле болын печәне ашаттылар...

Мул печәнле болыннардан ерак урнашкан колхоз белән утыз елга якын җитәкчелек иткән бу председательнең сүзләрендә һичбер арттыру юк иде. «Яңа юл» колхозы алдына да су астында калган мең ярым гектар чамасы болынлыклардан чабып алына торган йөзләрчә тонна терлек азыгын нәрсә бәрабәренә тулыландырырга, дигән сорау килеп басты. Терлекләрнең баш санын киметү турында сүз дә булуы мөмкин түгел иде. Тиз арада культуралы көтүлекләр булдырырга, тамыразыклар, кукуруз, көнбагыш, люцерна һәм вика игү звенолары оештырырга кирәк иде. Аларның җитәкчеләре итеп Әхәт Мәхмүтов, Габдулла Нәсбиев, Гомәр Хисбуллин кебек тәҗрибәле механизаторлар, махсус белемле кешеләр беркетелде. Михаил Логинов басуларга «яңгыр яудыручы» булып билгеләнде.

Хәзер колхозның сугарулы чәчүлекләрендәге өч насос станциясе 400 гектардан артык мәйданга су сиптерә. Нәтиҗәдә кайбер участоклардан гектар саен 310 ар центнер печән алынган. Моңа ирешүгә механизаторлардан Рәфыйк Кәримов һәм Габит Әскәрев аеруча зур көч салганнар. Яхшы сыйфатлы ямь-яшел печән зур-зур эскиртләргә өелгән, бозылмасын өчен, өсләре арыш саламы белән ябылган. Давек бригадасының Роберт Гайниев җитәкчелегендә кукуруз звеносы һәр гектарда уртача дүртәр йөз центнер яшел масса үстергән.

Ел әйләнәсенә терлек азыгына мохтаҗлык булмаячагы һәркемне куандыра. Ләкин, аңа карап, азыкның бер генә учмасын да әрәм-шәрәм итүгә юл куелмый, һәр төр азык исәптә тора. Бу вазифа хезмәт ветераны пенсионер Зиннур Борһановка тапшырылган.

Терлек азыгы хәзерләү өлкәсендә яуланган биеклекне киләчәктә дә кулдан ычкындырмас өчен сугару агрегатларын күздән үк карап-әзерләп кую, аларның әйбәт сакланышын тәэмин итү чараларын күрәләр.

Мелиоратор Михаил Логинов дизельләр ярдәмендә эшләүче җайланмаларны киләчәктә электр насослары белән алыштырырга тели. Колхоз җитәкчеләре дә аның бу фикерен хуплыйлар. Моны гамәлгә ашыру шактый ягулыкны янга калдырырга, сугару җайланмаларының тәгәл эшләвен көйгә салырга мөмкинлек бирәчәк.

Калинин исемендәге колхоз председателе Касыйм Гафиятов «Күрәзәчелеге» әнә шул рәвешле тормышка ашмый калган. Болыннарыбыздан колак кактык, дип, коелып төшмәгәннәр, терлек азыгы булдыруның яңадан-яңа ысулларын тапканнар.

* * *

Партком секретаре Шакирҗан Закиров белән сөйләшеп утырабыз. Шакирҗан — минем классташ кына да түгел, партадаш сабакташым. Исте калган: аның дәфтәркаләмнәре күбрәк була иде. Каян табыштыргандыр, анысын белмим, әмма ул шуларны, тип-тигез итеп, икебезгә бүлә торган иде. Сигезенче классны бетерер-бетермәс аңа укуын ташларга туры килде. Партия райкомы каршындагы бакча янындагы

Мактау тактасындагы рәсеменә карап торуымны исәпләмәгәндә, мин аның белән бик күп еллар үткәч кенә очраштым. Ул вакытта минем элекке танышым «Яңа юл» колхозында баш бухгалтер булып эшли иде инде. Менә, ниһаять, без узган гомерләр, бүгенге хәл-әхвәлләр турында әңгәмә коертабыз. Шакирҗан «Алга» колхозында бухгалтер ярдәмчесе, аннары Гөлек авылындагы хуҗалыкта бухгалтер булып эшли. Уфадагы бухгалтерлар техникумын тәмамлаган белгеч эреләндерелгән «Яңа юл» колхозына баш бухгалтер итеп билгеләнә. Моннан унбер ел элек колхоз коммунистлары аны беренче тапкыр партком секретаре итеп сайлыйлар.

Коммунистларның күпчелеге колхоз производствосының иң җаваплы тармакларында эшли. Тауасты Байлар фермасындагы уңган савымчы Римма Хәмидуллинаны партиянең Минзәлә районы XXVI конференциясенә делегат итеп сайлаганнар. Аның үрнәген үзләренә өлге итеп алган Суфия Гыймаева, Әнисә Гаригова, Фәридә Хәмәгдинова, Фәгыйлә Гыймадиева һәм Закира Гыйлаҗева кебек савымчыларның рәсемнәре — колхозның Мактау тактасында. Алар хезмәтенең матур нәтиҗәсе буларак, хуҗалык үткән ел дәүләткә сөт сату планын 105 процент итеп үтәгән.

Партком алдынгыларының эш тәҗрибәсен уртаклашуга даими игътибар бирә. Политик уку сәгатьләрендә КПСС ҮКы Пленумнары карарларын өйрәнәләр, аларны тормышка ашыру буенча конкрет бурычлар билгелиләр. Язгы чәчү, урып-җыю, терлек азыгы хәзерләү, бәрәңге алу кебек аерата җаваплы чорларда, кагыйдә буларак, бөтен тәрбия-аңлату чаралары, эш урыннарында үткәрелә.

Партком секретаре булмәсенә колхоз председателе Мулланур Сабиров килеп кергәч, сүз кабат хуҗалык мәшәкатьләренә күчте. Узган ел бөртекклеләрнең һәм кузаклыларның һәр гектарыннан уртача 24,8 центнер уңыш алып, 47 мең центнер ашлык җитештергәннәр, дәүләт алдындагы изге бурыч 106 процентка үтәлгән.

Терлекчелек буенча да колхоз районның беренчеләре рәтендә бара.

Колхоз составындагы авылларның хәле белән конкрет кызыксынуымны ишеткәч, бу хуҗалык белән әле яңарак кына җитәкчелек итә башлаган председатель куен дәфтәрен тартып чыгарыр дип көткән идем. Ялгышканмын. Бөтенесе — аның хәтерендә икән, чатнатып әйтә барды. Киресенчә, язып алу өчен куен дәфтәренә минем үземә үрелергә туры килде. «Яңа юл» колхозы авылларында барлыгы 401 йорт булып, шуларның 204 е Дәвектә, 161 е Тауасты Байларында, 36 сы Мияштә икән. Колхозда мең ике йөзләп кеше яши. Аларның иң зур күпчелеген укучылар, пенсионерлар һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәшкил итә. Колхозда механизаторлар күп, ул куәтле техникага бай.

Колхозның төп кадрлары шушы туган төбәктә тәрбияләнеп үскәннәр. Яшь кадрлар хәзерләү мәсьәләсе дә — һәрвакыт игътибар үзәгендә. Хуҗалыкның кайсы гына тармагына күз салма, һәрберсендә диярлек колхоз исәбенә укып кайткан белгечне күрәсең. Бу уңайдан зоотехник-селекционер Фәннур Хамматов, авыл хуҗалыгы машиналары инженеры Рафак Зәкиев, лаборантка Рәҗибә Гыйззәтуллина һәм башка күп кенә белгечләрнең исемнәрен атап китү урынлы булыр. Хәзерге вакытта Лузия Билалова, Афина Нуретдинова, Рәмзия Гатина — югары уку йортларында, берничә яшүсмер техникум һәм училищеларда белем алалар.

«Яңа юл» колхозында яшьләрне авылда калдырырга әллә нинди мәшәкатьле чаралар күрергә туры килми. Аларда авылга мәхәббәт бик кечкенәдән үк тәрбияләнә, күрәсең.

— Быел яз көне армия хезмәтен тутырып кайткан биш егетебезнең бишесе дә колхозда эшкә калды,— ди комсомол комитеты секретаре Минзилә Гыйльметдинова.— Колхоз идарәсе аларның һәркайсын үзләре теләгән эшкә урнаштырды. Урып-җыю чорында кырчылык бригадаларында комбайнчылардан комсомол экипажлары төзелде... Кызларыбыз күбрәк балалар бакчасында, медпунктта, бухгалтериядә, терлекчелектә, бакчачылыкта эшлиләр...

Дөрес, өлкәннәр белән яшьләрнең хезмәтен аерым-аерым күрсәтү мөмкин түгел, аның кирәге дә юк. Чөнки «Яңа юл»да өлкән һәм яшь буын кешеләре кулга-кул тотынышып эшлиләр. Һәм колхозның һаман алга таба атлавында нәкъ шул бердәмлек, буыннар дуслыгы иң ышанычлы таянычтан саналырга хаклы.

**Люция Зиннурова,**
КПССның Сарман райкомы секретаре

# ХЕЗМӘТКӘ ҖЫР КУШЫЛСА

Шулай бервакыт Ләке авылында алюминий чаңгы таяклары, нечкә торбадан эшләнгән гардиналарның юкка чыгуыннан зарландылар. Соңыннан сере ачылды: баксаң, алардан... курай, күпләп-күпләп курай ясаганнар икән...

Халык теленде кайчак кызык өчен уйлап чыгарылган мәзәкләр дә йөри, ә менә «курай вакыйгасы»н яшәеш үзе китереп чыгарган. Иң әһәмиятлесе, бераз сәеррәк тоелган мондый хәл күңелле күренеш булырак, кешеләрнең эч йөзен, рухи ихтыяҗын, җаннары теләгәнне күрсәтүче «лакмус»ларның берсе буларак кабул ителә. Ә чаңгы таякларының югалуына бик үк пошынмыйк, нишлисең бит, «сәнгать корбаннар сорый».

«Сандугачлар сайрый, кайда сайрый, Сарман буйларында тирәктә шул...» Ватаныбызның теләсә кайсы төбәгендә яратып җырлана торган мәгълүм җырдагы әлеге сүзләр генә дә Сарманның халык талантларына бай булуы ягыннан үзенә күрә бер «феноменаль як» икәнлеген искәртәләр шикелле. Сарманның исеме үк җырлап тора. (Һәрхәлдә, безгә шулай тоела.) Безнең якларда «сиртмәле суыргычлар» җирнең тирән катламнарыннан көне-төне нефть чыгаралар. Ерак киләчәктә, бәлки, алар туктап та калырлар. Ә менә халык рухы катламнарыннан чыга торган чишмәләр, җыр-моңның күзгә күренмәс «артезиан коелар»ы саегуны белмиләр. Сарман янындагы Зәңгәр тау үз куенындагы бакырны инде әллә кайчан биреп бетергән, ә халык талантлары һаман саен ачыла торалар.

Бездә кайсы гына авылга барып чыксаң да, һәркемдә данлы якташларыбыз белән горурлану чаткысын тоясың. Барлый башласаң, районыбыз күрке саналучы талантлар шактый җыела икән. Әмма мин сүзне аларның барысы турында да алып бармыйм, фәкать әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә танылган кайбер шәхесләрне генә атап китәм.

Күпме тыңласаң да тыңлап туймаслык җырлары белән халкыбызның тирән мәхәббәтен яулаган җырчы — РСФСРның халык артисты, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакиров сарманлыларны хаклы рәвештә горурландыра. Дөрес, хәзер ул Сарманга сирәгрәк кайта, әмма кайткан саен халыкның «күңел сандыклары»нда сакланган борынгы җырларны үз репертуарына алып китә. Әлеге җырлар аның башкаруында кинәттән табылган кыйммәтле җәүһәр сыман ялтырап-нурланып китәләр, икенче төрле әйткәндә, яңадан туып, озын-озак юлга чыгалар.

«Сандугачлар сайрый, кайда сайрый...» Без бик хаклы рәвештә Зөһрә Сәхәбиеваны да үз сандугачыбыз итеп саныйбыз. Бөтен республиканы тамаша залы итеп, телевизордан җырлыймы, радио аша чыгыш ясыймы — аны һәркем үз итеп каршы аладыр. Зөһрә тавышында без үзебезнең якларга хас бормаларны һәм моңны ишетеп сөенәбез һәм ихлас горурлану тойгылары кичерәбез.

Музыка сәнгатенә хезмәт итүче якташларыбыз турында сөйләгәндә, без композитор Мәсгут Латыйповны зур горурлану белән искә төшерәбез. Сөйләүләргә караганда, аның әтисе Мәүлетгали ага — Тукайны якыннан белгән һәм аралашкан кеше. Бөек шагыйрьнең рухи йогынтысы, күрәсең, аның улына да күчкән, һәм Мәсгут, үсеп җиткәч, кайчандыр Тукай хыялланган милли композитор булу дәрәҗәсенә ирешкән. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәсе килә: моннан шактый еллар элек М. Латыйпов тырышлыгы белән районның «1 Май», «Җиңүче», Серго исемендәге, «Татарстан», «Мәгариф» колхозларында «Сарман чәчәкләре» исемендә инструменталь ансамбльләр оештырылган иде. Мәктәпләрдә белем алучы 100 кызны берләштергән бу җыелма ансамбль заманында халыкка бик игелекле хезмәт күрсәтте. Тора-бара алар, урта мәктәпне тәмамлап, төрлесе төрле якка таралыштылар. Берәүләре — музыка училищесына, икенчеләре культура институтына юл тотты. Ә инде хәзер аларның күбесе культура йортларында эшли. Аерым сәнгать эшлекләре безгә менә нинди ярдәм күрсәтә алалар. Игелекле хезмәт югалмый. Җыр-моң чишмәләре тагын да тулышыбрак ага, халык иҗаты традицияләре баетыла-баетыла дәвам иттерелә.

«Сарман буйларыннан үткән чакта, Тыңларсыңмы җырлар җырлармын...» Безнең якларның бәрәкәтле туфрагы, әйе, үзләре җырлар иҗат итүчеләрне дә тудырган. Музыка сөючеләр якташыбыз Ифрат Хисамовны яхшы беләләрдер. Үзенең көйләре буенча күпләргә таныш булган «курайчы егет»ебез «Курайда уйнарга өйрән» дип исемләнгән китап-кулланма да язды. Музыкант якташларыбыздан Валерий Әхмәтшинның «Чыгарсыңмы каршы алырга» җыры (Дамир Гарифуллин сүзләре) аеруча бәхетле язмыш кичерә. Әлеге җырны Татарстанның теләсә кайсы төбәгендә яратып башкаралар. Шулай ук Рафис Уразаев тарафыннан иҗат ителгән «Сарманым» җыры да (Миргасим Гаскәров сүзләре) тиз арада халыклашып китте, Бөтенсоюз радиосының «Җир һәм кешеләр» тапшыруында берничә мәртәбә яңгырады. Бу җәһәттән әйтеп узыйм: композитор һәм җырчы егетебез Рафис Бохара музыка училищесын тәмамлаган. Бүгенге көндә ул Мортамак авылы культура йорты директоры булып эшли. Биредә аның оештыру сәләте дә, сәхнә осталыгы да киң ачылды. Саклаубаш урта мәктәбе укытучысы Рөстәм Шәмсиев, Җәлил музыка мәктәбе директоры Мәгафур Йөзлебаевның да күңелгә уелып калырдай җырлары байтак. Якташыбыз Зөфәр Сәхабиев та көйләр язарга һәм җырларга ярата. Хәзер ул Мәскәү училищеларының берсендә музыка укыта. Һәвәскәр композиторның Ф. Шәфигуллин, К. Булатова, Ә. Габиди шигырьләренә язылган җырларын үзешчәннәр бик теләп башкаралар.

«Кечкенә клублардан башка зур поэзия булмас иде...» Шушы урында Р. Гамзатовның өнә шундый сүзләре искә төште. Клуб һәм поэзия... Әлеге төшенчәләр арасында, бер карасаң, бәйләнеш юктыр кебек тоела. Чынлыкта исә аларга үзара бәйләнешле тирән мәгънә салынган. Әйтик, клуб төшенчәсе авыл кешеләренең эч йөзен нурландыручы, халык җаныннан төртеп чыккан теләсә нинди талант шытымнарына яктылык һәм җылы бирүче культура учакларының берсе буларак күз алдына килә. Ә безнең социалистик сәнгать үсеше турыдан-туры бөтен халыкның рухи үсешенә бәйле. Шушы бәйләнештән чыгып караганда, Сарман җиренең рухи потенциалы үзенең поэзиясен дә барлыкка китерде, кон-

кретрак әйткәндә, үзенең язучыларын да дөньяга чыгарды: Вәдүт Мифтахов, Әюп Гәрәй, Сөббух Рафиков, Аяз Гыйләҗев, Хәниф Хәйруллин, Адлер Тимергалин, Мәдинә Маликова, Клара Булатова, Дилрә Зөбәерова, Рәфкат Кәрами, Әзһәр Габиди...

Безнең якларның «рухи байлыклар картасы»н менә кинди талантлар бизи. Халыкның гасырлар буе җыелып килгән культура хәзинәсе менә кемнәрнең күңелләреннән ургыла. «Визитка»быздагы әлеге исемнәр белән горурлану күңелләргә, әлбәттә, җиңеллек китерә, ә иңнәргә тагын да зуррак йөкләр өя шикелле. Күренекле якташларыбыз безгә һәрвакыт сынап карыйлардыр төсле тоела. Халык талантларын табу һәм үстерү юнәлешендә, димәк, үзебезнең «марка»ны төшермәү, һәрвакыт биеклектә калу өчен бездән яңадан-яңа резервларны ачу, мөмкинлекләрдән максималь файдалану һәм җаваплылыкны арттыру сорала.

Халкыбызның гаять тирән мәгънәле мондый мәкале бар: «Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә...» Яхшы мәгънәдәге тук кеше, димәк, җитеш тормышта гомер итүче. Ә халыкның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт иясенең эш шартларын яхшырту, белем бирү челтәрен киңәйтү, буш вакытны арттыру культураны моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә үстерергә, кешеләрнең күпьяклы рухи камилләшүен, халык талантларының чәчәк атуын тәэмин итәргә мөмкинлек тудыра. Ленинча әйткәндә, нәкъ менә шундый җирлектә «яңа, бөек коммунистик сәнгать» үсеп чыга.

Культура үсешен материаль үсештән аерып булмый. Әгәр без культура өлкәсендә күпмедер уңышка ирешкәнбез икән, аларның барысы да социаль-экономик үсеш нигезенә таянып торалар. Әлеге берлекнең күркәм нәтиҗәсе районыбыз җирлегендә дә ачык чагыла. Бүгенге үрләр биеклегеннән караганда, ирешелгәннәр уч төбендәгечә күренә. Район үзәге Сарманны гына алыйк. Соңгы елларда ул күзгә күренеп матурайды. Колхозлашу елларында хезмәт уңышларына ирешкән алдынгыларны Сарман өстеннән аэропланда очыртып әйләндергәннәр, һәм ударниклар әле шул заманда да Сарманның матурлыгына сокланганнар. Ә бүген район үзәге танымаслык булып үзгәрде. Биредән төрле якка асфальт юл китә. Ә һава юлы республикабызның башкаласы белән тоташтыра. Күп катлы якты йортлары белән шәһәр төсен ала бара Сарман. Ә тагын ун елдан ул бөтенләй яңарачак. Төзек урамнар, иркен мәйданнар тагын да күбәер. Моңа беркем дә шикләнми, чөнки барысы да районның социаль үсеш планына салынган.

Безнең яклар «кара алтын» бирүче төбәк буларак та танылган. Патриот шагыйрь Муса Җәлил исемен йөртүче кала районыбыз җирендә үсеп чыкты. Дөрес, аны поселок диләр, әмма ун мең халкы булган һәм үзенең 25 еллык бәйрәменә әзерләнүче Җәлилдә яшәүчеләр аны хаклы рәвештә «Мәскәүнең бер почмагы» дип атыйлар. Мәһабәт кунакханәсен, Техника йортын, кибетләрен, шифаханәсен, көнкүреш хезмәте күрсәтү үзәген, санаторий-профилакторийны карап йөргәннән соң, кайнар һәм салкын суның һәр өйдә булуын һәм тагын башка дистәләрчә уңайлыкларны искә алсак, җәлилләрнең сүзләрендә хаклык барлыгына ышанасың.

Үткәннәр, бүгенге һәм киләчәк турында хәзер һәр кеше уйланадыр. Унберенче бишьеллыкның дүртенче елы уртасын узып барабыз. Тагын ел ярым чамасы вакыт үткәннән соң, уникенче бишьеллык бусагасыннан атлап керәчәкбез. Агымдагы бишьеллык хакында уйланганда, әлбәттә, сүз ирешелгәннәргә килеп тоташа. Шунысы куанычлы: узган ел районыбыз эшчәннәре игенчелек һәм терлекчелек буенча барлык планнарны уңышлы үтәп чыктылар. Дәүләт амбарларына 60 мең тонна ашлык, 62 мең тонна шикәр чөгендере озатылды. Ит һәм сөт сату планнары да арттырып үтәлде. Саннарны күп китерү әдәби журнал материалында

ХЕЗМӘТКӘ ЖЫР КУШЫЛСА ◆ ЛЮЦИЯ ЗИННУРОВА ◆

бәлки килешеп тә бетмидер. Әмма безнең уңышларыбыз шул саннар артында саллырак күренә, һәм алар, халыкның хезмәт һәм политик активлыгын күтәрү, идея-тәрбия эшен яхшырту, хезмәт дисциплинасын ныгыту, социалистик ярышны киң җәелдерү, хезмәт ияләре арасында культура-агарту эшләрен яңа баскычка күтәрү нәтиҗәсе буларак, горурлык һәм дәрт-дәрман уяталар, киләчәккә ышаныч тудыралар.

Хезмәткә җыр кушылса... Кайчак хуҗалык эшләре белән үзешчән сәнгать коллективы эшчәнлеген чагыштырып карарга туры килә, һәм алар арасындагы ике яклы җанлы элемтәне тоеп, канәгатьләнү хисе кичерәсең. Мисалга «Җиңүче» колхозын гына алыйк. Биредәге культура йорты хезмәткәрләре товарлыклы-сөтчелек фермасы савымчыларын концертларда катнаштыруны максат итеп куйдылар. Тиздән савымчыларның җыр ансамбле оешты. Һәм тора-бара ферма күрсәткечләре дә яхшыра башлады, алдынгылар саны да ишәйде. Димәк, кызларның үзешчән сәнгать өлкәсендәге активлыклары турыдан-туры хезмәт җитештерүчәнлегенә дә шифалы йогынты ясаган. «Музыка тыңлаганнан соң,— дип язган Гете,— минем эшем һәрчак яхшырак бара». Музыка сәнгате материаль байлык тудыручыларга да нәкъ менә шундый этәргеч бирә, җыр үзенең канатлары белән теләсә нинди авырлыкларны күтәрешә.

Сәнгатьнең югары әхлаклылык, хезмәт сөючәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүдәге роле районның музыка һәм художество мәктәпләре эшчәнлегендә дә ачык күренә. Музыка коралларында уйнарга, җырларга һәм биергә яки рәсем төшерергә, сын ясарга өйрәнүче балалар арасында начар өлгерешле укучыларны, тәртип бозучыларны, әти-әниләренә булышмаучыларны очрата алмассың. Сәнгать менә нинди сихри көчкә ия!

Җырлап иген иккән,
Җырлап гомер иткән
Сарман ягы элек-электән.
Туган ягым җырны,
Җыр Сарманны
Үзенеке иткән, үз иткән...

Бездә март айларында уздырыла торган җыелма концертлар үзешчәннәрнең чын-чынлап олы бәйрәменә әверелә. Җыелма хорда катнашучылар, сәхнәгә генә сыймыйча, тамаша залына да төшеп басалар. Мондый чакта район культура йорты тоташ бер хор коллективына әйләнә. Партия, Ленин, Ватан турындагы җырлар һәркемдә горурлык һәм күтәренкелек тойгыларын уяталар. Дуслык, туганлык хакындагы җырлар кемнәрнең генә күңел түренә барып җитми икән дә, иң матур хисләрен кузгатмый икән?! Хәрәкәткә бай рус, татар, башкорт, үзбәк, мари, удмурт һ. б. халыкларның милли биюләре сәхнәдә кабатланган саен күп милләтле илебез культурасының үзара баюын, нур янында нур булып балкуын тоясың, халыклар дуслыгының сәнгатьтәге якты гәүдәләнешен күреп сөенәсең.

Мондый концертларда районыбыз талантлары, гадәттә, һәръяклап ачыла, сәхнә белән тамашачы арасында, әйтерсең, барлык төсләре белән балкып торучы салават күпере сузыла. Йомгаклау концертлары сарманлыларның рухи күтәренкелеген көзгедәгечә чагылдыра. Ә көзгедә исә һәр нәрсә үз төсе белән күренә. Сөенечле яклар һәркемнең уртак шатлыгына, җитешсезлекләр исә уртак көенечкә әверелә.

Үзешчән сәнгать казанышларын барлаганда, район культура йорты каршында эшләүче агитбригада эшчәнлегенә аерым тукталып үтәргә кирәктер. Әлеге коллектив Бөтенсоюз фестиваленең Беренче дәрәҗә дипломы, Бөтенроссия фестивалендә лауреат исемен һәм зур алтын медаль яулады. Мәскәүдә үткәрелгән йомгаклау концертында һәм

Бөтенроссия хор җәмгыятенең 100 еллыгы уңаеннан оештырылган концертта катнашты. РСФСР Культура министрлыгы һәм культура работниклары профсоюзлары үзәк комитеты, шулай ук «Агитатор» журналының махсус грамоталары белән бүләкләнде.

Ә «Яшьлек» җыр һәм бию ансамбле, Бөтенроссия зона смотрында (Ульяновск) призлы урынны алып, республикабыздагы авыл үзешчәннәре иҗаты тарихында беренче мәртәбә буларак, татар совет милли сәнгатен чит илдә — Болгариядә күрсәтү хокукын яулады. Үзешчәннәребез Г. Димитров исемендәге Яшьләр үзәгендә үткәрелгән халыкара фестивальдә дүрт алтын, җиде көмеш медальгә лаек булдылар. Аларны София, Бургас, Плевен, Русе һ. б. шәһәрләр тамашачысы алкышлады. Әлеге иҗат коллективы хәзер дә үсештә, аның чыгышларын һәркайда көтеп алалар. Автомобиль төзүчеләр, Түбән Кама, Әлмәт, Зәй районнары эшчәннәре алдында да алар еш булалар, хезмәт ияләрен җиңүле хезмәткә рухландыралар.

Хәзерге кешенең рухи тормышын, кабатлап әйтик, культура учакларыннан башка күзаллап булмыйдыр. Культура йорты, клуб, китапхәнә, Кызыл почмак — һәммәсе җанны җылыта торган гаҗәеп учаклар. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин 1913 елда ук инде «клубларны эшчеләрне агарту өчен иң мөһим позицияләрнең берсенә әверелдерү» кирәклеген күрсәткән. Тикмәгә генә А. В. Луначарский клубны социализмның бер кисәкчеге итеп санамаган. Чыннан да клубларны кайнап торган тормышыбызның якты бер аланына тиңләргә буладыр. Культура учаклары коммунистик тәрбия эшенә ярдәм итәләр, кешеләрнең иҗади сәләтләрен үстерешергә булышалар.

Ләке авылы культура йортының «Игенә» фольклор ансамбле нигездә колхозчыларны берләштерә. Әлеге коллектив керәшен татарлары җырларын тарату буенча мактаулы эш башкара. Хәзер инде эфир дулкыннарында еракларга яңгырый торган «Әйдә, әйдә...» җыры элекке заманнарда шушы авылда туган. «Игенә»не оештыруда колхозның партком секретаре Роза Аксакова башлап йөрде. Үзе дә ул, культура эше фидакаре буларак, концертларда еш катнаша.

Җырны гомерлек юлдаш итүчеләр, ягъни хезмәт һәм сәхнә ветераннары да аз түгел бездә. Мәсәлән, «Үрнәк» колхозыннан Ленин ордены кавалеры Мөдәррис Хөснетдинов, «Коммунизм» колхозыннан Хәли Хәбибуллин, «Җиңүче» колхозыннан Нурислам Фәхрисламов, Тукай исемендәге колхоздан Әсма Заһирова, «Родина» колхозыннан Нурулла Нәбиуллин әнә шундыйлардан санала. Иң куанычлысы, әлеге ветераннарның эшен хәзер үзләре белән берлектә балалары дәвам иттерә. Ә гаилә ансамбльләре турында сөйләгәндә, без «Тукай» совхозыннан Фәрхетдиновларны, Тукай исемендәге колхоздан Хатиповларны, «Родина» колхозыннан Таҗиевларны горурланып искә алабыз. Атаклы җырчыбыз Илһам Шакировның бертуган абыйсы механизатор Кыям Шакиров тавышына да сокланып туймассың. Баксаң, аның кызы да җырлый икән. Дүртенче класста гына укый торган әлеге кызчык Сарман сәхнәсендә дә уңышлы чыгыш ясады. Менә шулай Шакировлар дәвам итә.

Шушы урында хезмәт ветераны Фатыйма апа Гайнемовага («Тукай» совхозы) аерым тукталып үтәсе килә. Халык хәтеренә ул гармунчы буларак кереп калган. Сугышка китүчеләрне дә Фатыйма апа тальяны белән озатып калган, җиңеп кайтучыларны да өздереп уйный-уйный каршы алган. Авылда бер генә концерт та аннан башка узмаган. Музыка белән тормышны ямьләндерергә өйрәнгән шушы хатын үзенең ире Бикмөхәммәт абый белән алты бала тәрбияләп үстергәннәр. Аларның һәммәсе дә музыканы ярата. Мәсәлән, Флүр, Флүрә, Вәзирә өчесе дә музыка училищесын тәмамлаган. Ә төпчекләре Әнүр баянда да, курайда да оста уйный. Вәзирә күп еллар инде Сарман музыка мәктә-

бендә укыта, яшь буынны җыр яратучан итеп тәрбияләү өчен бөтен көчен бирә.

Авылда культура комплексының горурлыгы, әлбәттә, җырчылар һәм биючеләр белән генә чикләнми. Колхоз һәм совхозларда драма түгәрәкләре дә эшли. Үзешчәннәр тарафыннан куелган спектакльләр авыл сәхнәләрендә зур уңыш белән күрсәтеләләр. Менә егерме ел инде Сарман һәм Теләнче Тамак халык театрлары күп милләтле совет драматургиясенең иста калырдай образларын иҗат итәләр. Классик драматургларыбыздан М. Фәйзинең «Галиябану», Г. Камалның «Беренче театр», «Бүләк өчен» һ. б. пьесалары буенча куелган спектакльләр аеруча зур кызыксыну һәм канәгатьләнү белән карала.

Кешене үзешчән сәнгатькә нәрсә тарта? Дөнья һәм кеше турында күбрәк белү, матурлык белән очрашу ләззәтен тату омтылышы, үзендә художникны ачу, рухи байлыкларыңны ишәйтү, иҗат итү теләге. Ә бит кеше табигате буенча ук дөньяга иҗатчы буларак килә, һәм бездә үзеңне төрле яклап ачар өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Кешеләрнең художество иҗатында күпләп катнашуы советча яшәү рәвешенең асыл сыйфатларыннан санала. «...Дәүләт гражданнарга үзләренең иҗади көчләрен, сәләтләрен һәм талантларын куллану өчен,— диелә СССР Конституциясендә,— реаль мөмкинлекләрне киңәйтүне үзенең максаты итеп куя». Ә үзешчән сәнгатьнең менә шундый шартларда югары баскычка күтәрелүе халыкның эстетик культурасын төрле яклап үстерү юнәлешендә ныклы адымнар белән алга баруны һәм халык иҗатындагы традицион формаларның иң яңа художество культурасы казанышлары белән органик төстә кушылып китүен күрсәтә. Традицион рәвештә үткәрелә торган үзешчән сәнгать смотрлары шуны раслый: кайбер коллективлар үзләренең осталык дәрәҗәләре буенча профессионалларга тиңләшә баралар. Үзешчән сәнгатьнең киң колач алуы халыкларның бөтен социалистик культурасын күтәрүдә куәтле факторга әверелә. Менә шундый күренеш безнең район җирлегендә дә күзәтелә. Үзешчәннәрнең осталыгы үсүе, аларның зур сәнгатькә юл ярулары зур канәгатьләнү тудыра һәм шул ук вакытта иҗат коллективлары алдына яңадан-яңа катлаулы бурычлар да куя.

Хәзер инде аерым хорларда элеккечә бер тавышка түгел, ә бәлки өч-дүрт тавышка җырлыйлар. Татар халык иҗатының җәүһәрләреннән саналган «Гөлҗамал», «Кара урман» кебек җырларны бездә профессиональ осталык белән башкаручылар байтак. Сарман сәхнәсеннән күтәрелгән Зөһрә Шәрифуллинаның Татар дәүләт филармониясе коллективында җырлый башлавы, шулай ук җырчы Мөҗип Исламовның үзешчәннәр арасыннан үсеп чыгуы да халык художество иҗатының камилләшү юнәлешендә югары баскычка күтәрелүе турында сөйли. Ә бит илебездә күп кенә профессиональ театрлар һәм башка иҗат коллективлары үзешчән сәнгать җирлегендә оештырылганнар, һәм алар үзешчәннәр хисабына тулылана баралар.

«Алтынчәч» операсыннан хореографик сюита...» Дөресен генә әйткәндә, авыл сәхнәсеннән менә шундый игъланны ишетергә без әллә ни күнекмәгәнбез. Музыка сәнгатенең мондый затлы һәм «нәзберек» үрнәкләре белән, гадәттә, шәһәрләрдә генә очраша аласың. Сарман үзешчәннәре шундый жанр буенча да көчләрен сынап карарга булдылар һәм авылларда опера сәнгатен өлешләп пропагандалау буенча сизелерлек уңышка ирештеләр. Аларның чыгышларын казанлылар да яратып кабул итте.

Шушы уңайдан кайчак уйланып та куясың. Нигә әле без авыл кешеләрен опера һәм балет сәнгате белән очрашу ләззәтеннән һаман да мәхрүм итеп киләбез. Белгәнебезчә, музыкаль театрның гастрольләр маршруты һәрвакыт зур шәһәрләр аша үтә, һәм без моны инде табигый

күренеш буларак кабул итәбез. Анысы театрның үзенчәлегеннән киләдер. Авыл кешеләренә мондый спектакльләрне шәһәргә барып карарга да гел-гел форсат чыгып тормый. (Дөрес, Казанга якынрак районнардан культпоходлар ясала, алары да күңелек очракта драма театрларына оештырыла.) Менә шушы урында сорау туа: ни өчен музыкаль театрлар авылда опера һәм балет сәнгатен пропагандалау өчен берәр төрле форма уйлап тапмыйлар. Әйтик, авыл сәхнәсендә опера яки оперетта, балет, музыкаль спектакльләрдән өзекләр белән чыгыш ясарга буладыр бит. (Аннары шунысын да онытмыйк: авыл яшьләренең күпмедер өлеше, телибезме-теләмибезме, тора-бара шәһәрдә яши башлый, димәк, алар әзерлекле булган очракта шундук театрның актив тамашачылары даирәсенә килеп кушылалар.) Музыкаль театр коллективы авылда опера һәм балет сәнгатен пропагандалаучы үзешчәннәргә дә шефлык ярдәме күрсәтә ала лабаса. Кыскасы, бу өлкәдә ничектер бергәләп эшләү таләп ителә. Ә иҗади хезмәттәшлек мөмкинлекләре байтак, бары тик эзләнергә генә кирәк.

Тагын бер мәсьәләгә тукталып үтәсе килә. Элегрәк авылдан авылга аю биетеп йөрүчеләр булган. Күчмә зоопарклар да йөргәләгән. Алар үзенә күрә яңа дөнья белән очрашу шатлыгы өләшкәннәр. Хәзерге коммуникация заманында мондый онытылмаслык очрашуларны бик рәхәтләнеп рештырырга буладыр. Аларның формалары күп төрле. Әйтик, ни өчен күчмә күргәзмәләр оештырмаска?! Татарстан сынлы сәнгать музее һәм Художниклар союзы мондый игелекле эшне авырыксынмыйча башкара ала дыр дип уйлыйм. Башкалабызда оештырылган күргәзмәләрне авыл кешеләренең барысы да карый алмыйлар. Ә сынлы сәнгать үрнәкләре белән якыннан очрашу, картиналардагы буяуларны күз нурлары белән капшап алу кешегә никадәрле эстетик ләззәт, иләһи көч, яшәү дәрте бирә! Әлеге тәҗрибәне без үзебезнең җирлектә, Сарман балалар художество мәктәбе мөмкинлекләреннән чыгып җәелдерергә омтылыш ясадык. Чыннан да мондый күчмә күргәзмәләр һәркайда гаять зур кызыксыну белән карала. Һәм менә Бөек Җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан районда балалар, үзешчән рәссамнар һәм көнкүреш сәнгате осталары конкурс-күргәзмәсе оештырылды. «Тынычлыкны саклау эшендә мин нинди файда китерә алам?» Шундый девиз астында тупланган күргәзмә бездә халыкның зур иҗат потенциалына ия булуын тагын бер мәртәбә раслады. Соклану һәм горурлану хисләре кичергәндә, ирексездән, М. Горький сүзләре хәтергә килә: «Халык — материаль кыйммәтләр булдыручы көч кенә түгел, ул рухи кыйммәтләрнең бердәнбер, саекмас чыганагы».

Бездә матур гадәт яши. Бәйрәмнәрне культура йортына җыелып уздырабыз. Урам бәйрәмнәре дә шулай уза. Ленин, Куйбышев, Җәлил һ. б. урамнарда яшәүчеләр оештырган тантаналар әле дә хәтердә саклана. Мондый бәйрәмнәргә әзерлек алдан ук башлана. Башта рәсем, кул эшләре, аш-су хәзерләү, йорт-җир, каралты-кура чисталыгы буенча махсус конкурслар үткәрелә. Теге яки бу урамда яшәүче кешеләрнең мактаулы эшләренә йомгак ясала. Беренче ударниклар, сугышта батырлык күрсәткән каһарманнар ачыклана. Тантана ахырында шул урамда яшәүчеләр тарафыннан озакка сузылган концерт күрсәтелә. Җырчылар, биючеләр, нәфис сүз осталары бергә күплөп җыела. Мәсәлән, шундый бәйрәмнәрнең берсендә хәтта грузин егете дә — көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсе эшчесе Шота Гагуадзе катнашты, «Әкълимә», «Уфа юкәләре» кебек җырларны һәркемнең күңел түренә үтәрлек итеп татарча башкарды. Мондый бәйрәмнәрдә халык иҗаты үсеше бик ачык булып күренә.

Үзешчән художество иҗаты турында сөйләгәндә, районыбызның ре-

сем төшерү, туку, чигү белән мавыгучыларына аерым тукталып үтәргә кирәктер. Әйткәнемчә, төрле бәйрәмнәр вакытында аларның иҗат үрнәкләреннән район культура йортында махсус күргәзмәләр оештырыла. Салават күперенең бар төсе салынган келәмнәр, чигүле тастымаллар, ашъяулыклар һәм җәймәләр кемнәрнең генә күз явын алмыйдыр?! Сатучы Ф. Гыйлфанова, типография эшчесе М. Талипова, культура йорты методисты Р. Һадиева, китапханәче Н. Вәлиуллина тарафыннан эшләнгән келәмнәрнең, Шыгай балалар бакчасында эшләүче Ф. Садыйкова суккан паласларның һәр бизәгендә кояш уйный, йолдызлар җемелди, ай нурлары сирпелә, чишмә чылтыравы ишетелә шикелле.

Халык иҗатының чишмә-чыганаклары, җир астындагы елгалар шикелле күзгә бәрелеп тормыйлар, шулай да аларның бетмәс-төкәнмәс булуын күңелең белән тоеп торасың. Халык талантлы балаларын туктаусыз тудырып тора. Җиребездә яңадан-яңа «моң катламнары» ачыла. Халык таланты күпкырлы. Үзем шушы хакта уйлыйм, үзем Яхшы Каран авылында яшәүче Сәгытдин абзый Камалиевны искә төшерәм. Балачакта чәчәк авыруыннан сукыр калган шушы кеше инде менә ничә дистә еллар буе кешеләргә тальяннар ясап өләшә. Үзе бер гармун фабрикасы кебек. Сәгытдин тальяннары... Аларның һәрбер өлеше сукыр гармунчының күңел күзеннән сирпелүче нурлар белән җылытылган. Шундый кешенең тальяннар ясавы — үзенә күрә бер батырлык. Якташым Сәгытдин абзыйның уйнавын тыңлаганда, ирексездән, яшәү мәгънәсе турында уйланасың, «Гомерем минем моңлы бер җыр иде» кебек шигъри сүзләрне тирәнрәк аңлый башлыйсың, тормышка мәхәббәтең көчәеп киткәндәй була, халкыбыз талантлары белән тагын бер мәртәбә горурланасың.

Хәзер икенче Бөтенсоюз үзешчән художество иҗаты фестивале бара. Әлеге смотр совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел тулуга багышлана. Бу бөек дата бер генә кешене дә тыныч калдыра алмыйдыр. Һәр коллектив, һәр хезмәт иясе хәзерге халыкара киеренкелек шартларында, империалистлар атом-төш коралы белән янаганда үз вөҗданы алдында, сугышта корбан булганнар алдында фидакарьлеге белән имтихан тота. Менә шундый җаваплылык үзешчән сәнгать коллективлары чыгышларында да ачык сизелә.

Бөтенсоюз смотрының үзәкләштерелгән авыл культура йортларында уздырылган беренче туры тамашачылар күңелендә якты хатирәләр калдырды. Яу кырында илебез азатлыгы өчен ятып калган каһарманнарга мәдхия булып яңгыраган җырлар һәм шигырьләр, совет сәхнә сәнгатенең югары гражданлык белән сугарылган башка күп төрле әсәрләре сугыш утын кабызырга тырышучыларга каршы көчле нәфрәт тудыралар. Ватаныбыз куәтен арттыру хакына армый-талмый эшләргә рухландыралар.

Смотрның икенче туры барышында район культура йортына берәмберәм колхоз һәм совхоз үзешчәннәре коллективлары җыелды. Алар сугышта һәлак булган җиде меңнән артык сарманлыларга, тылда тормышның бөтен авырлыгын үз җилкәләренә алган хатын-кызларыбызга дан җырладылар. «Үрнәк», «Җиңүче», «Татарстан», «Корыч кул» колхозлары, «Тукай» совхозы үзешчәннәре концертларында тормышка мәхәббәт, ирешелгән уңышлар белән чиксез горурлану хисләре ташып торды. «Совет солдаты», «Аналар сугыш теләми», «Җайдаклар», «Дуслык» исеме астындагы әдәби-музыкаль композицияләрне караганда, кемнәрнең генә күңеле тетрәнмәгән, кемнәрдә генә дәртле һәм оптимистик уйлар тумаган икән! Бөек Октябрь революциясенә кадәр «бөлгән һәм үлгән» як булып саналган Сарман якларының нурлы һәм җырлы төбәккә әверелүе әлеге концертларда күзгәдәгечә чагыла.

Фестиваль барышында авыл культурасының материаль базасын ны-

гыту зарурлыгы да бөтен кискенлеге белән ачыла. Үзешчән сәнгать коллективларының репертуарын коммунистик мораль, гуманизм һәм югары гражданлык рухындагы яңа әсәрләр белән баету, милли коллективлар арасында рухи кыйммәтләр алмашу... Смотр дәвамында мондый юнәлештә эшләү дә таләп ителә. Шунысын да әйтергә кирәк: репертуар һәм методик әдәбиятның сыйфаты әлегәчә түбән булып кала бирә. Тормыштагы төрле вакыйгалар, бәйрәмнәр, кичәләр өчен сценарийлар җитенкерәми. Хезмәт ветераннарын хөрмәтләү-тәбрикләү өчен, мәсәлән, җитди уйланып язылган бер кулланма да таба алмыйсың. Ферма уңганнарын, кыр батырларын данлау өчен кулга тотардай ярдәмлекләр күренми. Соңгы вакытта махсус рәвештә эстрада сәнгате өчен язылган юмор һәм сатира әсәрләре дә азаеп китте шикелле. Рухи азыкны да төрләндереп-яңартып тору таләп ителә.

Авыллардагы үзешчән сәнгать энтузиастларын профессиональ коллективларга стажировкага чакыру, иҗат союзларының районнарда консультация пунктларын оештыру, аерым культура эшлекләрен билгеле бер коллективка беркетү һ. б. шундый формаларны киңрәк җәелдерергә кирәктер. Халык художество иҗатының үсүе иң беренче чиратта авыл культурасы кадрларының белеменә, осталыгына һәм энтузиазмына бәйле. Казан культура институты, культура-агарту училищелары кадрлар хәзерләүдә һәр районның ихтыяҗын истә тотып эш итсәләр, авыл кешеләренең рухи үсеше юнәлешендә тагын да зуррак файда китерә алырлар иде шикелле. Кызганычка каршы, районыбызда йөздән артык культура работнигының нибары тугызы гына югары белемле. Ә махсус урта белемгә ия булучылар саны кырыктан артмый. Мондый күренеш башка районнарга да хастыр дип уйлыйм.

Кешенең рухи ихтыяҗларын формалаштыру, шәхеснең идея-политик, әхлакый йөзенә актив йогынты ясау — социалистик культураның мөһим миссиясе. Халык иҗатының тәрбияви йогынтысын көчәйтү, совет кешеләренең буш вакытын файдалануда аның ролен үстерү Бөтенсоюз смотрының да әһәмиятле бурычларыннан санала. Коммунистик тәрбия эшендә һәм хезмәт ияләренең төп эштән калган вакытын рациональ файдалануда халык иҗатының ролен күтәрү зарурлыгы КПСС Үзәк Комитетының «Үзешчән художество иҗатын тагын да үстерү чаралары турында»гы карарында да ассызыклап әйтелә.

Эстетик тәрбия алу, гадәттә, мәктәптә башлана. Биредә без бөтен гомеребезгә җитәрлек гүзәллек хисе чумырып алабыз, әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен аңларга, бәяләргә өйрәнәбез, беренче мәртәбә иҗатка тартылабыз. Балалар һәм яшүсмерләрнең актив ялын оештыру, аларның художество иҗатын үстерү буенча мәктәпләрдә үткәрелә торган реформа уңаеннан гаять зур бурычлар куела. Әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә Бөтенсоюз смотрыннан да нәтиҗәле файдаланырга кирәктер. Ә бит фестивальдә катнашучыларның яртысы — мәктәп балалары һәм профтехучилище укучылары.

Тормыш күрсәтә: хуҗалыкларның социаль-экономик үсеше планына үзешчән сәнгатьне үстерү буенча да конкрет йөкләмәләр кертелсә, гадәттә, халык талантларының ачылуы һәм чәчәк атуы өчен яхшы шартлар тудырыла. Ә үзешчән иҗатның үсүе үз чиратында кешеләрнең үзаңын тагын да камилләштерергә, шәхестә яңадан-яңа көч чыганакларын ачарга, җәмәгатьчелек тәртибен, хезмәт дисциплинасын яхшыртырга, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга, кыскасы, колхоз һәм совхозларны социаль-экономик яктан югары баскычларга күтәрешергә ярдәм итә. Партиянең район комитеты материаль һәм рухи тормышның органик рәвештә алга баруы өчен, художество иҗатының һәм, гомумән, авыл культурасының социаль-экономик үсештән аерылмавы өчен мөмкин булганнарның барысын да эшләргә омтыла. Бу уңайдан

безгә КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумында да зур бурычлар йөкләнде: «Үзешчән иҗатны үстерүгә, массаларның культура кыйммәтләреннән файдалануга даими игътибар бирергә кирәк».

Сарман. Ленин урамы.

Мин көн дә шушы урамнан эшкә барам. Әнә кемдер кичәге концертта яңгыраган яңа җырны үзалдына көйләп уза. Ничәнчедер әтәч кычкырып куя. Менә бер бала үзенең куанычын әнисенә белдерә: «Бүген бакчада концерт куябыз!..» Әнә кемдер, үзе дә сизмәстән, театрда уйныйсы роленә «кереп китте» шикелле. Менә культура бүлеге автобусы кычкыртып уза — агитбригаданың игенчеләр алдында чыгыш ясарга китеп барышы. Ачык тәрәзәләрдән дәртле җыр авазлары бөркелеп кала.

Син дә җырла, батыр егет,
Син дә җырла, матур кыз!
Матур булсын, матур булсын,
Матур булсын бу тормыш!

«Җыр төягән» автобус күздән югала. Үземнең үзешчәннәр арасында чыгыш ясаган чагымны искә төшереп, әлеге җырны авыз эченнән генә дәвам иттерәм:

Илебезнең халыклары
Матур тормыш коралар.
Тыныч булсын, тыныч булсын,
Тыныч булсын дөньялар!

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Мөнир Әһлиуллин

# ЯНЫГЫЗГА КАЙТЫР ИДЕМ!..

Брежнев шәһәреннән кузгалган автобус, сәгать ярым дигәндә, Кама Аланында төзелә торган АЭС дирекциясе янына килеп тә туктады. Карашым ике катлы бина стенасына беркетелгән зур гына рәсемгә төште: такыя кигән озын чәчле, мөлаем йөзле кыз, куш кулын алга сузып, Тынычлык символы булган ак күгәрчен очыра. Аның баш өстендә кояш балкый. Артта — атом электр станциясеннән сузылган чыбыклар, якты лампалар. Рәссам паннога тирән мәгънә салган: бу атом станциясе бары тик тынычлыкка, кеше бәхетенә генә хезмәт итәчәк! Бу теләк — атом станциясе төзүчеләренең уртак хыяллары, максатлары — тыныч, мул тормыш. Алар бу теләккә ирешү өчен, көчләрен дә, осталыкларын да кызганмыйлар.

* * *

АЭС төзү идарәсенең баш инженеры Анатолий Дмитриевич Прохоренко кабинетының ишеге һич ябылып тормый. Керүчеләр ияк кагып кына исәнләшәләр дә үзләрен борчыган мәсьәләне кузгаталар:

— Бетон заводы төзелешенә балкалар килеп җитмәде.

— Беренче объектта кран ватылды...

— ГДРдан килгән тулай торак сызымнары аңлашылмый...

Баш инженер әле телефон трубкасына үреләэ, әле сызымнарны аңлатырга керешә. Бераздан без Анатолий Дмитриевич белән АЭС төзелешендәге бүгенге хәлләр, киләчәккә планнар турында әңгәмә корып җибәрдек.

— Бүген иң мөһиме Пионер базасындагы эшләрне тәгәлләү, — диде баш инженер. — Безнең өчен иң кирәк нәрсә ул. Хәзер төп төзелешкә тотынганчы иң элек аның таянычын булдыралар. Ягъни әлеге төзелешкә кирәкле бетон заводы һәм башка объектлар салына. Анысын да буш кул белән торгызып булмый. Анысы өчен беренчел, кечерәк база ясала. Аны без Пионер базасы дип йөртәбез.

Сөйләгәндә Анатолий Дмитриевичның карашлары очкынланып-очкынланып китә. Илебезнең бик күп почмакларында электр утлары кабызуда катнашкан ул. Соңгы елларда Зәй ГРЭСы, Түбән Кама ГЭСы төзелешендә җаваплы эшләр башкарган. Атом электр станциясе төзүнең үзенчәлекләре бар: чагыштырмача кечкенә мәйданда гаять зур энергия корылмасы күтәрелә. Дөрес, илебезнең башка төбәкләрендә моңа охшаш станцияләр эшли. Әмма Татарстан АЭСы үзенең егәрлеге белән дә, төзелеше белән дә алардан аерылып тора. Шуңа да баш инженер бирегә элек бергә эшләгән иң ышанычлы төзүчеләрне дә

алып килгән. Алар турында сүз чыккач, Анатолий Дмитриевич беренче булып Әнвәр Ибраһимов бригадасын атады.

— Ул бригада кешеләрен күрми китмәгез, — диде ул. — Тынгысыз, эзләнүчән егетләр.

Бригадир Әнвәр Ибраһимов Сарман якларында туып үскән. 25 ел инде электр станцияләре сала. Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләнгән. Ләкин бу юлы бригадирның үзе белән очрашырга насыйп булмады. Күптән түгел идарәдә бригадалар ярышына йомгак ясалган. Ибраһимов бригадасы җиңүче булып чыккан. Бригадирга диңгез буена турист путевкасы биргәннәр. Ял итәргә барыргамы, юкмы дип икеләнеп торганда, хезмәттәшләре аны китәргә ризалаштыралар.

— Бар, Әнвәр, бераз дөнья күреп, ял итеп кайт. Эш өчен кайгырма, ышан безгә! — дип, озатып калганнар.

Егетләр бердәм, дус эшлиләр, инде ничәмә-ничә төзелештә нык-лыкка бергәләп сынау үттеләр алар. Бригаданы ышанып калдырырга кеше дә бар. Эретеп ябыштыру остасы Фирдәвес Галимов Әнвәр Сәләхиевичның күз алдында үсте. Ун ел буенча бергәләп күпме биналар кордылар алар. Үткән ел Брежнев шәһәренә төзүче бригадирлар әзерләү курсына кемне җибәрү турында сүз чыккач, Әнвәр, ике дә уйлап тормыйча, Фирдәвес Галимовны күрсәтте. Хәзер Фирдәвес еш кына Әнвәрне алыштыра.

Бригада членнары балалар бакчасына нигез салалар иде. Пионер базасында төзүчеләр өчен торак йортлар да, ашханә дә, культура йорты һәм балалар бакчасы да булырга тиеш. Төзелештә яшь гаиләләр көннән-көн арта. Балалар бакчасына бүген ихтыяҗ аеруча зур. Бинаның булачак нигезе янында блоклар күрү бераз гаҗәпләндерде. Тик бригадир елмайды гына.

— Бер яңалык куллана башладык бит әле, — диде ул.

Яңалык дигәннәре болай туа. Пионер базасында төзелешнең яңа башланган көннәре. Көн саен илнең төрле почмакларыннан төзүчеләр килеп тора. Вагоннарга көйләнгән ашханә көннән-көн кысанлаша, төшке аш вакытында су буе чират тезелә. Шуңа да АЭС төзү идарәсе дирекциясе тиз көндә яңа ашханә булдырырга карар бирә. Нигез салу Ибраһимов бригадасына тапшырыла. Баш инженер аңа: Мөмкин кадәр тизрәк салырга иде дип кала.

Әйтүе генә җиңел — тизрәк салырга?! Аның өчен башта такталардан форма ясарга, аңа бетон измәсе тутырырга, берничә көннән әлеге такталарны яңадан сүтеп алырга кирәк. Болар турында уйланып йөргәндә бригадирның башына бер фикер килеп төшә: «Бәлки форманы тимер-бетон блоклардан ясаргадыр? Краннар белән куясың, измә каткач, яңадан күтәрәсең». Бригада членнары да, баш инженер да бу фикерне хуплыйлар.

Яңача салу нәтиҗәсендә ул нигез гадәттәгедән ике атнага иртәрәк өлгерә, күп кенә такта янга кала, балта осталары башка төзелешләргә күчерелә. Экспертлар яңача салынган нигезнең сыйфатына яхшы бәя бирәләр.

Балалар бакчасы нигезен дә шулай салырга булганнар. Фирдәвес Галимов белән төзелеш буйлап атлыйбыз. Яшь бригадир, монтажчылар янына тукталып, эшнең сыйфатын тикшереп үтә. Тирә-якка очкыннар сиптереп, тимер-бетон плитәләрне ябыштыручы янынан үткәндә сорап куйдым:

— Нихәл, егет, буламы?

Ул исә кара күзлекле битлеген салды да, энҗедәй тезелгән тешләрен ялтыратып, елмайды. Егет дигәнем, түгәрәк йөзле чибәр кыз булып чыкты.

— Ялгыштыгыз, абый, таныш булыйк, Мәүлидә, — диде.

Ибраһимов бригадасы 17 кешедән тора, 16 ир һәм бер кыз. Мәүлидәнең бригадага эшкә килүенә бер генә ел икән. Пермь шәһәрендә эретеп-ябыштыру һөнәрен үзләштергән, йортлар салган. Туган ягында шундый зур төзелеш башлануын ишеткәч, күңеле бирегә ашкынган. Кадрлар бүлегеннән аны Ибраһимов бригадасына җибәрәләр, һәр яңа кешене кабул иткәндә генә бригада киңәшкә җыела. Монтажчыларның эше катлаулы да, хәвефле дә. Шуңа күрә Мәүлидәгә каршы чыгучылар да була. Арадан берсе:

— Эшләп күрсәтсен, нәрсәгә сәләтле икәнен күрик,— ди.

Мәүлидә аппарат янына килә. Ике панельне бергә беркетергә кушалар. Тирә-якка очкыннар чәчри. Монтажчылар кызның җитез хәрәкәтенә, тимер җөйләрнең тигезлегенә карап сокланалар. Соңгы карар бердәм була: «Алырга! Безнең кыз бу».

16 ир-егет һәм бер кыз, бергәләшеп, Татарстан АЭСы төзелешендә берсеннән-берсе җаваплы объектлар салалар, эзләнәләр, төзелешкә күп кенә яңалыклар да кертәләр. Биналарның нигезен салудагы яңалык партия Үзәк Комитетының декабрь (1983 ел) Пленумы куйган олы бурычка — хезмәт җитештерүчәнлеген планнан тыш бер процентка күтәрү, продукциянең үзкыйммәтен өстәмә рәвештә 0,5 процентка киметү бурычын хәл итүгә — аларның конкрет өлеше. Инде бу яңалыкның башка төзелешләргә дә юл алуын көтәргә кирәк.

* * *

АЭС дирекциясенең баш инженеры урынбасары Фәрхәт Фәйрушин бүлмәсенә почта генә киенгән бер кеше килеп керде.

— Рәхим Дәүләтбаев булам мин,— дип таныштырды ул үзен.— Чернобыльскидагы АЭСта эшлим. Үзем — Саба районыннан. Кунакка кайткач, күңелем түзмәде, сезне күреп китәргә булдым. Ошады. Станция өлгергәч, сезгә эшкә кайтыр идем...

Рәхим югары белемле инженер, АЭСта цех начальнигы урынбасары булып эшли икән.

— Сезнең кебек белгечләр кирәк булачак, керүегез өчен рәхмәт,— диде аңа Фәрхәт Фәйрушин.— Станциягә җиһазлар куяр көн җиткәч, хәбәр итәрбез.

Кунак саубуллашып чыгып китүгә, Фәрхәт алдыма калын гына папка китереп куйды. Ул илебезнең төрле почмакларындагы атом электр станцияләрендә эшләүчеләрдән килгән хатлар белән тулы. Аларның күбесе Татарстанда туып-үскән. Туган якларында энергетика баһадиры төзелүен ишетеп, аның кайчан файдалануга тапшырылуы турында сорашалар. «Мин сезгә кайтыр идем...» һәр хат шушы сүзләр белән тәгәлләнә.

— Без бер генә хатны да игътибарсыз калдырмыйбыз,— ди Ф. Фәйрушин.— Вакыты җиткәч, без аларны эшкә чакырачакбыз. АЭСка югары квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр бик кирәк булачак.

Татарстан АЭСының әлегә нигезе генә салынып ята. Ләкин бүген үк инде анда эшләячәк белгечләр хәзерләү турында кайгырталар. Әлбәттә, башка станцияләрдән кайтучыларга гына исәп тотмыйлар. АЭС директоры Лев Николаевич Журавлев илебезнең энергетиклар әзерләүче күп кенә институтларында булган, киләчәктә Кама буендагы станциядә эшләргә теләүче егет-кызлар белән сөйләшкән. Хәзер СССР Югары һәм махсус урта белем министрлыгының тиешле бүлекләре белән аларны илебезнең атом электр станцияләренә тәҗрибә тупларга җибәрү мәсьәләсе хәл ителә. Кама политехника институтында

махсус факультет, АЭСның профессиональ-техник училищесын ачу турында да сөйләшүләр алып барыла.

Әлегә исә Кама Аланына төзүчеләр хуҗа. Хатлар да күбрәк төзүчеләрдән килә. Шул хатлар артыннан, чемоданнарын күтәреп, яшь егетләр һәм кызлар, инде тормышның әчесен-төчесен татыган өлкәнрәкләр дә бирегә кайтып төшәләр. Татьяна һәм Сергей Титаренколарның, уллары Денисны ияртеп, Волгоград өлкәсеннән АЭС төзелешенә килүләренә әле күптән түгел. Яшь гаиләне биредә үз иткәннәр. Монтажчы Сергей берсеннән-берсе матур йортлар сала. Татьяна төзүчеләргә тәмле ашлар пешерә. Күптән түгел бу гаилә тормышында шатлыклы вакыйга булды. Ул көнне Сергей биш катлы өйнең өченче катында тимер-бетон плиталәр беркетә иде. Ак халатлы медсестра кызның ашыга-ашыга баскычтан менүен күреп, Сергей аның каршысына йөгерде.

— Кем? Кызмы, улмы?

— Икесе дә, Сергей. Котлыйм, игезләр...

Хезмәттәшләре, Сергейны күтәреп алып, һавага чөйделәр. АЭСта игезәкләр туу хәбәре сәгате-минуты белән поселокка таралды. Кичен 12 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы Рәис Сәләхов бүлмәсендә профком утырышы була. Яшь гаиләгә ике бүлмәле квартирага ордер языла. Сергей бәләкәйләрне яңа квартирада каршы ала...

Титаренколарның «куллары җиңел» диләр. Күптән түгел поселокта Симоновлар гаиләсендә дә игезәк балалар туа. Хәзер биш, тугыз катлы өйләргә байый баручы Кама Аланы урамнары балаларның чыр-чуыннан гөрләп тора.

— Берничә ел элек безнең авылда елына 2—3 бала туа иде,— ди фельдшер-акушер Анна Калмакова.— Мин монда утыз ел эшләдем. Инде кирәгем калмады, пенсиягә китәрмен, дип уйлап тора идем. Станция төзелә башлагач, кабат эш артты. Үткән ел гына бездә илленләп бала туды.

Биредә утыз елдан артык укытучы булып эшләгән мәктәп директоры Алексей Зиминга да пенсиягә китүне кичектерергә туры килгән. Авылда халык кимегәч, сигезьеллык мәктәптә нибары утызлап бала кала. Инде мәктәпне ябаргамы, юкмы дип йөргәндә, мәктәп коридорлары яңадан балаларның шат авазлары белән тула. Төзүчеләр, ике ай дигәндә, яңа мәктәп салып бирәләр. Быел сентябрьдә балалар саны ике йөзләп булачак. Поселокта мең ярым укучыга исәпләнгән яңа мәктәп салына.

АЭС төзелешендә хезмәт кешесе турында аталарча кайгырту сизелеп тора, ул дәртләнеп эшләсен, рәхәт ял итсен өчен, бөтен шартларны тудырырга тырышалар. Төзүчеләр һәм энергетиклар яши торган поселокка гына күз салыйк. Анда берсеннән-берсе матур, бөтен уңайлыклары булган биш, тугыз катлы йортлар тезелеп киткән. Хәзер ел саен 20 мең квадрат метрдан артык торак төзелә. Дөрес, әлегә һәр кешегә бөтен уңайлыклары булган квартира җиткереп булмый, ә менә гомуми торакка — рәхим ит! ГДРдан кайтарылган җыелма бу биналар яшәү өчен бөтен кирәк-яраклары белән җиһазландырылган; йомшак кәнәфиләр, карават һәм өстәлләр, лампалар, аш-су пешерү әйберләре — бары да бар. Монтажчы егетләр тулай торакны атна-ун көн эчендә торгызып куялар. Рәхәтләнеп яшә! Энергетиклар поселогында бер катлы — 5, ике катлы 4 шундый җыелма торак салынып ята. Аларда 500 дән артык егет һәм кыз яшәячәк. Хәзер инде әлеге торакларның берничәсе файдалануга тапшырылган. Брежнев шәһәрендәге йортлар төзү комбинатының профсоюз оешмасы председателе урынбасары Рафаэль Сөләйманов әлеге гомуми торак биналарын зур бер горурлану белән таныштыра. Киң, иркен бүлмәләрдә ике-өч

кеше тора. Стеналарда матур обойлар, идәннәрендә төсле ленолиум, йомшак паласлар. Һәр җирдә пөхтәлек, әйтерсең лә, санаторий бүлмәләре.

— Кызлар, ничек яшисез? Дәгъваларыгыз юкмы?— диде төзү-монтаж идарәсе начальнигы Рәис Сәләхов.

— Барысы да әйбәт. Тик менә душ белән кер юу бүлмәсе дә булса икән!..

— Борчылмагыз, озакламый мунча өлгертәбез. Анда кер юу бүлмәсе дә булачак,— диде ул.— Шулай да вакытлыча берәр җаен табарга кирәктер.

Идарәдә уйландылар да, яңа өлгерткән йорттан ике бүлмәле квартираның берсен, гомуми торакта яшәүчеләр өчен, вакытлыча душ һәм кер юу бүлмәсе итеп файдаланырга булдылар.

АЭС төзүчеләре өчен фельдшер-акушерлык пункты салынган. Врачлар О. Образцов, Г. Баһавиева һәм Р. Ситдыйков төзүчеләргә ярдәм күрсәтергә әзер. Түбән Кама район больницасы ашыгыч медицина ярдәме күрсәтергә алынган.

Болар барысы да — кеше һәм аның ихтыяҗлары турында кайгыртуның матур үрнәкләре. Ә менә республиканың Халыкара көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм Сәүдә министрлыклары АЭС төзүчеләре турында онытып җибәргәннәр диясе килә. Поселокта көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты юк. Кием тегү, аяк киемнәре ремонтлау, хәтта чәч алдыру проблемага әйләнгән. Кызлар, зарланып:

— Берәр бәйрәм булса, чәчне рәтләтер өчен, 80-90 чакрымдагы Брежнев, я булмаса Түбән Кама шәһәренә барабыз.

Кайчандыр Кама Аланы кешеләре өчен генә салынган азык-төлек кибете дә бүгенге төзүчеләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый. Әле анысының шүрлекләре дә яртылаш буш. Поселокта яңа, зур кибет ачып җибәрергә бик вакыт.

Дөрес, АЭС төзүчеләр тормыштагы бу кыенлыклар, вакытлы авырлыклар алдында аптырап кала торганнардан түгел. Эштәге отыш хакына, берни белән дә исәпләшми торган энтузиастлар яши монда. Тормыш булгач, төрлесе килеп чыга икән. Төзү-монтаж идарәсе начальнигы Рәис Сәләхов шундыйларның берсен иskә төшереп алды.

...Яңгырлы, шыксыз ноябрь төнендә була бу. Поселокны шомлы кызыл шәфәкъ урап ала. Кешеләр урамга йөгереп чыгалар.

— Янгын, янгын! Ашханә яна!..

Бер гамьсезе тәмәке төпчеген төшереп калдырган да такталардан гына ясалган ашханәгә ут капкан. Бер сәгать дигәндә, кара күмер өеме генә торып кала. Бу — шимбә көнгә каршы була. Дүшәмбе көнне йөзләгән төзүче эшкә киләчәк. Аларны кая тукландырырга! Менә шул турыда баш вата Рәис. Дөрес, буш вагоннар бар барын. Ләкин алардан ике көн эчендә ничек ашханә эшләп өлгертәсең? Төзүчеләре дә юк бит әле. Бәлки бөтен поселок халкы белән өмә үткәрергәдер? Рәис Сәләхов шундый нык карарга килеп өйдән-өйгә кереп, өмәгә кешеләр чакыра. Поселокта яшәүчеләр, ял көненә планлаштырылган эшләрен калдырып, кулларына балта, чүкеч тоталар. Ике көн, ике төн буена ашханә төзелешендә балта тавышлары яңгырап тора. Ә инде дүшәмбенең төшендә төзүчеләрне яңа ашханәдәге тәмле сый көтеп ала.

* * *

АЭС төзелеше, андагы фидакарь кешеләр белән саубуллашканда күз карашым дирекция бинасына эленгән рәсемгә кабат төште. Башына такыя кигән кыз миңа тагын да мөлаемрак, зәңгәр күктәге кояш тагын да яктырак, җылырак тоелды.

Нур Гыйззәтуллин

# ӘДӘБИ ОЕШМАЛАРДАН — БЕРДӘМ СОЮЗГА

Октябрь революциясенең беренче көннәреннән ук Совет хөкүмәте культура мәсьәләләренә гаять зур игътибар бирде. 1917 елның 9 ноябрендә Халык Комиссарлары Советы «Матбугат турында» декрет чыгарды, ә 29 декабрьда Дәүләт нәшрияты оештырылды. В. И. Ленинның «Безнең газеталарның характеры турында»гы һәм башка мәкаләләрендә, чыгышларында, М. Горькийга, А. Серафимовичка язган хатларында бөтен культура эшләрен халыкка якынайту, сәнгать һәм фәнне халыкның революцион көрәше ихтыяҗларына буйсындыру мәсьәләләре куелды. Культура революциясе социалистик революциянең аерылгысыз өлеше икәнлеге ачык белдерелде.

Революция барлык әдипләр алдына яңа әдәбиятның эчтәлеге, аның характеры, милли һәм интернациональ үзенчәлекләре ничек булырга тиешлекне ачыклау бурычын куйды.

Үткәннең культура мирасына мөнәсәбәт һәм яңа җәмгыятьнең культурасы турындагы сорауларга да ачык җаваплар бирү кирәк иде. Тарих тарафыннан дөреслеге расланган ул җавапларны В. И. Ленин бирде. 1920 елның 2 октябрендә Россия коммунистик яшьләр союзының III Бөтенроссия съездында сөйләгән речендә ул болай дип белдерде: «Пролетариат культурасы капиталистик җәмгыятьнең, алпавытлар җәмгыятенең, чиновниклар җәмгыятенең изүе астында кешелек дөньясы барлыкка китергән белем запасларының закончалыклы үсеше булырга тиеш... Кешелек дөньясы тудырган барлык белем байлыклары белән зиһенеңне баетканда гына коммунист булырга мөмкин» [1].

Берничә генә көн үтә, һәм В. И. Ленин 8 октябрьда «Пролетариат культурасы турында» дигән резолюция проектында бу культураның төп эчтәлеген һәм рухын билгели: «Совет эшче-крестьян республикасында мәгариф эшенең бөтен куелышы, гомумән политик агарту өлкәсендә дә, шулай ук махсус сәнгать өлкәсендә дә, пролетариат диктатурасының максатларын уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен, ягъни буржуазияне бәреп төшерү өчен, сыйныфларны бетерү өчен, кешенең кешене һәртөрле эксплуатацияләвен бетерү өчен, пролетариатның сыйнфый көрәш рухы белән сугарылган булырга тиеш» [2].

Гаять авыр еллар. Илнең экономик-политик тормышында гына түгел, культура өлкәсендә дә катлаулы проблемаларны хәл итәргә кирәк иде. Шундый мәсьәләләрнең берсе — пролеткультка карата мөнәсәбәтне ачыклау булды.

В. И. Ленин һәм партия Үзәк Комитеты пролеткульт мәсьәләсенә зур игътибар бирәләр. 1920 елның октябрь аенда гына да бу мәсьәлә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы утырышларында өч тапкыр тикшерелә. Шул ук елның ноябрендә Үзәк Комитет Пленумында В. И. Ленин язган резолюция проекты бер үзгәрешсез диярлек кабул ителә һәм 1920 елның 1 декабрендә РКП(б) Үзәк Комитеты «Правда» газетасында «Пролеткультлар турында» хат игълан итә.

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 31 том, 283 б.
[2] Шунда ук, 314 б.

Партия Үзәк Комитетының бу хатында, пролеткультның социалистик культура төзелешендәге тупас ялгышларына бәя бирелү белән бергә, культура өлкәсендәге бурычларның гомумхалык мәнфәгатьләре, революция белән аерылгысыз бәйләнештә булуы да билгеләнде. Пролеткульт Халык Мәгариф Комиссариатына керде. 1920 елда Мәскәү пролеткультында «Кузница» исемендә группа да оеша, аңа Ф. Гладков, А. Новиков-Прибой, Н. Ляшко, В. Бахметьев һәм башка язучылар керә. Бу группа «коммунистик җәмгыять төзү өчен көрәшнең, яңа кешене хезмәт процессында сурәтләү, әсәрләрнең сәнгатьчә сыйфатын күтәрүнең төгәлрәк бурычларын билгели. Ләкин әле барыбер классик мираска кимсетеп карау, абстракт символизм белән мавыгу кебек кимчелекләрдән арынып җитә алмый.

Егерменче елларның беренче яртысында рус әдәбиятында башка группалар да барлыкка килгән иде («Серапион туганнар», Крестьян язучыларының Бөтенроссия җәмгыяте, «Октябрь», «Яшь гвардия», «Сәнгатьнең сул фронты» — ЛЕФ, «Конструктивистларның әдәби үзәге», «Перевал», Пролетариат язучыларының Россия ассоциациясе һ. б.) Бу группа һәм оешмаларның әдәби процесска ясаган йогынтылары, культура үсешендәге рольләре төрлечә булды. Алар арасында фикер каршылыклары, иҗат практикаларында үзгәлекләр бар иде. Шуның өчен аларның барысын да әдәби процессның реаль каршылыкларын тигезләүче бердәм агым дип карау дөрес булмас. Иң әһәмиятлесе — бу группалар яңа культура, яңа тормыш төзү эшендә үз юлларын табарга омтылган язучыларны берләштерә иде.

Менә шул шартларда совет платформасында торып иҗат иткән бөтен язучы һәм шагыйрьләрне бердәм оешмага туплау идеясе егерменче еллар башында ук күтәрелә. Ләкин аны тормышка ашыру шактый зур авырлыклар белән бара.

РКП(б) Үзәк Комитетының «Матур әдәбият өлкәсендә партиянең политикасы турында» 1925 ел 18 июнь резолюциясендә егерменче еллар уртасындагы әдәбият үсешенең каршылыклы якларына да игътибар бирелде. Бу резолюциядә «сәнгатьнең һәм шул җөмләдән әдәбиятның сыйнфыйлык табигате... чиксез күп төрле формаларда гәүдәләнсә дә, сыйнфый җәмгыятьтә нейтраль (битараф) сәнгать юк һәм була да алмый» дип билгеләнде һәм шуның белән В. И. Ленинның әдәбиятның партиялелеге турындагы мәгълүм тезисы кабат белдерелде. Резолюциядә партиянең матур әдәбият өлкәсендәге политикасы, пролетариат һәм крестьян язучыларына, «юлаучылар» дип йөртелгән язучылар һәм башкалар арасындагы мөнәсәбәтләр ничек булырга тиешлеге ачык күрсәтелде.

Бу резолюциядә яңа художество культурасына җитәкчелек итүнең партиячел принциплары чагылды, культура өлкәсендә эшләүче интеллигенция, бигрәк тә язучылар белән яңа шартларда ленинчыл җитәкчелек итү мәсьәләләре ачыкланды. Әдәбият һәм сәнгатьнең сыйнфый характерда булуы һәм гомум-пролетар эшнең бер өлеше икәнлеге кабат билгеләнде.

Илебезнең башкаласы Мәскәүдә барлыкка килеп, соңрак төрле төбәкләргә таралган бу яңалыклар татар культура тормышының үзәгенә әверелгән Казанга да тәэсир итми калмады. Монда иҗтимагый-политик һәм культура тор ышындагы уртак объектив моментлар белән бергә, кайбер субъектив сәбәпләрне дә искә алырга кирәк.

Бу елларда татар культура эшлеклеләре, язучылары һәм шагыйрьләре, журналистлар Мәскәү белән нык бәйләнеш урнаштыралар. Алар дәүләт оешмаларында, газета-журнал редакцияләрендә эшлиләр, Мәскәүдәге әдәби хәрәкәткә дә катнаша башлыйлар. Г. Ибраһимов, М. Вахитов белән бергә, Милләтләр халык комиссариаты карамагындагы Мөселман комиссариатын оештыруга катнаша. М. Җәлил егерменче елларда ВЛКСМ Үзәк Комитеты татар-башкорт секциясенең бюро члены һәм «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларының редакторы булып эшли. Егерменче еллар башында К. Нәҗми Мәскәүдә Югары хәрби-педагогик мәктәптә укый. Г. Нигъмәти 1921 елда Мәскәүгә килә һәм, Көнчыгыш хезмәт ияләре Коммунистик университетының бер еллык курсын тәмамлагач, шушы ук университетта татар әдәбияты турында лекцияләр укый. 1923 елда ул Мәскәү журналистлар институтында

белем ала һәм 1923—1926 елларда партия Үзәк Комитетының матбугат бүлегендә эшли һ. б.

Соңыннан барысы да диярлек Казанга кайткан бу язучылар бик табигый, татар әдәби хәрәкәтенең җанланып китүендә, яңа әдәби түгәрәкләр һәм оешмалар төзеп җибәрүдә актив роль уйныйлар.

Шул вакытларны искә төшереп, шактый еллар үткәч — 1956 елда К. Нәҗми болай дип язды: «Октябрь революциясе миллионнарның иҗат энергиясен ачып җибәрде һәм илебездәге барлык халыкларның әдәбиятлары үсешенә этәргеч көч бирде дип әйтәбез икән, бу хакыйкатьне теге яки бу әдипне бәяләү белән генә түгел, бәлки аларның иҗат оешмаларына да дөрес характеристика бирү ярдәмендә дәлилләргә кирәк. Октябрь революциясенә кадәр татар язучыларының үз әсәрләрен, иҗат проблемаларын тикшерерлек аз санлы коллективы да юк иде. Ул гына да түгел, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал кебек язучылар да беренче тапкыр совет чорында гына Казан шәһәрендә очраштылар. Ә бит менә шундый очрашулар, бергәләп иҗтимагый-политик эш алып бару өчен уңай шартларны, беренче әдәби түгәрәкләрне: «Завод»— 1923 ел (миңа да аны оештыручыларның берсе булырга туры килде), «Часовой» (Шамил Усманов тарафыннан 1923 елда оештырылды), «Октябрь» (1924 елның башында Казан шәһәре коммунистларының Үзәк клубы каршында оештырылды) тудырдылар...»[1]

Татар совет язучыларының иң зур күпчелеген үзенә туплаган беренче зур оешма — «Октябрь» түгәрәгенең әдәбияттагы төп юлы аның декларациясендә ачык билгеләнде.

1924 елның 15 февралендә «Безнең байрак» газетасында «Татар инкыйлаби эшче-крестьян язучыларының «Октябрь» түгәрәгеннән урыннардагы шагыйрь, әдип, мөхәррирләргә, әдәбият мөхиплеренә, түгәрәк һәм башка оешмаларга ачык хат»ы игълан ителә. Бу хатта: «Без — Казандагы инкыйлаби әдип-шагыйрьләр, киләчәктә әдәби хәрәкәтләрнең киңәюе, үсүе, баюы, ныгуы юлында иң зур җитешсезлекләрдән булган таркаулыкны бетереп, Казандагы бөтен инкыйлаби-советчы татар әдип-шагыйрьләренең «Октябрь» исемендәге гомуми түгәрәкләрен оештырырга карар бирдек һәм шуның гамәли адымнарын атладык»,— дип белдерелә. Түгәрәкнең төп бурычлары дип «социализм өчен хезмәт... буржуазия, мещанлык, милләтчелек, динчелек идеологиясенә каршы көрәшү», «әдәбиятта революцион позицияләрдә торып күзәтчелек» итү һ. б. алына.

Бу хатка «Октябрь» түгәрәген оештыручылар: шагыйрь Фәтхи Бурнаш, язучы Шамил Усманов, шагыйрь Кави Нәҗми, язучы Ф. Әсгать, шагыйрь Г. Кутуй кул куялар.

«Октябрь» татар совет язучыларын бер оешмага туплауда шактый эш башкара. Түгәрәк коллективы даими рәвештә «Иптәш» исемле стена газетасы чыгарып килә, газета һәм журнал битләрендә күп кенә әсәрләр бастыра. Бөек юлбашчы истәлегенә багышланган «Ленин» исемле җыентык, «Кызыл Армия сафында татар-башкортлар» дигән альбом-җыентык чыгара, буржуаз милләтчелек күренешләренә каршы көрәш алып бара. Ләкин бу оешма үзенең оештыру принциплары белән байтак кына татар совет язучыларын читтә калдыра. Әдәби мираска мөнәсәбәт мәсьәләләрендә дә бу түгәрәкнең пролеткультлык рухындагы ялгышлары була.

1924 елда «Октябрь» түгәрәге членнарының бер өлеше Г. Кутуй һәм Г. Толымбай җитәкчелегендә «Сулф» (Сул фронт) исемле яңа түгәрәк төзиләр һәм «Октябрь»дән аерылып чыгалар. Шул уңай белән 1924 елның 20 апрелендә «Октябрь» членнарының гомуми җыелышы бертавыштан кабул иткән карарында: «Сулф», футуризм агымнарын гына пролетариатныкы санап, кастовый оешмага әверелсә, «Октябрь» түгәрәге үзенең идеологиясе белән дә, әдәби-иҗат эшләренең тирәнәя баруы белән дә буржуазия идеологиясенә каршы көрәшнең нык оешкан отряды булачак»,— дип белдерелә. 1924 елның 22 июнендә үткәрелгән җыелышта бу мәсьәлә кабат тикшерелә, «коммунистлар партиясе членнарының төрле әдәби түгәрәкләрдә эшләвенең зарарлы булуын искә алып», сулфчыларга «Октябрь» түгәрәгенә кайтырга тәкъдим ителә. «Сулф» озакламый тарала һәм аның күпчелек өлеше кабат «Октябрь»га кушыла.

---

[1] Нәҗми К. Әдәбият дөньясында. Казан, 1976, 158 б.

Бу ике күмәк эшчәнлегендә совет әдәбиятының үсеш юллары турында хаталар һәм каршылыклар булса да, алар буржуаз милләтчелек күренешләренә, мещанлыкка кискен рәвештә каршы чыгулары белән күп кенә уртак сыйфатларга ия иделәр.

Беренче әдәби түгәрәкләр, шулай ук «Октябрь» һәм «Сулф» күмәкләре дә озын гомерле булмадылар. Аларның эшчәнлегендә зур каршылыклар бар иде. Аларның ялгышларыннан берсе — «юлаучылар» дип йөртелгән язучыларга карата мөнәсәбәттә күренде. Бу мөнәсәбәт Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларыннан соң күтәрелеп чыккан зур төркем яшь язучыларны татар демократик әдәбияты вәкилләренә, классик традицияләрне дәвам иттерүчеләргә каршы куюга, «яңа», «пролетар» сәнгать һәм әдәбият тудыру өчен көрәшүчеләрне генә алгы планга күчерүгә китерә. Ләкин мондый хәлләр әдәбиятның төп үсеш сызыкларын билгели алмадылар.

Менә шушы шартларда совет платформасында торучы барлык татар язучыларын бердәм әдәби оешмага берләштерү фикере һаман реаль төс ала.

Татар совет язучыларын бер оешмага туплау һәм аларның әдәби осталыгын үстерү мәсьәләләре бу еллардагы көндәлек матбугатта, журналларда да еш күтәрелә. Күп кенә мәкаләләрдә укучылар составының үзгәрүе, аның киң массага әверелә баруы әйтелә. Шушы шартларда әдәби иҗат эшен дә яңа юлга күчерү кирәклеге һаман ачыклана бара.

Г. Нигъмәтинең 1926 елда басылып чыккан «Матур әдәбиятыбыз тирәсендә» исемле мәкаләсендә бу мәсьәлә кабат күтәрелде. Татар әдәбияты алдында торган аерым бурычларны билгеләп үткәннән соң, автор язучыларның яңа оешмасын төзү мәсьәләсенә күчә: «Бу оешма совет язучылары оешмасы исемендә төзелеп, анда җитәрлек пролетариат ядрәсе тәэмин ителсен... Бу оешма безнең искедәге түгәрәкләрнең күпләре эшләгәнчә: «Иске заман язучыларын яңа заман корабыннан алып ташларга кирәк» дигән лозунгларны куймасыннар, аны башларыннан чыгарсыннар. Бу оешмага совет платформасында торган, үзен социализм иленең бер әгъзасы итеп хис кылган, шуңар күрә дә социализм мәдәнияте төзешүгә катнашуны үзенә бурыч итеп алган һәрбер язучы кертелергә тиеш»[1].

Г. Ибраһимов та бөтен татар язучыларын (билгеле — совет платформасында торучы язучыларны) бер оешмага туплау идеясе белән нык кызыксына. Аның төп омтылышы — татар телендә иҗат итүче барлык революцион иҗат көчләрен бер йодрык итеп туплау, аларның бөтен иҗатын бер максатка — Советлар властен ныгытуга юнәлтү, матур әдәбиятны социалистик революция эшенә хезмәт итүгә юнәлтү иде. 1927 елның 30 гыйнварында ул «Кызыл Татарстан» газетасында «Татар әдәбияты җәмгыяте» дигән мәкаләсендә әдәби оешма төзү һәм аның төп принциплары турында язып чыга. Шушы максатны тормышка ашыру юлындагы башка практик адымнар белән бергә, Г. Ибраһимов 1927 ел башында ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитетына хат белән мөрәҗәгать итә[2].

Татар әдәбияты җәмгыятен төзү мәсьәләсе буенча 1927 елның 9 февралендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты матбугат бүлегендә киңәшмә үткәрелә. һәм анда язучылар оешмасын төзү турында тиешле карар хәзерләү буенча комиссия төзелә һәм бу комиссия составына Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, Г. Толымбай, Г. Нигъмәти кертелә.

Менә шул рәвешчә, соңыннан безнең әдәбият тарихында «Татар совет язучылары җәмгыяте» дип исем алган оешмага нигез салына. Ләкин 1927 елның мартында Г. Ибраһимовның каты авыруы һәм шул ук елның апрелендә Кырымның Ялта шәһәренә озак вакытларга дәваланырга китүе һәм башка оештыру мәсьәләләре белән бәйле хәлдә, бу оешманың официаль төс алуы бераз соңгарак кала.

1927 елның август аенда Г. Гали: «Оешма татар язучыларыныкы гына булып түгел, Татарстан язучыларыныкы булып төзелә. Димәк, анда рус язучылары да, башкалар да керәчәкләр»[3],— дип белдерә һәм шуның белән бу оешма эшендәге яңа милли момент билгеләнеп үтелә. Оешманың төп бурычлары — язучыларның профес-

---

[1] Нигъмәти Г. Матур әдәбиятыбыз тирәсендә. — «Безнең юл», 1926, 11—12 сан.
[2] Татарстан партия архивы, ф. 15, эш 465, 55 б.
[3] Галиев Гомәр. Оешу алдыннан.— «Безнең юл», 1927, 8 сан.

сиональ осталыгын күтәрү, марксистик позицияләрдән торып әдәбиятка җитәкчелек итү, буржуаз милләтчелек идеологиясенә каршы көрәшү дип билгеләнә.

1928 елда төзелгән ике оешма: Татар совет язучылары оешмасы һәм Татар пролетариат язучылары ассоциациясе шактый уңай роль башкаралар. Ләкин әле боларның эшчәнлегендә кимчелекләр дә шактый күренә. «Ике оешма арасында язучыларны бүлешү, боларның һәркайсында күренгән түгәрәкчелек, ТАППның ялгыз пролетариат язучыларын гына тәрбия итүне максат тотып та, совет язучылары күпчелеген үзеннән читкә тибәрүе, иҗат методы мәсьәләләрендә ялгыш положениеләр күтәреп чыгу (диалектик материализм методы), язучыларның метод мәсьәләләрендә эзләну юлларын чикләү (Демьянлаштыру лозунгысы)— совет әдәбияты үсешенә нык комачаулык иттеләр»[1].

Бераз вакытлардан соң ТАПП һәм Совет язучылары оешмасы күп кенә мәсьәләләрне бергәләп хәл итә башлыйлар, формаль яктан ике оешма булып исәпләнсәләр дә, принципиаль мәсьәләләрдә уртак позицияләргә басалар.

«Яңалиф» журналы да (ул 1926 елның февралендә «Яңалиф» җәмгыяте органы булып чыга башлаган иде) Совет язучылары оешмасы органына әверелә һәм «Айлык әдәбият, сәнгать, художество, экономика һәм тәнкыйть журналы» буларак «Татарстан халык агарту (мәгариф) комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасы органы» дип атала. Редакторы — Ф. Сәйфи-Казанлы, редколлегия членнары — Г. Нигъмәти, И. Рәхмәтуллин, З. Гали, И. Рәми була. Зур форматта, күп санлы иллюстрацияләр белән чыгарылып килгән бу журналда илнең политик һәм экономик тормышыннан төрле материаллар, чит ил хәбәрләре, Кызыл Армия тормышы күренешләре, Татарстан халык хуҗалыгындагы яңалыклар белән бергә, күп санлы шигырьләр һәм хикәяләр, очерклар, тәнкыйть мәкаләләре, татар әдәбияты тарихына караган төрле материаллар урнаштырыла.

1931 елның 26 декабрендә Татар совет язучылары оешмасының гомуми җыелышында яңа җитәкчелек сайлана. Идарә составына Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, А. Шамов, Х. Хисмәтуллин, Ә. Мәҗитов член булып, М. Гали һәм М. Парсин — членлыкка кандидат итеп кертеләләр. Оешма идарәсенең председателе — Г. Нигъмәти, секретаре — А. Шамов була. Шушы ук җыелышта Казандагы завод-фабрикалар янындагы әдәбият түгәрәкләренә җитәкчелек итү өчен ТАПП белән берләшеп аерым бригадалар төзелә[2].

Егерменче еллар ахырында Крестьян язучылары оешмасы да яшәп килә. Берничә ел дәвамында ТатЛОКАФ яши.

Ләкин утызынчы еллар башында инде илдә язучыларның төрле группалары һәм оешмалары яшәве кирәксезгә әйләнде. Чөнки алар бу вакытта тормышның һәм шулай ук әдәбиятның алга үсүе өчен кирәк булган таләпләренә җавап бирә алмыйлар иде. Шулай ук иске оештыру формаларының кимчелекләре дә ачык күренде. РАППның аерым җитәкчеләренең үз шәхси карашларын бөтен әдәбиятка тагарга омтылулары белән дә килешеп булмый иде. Мондый кимчелекләр ТАПП эшчәнлегендә дә күренде.

Вульгар-социологик карашлардан чыгып, ТАПП җитәкчелеге аерым өлкән буын язучыларны «юлаучылар» дип атады. Кайберәүләргә «либераль буржуа язучылары», «вак буржуа язучылары» дигән бәя тагылды.

Мондый күренешләр, билгеле, республикадагы әдәби көчләрнең берләшүенә зарар итәләр һәм аларның игътибарын әдәби иҗат эшеннән мәгънәсез бәхәсләргә юнәлтәләр иде. һәм шуның өчен дә 1930 елның августында ТАПП членнарының Казан шәһәре күләмендә үткәрелгән гомуми җыелышы үзенең карарында ТАПП җитәкчелеге татар язучыларының төп өлешеннән аерылуын бик дөрес күрсәтеп үтә.

ТАПП җитәкчелеге тарафыннан: «Производство ударникларын — әдәбиятка!» дигән чакыру-лозунг та яшь әдәби көчләрнең үсүенә нык ярдәм итмәде. Чөнки бик күп авыл һәм эшче хәбәрчеләрен язучылар дип игълан итү язучының художник буларак талантын инкяр итүгә китерә иде.

Болар һәм тагын башка бик күп фактлар язучыларны оештыру формаларының

---

[1] Нигъмәти Г. Социалистик реконструкция чорында татар совет матур әдәбияты.— «Совет әдәбияты», 1934, 7 сан, 109 б.
[2] «Яңалиф», 1931, 12 сан, 76 б.

инде искергәнлегән һәм аларның татар совет әдәбияты үсешенә комачаулавын ачык күрсәтте.

Мондый характердагы хәлләр башка әдәбиятларда да бар иде.

Язучылар оешмасының яңа формасын эзләү, аларны бердәм совет платформасы нигезендә берләштерү әдәбиятларның үзләренең эчке үсеш процессы һәм илнең иҗтимагый-политик тормышы таләпләре белән көн тәртибендә беренче планга күчте.



1932 елның 23 апрелендә ВКП(б) Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» карар кабул итте. Бу карарда социализм төзелешенең зур уңышлары нигезендә әдәбият һәм сәнгатьнең сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да зур үсешкә ирешүләре билгеләнеп үтелде. Бу карар әдәбиятның идея ягыннан үсүен билгеләде, бер язучылар группасының икенче группалар өстеннән җитәкчелек итәргә омтылуларына отпор бирде һәм шуның белән әдәби хәрәкәт атмосферасын чистартты. Карар буенча социалистик төзелешкә актив катнашырга теләүче барлык язучыларны совет язучыларының бердәм союзына берләштерергә тәкъдим ителде.

ВКП(б) Үзәк Комитеты карары игълан ителгәч, татар язучыларының гомуми җыелышы уздырыла һәм бу җыелыш шундый нәтиҗәгә килә: «ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм Өлкә Комитетының «Әдәбият-художество оешмаларын үзгәртеп кору турында»гы карарларын тормышка ашыру теләге белән совет язучыларының Татарстан күләмендәге беренче конференциясен чакыру һәм әдәбият хәрәкәте белән җитәкчелек итү өчен түбәндәге составта оештыру комитеты төзергә: Г. Нигъмәти (председатель), З. Гали (председатель урынбасары), М. Әмир (секретарь), И. Гази, К. Нәҗми, Мөслимова, Шапошников, Зернит, Имаметдинов, Г. Гали, Г. Иделле, Ш. Камал, Быков.

«Атака», «Яңалиф» журналларын чыгаруны дәвам иттереп, аларны Татарстан совет язучылары союзының органнарына әйләндерергә, шуңа туры китереп, аларның характерларын үзгәртергә: «Атака»ны — массовый популяр художество-тәнкыйть журналына, «Яңалиф»не — художество-сәяси әдәбият һәм сәнгать теориясенең төп проблемаларын эченә алган журналга әйләндерергә һәм исемнәрен үзгәртергә».

ТАПП кушуы буенча кул куялар: З. Гали, К. Нәҗми, И. Гази, М. Садри, Лядин, Дмитриев. ЛОКАФ кушуы буенча: К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Иделле, Х. Әһли, С. Гыйлфан. Совет язучылары җәмгыяте кушуы буенча: Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи, Х. Кәрим, Хисмәтуллин, Тинчурин. Колхоз-пролетар язучылары оешмасы кушуы буенча: Имаметдинов, Рәфиков, Г. Галиев, Ш. Рәмзи, Ә. Хәбиб» [1].

1932 елның ахырында «Атака» һәм «Яңалиф» журналлары бетерелеп, Татарстан совет язучылары союзын оештыру комитеты органы буларак, 1933 елның гыйнвареннан «Совет әдәбияты» исемендә «айлык әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть» журналы чыга башлый.

Совет язучылары съездына хәзерлек айларында татар язучыларының башка тугандаш республикалар язучылары белән иҗат бәйләнешләре дә көчәеп китә. 1932 елның августында Казанга таҗик язучылары һәм журналистларыннан бер төркем килә һәм алар татар әдәбиятының торышы белән танышалар. 1933 елда Казанга рус совет язучысы Л. Сейфуллина килә һәм татар язучылары белән берничә тапкыр очраша. Шәһәрдәге әдәбият түгәрәкләренә катнашучыларның гомуми җыелышында ул әдәби осталык турында доклад ясый, һәм бу доклад татар матбугатында басылып чыга [2].

Язучылар съездына хәзерлек уңае белән, 1934 елның март башында Казанда СССР Язучылар союзын Оештыру комитетының бригадасы эшли. Аның составында В. Киршон, А. Новиков-Прибой, Ю. Олеша, И. Ильф, Е. Петров, С. Кирьянов һәм берничә татар язучысы була. Оештыру комитетының шул ук елда Мәскәүдә 7—11 март көннәрендә үткәрелгән III Пленумында татар әдәбияты һәм съездга хәзерлек турында К. Нәҗми, В. Киршон, С. Кирьянов һәм башка язучылар чыгыш ясый.

1934 елның 25—29 июль көннәрендә Казанда Совет язучыларының Беренче Бөтен Татарстан съезды үткәрелә. Киң совет җәмәгатьчелеге катнашы белән үткән

---

[1] «Атака», 1932, 7 сан, 7 б.
[2] Сейфуллина Л. Мин ничек язам.— «Совет әдәбияты», 1933, 3—4 сан 65 б.

бу съезд, татар совет әдәбиятының үсешенә йомгак ясау белән бергә, язучыларның иҗат активлыгын күтәрү, яшь язучы кадрлар тәрбияләү, социализм эпохасына тиң булырлык әсәрләр тудыру мәсьәләләрен тикшерә, татар совет әдәбиятының үсү перспективаларын билгели. Съездда татар совет әдәбияты, аның аерым жанрлары турында докладлар белән Г. Ризванов, Г. Гали, Г. Нигъмәти, Р. Ишморат, К. Тинчурин, Ф. Кәрим чыгыш ясыйлар. Докладлар буенча фикер алышуларда күп кенә язучылар, җәмәгать оешмаларыннан, Кызыл Армия частьларыннан, промышленность предприятиеләреннән һәм колхозлардан вәкилләр катнаша.

«Татар совет әдәбияты социалистик төзелешнең бөек пафосы белән сугарылган әсәрләр тудыру чорына керде» дигән фикер барлык докладларда һәм чыгышларда аерата басым ясап әйтелә.

Съезд барган көннәрдә Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты президиумы һәм Халык Комиссарлары Советы «Татарстан совет язучыларының иҗат-культура көнкүреш шартларын яхшырту турында» махсус карар кабул итәләр.

Съезд Татарстан совет язучылары союзы идарәсен (председатель — К. Нәҗми, членнары — К. Тинчурин, Г. Гали, Г. Толымбай, Х. Туфан, Л. Гыйльми һ. б.) сайлый. Совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездына сайланган делегатлар арасында, татар язучылары белән берrәттән, М. Горький, В. Киршон, А. Новиков-Прибой да күрсәтелә.

1934 елның августында СССР совет язучыларының беренче съезды булды. Съездда Советлар Союзының 52 милләт язучысы, чит илләрдән прогрессив язучылар катнашты.

Партия Үзәк Комитеты исеменнән чыгыш ясаган А. А. Жданов совет әдәбиятының дөньяда «иң идеяле, иң алдынгы һәм иң революцион» әдәбият икәнлегенә аерата басым ясады.

Съездда совет әдәбияты турында зур доклад белән М. Горький чыгыш ясады. «Совет әдәбияты ул рус телендәге әдәбият кына түгел, бәлки бөтен Союз әдәбияты,— диде М. Горький үзенең докладында.— Безнең туган республикаларның әдәбиятлары, тик тел ягыннан гына аерылып, капитализм тарафыннан таркауландырылган барлык хезмәт ияләре дөньясын берләштерүче шул ук идеянең яктысында һәм файдалы йогынтысында үсәләр һәм эшлиләр,— димәк, безнең азчылык милләтләр иҗатын үзебез күпчелек булганга күрә генә игътибарсыз калдырырга хакыбыз юк. Сәнгатьнең кыйммәте сан белән түгел, бәлки сыйфат белән үлчәнә. Әгәр бездә үткән заманда гигант Пушкин булган икән, моңардан әле әрмәннәр, грузиннар, татарлар, украиннар һәм башкалар әдәбият, музыка, рәсем һәм архитектураның иң бөек мастерларын бирә алмаслар дигән сүз килеп чыкмый. Шуны онытырга ярамый: социалистик республикалар Союзының бөтен территориясендә барлык хезмәт халкы массасының «намуслы, кешечә тормышка», яңа тарихны иркеле рәвештә иҗат итүгә, социалистик культураны иҗат итүгә күтәрелү процессы тизлек белән үсә бара»[1].

Съездда милли республикалар әдәбиятлары буенча (украин, белорус, әзербәйҗан, әрмән, грузин, үзбәк, таҗик, төрекмән) докладлар белән бергә, татар әдәбияты турында да доклад тыңланды. Татарстан совет язучылары союзы идарәсе председателе Кави Нәҗми тарафыннан ясалган бу докладта татар әдәбиятының социалистик Татарстандагы экономик һәм культура төзелешләренең киң фонында һәм шулар белән тыгыз бәйләнештә үсүе яктыртылды. Бу уңышлар әдәбиятның идея-художество дәрәҗәсе үсү, чынбарлыкны тирәнрәк сурәтләве, тематиканың киңәюе белән билгеләнә; әдәби интеллигенциянең иң зур өлешенең ныклап советлар власте ягына чыгуы белән, пролетар интернационализмы өчен көрәштә буржуаз-милләтче элементлар калдыкларына тагы да кискенрәк удар ясалуы белән характерлана,— дип белдерде докладчы[2].

Съездда чыгыш ясаган драматург Кәрим Тинчурин ВКП(б) Үзәк Комитетының 1932 ел 23 апрель карарының бөтен совет әдәбияты, һәм шул исәптән, татар совет әдәбияты үсеше өчен булган гаять зур тарихи әһәмиятенә аерата нык тукталды, татар

---

[1] Горький М. Әдәбият турында. Казан, 1941, 210—211 б.
[2] Нәҗми К. Татар матур әдәбияты. Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездында ясалган докладның кыскартылган стенограммасы буенча.— «Совет әдәбияты», 1934, 10 сан, 39—49 б.

драматургиясе тарихын яктыртып узды, заман драматургиясе һәм театры алдында торган бурычларны күрсәтте [1].

Бу съездның әһәмияте турында республика матбугатында күп кенә материаллар басылып чыга. «Совет язучыларының Бөтенсоюз съезды, һичшиксез, матур әдәбият сызыгы буенча гына түгел, гомумән художество культурасы өлкәсендә яктырткыч эз калдырган тирән мәгънәле тарихи вакыйгаларның берсе булып күз алдына баса. Бу съезд яңа сыйныфның бөек коллективизм идеяләрен гәүдәләндерүче, житәкләүче сугышчан большевизмның матур әдәбият фронтындагы бөек җиңү тантанасын күрсәтте. Аның тәэсире һәм гаять зур әһәмияте әлбәттә Советлар Союзы белән генә чикләнмичә, ул бөтен җир шарыннан диярлек намуслы, революцион матур әдәбият вәкилләрен үзенең орбитасына тартты»,— дип язды Ш. Камал. «Мин съездддан «язучылык» профессиясенең социалистик илне төзүдә җаваплылыкта инженердан, архитектордан, профессордан, җаваплы совет эшчесеннән — гомумән җаваплы эшченең һич берсеннән ким түгеллегенә тирән ышанып кайттым»,— дип белдерде Ф. Сәйфи-Казанлы [2]...

Шулай итеп, күпмилләтле совет әдәбияты үсешендәге яңа этапка язучылар Коммунистлар партиясе тирәсенә тагын да тыгызрак тупланган бердәм сафларда килеп керделәр.

Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә барлык совет язучыларының бердәм союзга тупланы тарихи зарури күренеш иде һәм аның иң дөрес юл булганлыгы утызынчы елларда ук ачык расланды.

Совет язучыларының бердәм союзга берләшүе, социалистик реализм методының формалашып җитүе һәм ныгуы — бәхәссез факт. Язучыларның тормышны тагын да тирәнрәк чагылдырулары, социализм төзүче халкыбызга тугры хезмәт итүе — шулай ук һәркемгә билгеле.

Язучыларның бердәм союзы оештырылу совет әдәбиятларының тагын да үсүе өчен зур стимул булды. Әмма шуның белән бергә, совет әдәбиятының үсеше бик тигез һәм каршылыксыз гына барды дип әйтү дә дөрес булмас иде. Вульгар-социологик карашларның рецидивлары әдәбият белеме һәм тәнкыйть өлкәсендә үзләрен шактый сиздереп килделәр. Бу хәл бигрәк тә классик әдәби мираска мөнәсәбәттә күренде. «Правда» газетасы 1936 елның 8 августында үткән заманның бөтен кыйммәтле культура байлыклары халыкка хезмәт итәргә тиеш, дип язып чыкты. «Правда» мәкаләсеннән соң совет язучылары союзы органнарында вульгар-социологик методологияне фаш иткән материаллар, классик әдәбиятны һәм аның вәкилләренең эшчәнлеген шактый тулы тикшергән һәм бәяләгән хезмәтләр басыла. Формализмга һәм натурализмга каршы көрәш көчәя. М. Горький һәм башка күренекле совет язучыларының чыгышлары бөтен илдә зур кызыксыну уяталар. Шул уңай белән 1936 елның март ахырында Татарстан совет язучылары союзы Казанда бөтен татар язучыларының гомуми җыелышын үткәрә. «Татар совет әдәбияты яңа күтәрелеш алдында» дигән доклад белән К. Нәҗми зур чыгыш ясый. «Әгәр дә буржуа дөньясының геройлары — алдау белән, алтын белән, кан белән, изелгән халык массасының күз яше белән шөһрәт тапсалар,— ди ул,— безнең геройларыбыз — халыкның үз кешесе, тигез хокуклы гражданнарның алдынгысы, үз үрнәге белән киң массаларны алга, яңа җиңүләргә омтылдыручы кеше буларак дан казаналар... Буржуа әдәбиятының герое — халыкка, «толпага» каршы куелган эгоист булса, совет әдәбиятының герое кешелек дөньясының иң алдынгы революцион идеалларын үзендә җыйган образ булып гәүдәләнә» [3]. Докладчы һәм җыелышта чыгыш ясаган язучылар татар совет әдәбиятында күренгән формализм һәм натурализм күренешләренә кискен отпор бирделәр.

Утызынчы елларның икенче яртысында әдәбият үсешендә башка каршылыклар һәм авырлыклар да була. Кайбер әсәрләрдә тормышның катлаулы конфликтларын читләтеп узу, милли әдәбиятның реалистик традицияләреннән билгеле күләмдә аерылу сизелә башлады; зур проблемалардан читләшү, көндәлек тормышның вак-

[1] Тинчурин К. Интернациональ бәйләнешне көчәйтик.— «Совет әдәбияты», 1934, 11 сан, 48—51 б.
[2] «Совет әдәбияты», 1934, 10 сан, 71—72 б.
[3] «Совет әдәбияты», 1936, 3 сан.

төякләре белән мавыгу куркынычы туды. Әдәбияттагы шул хәлгә нык борчылып, М. Җәлил 1940 елның 7 декабрендә Татарстан совет язучылары союзы идарәсе исеменнән ясаган отчет докладында: «Безнең язучылар әле һаман хәзерге тормышның төп проблемаларыннан читтәрәк торалар, ә күбрәк шәхси тормыштагы бик артык типик булмаган, артык зур әһәмияте күренмәгән, вак, очраклы күренешләр белән мавыгалар» [1], дип белдерергә мәҗбүр булды.

Ләкин мондый хәлләр, әдәбиятка зарар китерсәләр дә, аның үсүен туктата алмадылар. Совет әдәбияты социалистик реализм методы белән иҗат ителгән яңа әсәрләр тудырды.

Утызынчы елларда күпчелек әсәрләрнең конфликтларына нигез итеп социализм көчләренең искелек калдыкларына каршы кискен көрәше алынды һәм егерменче еллар әдәбиятында шактый тулы яктыртылган сыйнфый көрәш темасы тагын да үстерелде, тирәнәйтелде. Егерменче еллар әдәбиятында көчле яңгыраган пафоста — искене җимерү пафосында ук инде яңаны төзү идеясе ята иде. Совет дәүләтенең социалистик тормыш төзү функциясе нәкъ утызынчы елларда ачык күренә һәм ул әдәбиятта да чагылыш таба. Алгы планга хәзер искене җимерүче герой түгел, ә яңаны төзүче хезмәт кешесе чыкты. Геройның хезмәткә мөнәсәбәте мәсьәләсенең яңача куела башлавы аерата күзгә ташлана: бу герой — хезмәт кешесе, хезмәткә социалистик мөнәсәбәткә ия булган һәм тормыштагы яңаны раслаучы кеше.

Тарихи вакыйгаларга бай булган кырыгынчы елларга совет әдәбияты зур иҗтимагый-политик һәм идея-эстетик тәҗрибә туплап килеп керде. Ул совет халкын патриотик рухта, дөньяда беренче социалистик җәмгыять казанышларын һәм азатлыгын саклап калу өчен көрәшкә хәзерлек рухында тәрбияләүгә хезмәт итте һәм бик хаклы рәвештә Коммунистлар партиясенең ярдәмчесе булып танылды.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк партия тарафыннан дошманны тар-мар итү өчен күрсәтелгән юллар күпмилләтле совет әдәбиятының яңа бурычларын билгеләделәр. Әдәбият, чын мәгънәсендә политик пропагандист һәм агитатор буларак, халык массаларында Ватанга бирелгәнлек, батырлык, җиңүгә ышаныч тәрбияләргә тиеш иде. Совет әдәбияты бу бурычны намус белән үтәде. Дошманны җиңү өчен аның бөтен ерткычлыгын фаш итәргә, аңа карата совет кешеләрендә чиксез нәфрәт тәрбияләргә кирәк иде. Совет язучылары үзләренең әсәрләре белән бу бурычны да уңышлы башкардылар.

Фашистлар һөҗүменең иң беренче көннәрендә үк татар язучыларының дошманга каршы көчле авазы яңгырады. «Кызыл Татарстан» газетасы 1941 елның 24 июнь санында Ә. Фәйзинең «һәркем үзенең көчен барласын», К. Нәҗминең «Фашизмга үлем!», Г. Кутуйның «Коммунизм өчен», С. Батталның «Хаклык бездә, җиңү безнеке» исемле шигырьләрен чыгара. Газетаның 25—26 июнь саннарында да татар шагыйрьләренең дошманга каршы көрәшкә күтәрелергә чакырган ялкынлы шигырьләре басыла. 28 июнь көнне Татарстан Язучылар союзының идарәсе утырышында «Язучылар союзының эшен хәрби ладка үзгәртеп кору» мәсьәләсе карала һәм кабул ителгән карарда «союзның бөтен эшчәнлеге дошманны тар-мар итүгә юнәлдерелгән булырга тиеш», дип белдерелә. 3 июльдә Татарстан язучыларының гомуми җыелышы сугыш чорында язучыларның конкрет эш чараларын билгели»... [2].

Сугыш башланганда илле кешедән торган Татарстан совет язучылары союзы членнарының кырыгы Хәрәкәттәге Армиягә яки фронт матбугатына китә. Бөек Ватан сугышы елларында татар телендә чыгып килгән уналты фронт газетасында күп кенә язучылар эшли [3].

Бөек Ватан сугышы елларында татар язучыларының иҗади эшчәнлеген үстерүдә СССР Язучылар союзының җитәкче органнары белән бәйләнешнең нык көчәеп китүе һичшиксез уңай күренеш булды.

1943 елның 21 октябрендә СССР Язучылар союзы Президиумында татар әдәбиятының Бөек Ватан сугышы елларындагы торышы махсус тикшерелә. А. Фадеев җитәкчелегендә барган бу сөйләшүгә Казаннан килгән Т. Гыйззәт, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Кашшаф һәм фронттан чакырып кайтарылган Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, Г. Галиев, М. Сад-

---

[1] «Совет әдәбияты», 1941, 1—2 сан, 110 б.
[2] Әдәбият баскычлары. Татар совет әдәбияты елъязмасы (1917—1973). Казан, 1976, 207—208 б.
[3] Татар совет әдәбияты тарихы. Очерклар. Казан, 1960, 442 б.

ри катнашалар. Сугыш елларында татар язучыларының эшчәнлеге турында Г. Кашшаф доклад ясый. Президиумдагы чыгышында А. Фадеев «татар әдәбияты тарихында проза әсәрләренең зур урын тотуын» аерата басым ясап күрсәтә һәм татар язучыларын «элекке әдәби традицияләрдән аерылмаска, элекке мастерлыктан өйрәнеп, аны тагын да үстереп, алга омтылырга»[1] чакыра. Президиум утырышы тәмамлану белән үк, А. Фадеев татар язучыларын партия Үзәк Комитетына алып бара. «ВКП(б) Үзәк Комитетының пропаганда һәм агитация бүлегендә минем докладны игътибар белән тыңладылар»,— дип язды Г. Кашшаф. Ул Татарстан Язучылар союзы органы булган «Совет әдәбияты» журналының бары 3 мең генә булып чыгуын әйтә.

«Шунда мине бүлдерделәр:

— Ничек, сездә журнал чыгамыни?

— Ә сез, Александр Александрович, бу турыда беләсезме?

Мин туктап калдым, бөтен тәнем калтырап китте: артыгын әйтеп ташладым, чөнки кайбер рус журналлары сугыш сәбәпле чыкмыйлар иде. Ләкин шул вакытта Фадеевның ягымлы тавышы ишетелде:

— Ә ничек соң, без җитәкчелек итәбез...

Авыр сугыш елларында татар телендәге журналның саклануын партия Үзәк Комитетында хупладылар гына түгел, бәлки югары бәяләделәр:

— Бу сезнең каһарманлык!»[2]

Партия Үзәк Комитеты «Совет әдәбияты» журналының тиражын өч тапкырдан күбрәк арттырырга һәм 10 мең экземплярга кадәр җиткерергә рөхсәт итә һәм кәгазь ягыннан ярдәм күрсәтә.

Бөек Ватан сугышы елларында совет язучылары үзләренең бөтен көчләре белән дошманны тар-мар итүдә катнаштылар, хәрби корал һәм художестволы сүз белән җиңүгә ярдәм иттеләр. Фронтта солдат я офицер, яки корреспондент булган меңләгән совет язучыларыннан 417 кешенең туган йортларына әйләнеп кайтмавын онытып булмый[3]. Бу исәпкә әле сугыш алды елларында әдәби иҗатка килгән һәм Язучылар союзы члены дип исәпләнмәгән йөзләрчә яшь талантлар керми...

Сугыш елларында татар әдәбияты да үзенең М. Җәлил кебек исеме бөтен дөньяга танылган герой шагыйрен югалтты. Сугыш кырында Ф. Кәрим һәлак булды. Х. Мөҗәй, Г. Кутуй, Н. Баян, А. Алиш, Р. Ильяс һ. б. күпләр Ватаныбыз өчен гомерләрен бирделәр.

Сугыш тәмамлану белән үк, халык илне торгызу эшенә керешә. Идеология фронты эшчеләренең дә җаваплылыгы нык артты. Бердәм Совет язучылар союзына оешкан әдипләр сугыштан соңгы елларда идеологик көрәш фронтының алгы сафларында булдылар.

Совет язучыларының 1954 елның декабрендә үткәрелгән Икенче съезды барлык әдәбиятларның 1934 елдан соң үткән егерме еллык тарихына йомгак ясады һәм алдагы бурычларны билгеләде. Аннан соңгы съездларда да күпмилләтле совет әдәбиятларының үсеше, яңа үрләр яулавы билгеләнеп барылды.

Татарстан Язучылар союзының 1950—1984 елларда үткәрелгән съездлары да татар язучыларының Ватан мәнфәгатьләре белән яшәвен, илебездәге коммунистик төзелеш практикасын һаман тулырак чагылдыра баруларын раслады.

Әйе, совет язучылары — һәрвакыт Коммунистлар партиясе белән бергә. Партия һәм Совет хөкүмәте совет язучыларына тулы ирек һәм иҗат мөмкинлекләре булдырды, аларга бары тик бер нәрсәне — «начар язу хокукын» гына бирмәде.

СССР Язучылар союзына берләшкән әдипләр партиянең ышанычын аклыйдылар. СССР Язучылар союзы һәм аның бер өлеше булган Татарстан Язучылар союзының 50 еллык юбилее — совет халкының һәм дөньядагы прогрессив культура эшлеклеләренең зур этәлеккә ия булган бәйрәме.

---

[1] «Совет әдәбияты», 1943, 11 сан, 86 б.

Кашшаф Г. Большой друг татарской литературы. К 70-летию со дня рождения Александра Фадеева.— «Советская Татария», 1971, 25 декабрь.

[3] Марков Г. За полвека.— «Вопросы литературы», 1982, 4 сан, 10 б.

# ДАВЫЛЛЫ ЧОР ЯДКАРЬЛӘРЕ

Безнең көнгә кадәр килеп җиткән татар язма ядкарьләре арасында XVIII гасыр эш кәгазьләре үзләренең күпсанлылыгы, тематик төрлелек һәм шул чор татар җәмгыятендәге барча катламнар тормышын яктыртулары белән аерылып торалар. Шулардан үзәк урынны 1773—1775 елларда Е. И. Пугачев җитәкчелегендә барган крестьяннар сугышына бәйле документлар алып торалар. Ул документларда шул давыллы чорның кайнар сулышы — крестьян юлбашчыларының «туры сөйләме», Урта Идел регионы халыкларының «рухи вә матди» тормышы искиткеч тулылык белән чагыла. Шуңа күрә бу документлар тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итәләр һәм соңгы елларда аларга багышланган хезмәтләрнең, шул җөмләдән, Ф. Хисамова һәм Ф. Фәсиев китапларының да матбугатта чыгуы көтелгән хәл»[1].

Бу ике автор үзара килешеп-сөйләшеп эш иткәннәр дип булмый. Шулай да бу хәл бер үк нәрсәне кабатлауга, мәгънәсез параллелизмга китермәгән. Киресенчә, бердәй материалны ике ноктадан карап өйрәнелгән фактлар һәм күренешләр турында объектив хакыйкатькә ирешүгә бик зур өлеш керткән. Авторларның игътибар аспектлары төрлечә: Ф. Хисамова үз алдына әлеге документларның телен һәрьяклап өйрәнү бурычын куйса, Ф. Фәсиев үзәккә тел материалын лингвотарихи яктан яктыртуны куя.

Хезмәтенең кереш өлешендә Ф. Хисамова «Пугачев циклы» документларына тукталып, аларның саклануын, өйрәнелү дәрәҗәсен һ. б. яктырта. Аннары автор бу документларның нинди телдә язылганлыгы мәсьәләсенә кагыла. Кайчакта (һәм бүгенгә кадәр) иске татар ядкарьләре телен «чыгтай теле», «Урта Азия әдәби теле» «иске төрки тел» дип, аның үзенчәлеген инкарь итү позициясендә торучылар очрый. Икенче берәүләр, уза китеп, гүяки аерымланып торган «Урал төркисе», «Казан төркисе» һ. б. турында сүз йөртәләр. Ф. Хисамова академик А. Н. Самойлович хезмәтләренә таянып, аерым «Идел буе төркисе» бар дип саный һәм тикшерелгән документлар иске татар әдәби телендә язылганнар дип раслый.

Керештән соң килгән беренче ике бүлек лексика һәм фразеологиягә багышланган. Аларда документларның традицион рәсми кәгазьләр калыбында булуы исбат итела һәм мөрәҗәгать, титулатура, шаһитлек штамплары-өлгеләре, нәзакәть һәм хөрмәт гыйбарәләре һ. б. күрсәтелә.

«Графо-фонетика» бүлегендә автор XVIII гасыр документларында бердәм орфографиянең сакланмавына, бер үк сүзләрнең (хәтта бер үк документта) төрлечә язылуына, кайбер сүзләрнең, бигрәк тә традицион татар төркисендә булмаган сүзләрнең 6—7 төрле язылышта йөрүенә игътибар итә. Әмма бу бүлек, бигрәк тә Ф. Фәсиев китабы белән чагыштырганда, эшләнеп бетмәгәнлек тәэсире калдыра.

Аның каравы, «Морфология» бүлеге бик кызыклы. Төгәл саннар белән күрсәтеп, Ф. Хисамова XVIII гасыр эш кәгазьләре телендә татар (кыпчак) тибындагы төрләнеш базис-нигез вариант булуын, чыгтай (карлук) тибындагы төрләнешкә караганда ешрак кулланганлыгын исбат итә. Аннары, шунысы да игътибарга лаек (һәм моны автор тиешенчә нигезләп раслый) кайбер карлук формалары татар теленә тирән үтеп кергәннәр, үз булып киткәннәр. Мәсәлән, чыгыш килеш кушымчасының уйгурча варианты -дин, -дыйн татарча (кыпчакча) вариант -дан, -тан (дән, тән һ. б.) белән бердәй ешлыкта кулланыла. Бу хәл-

[1] Хисамова Ф. М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. Казан университеты нәшрияты, 1981; Старотатарская деловая письменность XVIII в. (сборник текстов). Казань, 1981. (Җыентыкны төзүче, документларны басмага әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны язучы Ф. С. Фәсиев.)

не гомумән татар теленең специфик үзенчәлеге диярга мөмкин: халык җырларында -дыйн, -дин формасы бүгенгәчә кадәр еш кына кулланыла; кайбер әйтемнәр, мәкальләр һ. б. тотрыклы тәгъбирләр составында бары тик -дин, -тин генә очрый: хәттин ашкан; күптин күп, чуктыйн чук һ. б.

Фигыльләрдә иске төрки формалары, исемнәр белән чагыштырганда, ешрак очрый. XVIII гасырда -гай, -гәй формантына беткән, теләк фигыльләр шактый еш кулланылган (хәзер бу форма диалекталь сөйләмдә -магае формантында гына очрый). Ф. Хисамова үзенең күзәтүләреннән түбәндәге мөһим нәтиҗәләр ясый: 1) фигыльләрнең «традицион» һәм «халыкчан» формалары XVIII гасыр язма телендә үзара каршы куелмаганнар, ә төзек бер тәгъбирләнеш системасын тәшкил иткәннәр; мәсәлән, -ган һәм -мыш формантлары бер-берсен тулысынча алмаштыра алмаганнар — стилистик яктан гына түгел, семантик яктан да алар арасында аерма, дифферентлык күзәтелә; 2) иске фигыль формаларының кайберләре чыгтай телендә, икенчеләре уйгур телендә, өченчеләре угыз телләрендә аеруча актив кулланыла. Моннан исә иске татар теленең тегеяки бу мәгълүм телнең «дәвамы» гына булмаганлыгы, мөстәкыйль табигате тагын да дәлилләрәк рәвештә ачыклана.

Ф. Фәсиев әзерләгән публикация төзүче язган күләмле сүз башыннан, әннары 74 документ-ядкарьнең кириллик транскрипциясеннән (аларның һәркайсына күпсанлы аңлатма, искәрмә, шәрех-комментарияләр бирелә), йомгак һәм библиография өлешеннән тора. Китап «текстлар җыелмасы» дип аталса да, реаль эчтәлеге белән ул — иске татар язма телен өйрәнүгә тәфсилле кереш булып тора. Моны китап азагында XVIII гасырга карамаган берничә документның аерым анализлануы да күрсәтеп тора. Китап киң теоретик гомумиләштерүләргә һәм төрле тарихи мәгълүматларга бай.

Ф. Фәсиев бик тыгыз стиль белән язганлыктан, китапның «кыскача эчтәлеген сөйләп бирү» аның үзен кабатлауга китерер иде. Шулай да авторның нинди моментларга аеруча игътибар иткәнлеген күрсәтү мөмкин һәм кирәктер.

Ф. Фәсиев өйрәнелгән документларның тел мәсьәләсендә экстралингвистик һәм саф лингвистик аспектлар булуына игътибар итә. Әдәби-язма телнең «кем теле» булуы аның кемнәр тарафыннан кулланылуына һәм таратылуына бәйле. Русча ядкарьләрдә XV гасырдан башлап «татарское письмо» дип аталган нәрсә — ул чыннан да нәкъ менә татар халкының элекке әдәби-язма теле. Ул телне башлап куллануучылар татарлар арасында гына түгел, башкортлар, казахлар, нугайлар һәм, хәтта, кавказлылар арасында да гамәлгә куючылар — патша администрациясендә хезмәт иткән йомышлы татарлар — абызлар, балалар укытырга чакырылган хәлфәләр һ. б. күпчелек очракта казан татарлары (Казан арты, яисә Тау ягы вәкилләре), мишәрләр һәм касыймлылар була.

Иске татар язма теленең лингвистик характеры мәсьәләсе бигрәк тә катлаулы. «Идел буе төркисендә» гарәп-фарсы, шулай ук көньяк төрки (уйгур, угыз) элементлары күп була, әлбәттә. Һәм бу хәл «иске татар язма теле» дигән төшенчәне «төрки тел» белән алмаштырырга тел белүчеләргә бер сылтау булып тора. Ф. Фәсиев мәсьәләне ачыклар өчен Идел буе төркисенең, ягъни иске татар язма теленең барлыкка килүен һәм үсешен тарихи шартлар белән бәйләнештә, эзлекле рәвештә марксистик тарихилык принцибын кулланып күрсәтеп бирә. Шул ук вакытта ул соң дәрәҗәдә конкрет: һәрбер аерым ядкарьдә ничәшәр процент татар-кыпчак, угыз, уйгур элементлары барлыгы, текстның нинди (югары, түбән, урта) стильгә тартым икәнлеге дә һәрвакыт күрсәтелеп барыла. Нәтиҗәдә бер генә документның да иске татар язма теленнән аерым «Урал төркисе» яисә «иске башкорт язма теле» турында сүз алып барырга нигез була алмавы ачыклана. Кузгатылган мәсьәләгә бәйле рәвештә түбәндәгеләрне әйтәсе килә. Татар теле төрки телләр системасында гомумән үзәк урынны алып тора. Лингвостатистик тикшерүләр буенча татар теле бер яктан үзбәк теленә (бигрәк тә китаби сүз һәм формаларда) иң якын торган тел. Нугай, казах, кыргыз телләре татар теленә үзбәкчәдән дә якынрак, ә инде карачай-балкар, караим, кумык, башкорт телләре аеруча якын. Әгәр кардәш халыкларның аерым вәкилләре «бу ядкарь теле безнең телгә иң якын тора, димәк ул безнеке!» дигән «логикага» күчәләр икән, татар ядкарьләрен үзбәкләр, кыргызлар һәм башкалар да үзләренеке дип уйлый алалар иң. Кызганычка каршы, андый очраклар, чыннан да күзәтелгәли.

Ф. Фәсиев күрсәткәнчә, борынгы угыз язма-әдәби теленең Хорезм тирәсендә

барлыкка килгән угыз-кыпчак варианты Идел буенда да кабул ителә. Шуңысы бар — татар халык теле һәрвакыт диярлек «китап теле» йогынтысында булган. Һәм көньяктан килгән әдәби-мәдәни тәэсирләр татар «халык телен» дә көньяк тарихи телләргә якынлаштырганнар.

Шул ук вакытта татар теле борынгы гомумтөрки чалымнарны иң тулы саклаган телләрнең берсе. Күрше чуваш, башкорт, казах, нугай телләрен генә алып карыйк: алар теге яки бу үзенчәлекләре (бигрәк тә аваз үзгәрешләре) белән гомумтөрки типтан кискен рәвештә аерылып торалар. Татар телендә (бигрәк тә әдәби телдә) бу җәһәттән берничдн сизелерлек үзенчәлек юк! Иске татар язма телен гомумтөрки язма тел дип карау мөмкинлеге шунлыктан туа да. Димәк, Ф. Фасиевнең татар язма тел тарихына карата язганнары бик вакытлы һәм урынлы булып чыга.

Ф. Фасиев хезмәтендә иске татар язмасының орфографиясе мәсьәләсе дә бик җентекләп карала. Автор ике нәрсәгә аеруча игътибар итә: 1) XVIII гасырда «тел» урынына «дил» дип, «тот» урынына «дут» дип язу һ. б. ш. очраклар орфографик шартлылык булганнар. Алар — үткән заманнар калдыгы. Орфографиядә мондый анахроник шартлылык, озын тарихка ия булган язма телдә килеп чыга. Мәсәлән, инглиз һәм француз орфографиясе бүгенгә кадәр XIV—XV гасырлар әйтелешен чагылдыра. 2) иске татар графикасында аффикслар гадәттә тик бер вариантта гына язылганнар, мәсәлән, -дан язылышы -тан, -дән, -тәннәрне дә белдергән. Мондый очракларда нинди фонетик үзенчәлекләр турында сүз йөртеп булмый, әлбәттә.

Ф. Хисамова һәм Ф. Фасиевнең бу хезмәтләрендә укучы XVIII гасырның материаль һәм рухи-мәдәни тормышына караган бик күп кызыклы фактлар таба ала.

Кайбер җитешсезлекләренә (аерым сүзләргә аңлатмаларның тулы булмавы һ. б.) карамастан, Ф. Хисамова һәм Ф. Фасиев хезмәтләре татар әдәби-язма теле тарихын һәм, гомумән, халкыбызның рухи культурасын өйрәнүдә яңа бер адым булып торалар.

**Рифкать ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ТӘРӘЗӘЛӘР КАЯ КАРЫЙ?

Без кайвакыт зарлангалап алабыз: матбугатыбызда көн-үзәк проблемаларны кешеләрнең катлаулы язмышы аша күрсәткән, киң образлы фикерләүгә һәм зур гомумиләштерү көченә ия булган очерклар әлегә җитәрлек дәрәҗәдә күренми. Ә менә «очерк» дигән мөһер сугылып та, гади бер зарисовкадан уза алмаган язмалар байтак. Чын мәгънәсендәге очеркларның сирәк булуына ни сәбәп соң? Әлбәттә, бу сорауга төрлечә җавап бирергә мөмкиндер. Минем исә шуны гына әйтәсем килә: матбугатта күренгән һәр уңышлы очеркны билгеләп үтәргә, яхшы очерклардан китап туплап чыгаруны хупларга, бу эштә тиешле ярдәм күрсәтергә кирәктер.

Мин, Рәмзи Максудовның «Тәрәзәләр кая карый?» дип исемләнгән очерклар җыентыгын әнә шундый уйлар белән кулыма алдым.

Җыентыкны укыганда иң әлек шуңа игътибар итәсең: автор үз геройларын әллә кайдан, «җиде чит-ән» артыннан эзләп йөрми, алар — безнең тормышыбызда, халкыбызның данлы үткәнендә. Китапның «Утлы еллар эзе» дип аталган беренче бүлеге, мәсәлән, тарихи вакыйгаларга һәм шәхесләргә багышланган. Әлбәттә, бу очракта фактларның төгәл булуы шарт, геройларның характерын ачуда документальлек өстенлек итәргә тиеш. Бер мисал китерик. Гражданнар сугышы ветераны Н. М. Глазуновка багышлап язылган «Камада ак пароход» очеркында вакыйгалар шаулы 1919 елга, яшь Совет хөкүмәтенең агитатор һәм инструкторларын, төрле комиссариат вәкилләрен сәяхәткә алып чыккан «Йөзмә ВЦИК» — «Красная звезда» пароходына барып тоташа. Язмадагы төп геройның әлеге пароходта В. И. Ленинның көрәштәше һәм тормыш иптәше Надежда Константиновна белән очрашуы, Крупскаяга бәйле булган вакыйгалар, аның көндәлегеннән юллар һәм нәкъ шул көннәрдә Ильичтан хат алуы, әлеге хатның эчтәлеге — барысы да төгәл сурәтләү-

не, документальлекне таләп итә. Бер карагандә, болар образлы фикерләүне чиклидер шикелле. Әмма, автор очеркның әдәбилегенә, образларның сәнгатьчә эшләнешенә ирешә алган. Очеркның яхшы укылуы, тәэсирле булуы әнә шуны раслый.

Күләм ягыннан әллә ни зур булмаган язмада һәр образны тулысынча ачып бирү кыен, әлбәттә. Ләкин шунысы хак: синең тарафтан алынган сурәтләү чаралары геройның характерын күрсәтүгә, очеркның төп максатына хезмәт итәргә тиеш. Р. Максудов та моны яхшы аңлый. Бу уңайдан мисал итеп, түбәндәге бер өзекне китерәсе килә.

«...Глазунов бер мәлгә югалып калгандай булды. Аның алдында иске танышы — Спасскидагы элекке политкомиссар Миронов басып тора иде. Ул аңа рапорт бирергә теләп:

— Иптәш комендант, рәсми чакыру буенча...— дип сүз башлаган иде, Миронов аны бүлдерде:

— Вольно, Николай Михайлович!.. Саумы яхташ? Килеп җиттекме?

Бик җылы күрештеләр. Комендант аны шунда ук Надежда Константиновна каютасына алып китте.

— Әйдә, аңа рапорт бирик без, иптәш комиссар...

— Нинди комиссар ди мин, иптәш Миронов...

— Революция комиссары,— диде Миронов. Аның тавышы җитди иде...»

Революция комиссары... Әйе, әлеге сүзләр вакыйга барышы сурәтләнгән вакытта ничек яңгыраса, алар бүген без күзалларга тиеш герой портретын да шул ук елларга хас кыскалык белән ачып бирә.

«Бүгенге авыл кешеләре...» Җыентыкның икенче бүлеге шулай атала, һәм, миңа калса, автор бу бүлектәге очеркларын иркенрәк, үз геройларының уй-хисләренә, омтылышларына, гомумән, яшәү рәвешләренә якынрак торып яза. Һәм бу гаҗәп түгелдер: нишләтәнне язуга карагандә, үзең күреп белгәнне язу җиңелрәк бирелә.

Еш кына шулай була: портрет-очеркка алынган авторлар үз героен заман кешесе итеп күрсәтү өчен аның биографиясендәге кызыклы урыннарны санап чыгарга, ирешкән бнеклекләрен күрсәтергә, инде дә килеп, аңа бирелгән хөкүмәт бүләкләрен тезеп чыгарга яраталар. Янәсе, менә кем ул, менә нинди ул минем герой! Саннар да була, яуланган биеклекләр дә күрсәтелә, ләкин... кеше үзе күренми кала, геройның үз дөньясы, тормыш фәлсәфәсе, яшәү мәгънәсе ачылмый кала. Рәмзи Максудовның очеркларында мин шуның киресен — төп игътибарны геройның эч йөзен, характерын, тирә-юньгә мөнәсәбәтен ачуга юнәлдерүне, һәрхәлдә, шуңа омтылуны күрдем.

Чыннан да, аның геройлары гап-гади кешеләр: алар, бер карагандә, башкалардан әллә ни аерылып тормыйлар, аерылып торырга омтылмыйлар да. Ләкин шул ук вакытта аерылып та торалар. Нәрсә белән? Әйтик, «Гигант» колхозында атлар караучы Нурулла Гафуров кай ягы белән кызыклы? Хезмәтен яратуы беләнме? Алай дисәң, хезмәтен яратып башкаручылар бик күп бездә. Ә шулай да, нәрсәсе белән аерыла соң башкалардан ат караучы Нурулла? Ә менә хикмәт нәрсәдә икән: эш кешесе генә түгел, дөнья гаме кешесе дә икән бит Нурулла!.. Күпләр инде аттан баш тарткан-да — машина яки мотоциклда җилдерткәндә, атның барлыгын бәйгеләрдә генә искә төшереп, бәйрәм узгач янә онытканда, Нурулла үз гаме белән йөри, бәхәскә керә, көрәшә икән бит! «И хода, сыер дигәндә, председателе дә утка баса, парторгы да. Сыер бер курмыйны ашамый икән, аңа шундук икенчесен салалар. Мә, малкай, күшә генә! Ә „бит чынлап торып уйласаң, сыер талымсыз мал ул. Сунын теләсә ниндие ярый аңа, чишмәнекен эчәсеңме, сазныкын бирәсеңме — берсен дә талымлап тормый...»

Менә шундый кеше Нурулла. Автор үзе әйтмешли, өендә сөт эчмидер бу, дип уйлавыгыз бар. Сыерда ачуы юк Нурулланың. Бүгенге көн белән генә яшәп, кик һәм тирәнтен уйлый белмәгәннәрнең, авыл кешесенең килачәгенә бармак аша гына карарга өйрәнгәннәрнең ачуын сыердан ала ул. Бәлки, нәкъ менә шушы Нурулла булмаса, аның «ат җене кагылган» холкы булмаса, «Гигант» колхозында күптән инде атлар калмас иде. Ә ул, әнә, республика күләмендәге ярышларда катнашырлык чаптарлар үстерергә, спортчы җайдаклар тәрбияләргә хыялланып йөри.

«Проворовлар» очеркында саллы бер басынкылык белән, әмма уларына биргән ялкын белән яктырып яшәүче өлкән Проворов образына сокланмый мөмкин түгел. Югыйсә сүз аның турында гына түгел, ә бәлки аның балалары турында бара сыман. Ләкин нигә соң күз алдына һаман шул образ, барлык уллары механизатор булган, хәтта кызын да механизаторга кияүгә биргән 60 яшьлек өлкән Проворов килеп баса

иде? Хикмәт шунда: беренче урын өчен бирелгән вымпелны әтисе комбайнына эләргә тәкъдим иткән Петр белән танышканда да, аннан яшьрәк Николайны күз алдына китергәндә дә, кибеттә кадак юк дип кайткан, әмма кәкрәйгән кадакны читкә ыргыткан төпчек Владимирга карап та без иң элек өлкән Проворовның ата һәм остаз булуы, гаилә башлыгы, тәрбияче булуы, үз балаларында хезмәткә мәхәббәт, игелеклелек кебек зур сыйфатларны тәрбияләгән кеше булуы турында уйлыйбыз икән.

«Ящикта тактадан суырган кадаклар бар. Шуларны турайтып карарбыз. Син, улым Володя, булмаса, шул эшне эшли тор әле»,— ди ата кибеттән кадак юк дип кайткан улына. Володя — төпчек, әмма ул да ир заты ич! Һәм, әлбәттә, кадак төзәйтеп утыру аңа бик ошап бетми, нәкъ менә шунлыктан ул ялгыш үз бармагына сугадыр. Мондый чакта, бармакка чүкеч эләксә, бик ачу килә. Володя да, кәефе китеп, кадакны веранда артына атып бәрә. «Өлкән Проворов тактаны фуганка белән буеннан-буена йөреп чыкты да әйләнеп килешли Владимир янына туктап:

— Анда, улым, веранда артына бер кадак төшеп китте. Алып килсәң икән шуны. Яңа әле ул, эшкә ярый әле ул,— диде».

Кем белә, өлкән Проворовның үзенә Петрны да, Николайны да менә шундый түземлелек белән, йомшак кырыслык һәм таләпчәнлек белән «кеше итәргә» туры килгәндер? Ышанып каласың: Проворовның әлегә бераз кызурак канлы, максаты бик үк ачык булмаган төпчеге — Володясы да тора-бара абыйлары кебек булыр, үз фамилияләренең дәрәҗәсен төшермәс.

Мин бары тик ике очерктан гына мисаллар китердем. Ә шундый кызыклы, характерлы геройлар җыентыкта шактый. Автор үз геройларын яратып яза һәм, шунысына рәхмәт, аларны идеаллаштырмый, бәлки нәкъ менә җир кешесе итеп калдыра. Бу— очеркның ышандыру көченә ия булуы, геройларның укучы күңеленә якын торуы дигән сүз. Үз ахирәтенең улы туена кергән, «баш кода» булып йөргән тол хатын Наталья, колхозчылар белән телгә килүне һәм дорфалык күрсәтүне бернигә дә санамаган, әмма колхоз стена газетасына эләгүдән уттан курыккан кебек курыккан бригадир ярдәмчесе Мәгъсүм, яшьләй үк сабанчы булып йөргән, армиягә алынгач, үзен тракторчы дип алдашкан, әмма теләгенә ирешкән һәм армиядән «отличный танкист» значогы тагып кайткан Нуретдин — болар барысы да хәтердә кала торган, эчке бер ярату, ихласлык белән сурәтләнгән образлар. Һәм алар аша автор бүгенге көн кешеләренең күңел тәрәзәләрен шактый киң итеп ачып бирүгә ирешкән. Ә ул тәрәзәләр, китаптан аңлашылганча, кояшка карыйлар...

*Харис* **ӘШРӘФҖАНОВ.**

**Әбрар Кәримуллин,**
филология фәннәре докторы

# «ГАСЫР» НӘШРИЯТЫ

*Кешелек хәтере вакытның җимергеч көченә каршы тора һәм культура дип аталган бөек хәзинәне барлыкка китерә.*

Академик Д. С. Лихачев.

Беренче рус революциясе гасырлар буе социаль һәм милли тоткынлыкта яшәп килгән халыклар тормышына давылдай килеп керде, аларның яшәешендәге зур үзгәрешләргә сәбәп булды. Бездә профессиональ театр барлыкка килүе газета-журналлар чыга башлау, уку-укыту өлкәсендәге зур үзгәрешләр — әнә шул революция дулкыннары җимеше. Шундый ук үзгәрешләрне без матбагачылык өлкәсендә дә ачык күрәбез. Халыкны агарту, аны кешелек җәмгыяте тудырган казанышлар хисабына баету, фән, техника, сәнгать казанышлары белән якыннан таныштыру өчен янып йөргән мәгърифәтчеләр беренче рус революциясе тудырган азмы-күпме мөмкинлекләрдән файдаланып китап басу эшен дә җайга салырга тырышканнар. Бу елларда барлыкка килгән эреле-вaклы китап ширкәтләре: «Юл», «Мәгариф», «Нур», «Каләм», «Иршад», «Насырия», «Өмед» һәм башка нәшриятлар әнә шул максатлардан чыгып оештырылганнар. Шундый нәшриятлар арасында эзлекле рәвештә демократик позицияләрдән торып эш иткән «Гасыр» нәшрияты да була. Ләкин Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Коләхметов һәм күп кенә башка язучылар турындагы, беренче татар большевигы Х. Ямашев турындагы хезмәтләрдә еш искә алына торган «Гасыр» нәшрияты тарихы матбугатта хәзергәчә яктыртылмаган килеш кала бирә. Шуны исәпкә алып, без «Гасыр» нәшрияты турында берничә сүз әйтергә булдык.

«Гасыр көтепханәсе» исеме белән билгеле бу нәшриятның тарихы «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе» исемле нәшрият белән бәйләнгән.

Бу нәшриятның тарихы шактый драматик башлана. Татар куштаннары Казан губернаторына: Ә. Хәсәни рөхсәтсез китап сату белән шөгыльләнә, аның номерына әллә нинди ят кешеләр җыела, анда патшага каршы сүзләр сөйлиләр дип шикаять язалар. Менә ул шикаять буенча 1908 елның 26 февралендә полиция надзирателе Печән базарындагы «Сарай» кунакханәсенең 16 нчы бүлмәсенә бәреп керә. Китап бәйләмнәре арасында эшләп ятучы Ә. Хәсәнидән китап сату өчен рөхсәт кәгазен күрсәтүне таләп итә. Ә. Хәсәни үзенең китап басу белән генә шөгыльләнмәвен, үзе баскан китапларны сату өчен аларны китап кибетләренә тапшыруын әйтә. Надзиратель «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе» бастырган китапларны тикшереп карый, алар арасында рөхсәтсез басылган китапларны таба алмый, аннан һәр басылган әсәрнең берәр данәсен алып губернатор канцеляриясенә алып китә [1].

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 1 ф., 4 тасвирлама, 3749 эш, 8 б.

Икенче көнне цензор Н. И. Ашмарин, китап сату эшләрен күзәтүче чиновник Вольский, пунәтәйләр белән Ә. Хәсәни бүлмәсендә, аның астындагы китап складында тентү ясыйлар. Шиклənерлек нәрсәләр таба алмагач, бүлмә һәм складка салган арестны алып, бәйләнмичә китеп баралар.

Полиция тарафыннан тентүнең юкка гына оештырылмавын яхшы аңлаган Ә. Хәсәни, киләчәктә бәйләнергә сылтау калмасын дип, китап сату өчен рөхсәт алырга була, үтенеч белән губернаторга мөрәҗәгать итә[1]. Үтенеч ике кеше исеменнән, Ә. Хәсәнинең үзе һәм Габдрахман Хәбибулла улы Рәхмәтуллин исеменнән бирелә. Үтенеч губернаторга кергәч, аның авторларының кем икәнлеген яшерен юл белән өч ай тикшерү була, шуннан соң гына, 1908 елның 30 июнендә аларга китап кибете ачарга рөхсәт бирелә. Рөхсәтне алгач ярты елдан соң, 1909 елның беренче январенда Евангелистов (хәзерге Татарстан — Ә. К.) урамында бертуган Ибраһимовлар йортында «Гасыр көтепханәсе» исемендә китап басу, сату ширкәте ачыла, бу ширкәт 1913 елның 20 маенда Мәскәү (хәзерге Киров — Ә. К.) урамындагы Мөхәммәдшакир Казаков йортына күчерелә.

«Гасыр» нәшриятының тарихы 1907 елдан ук башлана. Әхмәтгәрәй Хәсәниннең үз сүзләре белән әйткәндә, ул китап басу эшенә 1907 елның 25 февралендә ук керешә. Аны тентүгә килгән вакытта «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе» грифы астында инде 12 китап басылып чыккан була. Шуларның унысы 1907 елда чыга. Алар арасында без алты исемдә «Театр мәҗмугасы» астында чыккан әсәрләрне күрәбез.

Шушы елны чыккан китапларның кайберләре «Әдәбият мәҗмугасы», кайберләре «Хифзыссыйхәт»[2], «Голүм вә фәннүн» серияләре белән чыкканнар. Алар А. С. Пушкинның «Дубровский» романы (С. Рахманколый тәрҗемәсе), Ф. Кәримнең «Морза кызы Фатыйма» романы, Г. Х. Рәхмәтуллин тәрҗемәсендә басылган Е. Кутеловның «Сәламәтлекне ничек сакларга», Г. Харис тәрҗемәсендә чыккан В. Горнның «Чуен юлны кем уйлап чыгара?» исемле китаплар. Шулай итеп китап басуга керешүнең беренче елында ук «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе» дүрт серия астында китап басуга ирешә. Соңыннан бу сериягә «Балалар дөньясы», «Уку китаплары» дигән тематик басмалар да өстәлә.

Бер уңайдан «Гасыр» аерым серияләрдә күпме китап чыгаруын да ачыклап китик:

| №№ п/п | Серияләр | Басма саны | Шул исәптән ничәсенең тиражы ачыкланган | |
|---|---|---|---|---|
| | | | басма саны | аларның гомуми тиражы |
| 1. | «Әдәбият мәҗмугасы» | 43 | 31 | 123.500 |
| 2. | «Театр мәҗмугасы» | 26 | 21 | 77.000 |
| 3. | «Хифзыссыйхәт» | 8 | 7 | 33.000 |
| 4. | «Голүм вә фәннүн» | 12 | 11 | 34.000 |
| 5. | «Балалар дөньясы» | 3 | 2 | 6.000 |
| 6. | «Дәрес китаплары» | 27 | 22 | 100.000 |
| 7. | Төрле китаплар | 13 | 8 | 27.000 |
| | Барысы | 133 | 101 | 406.500 |

Биредә 1918 елга хәтле чыккан басмалар гына исәпкә алына, чөнки бу елдан соң чыккан басмаларның сериясе күрсәтелми.

Таблицада күренгәнчә, китап репертуарының абсолют күпчелеген драма, матур әдәбият әсәрләре алып тора.

Беренче адымнан ук шулай серияләп китап чыгара башлау Ә. Хәсәни белән Г. Х. Рәхмәтуллиннарның китап басу эшенә бик нык әзерләнеп керешүләрен күрсәтә. XX йөз башында кайбер нәшриятлар эшчәнлегендә серияләп китап басу күренгәләсә дә, башыннан алып ахырына хәтле серияләп китап чыгарганнары күренми. Бу серияләрнең исеменнән ук, «Гасыр» нәшриятының нинди максатлардан чыгып эш итүен аңлау авыр түгел. Аларның үз сүзләре белән әйткәндә: «Гасыр көтепханәсен»

[1] Шунда ук. 6 б.
[2] Хифзыссыйхәт — сәламәтлек саклау, гигиена.

ачу гаять әһәмиятле булган китап басу эшен доход-керем чыганагы итеп, кесә калынайту максатыннан чыгып эшләнмәде. Киресенчә, мәһим һәм файдалы әсәрләр бастырып, милләтебезнең алга китүенә ярдәм итүдер. Менә шуннан чыгып бу нәшриятны оештырганда, аны бер яктан милли әдәбиятның үсешенә һәм халык массаларына таралуына ярдәм итүдә, икенче яктан халкыбызны Европа, шул исәптән рус әдәбияты белән, якыннан таныштыруда файдалану күздә тотылды[1]. (Өзек хәзерге телгә җиңеләйтелеп бирелә.— Ә. К.)

Шушы максатыннан «Гасыр» бер вакытта да читенмичә эшләп килде. Моны ачыклауга керешкәнче, шушы нәшриятта күпме китап чыгуын күрсәткән таблица белән танышып китик:

| Еллар | Басма саны | Шул исәптән ничәсенең тиражы ачыкланган | |
|---|---|---|---|
| | | басма саны | аларның гомуми тиражы |
| 1907 | 10 | 6 | 20.500 |
| 1908 | 12 | 9 | 37.000 |
| 1909 | 18 | 12 | 43.000 |
| 1910 | 8 | 7 | 24.000 |
| 1911 | 15 | 9 | 43.000 |
| 1912 | 20 | 16 | 60.000 |
| 1913 | 18 | 14 | 55.000 |
| 1914 | 18 | 17 | 66.000 |
| 1915 | 4 | 4 | 19.000 |
| 1916 | 7 | 7 | 32.000 |
| 1917 | 5 | 1 | 2.000 |
| 1918 | 12 | 1 | 6.000 |
| 1919 | 7 | 4 | 30.000 |
| 1921 | 2 | — | — |
| Барысы | 153 | 107 | 437.500 |

(Бу мәгълүматларның 1915—1921 елларга карагганнары тулы ук булмавы мөмкин, чөнки бу елларда чыккан китаплар турында архив чыганакларында материаллар очрамый.)

Таблицадан күренгәнчә, «Гасыр» елына уртача 10—15 китап басудан узмаган. Әгәр кайбер татар нәшриятларының елына йөзләп китап басуын искә алсак, «Гасыр» китап басып кесә калынайту турында уйламаган дип әйтә алабыз.

Матур әдәбият китаплары арасында беренче урынны татар язучыларының әсәрләре алып тора. Мәсәлән, «Әдәбият мәҗмугасы» сериясенә кергән 43 басманың егерме җидесе татар әдипләренең китаплары. Алар арасында Г. Ибраһимовның «Сөю сәгадәт», «Карак мулла», «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» хикәяләрен күрәбез. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын да «Гасыр» нәшрияты бастыра башлый. Романның ике табагы басылып бетеп килгәндә патша цензурасы аңа арест сала, шунлыктан бу әсәр бары революциядән соң гына дөнья күрә алды. «Әдәбият мәҗмугасы» сериясендә Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт», «Татар кызы», С. Җәләлнең «Дим буенда», Г. Галиминең «Явызлыкның җәзасы», «Нәҗип Думави хикәяләре», Г. Коләхметовның «Ник уйгандым» һ. б. әсәрләр дә бар.

Тәрҗемәләр арасында беренче урынны рус әдәбияты алып тора. Алар А. С. Пушкинның Г. Рәшидов тәрҗемәсендә чыккан «Буран», С. Рәхматуллин тәрҗемәсендә «Алеко яки чегәннәр», М. Ю. Лермонтовның «Безнең заман героеннан алынган «Черкес кызы» (Г. Кәрам тәрҗемәсе), И. С. Тургеневның «Яһудие» (С. Рахманколый тәрҗемәсе) һәм башка китаплар. Бу китапларның кереш өлешендә рус әдипләренең портретлары, аларның тормышы һәм иҗаты турында очерклар басылган. Татар басмачылыгында рус әдәбияты белән якыннанрак таныштыру өчен язучыларның портреты һәм биографиясе белән китап басу эшен «Гасыр» башлап җибәрүен ассызыклап күрсәтү кирәк. Бу инициативаның авторы Ә. Хәсәни булды.

«Гасыр» нәшрияты 1909 елны М. Горькийның «Два мужика» исемле хикәясен басып

[1] 1909 елда, гыйнварда, Казанда яңа ачылмыш «Гасыр» кәтепханәсенең әсами кәтебе. 2 нче нумер. Казан, 1909, 1 б.

чыгарды. С. Рахманколый тәрҗемәсендә «Ике сукбай» исеме белән чыккан бу басма М. Горькийның революциягә кадәр татар телендә чыккан бердәнбер китабы булды.

Шушы елны Оренбургта Фатих Кәрими нәшрияты М. Горькийның «Ана» романын татар телендә басуга керешә. Татар куштаннары бу турыда жандармериягә хәбәр итәләр, һәм Оренбург жандармнары төнлә типографиягә налет ясап бу романның наборын тараталар, татарча тәрҗемә текстын конфисковать итәләр, типографияне ябу белән куркытып әсәрне басуны тыялар.

Патша цензурасы М. Горький әсәрләрен татар телендә басуны тыю гына түгел, хәтта вакытлы матбугат битендә аның исемен әйтүгә дә юл бирми килде. Бу яктан, «Гасыр» нәшриятының бөек пролетар язучысы М. Горькийның бер әсәрен басып чыгарып кала алуы үзе күренекле, кызык факт. Бу факт үзе генә дә «Гасыр» нәшриятының нинди юнәлештә эшләгәнен чамаларга мөмкинлек бирә.

«Гасыр»ның тәрҗемә басмалары турында сөйләгәндә, Ж. Верның «Сиксән көндә дөньяны әйләнү» әсәре басылырга әзерләнүне дә күрсәтергә кирәк, ләкин бу басманы без таба алмадык.

Шәрык әдәбияты үрнәкләреннән «Әдәбият мәҗмугасы» сериясендә Г. Камал тәрҗемәсендә Т. Касбарның «Саран», К. Бәшир тәрҗемәсендә Р. Әхмәднең «Бичара егет», С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә «Кара ханым», «Мәңгелек мәхәббәт» кебек хикәя, повестьлар басыла.

Драматургия әсәрләрен басу буенча да «Гасыр» татар укучыларын рус һәм Европа халыкларының әдәби үрнәкләре белән таныштыру юлыннан бара. «Театр мәҗмугасы»нда чыккан китаплар арасында без А. С. Пушкинның «Борис Годунов» (С. Рахманколый тәрҗемәсе), Борисовскийның «Аулакта очрашу» (Г. Рөстәм тәрҗемәсе), Г. Сибиряковның «Асрау кыз» (В. Апанаев тәрҗемәсе), билгесез авторның «Хатыннар хәйләсе» комедия һәм драмаларын күрәбез. Европа телләреннән тәрҗемә иткән әсәрләр арасында Л. Мостафа тәрҗемәсендә чыккан Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт»ен күрсәтеп була.

«Театр мәҗмугасы» сериясенә кергән әсәрләр арасында төп урынны татар әдипләре әсәрләре алып тора. Аларның кайберләре инде искә алынып үтелде. Бу сериягә, шулар өстенә, Г. Камалның «Беренче театр», «Уйнаш», «Кайнеш», «Безнең шәһәрнең серләре», Ф. Әмирханның «Яшьләр», «Тигезсезләр», Г. Кариевның «Артист», Исхак Казаковның «Помада мәсьәләсе», Г. Рәхимнең «Дача кайгысы», Г. Ильясның «Батыр тегүче һәм үги ана», авторы күрсәтелмәгән «Бер сәгатьлек хатын» һәм башка драма, камедияләрне өстәргә мөмкин. Шушы сериядә чыккан әсәрләр арасында Гафур Коләхметовның «Яшь гомер» драмасы да бар. Казан цензоры Н. Ф. Катанов тарафыннан «эшчеләр союзы һәм пролетариат» турындагы күп урыннары сызылып дөнья күргән бу драма пайтәхеттә яшәгән, элек татар китабы цензоры булган В. Д. Смирнов кулына эләгә. Бу китап белән танышуга В. Д. Смирнов матбугат эшләре үзәк комитетына донос яза. «Эшче пролетариатка, аның атаманнарына дифирамба җырлаучы» бу әсәрне цензор ни өчен басарга рөхсәт биргән, драманың төп максаты «пролетарийларда, турысын гына әйткәндә, сукбайларда мөлкәтле сыйныфларга һичбер нигезсез дошманлык тудырырга тырышу һәм шул фикергә татар массаларын ышандырырга маташу» диг драманы тыярга чакыра. Шушы донос белән китапны эзәрлекләү башлана, аны басарга рөхсәт иткән Н. Ф. Катановка каты шелтә ясала, китапның нашире Ә. Хәсәни өстеннән күзәтү оештырыла.

1908 елгы тентү вакытында «мин сәяси китаплар бастырмадым», «Гасыр» нәшриятын ачкач та, анда «киләчәктә андый әсәрләр бастырмаячакмын» дип сүз биргән Ә. Хәсәнинең бу сүзләре губернатордан нәшрият ачар өчен рөхсәт алуны җиңеләйтү өчен генә әйтелгәне күренә. Моңа «Яшь гомер» драмасын басу үзе мисал булып тора. Шуның өстенә Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын басуга керешкән нәшриятның да «Гасыр» икәнен искә төшерсәк, «сәяси китаплар басу белән» шөгыльләнмәячәкмен дип бирелгән сүзнең ни өчен әйтелгәне яхшы аңлашыла. Аның «Хифзыссыйхәт» сериясендә чыккан китаплары да рус галимнәре, медиклары әсәрләреннән тәрҗемәләр. Алар арасында беренче ярдәм күрсәтү, аптека һәм дарулар, акушерство һәм гинекология, педиатрия, санитария буенча китапларны күрәбез. Медицина буенча басылган әсәрләр арасында берсе — «Рәсемле хифзыссыйхәт дәресләре» генә татар врачыныкы, аның авторы Габдулла Кугешев.

«Гасыр»ның «Голум вә фәннүн» сериясендә басылган китаплары фән, техника казанышларын аңлатучы фәнни-популяр хезмәтләр. Аларның күбесе укучыларда дөньяга материалистик караш тәрбияләүгә хезмәт иткән әсәрләр. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен аларның исемнәре белән танышу да җитә. Алар рус мәгърифәтчесе В. Лункевичның «Күк һәм йолдызлар», «Җир» (Ә. Хәсәни тәрҗемәләре), «Бер тамчы суда тереклек» (Г. Гобәйдуллин тәрҗемәсе), «Су» әсәрләре, «Телләр тарихы» исемле атаклы рус мәгърифәтчесе Н. Рубакин хезмәте (С. Рахманколый тәрҗемәсе) һ. б. Бу сериягә кергән китаплар арасында Идрис Хәмидовның «Гыйлем хайванат»тан калганнары барысы да рус теленнән тәрҗемә ителгән хезмәтләр. «Гасыр» нәшрияты оештырылганда анда башта уку-укыту китаплары басу күздә тотылмый, бу эш белән башка татар нәшриятлары ул вакытта киң шөгыльләнәләр. Нәшриятның халык өчен зарури, дөньяви китаплар басуын, аларның югары сыйфат белән чыгарылуын күргән авторлар Ә. Хәсәнине мәктәпләр өчен китап басу эшенә дә өнди башлыйлар. Әнә шуннан чыгып «Гасыр» «Дәрес китаплары» исеме астында яңа серия ачып җибәрә. Бу сериядә Г. Ибраһимовның «Татар сарыфы», «Татар нәхүе», «Яңа әдәбият», «Татар имласы», Г. Алпаровның «Татар әлифбасы», Г. Фәхретдиновнең «Рәсемле җәгърафия», «Рәсемдә гыйльми нәбатат», Г. Сәйфуллинның «Инша дәресләре», Н. Надиевның «Русия тарихы», Ш. Әхмәдиев белән Г. Гафуровның (Г. Чыгтай) «Туган тел», «Беренче мөгаллим», «Икенче мөгаллим» кебек китаплары басылып чыга.

Мәктәпләр өчен чыгарылган уку китаплары арасында үзләренең эчтәлеге белән энциклопедик характердагы хрестоматияләр бар. Менә С. Рахманколый чыгарган, ике кисәктән торган «Мөнтәзәм кыйраәт китабы». Анда уку өчен шигырьләр, хикәяләр, мәсәлләр, мәкаль-табышмаклар белән беррәттән бик күп темаларга популяр мәкаләләр урнаштырылган: «Ашамлык вә ачлык», «Кием-салым», «Җир вә туфрак», «Һава», «Кояш», «Су», «Тамчылар», «Таш», «Яңгыр һәм кар», «Чык вә кырау», «Ат», «Арыслан», «Җылан вә кәлтә», «Бер тамчы су», «Игенчелек», «Балыкчылык», «Хәйван асраучылык», «Игенченең дуслары вә дошманнары», «Үсемлекләрнең үрчүе», «Агачларның үсүе», «Көчнең алмашынуы», «Ватанымыз», «Волга», «Кавказ», «Казан» һ. б. Икенче кисәгеннән дә үрнәкләр китерик: «Адәмнең гәүдәсе», «Гыйльме хикмәт вә кимия», «Җирнең рәвеше», «Дөньяның кырые бармы?», «Эссе һәм салкын», «Көн һәм төн», «Ел фасыллары», «Халыклар вә мәмләкәтләр», «Русиянең башлануы», «Русиянең хәзерге вә борынгы хәле», «Куликово сугышы», «Петр Великий», «Екатерина Вторая», «Мәгърифәт» һ. б.

Хөсәен Әбүзәров төзегән ике томлык «Уку китабы» да үзенең эчтәлеге белән бик бай мәгълүматларны эченә алып тора. Ул Л. Н. Толстойның рус мәктәпләре өчен төзегән, йөзгә якын тапкыр басылып чыккан уку китабын хәтерләтә. Х. Әбүзәров китабында да уку өчен шигырьләр, кыска хикәяләр, мәзәкләр, мәсәлләр белән бер рәттән төрле өлкәләр буенча популяр аңлатмалар китерелә, шулар белән бер рәттән ул үзенең китабына мул итеп татар халык авыз иҗаты әсәрләрен дә кертә.

«Дәрес китаплары» сериясендәге китаплар бик кыска вакыт эчендә икешәр, өчәр мәртәбә басылып чыгуы аларның ни хәтле популяр булуын, аларны олылар да яратып укуын күрсәтә.

«Гасыр» нәшрияты «Халык әдәбияты» сериясе белән дә китап басу эшенә керешә, шул сериядә Х. Бәдигыйның татар халык җырлары, мәкальләре, табышмакларыннан торган өч томлык китабы чыга.

«Гасыр» нәшрияты чыгарган С. Рахманколый белән Г. Кәрамның «Урысча-татарча мөкамаль лөгать» турында да бер-ике сүз әйтми үтү килешмәс. Бу зур күләмле булуы белән генә түгел, төзелеше ягыннан да гаять камил эшләнгән, һәр сүзнең мәгънәсе аңлатылган, һәр сүзнең басымын күрсәткән сүзлек буларак та татар лексикографиясендә үрнәк булырлык хезмәт була. Ул киң катлау татар укучылары тарафыннан гаять җылы кабул ителә. Аның турында татар вакытлы матбугаты да күп язып чыга. «Шура» журналы (1911, 7 сан) бу уңай белән: «Шәкертләр, мөгаллимнәр вә гомумә һәр сыйныф халкы тарафыннан көтелеп тормакта булган ошбу әсәр шәмди басылып базарга чыкты. Бонда русча сүзләр рус хәрефләре илә язылып үз лөгатемез (төрки)гә тәфсир иделмешдер. Габделкаюм әфәнде Насыйри һәм бер лөгать тәртип идеп бастырмыш иде», «бу көндә (аның — Ә. К.) бер нөсхәсе дә калмамышдыр... Ошбу әсәр илә иң кирәкле вакытында нәшир улдымыштан халкымызның истафада итәчәк-

ләрендә шөбһә юк. Һәр хосусый вә мәктәпләрдә берәр нөсхәсе улынырга тиешле»,— дип язып чыга. Әстерхандагы «Идел» газетасы да (1911, 339 сан) «Казанның «Гасыр» көтепханәсе тарафыннан нәшер улынмыш, вә С. Рахманколый һәм Г. Кәрам тәртип иделмеш «Урысча-татарча мөкамаль лөгать» китабы... русча белгән вә белмәгән кешеләрнең барсына да бик кирәк китап» дип аны хуплап каршы ала.

Бу сүзлекнең ни кадәр популяр булуы аның 1921 елда яңадан басылуы һәм үзбәк теленә тәрҗемә ителүендә дә ачык күренә. Ул 1927—1928 елларда Ташкентта ике том булып басылып чыга. Аның титул битендә болай дип күрсәтелгән: «Рахманколый С., Кәрам Г. Русча-үзбәкчә мөкамаль лөгать. Хар кәлиманең турли мәгъналари вә рус телендә ишлатилаб юргян чет сүзләр тәмам курсәтелгән. Тәз. 2 нче нәшридән үзбәкләшдерди Ашуран Зохири. Ред. И. Кулиев».

«Гасыр» чыгарган китапларга күзәтүне шушында тәмамлап, бу нәшриятта дини, халык арасында популяр җыр, кыйссалар басылмавын да әйтеп үтәргә кирәк. Китап басу өлкәсендә башыннан ахырына кадәр демократик позицияләрдә торган «Гасыр» нәшрияты кебек «Көтепханәләрне» XX йөз башы татар нәшриятлары арасында табу җиңел түгел. «Гасыр»ның бу ягын заманында ук күргәннәр: «Ошбу ширкәтнең һәр вакыт әһәмиятле вә файдалы әсәрләр нәшир итделегә күренәдер. Гүзәл кәгазьдә, ачык хәрефләр илә нәфис рәвешдә басылмыш китаплары белән ул башка нәшриятлардан аерылып тора» дип язып чыга «Шура» журналы (1911, 7 сан).

«Гасыр» нәшриятының культурабызда тоткан урынын билгеләү кирәк булса, анда басылган әдип, галимнәрнең исемнәрен санап үтү генә дә җитәчәк. Алар Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Колахметов, С. Рәмиев кебек классиклар. Г. Алпаров, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Г. Газиз, Г. Гафуров, Ш. Әхмәдиев, С. Рахманколый, Г. Кәрам, З. Нуркин, С. Сөнчәләй, Г. Кариев, И. Казаков, Г. Фәхретдинев кебек тарихта эз калдырган күренекле шәхесләр.

«Гасыр» нәшриятының китап репертуары белән танышкач, аның басу өчен әсәрләрне бик ныклап сайлап алуын, бу сайлауда критерий булып аның халык мәнфәгатенә туры килүе, әдәбиятыбызга, культурабызга ярдәм итүгә нигезләнгән икәнен күрәбез.

«Гасыр»ның нәшриятчылык белән шөгыльләнүе турында сүз барганда аның татар китап тарихында беренче буларак, татар әдипләре, сәнгать эшлеклеләренең портретларын басу эшенә керешүче беренче «көтепханә» булуын да әйтеп үтәргә кирәктер. Ә. Хәсәни «Гасыр» нәшрияты исеменнән 10 нчы еллар башында үзе хөрмәт иткән таныш язучыларның, артистларның рәсемнәрен почта открыткасы итеп басуга керешә, алар арасында без Г. Камал, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Кариев белән С. Гыйззәтуллина, «Сәйяр» труппасы артистлары һәм башка открытка-фотолар күрәбез.

«Гасыр» нәшриятының китаплары турында сүз барганда, аларның полиграфик, редакцион һәм художество эшләнеше ягыннан да югары сыйфатлы булуын күрсәтергә кирәк. Бу турыда заманында югарыда искә алган «Шура» журналы да язып чыга. Аның китаплары яхшы кәгазьдә, ачык, матур шрифтлар белән, редакцион яктан текстлары камил эшләнеп басылганнар. Шул ук вакытта Ә. Хәсәни, басылган информацияне укучыларга яхшырак аңлату йөзеннән китапларда иллюстрация куллануга зур игътибар бирә. Бигрәк тә фәнни-популяр сериягә кергән басмаларда бу ачык чагыла. Мәсәлән, 54 битле «Җир» китабында 27 иллюстрация, 56 битле «Күк һәм йолдызлар» китабында 34, «Су» китабында 26 рәсем урнаштырылган. Инде әйтеп үткәнчә, Ә. Хәсәни әдипләрнең әсәрләрен басканда аларның китапларына авторларның рәсемнәрен дә бирә башлый.

Яхшы кәгазьдә, зур иллюстрацияләр белән басу китапның үз бәясен арттыра. Ләкин шулай булса да «Гасыр» чыгарган китапларның сатылу бәясе башка татар китаплары бәясе белән бертигез була. «Гасыр» басмалары белән спекуляция ясамасыннар өчен Ә. Хәсәни китапларның үзенә аның бәясен бастырып чыгара. Революциягә хәтле чыккан китапларда бәясен күрсәтеп басу әле китапчылык практикасына кермәгән була. Әгәр «Гасыр» доход артыннан куса, ул китапның сәнгатьчә эшләнешенә әһәмият бирмәс иде.

«Гасыр»ның доход артыннан кумавы ул чыгарган китапларның тиражында да чагыла. Әгәр XX йөз башында чыккан татар китапларының уртача тиражы 7000 белән хисапланса, «Гасыр» чыгарган китапларның уртача тиражы 4000 белән исәпләнә. Нәш-

рият китап сату эше белән киң шөгыльләнми. «Гасыр» нәшриятын ачарга бирелгән шаһәдәтнамә буенча Ә. Хәсәни төрле җирләрдә китап кибетләре ачарга хаклы булса да, ул китап сату белән нәшрият эшеннән бушаган арада гына шөгыльләнгән. Китап сату нәшриятның эш бүлмәсе белән рәттән икенче кечкенә генә бүлмәдә оештырылган була. Нәшрият чыгарган китапларны сату өчен Ә. Хәсәни аларны комиссион тәртиптә «Мәгариф», «Милләт», «Сабах» һәм башка ширкәтләрнең китап кибетләренә дә тапшырып торган. «Гасыр»ның үз типографиясе дә булмый. Аның заказлары нигездә И. Н. Харитонов, аннан «Өмед» типографиясендә, өлешчә «Берадәрән Кәримовлар», «Милләт» басмаханәләрендә басылып килә.

«Гасыр» нәшриятын ачучы Ә. Хәсәни һәм Г. Х. Рәхмәтуллин кем булганнар соң? «Гасыр» көтепханәсен ачу уңае белән кергән үтенеч буенча губернатор аларның кем булуын тикшерүне оештырган. Әнә шул яшерен тикшерү буенча җыелган мәгълүматлардан күренгәнчә, Әхмәтгәрәй Хәсәни 1883 елның 15 декабрендә Казан губернасы, Казан өязе Әтнә волостеның Олы Әтнә авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килгән [1]. Әтисе Сибгатулла Нургали улы Хәсәнов 1887 елда гаиләсе белән Казанга күчеп килә. Биредә сәүдә эше белән шөгыльләнә башлый, тиз арада аякка баса һәм манфактура белән сату итүче сәүдәгәргә әйләнә.

Әхмәтгәрәй башлангыч белемне мәдрәсәдә ала, аннан әтисе аны укытучы яллап өйдә укыта. Ә. Хәсәни рус, төрек, француз, гарәп телләрен ныклап өйрәнә.

Рус, Европа әдәбияты, сәнгате, тарихы буенча киң мәгълүматлы Ә. Хәсәни шәрык культурасын да яхшы белгән. Шул ук вакытта татар мәгърифәтчелеге йогынтысында тәрбияләнгән Әхмәтгәрәй яшьтән үк язучылык, тәрҗемәчелек өлкәсендә дә көч сынап карый. Зәйнәп Хәсәния үзенең истәлекләрендә «Ирем Гәрәй Хәсәни әдәбиятны бик ярата торган иде. Шуңа күрә ул бөтен гомерен, тормышын нәшрият эшләренә, китап бастырып тарату эшләренә багышлады»,— дип яза [2]. Ә. Хәсәни нашир, редактор гына түгел, ул язучы да. Архив документларыннан без аның әдәбиятта «Г. Ильяс» псевдонимы белән чыгуын ачыкладык. Югарыда искә алынган «Гасыр» нәшрияты бастырып чыгарган «Хат болгатты», «Деньщик Гали» комедияләре, «Батыр тегүче һәм үги ана» китабы «Г. Ильяс» тарафыннан язылганнар.

Нашир, редактор, язучы булу өстенә Ә. Хәсәни тәрҗемәче дә. Югарыда искә алынган В. Лункевичның «Җир», «Күк һәм йолдызлар»ын ул тәрҗемә иткән. Ә. Хәсәни тәрҗемәсендә А. П. Чеховның «Бәхәс» («Аң», 1914, 16, 17, 18 саннар), А. В. Амфитеатровның «Укучы-дуст» («Аң», 1914, 23 сан), А. Апинянскийның «Нинди киңлек» («Аң», 1915, 15, 16 саннар) хикәяләре басыла. Аның француз теленнән турыдан-туры тәрҗемәсе астында «Аң» журналында атаклы француз язучысы Анатоль Франсның «Бине Бәшир хикәясе» (1916, 21 сан) чыга. Шунысына игътибар итү кирәк: Ә. Хәсәниненең үз әсәрләре дә, тәрҗемә ителгән әсәрләре дә жанрлары буенча юмор-сатира әсәрләре.

Ә. Хәсәни яшьтән үк рус телен белгән, рус әдәбиятын яратып укыган, аңа зур мәхәббәт белән караган, шуңа күрә ул татар әдәбиятының да рус әдәбияты үрнәгендә тизрәк үсә алачагын аңлап эш иткән. Ә. Хәсәни «Гасыр»да басылган китаплардагы теге яки бу рус язучысының тормышы һәм иҗаты турындагы очеркларның да авторы. Бу яктан ул әдәбият белгечә булмасак та тәкъдир ителергә тиешле кеше. «Гасыр» нәшриятының китап сату өчен бер бүлмәсе, аның артында Ә. Хәсәни эшли торган икенче бүлмәсе булуын әйткән идек инде. Әнә шул икенче бүлмә татар әдипләре, галимнәре, артистлар, укытучылар очраша торган әдәби салонга әйләнә. «Аң» журналы оештырылгач, шушы бүлмә журналның редакциясенә әверелә. «Аң» журналының җаваплы секретаре булып берничә ай эшләгән Г. Ибраһимов та шул бүлмәдә эшли.

Бу бүлмәдә язучылар, артистлар, галимнәр белән беррәттән «Аң» һәм «Гасыр»да басылучы авторлар да еш булып тора. Биредә уку-укыту, мәктәп-мәдрәсә, әдәбият, сәнгать, халык мәгърифәте, яңа чыккан китаплар турында фикер алышулар, бәхәсләр еш булып тора. Бу очрашуларны яхшы белгән Зәйнәп Хәсәния бу турыда менә болай искә ала: «Гасыр» нәшриятының хәзерге Татарстан урамында ике бүлмәсе бар

---

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 1 ф., 4 тасвирлама, 3749 эш, 4 б.
[2] Хәсәния З. Хатер турында.— Азат хатын, 1967, 4 сан, 16 б.

иде. Эчкәре бүлмә — редакция, эш бүлмәсе, алгы бүлмә кибет. Менә шул эш бүлмәсе һәрвакыт гөр килеп тора иде. Анда Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Х. Ямашев, Г. Коләхметов, Г. Рәхим һ. б. бик еш булалар иде. Алар һәр яңалык турында сөйләшәләр, үзләренең яңа әсәрләрен укып фикер алышалар иде».

«Гасыр» нәшриятының эше рәткә салынгач [1], Ә. Хәсәни татарча журнал чыгарырга хәзерләнә башлый. һәм үзенең журнал чыгару турындагы планнары белән киңәшләшү өчен шул «эш бүлмәсенә» үзенең якын күргән таныш язучыларын чакыра. Бу киңәшмәгә жандарм агенты да үтеп кергән. Аның бу киңәшмә турында жандарм управлениесенә язган доносында без түбәндәге юлларны укыйбыз: «Шушы елның (1911 нче — Ә. К.) 26 июлендә Евангелистовский урамда Хәсәнов йортында татар әдәбияты түгәрәге җыелды. Бу җыелыш татар телендә рус журналлары кебек калын әдәби-сәяси журнал чыгару турында карар кабул итте. Аның максады яшьләрне оештыру, берләштерү булачак... Бу мәсьәләне караган шушы җыелышта (Габдел) Бари һәм (Әхмәт) Гәрәй Хәсәновлар... Габдулла Тукаев, Фатих Әмирханов, учитель Коләхметовлар катнаштылар» [2].

Профессор Р. И. Нәфиков бу «әдәби түгәрәкне» оештыручы һәм аның җитәкчесе татар большевигы Х. Ямашев булу турында яза [3]. Х. Ямашев үзе дә «Гасыр»ның эш бүлмәсендә җыела торган әдәби түгәрәк кичәләрендә еш булган. Менә бу фактлар Ә. Хәсәнинең Х. Ямашев белән якын таныш булуы өстенә, аның җитәкчелеге астында эшләвен дә күрсәтә. Шушы уңайдан Х. Ямашевның 1912 елның 13 мартында кичке 8 сәгатьтә «Гасыр»ның эш бүлмәсендә Ә. Хәсәни, Г. Коләхметов, Ш. Әхмеров һәм бэшка татар зыялылары белән сөйләшкәндә баш миенә кан йөгерүен, шушы бүлмәдән соңгы юлга китүен дә искә алыйк [4]. Бу факт та Х. Ямашевның Ә. Хәсәни белән никадәр якын таныш булуын, «Гасыр»ның эш бүлмәсен кирәкле кешеләр белән очрашу урыны итеп файдалануын күрсәтә.

Шушы әдәби түгәрәктә журнал чыгару турында карарга килүдән ел ярым вакыт үткәч, Ә. Хәсәни губернаторга мөрәҗәгать итеп журнал чыгарырга рөхсәт ала. 1912 елның 15 декабрендә «Аң» журналының беренче саны басылып чыга. Журналның беренче бите Г. Тукайның журнал чыгу уңае белән махсус язылган шигыре «Аң» белән башлана. Шушы номердан алып, Г. Тукай исән вакытта журналның һәр саны шагыйрьнең яңа шигырьләре белән ачыла. «Аң» журналының секретаре булып эшләгән Зәйнәп Хәсәния «Г. Тукай журналдагы әдәби хәрәкәткә җитәкчелек итә, юнәлеш бирә иде»,— дип искә ала.

Бу журналның оештырылу, эшләп килү тарихы, әдәбиятыбызда, культурабызда тоткан урынын билгеләү киләчәктә өйрәнелергә тиешле махсус тема.

Ә. Хәсәнигә «Гасыр»ны оештыруда компаньон булып катнашкан, вакытлыча «Аң» журналының редакторы да булып эшләгән Г. Х. Рәхмәтуллин кем булган? Архив документларында ул «Абдрахман Рахми», «Абдрахман Рахматуллин» дип тә искә алына [5]. Полиция тарафыннан аның турында тупланган документлардан күренгәнчә ул 1908 елда Казанның Тихвинская урамында Иманкуловлар йортында яшәгән [6].

Г. Рәхмәтуллинның Г. Кәрам исемендәге псевдоним белән чыккан күренекле театр тәнкыйтьчесе булуын без Р. Мөхәммәдиев хезмәте буенча беләбез. Анда Г. Кәрамның биографиясе турында шактый гына мәгълүматлар да китерелгән [7]. Ул 1878 елда Казанда туган, яшьтән ятим калгач, аны сәүдәгәр Мифтах Иманкулов тәрбиягә алып үстергән. Башта Казанның бер мәдрәсәсендә укыган, аннан Стамбул университетының әдәбият факультетын тәмамлаган. Рус, Европа, татар, шәрык культурасын яхшы белгән зыялы булган. 1905 елда Казанда беренче татарча вакытлы матбугат барлыкка килү белән «Казан мөхбире», «Йолдыз» газеталарында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән катнаша башлый. Югарыда «Гасыр» нәшриятында башка телләрдән алып басылган күп кенә әсәрләрнең тәрҗемәчесе Г. Х. Рәхмәтуллин икәнен күрдек. Ул үзе-

---

[1] «Гасыр» нәшрияты чыгарган китапларның бер өлеше «Гасыр», күп өлеше «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә ширкәсе» грифы астында басылган.

[2] Нафигов Р. И. Социально-политические взгляды Г. Тукая.— В кн.: Габдулла Тукай. Казань, 1968, 46 б.

[3] Шунда ук, 46 б.

[4] Коләхметов Г. Сайланма әсәрләр. Казан, 1981, 359 б.

[5] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 828 ф., 1 тасвирлама, 22 эш, 22, 66, 88 битләр.

[6] Шунда ук, 273 ф., 1 тасвирлама, 5 эш, 15 б.

[7] Мөхәммәдиев Р. Әгәр без янмасак... Казан, 1980, 122—130 бб.

нең тәрҗемәләрендә «Г. Х. Рәхмәтуллин» дип чыкса, әдәби-тәнкыйть әсәрләрен нигездә «Г. Кәрам» псевдонимы белән яза.

Аның псевдонимнарына карата тагын бер кызык факт бар. «Гасыр» нәшриятының «1913 нче ел өчен чыгарылган китаплар исемлегендә Борисовскийның «Аулакта көрәшү» комедиясен татарчага тәрҗемә итүче итеп Г. Кәрам күрсәтелә, ә басмада аның тәрҗемәчесе «Гали Рөстәм» диелгән. «Гали Рөстәм» дигән исем «Гасыр» чыгарган тагын ике китапта очрый: берсе В. Пинегинның «Йорт хайваннары тәрбиясе»нең тәрҗемәчесе, ә икенчесе «Көтелмәгән кадерле кунак» комедиясенең авторы. Әгәр «Гасыр» нәшрияты китапларының исемлеген төзүчеләр Ә. Хәсәни яки З. Хәсәния булуын искә алсак, алар исемлекне төзүдә китапка карамыйча гына авторларны, тәрҗемәчеләрне күңелдән белүе буенча гына эш иткәннәр, китапта аның нинди исем белән чыгуын истән чыгарулары бик мөмкин дип уйлыйбыз. Шуннан чыгып без «Гали Рөстәм» Г. Кәрам булырга тиеш дип уйлыйбыз, ягъни ул Г. Рәхмәтуллинның икенче псевдонимы булган. Гали Рөстәм исемле автор татар матбагачылыгында башка бер басмада да, журнал битләрендә дә очрамый.

Г. Кәрамның татар театры тәнкыйте өлкәсендәге эшчәнлеге Р. Мөхәммәдиевнең күрсәтелгән хезмәтендә тикшерелгән, шуңа күрә без аның эшчәнлегенә тикшерелә торган тема буенча гына тукталабыз.

Г. Кәрам, Г. Ибраһимовтан соң беренчеләрдән булып бөек украин язучысы Тарас Шевченко турында язып чыккан тәнкыйтьче дә. («Аң», 1915, 107—108 бб.) «Аң» журналы битләрендә татар театры, аның спектакльләре, аерым артистлар турында басылган барлык хезмәтләр аның каләме астыннан чыккан. Ә аларның саны йөзгә якынлаша. Ул рус һәм төрек телләреннән шактый гына матур әдәби әсәрләр тәрҗемә иткән. Аның фәнни-популяр әсәрләр тәрҗемә итүен «Гасыр» нәшриятының китап репертуарын тикшергәндә күреп үттек.

Бөек Октябрь революциясеннән соң да Г. Кәрам театр тәнкыйте өлкәсендә даими эшләп килә [1], шул ук вакытта тәрҗемә эшен дә дәвам итә. Аның тәрҗемәсендә татар телендә В. И. Ленинның «Нәрсә эшләргә?» (1930), «Коммунистлар интернационалы» (1926) әсәрләре басылып чыкты.

Шулар өстенә Г. Кәрамның пайщик буларак «Гасыр» нәшриятын ачуда катнашудан тыш, Ә. Хәсәни белән рухи яктан да бик якын кеше булуын күрәбез.

Ә. Хәсәни, Г. Рәхмәтуллин кебек фидакарьләр тарафыннан оештырылган «Гасыр» нәшриятының аң-белем таратудагы эшчәнлеге культурабыз тарихының якты сәхифәләрен тәшкил итә.

---

[1] Кәримуллин Ә. Татар сәхнәсе. Казан, 1979, 309 б.

## Сәлам Алишев

# ПУГАЧЕВ ПОЛКОВНИГЫ

Татарстанның хәзерге Биектау районының Олы Кавал авылында моннан ике йөз ел элек, ягъни XVIII гасырның икенче яртысында 300 ләп йорт, 2 мәчет, бер мәдрәсә һәм бер мәктәп булган. Ул үзенең матур табигате, кешеләренең киң күңеллеге, эшчәнлеге белән тирә-юньдә дан тоткан. Ләкин халык арта барган саен, иген игү өчен җир җитми башлаган. Җитмәсә, күршегә бер алпавыт килеп утырган һәм байтак җирне үзенә тартып алган. Шуның өстенә крестьяннар күптөрле салымнардан да җәфа чиккәннәр.

Менә шундый социаль һәм милли изелү шартларында яшәгән Олы Кавал авылында Әхмәт картның Исхак исемле малае үсеп буйга җитә. Ул 1732 елда туып, үз авылында 1760 елларга кадәр тора. Шунда өйләнеп, гаилә дә корып җибәрә. Ләкин җир җитмәү бәхетне читтән эзләргә мәҗбүр итә. Башка бик күп якташлары кебек ул да Оренбург якларына китеп урнашырга ниятләгән. Билгеле булганча, XVII—XVIII йөзләрдә Казан, Зөя, Сембер өязләреннән ярлы татар крестьяннары Оренбург якларына күпләп күчеп килгәннәр. Минзәлә һәм Бөгелмәдән Оренбургка кадәр Яңа Мәскәү юлы дип аталган җир буйлап татар авыллары үзенә күрә бер «коридор» хасил иткәннәр. Алар арасыннан Каргалы, Йөзәй, Сарманай, Биккол, Мостафа һ. б. кайберләре бик зур булып үсеп киткәннәр. Исхак Әхмәтов та 1763 яки 1764 елда Мостафа авылына күчеп килә, үз хуҗалыгын оештырып җибәрә һәм шунда крестьяннар сугышына кадәр гаиләсе белән яши. Димәк, аны Казан арты егете дип тә, Муса Җәлилнең ерак авылдашы дип тә санарга мөмкин.

Исхак Әхмәтов 1774 елда пугачевчылар эшен тикшерүче яшерен комиссиядә сорау алган чакта болай сөйләгән: «1773 елның сентябрь ахырында мин бер олау ашлыгымны төяп, Оренбургка сатарга алып бардым. Ләкин аны сатып эшне бетергәч, шәһәр капкаларын бикләп куйдылар һәм беркемне дә чыгармый-кертми башладылар». Исхакның Оренбургка ашлык сатарга баруы гадәти хәл. Аңа җан башыннан салым түләү өчен генә дә 17 пот арыш оны сатарга кирәк булган. Ул вакытта арыш онының поты 10 тиен торган. Ә менә шәһәр капкаларын бикләп кую инде гадәти хәл түгел, ул Пугачев восстаниесенең башлануы белән бәйләнгән. Билгеле булганча, 1773—1775 еллардагы Крестьяннар сугышы Җаек (хәзерге исеме Уральск) шәһәреннән ерак түгел җирдә 1773 елның 17 сентябрендә башланган. Е. И. Пугачев Урал казаклары, аларга кушылган татарлар һәм калмыклардан бер отряд туплап, Җаек елгасы буендагы крепостьларны ала башлый. Аңа тиздән изелгән халык вәкилләре — татар, башкорт, мари, чуваш, удмурт крестьяннары күпләп кушыла башлый. Урал заводларында эшләүчеләр, солдатларның да бер өлеше аның ягына чыга. Е. И. Пугачев вак гарнизоннарны тар-мар итә-итә 1 октябрьда Каргалы авылына килә, монда аны гади халык бик зурлап каршы ала. 4 октябрь көнне Пугачевның төп көчләре Оренбургка килеп җитәләр һәм 5 октябрьда шәһәр тулы чолганышта кала. Әнә шул вакытта инде капкалар ябыла һәм бик күп кеше, шул исәптән Пугачевны кабул итәргә теләүчеләр дә, теләмәүчеләр дә, хөкүмәт гаскәрләре дә бикләнеп калалар. Сорау алганда Исхак Әхмәтов, мин анда декабрь ахырына кадәр тордым, ди. Ләкин бу сүз сорау алучыларны ялгыштыру өчен генә әйтелгән. Чөнки ул төрле сәбәпләр табып шәһәрдән чыгып китәргә октябрь

аенда ук омтылган. Утенечләрен исәпкә алып булса кирәк, октябрь ахырында Оренбург губернаторы Рейнсдорп һәм коллежский советник Тимашев аны Бөгелмәдән Яңа Мәскәү юлы белән килүче баш күтәрүчеләрне тар-мар итәргә юнәлгән хөкүмәт гаскәрләренең башкомандующие генерал Кар «җәнабларына» тапшырырга дип яшерен пакет биреп чыгарып җибәрәләр. Монда шуны әйтеп узыйк: губернатор Рейнсдорп әле 4 октябрьдә ук, Е. И. Пугачевны тотып Оренбургка китерү өчен, соңыннан Пугачевның якын көрәштәшенә әйләнгән Хлопуша-Соколовны да шәһәрдән шулай чыгарып җибәрә. Ләкин ул юлда очраган Муса Галиев белән туп-туры Е. И. Пугачевка килә һәм баш күтәрүчеләр сафына баса. Исхак Әхмәтов та Е. И. Пугачев урнашкан Берда бистәсенә килә һәм аңа губернатор пакетын тапшыра. Димәк, ул үз авылына да кайтмаган, генерал Кар янына да бармаган. Е. Пугачев үзенең укый-яза белмәгәнлеген күрсәтмәс өченме яисә кешеләрдән анык турында сорашу өченме, пакетны алгач, Исхакны А. А. Овчинников янына җибәрә. Овчинников бу вакытта баш күтәрүчеләр гаскәрендәге казакларның походный атаманы итеп сайланган була һәм шулай ук гомуми гаскәр эшләре белән дә шөгыльләнгән. Ике сәгатьтән соң, ди Әхмәтов, мине Пугачев яңадан чакыртып алды һәм Каргалы татары Муса Галиев хуп күрүе буенча үзенең хезмәтендә калырга кушты. Сорау алу вакытында Әхмәтов Оренбург камалышы вакытында пугачевчылар сафындагы хезмәте турында бөтенләй диярлек сөйләмә. Ләкин аның актив восстаниечә булуы турында фараз итәргә бик мөмкин. Хәлбуки, 1774 елның март аена кадәр, ягъни камалыш беткәнче байтак мөһим вакыйгалар булып уза.

Генерал Кар армиясе восстаниечеләр тарафыннан 8—9 ноябрьларда тулысынча тар-мар ителә. Бу сугыш Йөзәй авылы янында була. Пугачевчыларның җиңүенә төп сәбәпләрнең берсе итеп, тирә-як халкының восстаниечеләр белән бер булып, хөкүмәт гаскәрләренә каршы сугышка чыгуларын да әйтеп үтәргә кирәк. Мостафа авылының бер кешесе — Зәет Кадеев әсир төшкәч бу турыда шулай сөйләгән: «Ноябрь башында Йөзәй авылы старшинасы Шәрип Юнысов безнең авылга үзенең татарларын җибәрде. Алар безне Пугачев отрядларына каршы чыкмаска үгетләделәр, һәм без аларга кушылдык, коралланган килеш генерал Кар командаларына каршы сугыштык». Исхак Әхмәтовның Е. И. Пугачевка китергән пакеты да күпмедер роль уйнагандыр, чөнки аңа хөкүмәт гаскәрләренең планы һәм бурычлары язылган булырга тиеш. Халыкның Пугачевны яклап чыгуы төрле формаларда булган. Мәсәлән, генерал Карга кушылырга тиешле 2 нче гренадерлар ротасын олаучы итеп алынган татар крестьяннары туп-туры А. А. Овчинников кулына китереп кертәләр.

1774 елның март ае восстаниечеләр өчен фаҗигале ай була: Пугачев төп көчләре белән Татищево крепостенда, Чика-Зарубин Уфа крепосте янында хөкүмәт гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителәләр.

Бу сугышта җиңелгәч, Е. И. Пугачев белән бергә Исхак Әхмәтов Каргалы бистәсендә, Сакмар шәһәрлегендә була. Сакмардан Е. И. Пугачев аны яхшы аргамакка атландырып Югары Җаек крепостена, башкорт старшина Мәхмүт Кадриевка хат белән җибәрә. М. Кадриев һәр йорттан бер атлы кеше җыярга, ягъни Е. И. Пугачев гаскәренә халык арасында мобилизация үткәрергә тиеш була.

Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар гаскәре һаман ишәя-зурая барып, Урал буе заводлары буйлап хәрәкәт иткән. Исхак Әхмәтов сорау алганда: «Без Пугачев белән Авзян-Петров заводына, аннан Белорецк заводына килдек. Завод кешеләрен армиягә алдык һәм Белорецкийда бер ай чамасы тордык»,— дип сөйләгән. Башка төр документлар белән расланганча, Е. И. Пугачев чынында Белорецк крепостенда өч атнадан артык торган. Чөнки яз көннәрендә юллар өзелгәч, хөкүмәт гаскәрләре дә, пугачевчылар да хәрәкәтсез калганнар. Бу һәр ике як өчен ял итү вакыты булган.

Май аенда хөкүмәт көчләре баш күтәрүчеләрне тагын кысрыклый башлаганнар. Ләкин крестьяннар армиясе дә көчәйгән һәм зурайган. 6 майда Пугачев Магнитный крепостен штурм ясап ала. Бу вакытта аңа каршы хөкүмәт гаскәрләренең зур хәрби көчләре юнәлтелгән. Көнчыгышта генерал Деколонг, Уфа ягыннан подполковник Михельсон һ. б. генераллар пугачевчыларны кысрыклый башлыйлар. Деколонгны алдап, алга үтеп китү өчен Е. И. Пугачев үзенең отряды белән Әхмәт Исхаковны Утлы-Карагай крепостен алырга җибәрә. Һәм менә шул крепостьны уңышлы алу Е. И. Пугачевка юлын алга дәвам иттерергә, генерал Деколонгны читтә калдырып узарга мөм-

кинлек биргән. Деколонг Магнитныйга килгәндә пугачевчылар анда инде булмаганнар. Карагай крепостен алган вакытта Исхак Әхмәтов зур хәрби осталык һәм батырлык күрсәткән булырга тиеш, ләкин бу турыда ул сорау алган вакытта, әлбәттә, сөйләми. Шундый зур хезмәт күрсәтүе өчен Е. И. Пугачевның үзе тарафыннан И. Әхмәтов полковник итеп билгеләнә һәм аның белән шуннан соңгы барлык сугышларында катнаша. Шул турыда сөйләгәннең соңында ул: Пугачевның Казанга юл тотарга ниятләгәнен беренче тапкыр Красноуфимск крепостенда ишеттем, ди. Чыннан да, Красноуфимскидан 11 июньдә чыгып, Е. И. Пугачев 18 июньдә Оса крепостена килгән. Аны алып, Рождественск һәм Воткинск заводлары аркылы ул 29 июньдә хәзерге Татарстан территориясенә керә һәм шул ук көнне Юски авылы аркылы узып, Әгерҗегә килгән. Крестьяннар һәр җирдә Пугачевны хөрмәтләп каршылаганнар, төрле бүләкләр тапшырганнар.

Авыл уртасындагы мәйданның бер ягына баш күтәрүчеләр армиясенә шул авылдан һәм тирә-юньнән килеп кушылучы сугышчылар тезелгән, икенче ягына гади халыкка җәбер-золым күрсәтүчеләрне җәзалау өчен дар агачы ясап куелган. Халык Пугачевка агылган, яңа полклар төзелгән. Е. И. Пугачев Казанга таба хәрәкәт иткәндә, үзе армиянең төп өлеше белән бер авыллардан үтсә, фланглардагы төрле отрядлар икенче авыллар аша үтеп, гаскәрләр киң фронт булып барганнар. Каманы кичкәндә дә, аңа кадәр дә Е. И. Пугачев «Казанга, аннан Мәскәүгә барабыз, тәхетемне алып, бөтен Россиядә гадел патшалык урнаштырабыз», дип, киң агитация ясаган. Рус һәм татар телләрендә манифест, указлар язылып, император Петр III (Е. И. Пугачев үзен шулай атап йөрткән) тарафыннан крестьяннар җан башыннан налог түләүдән, рекрут бирүдән азат ителгәннәр. Халыкларга да үз диннәрен тотарга, милли гореф-гадәтләрен үтәргә хокуклар бирелгән. Крепостнойлар алпавыт коллыгыннан азатлык алганнар. Шуңа күрәдер, Оса крепостенда крестьян армиясе составында 7 мең кеше булса, Әгерҗегә килгәндә ул 12 меңгә, ә Казанга килгәндә 25 меңгә җиткән. Тирсә, Аккуҗа, Сокман, Алнаш, Камай, Бондюг һәм башка кайбер авыллар аша узып, баш күтәрүчеләрнең төп гаскәре 1 июльдә Алабуга шәһәренә килеп җиткән. Пугачев үзе завод хуҗасы Красильников өендә кунган. Ул монда полковник Исхак Әхмәтовны чакырып алган да: «Менә сиңа русча һәм татарча манифестлар. Арча, Җөри һәм Галич юлы авылларында йөр. Манифест һәм указларны укып халыкны восстаниегә күтәр. Казанга юл алып, миңа кушылсыннар. Казан зур шәһәр ул. Аны бөтен халык белән ябырылып алырга кирәк», дигән. Ләкин Исхак бу юлга чыга алмый калган, чөнки Е. И. Пугачев янына Бахтияр Канкаев килеп, бу бурычның инде үтәлгәнлеген, Казанга кадәр юл аның кул астында булуын, ул төбәктәге халыкның восстаниегә күтәрелгәнлеген сөйләгән. Алабугага шулай ук Котловка авылының крестьяны, Е. И. Пугачевның 1773 елның май аенда Казаннан качып киткәч танышкан дусты Карп Карасев та килгән. Пугачев аны Котловка волосте полковнигы итеп билгеләгән һәм Тирсәдә үзенә тапшырылган морза Тәвкилев кызын аңа биреп җибәргән.

Е. И. Пугачев гаскәре Мамадышта 2—5 июльдә булып, 6 сында Арчага юнәлгән. Аңа һәрбер авылдан баш күтәргән крестьяннар төркеме кушылган. Мәсәлән, Саба, Җөри, Нырсы һәм башка кайбер авыллар хезмәткә яраклы барлык кешеләрен җибәргәннәр. Исхак Әхмәтов үз полкы белән төп гаскәрнең алдыннан йөргән. Пугачев полковнигы туган якларына җиңүче булып 12 елдан соң әйләнеп кайткан. 10 июльдә алар Арчадан чыгып Казанга юл тотканнар. Бөтен Казан өязе бу вакытта восстание хәлендә булган. Аты, Казиле, Уракчы тагын башка йөзләгән авыллар азатлык өчен сугышка 40—50 шәр кеше озатканнар. 10 июль көнне Пугачев Ямаширмә авылы янында хөкүмәт гаскәре белән очрашкан. 100 кешелек пехотасы, 100 карабинеры һәм бер батареясы белән полковник Толстой баш күтәрүчеләрне Казанга җибәрмәскә тиеш була. Ләкин кыска гына вакыт эчендә бу отряд тар-мар ителгән: солдатлар халык ягына чыкканнар, офицерлар, гадәттәгечә, үз җәзаларын алганнар. Е. И. Пугачев сугыш кырында кунып, икенче көнне, 11 июльдә Казанга килеп җиткән. И. Әхмәтов әйтүенчә, крестьян гаскәре Казан астындагы Троицк тегермәне (хәзерге компрессор заводы каршысында) янында лагерь корып урнашкан. Бер яктан зур болын җәелеп яткан, икенче якта Казанка елгасы, аның буйлап сузылган әрәмәлек урманга барып тоташкан.

Кичкә таба Е. И. Пугачев якын иптәшләрен алып, шәһәр ныгытмаларын карарга барган. Ни хәлдә булган соң ул вакытта Казан?

Казан XVIII гасырда әле, искедән килгәнчә, өч өлешкә бүленгән: Таш кремль, агач шәһәр яки посад һәм бистәләр. Шәһәрдә тугыз зур урам, 170 ләп кечкенә урам һәм тыкрыклар тәртипсез рәвештә сузылганнар, аларда барлыгы 3940 йорт булган. Халык саны 15 меңнән артык исәпләнгән. Шәһәр тирәли сукночылар, кирпеччеләр, ямщиклар Бишбалта, Кәҗә, Иске һәм Яңа татар бистәләре һ. б. урнашкан. Шәһәрдә 70 ләп «завод-фабрика» булган. Генерал-губернатор фон Брандт кулында 2 меңгә якын гаскәр булган. Казанны баш күтәргән халык массаларыннан саклау өчен власть-лар шәһәр оборонасын оештырырга уйлаганнар. Бистәләрне кертмичә (алар үзләрен үзләре «сакларга» тиеш булганнар) шәһәр оборонасы 4 өлешкә бүленгән: 1) Казанкадан Арча кыры аша (Арча кыры ул вакытта хәзерге Гоголь урамыннан башланган) Кабан күленә кадәр линия генерал Баннер командалыгына, 2) Плотиннан ямщиклар бистәсенә кадәр ара генерал Ларионовка, 3) аннан ары (хәзерге тимер юл вокзалыннан алып) Казанканың яры буйлап, адмиралтейство линиясе, аның командиры полковник Свечин командалыгына бирелгән, 4) Кремльнең төньяк-көнбатыш өлеше, Казанка елгасы буйларының саклау адмиралтейство офицеры Щелин кулында булган. Шәһәрнең күрсәтелгән линияләре хәрби ныгытмалар белән әйләндереп алынган һәм батареялар белән тәэмин ителгән. Пугачев гаскәренең төп өлеше һөҗүм итеп килү юлына хөкүмәт туплары түбәндәге тәртиптә урнаштырылганнар: хәзерге Зур Кызыл һәм Толстой, Карл Маркс һәм Толстой, Бутлеров һәм Толстой урамнары чатларында һәм Калинин урамы буенча 1 нче шәһәр больницасы янында, тау өстендә. Шулай ук кайбер башка җирләрдә дә туплар куелган. Гимназистлар һәм чиновниклар үзләре бер отряд төзеп Арча кырыннан сакларга булганнар. Пугачевчылар эшен тикшерүче яшерен комиссия рәисе генерал Потемкин аңа бирелгән отряд белән алар янында ук урнашкан. Арча кырын ерак түгел әрәмәлекләр белән капланган елга-ермаклар башланып киткән, төньяк-көнчыгышта Казанка елгасы буйлап үзәнлек җәелгән.

Е. И. Пугачев 11 июль кичендә әнә шул урыннарны күзәтеп йөргән, Казанны белүчеләрдән сорашкан. Хәер, ул аны үзе дә яхшы белгән. Мәгълүм булганча, ул 1773 елның 4 январеннан 29 маена кадәр Казан төрмәсендә яткан. Губерна властьларына гаебен аз күрсәтеп, үзенә карата төрмә режимын йомшартуга ирешкән. Аңа шәһәр урамнарында сак астында булса да, ул вакытлардагы гадәт буенча, хәер сорашып йөрергә рөхсәт иткәннәр. Е. И. Пугачев үзен көчле сак астында гомерлек каторгага, Нерчинскига җибәрергә боерган хөкүмәт карары килер алдыннан, ике-өч көн элек, төрмәдән качып китә. Казан губернасы авылларында 29 майдан август башына кадәр яшеренеп йөри дә, шуннан Җаек буйларына китә. Сентябрь аенда, әйткәнебезчә, ул дәһшәтле восстание күтәреп җибәрә. Менә ул яңадан, хәзер инде «бөтенроссия императоры» сыйфатында, баш күтәргән халык юлбашчысы буларак кире әйләнеп Казанга килгән.

Шул ук көннең кичендә аның янына шәһәрнең татар бистәләреннән бер төркем кеше бүләкләр алып килгәннәр, Казанга ничек һөҗүм итәргә кирәклеге турында киңәшләр биргәннәр. Аларны чәй эчереп, указ-манифестлар биреп озатканнар. Әле аңа кадәр үк, көндез пугачевчылардан губернатор исеменә, шәһәр халкына һәм бистә татарларына указлар җибәрелгән була. Аларда шәһәрне «император агъзам хәзрәтләре Петр Федоровичка» сугышсыз бирү, халыкны төрле җәбер-золымнардан коткару турында язылган була. Ләкин властьлар аларга җавап бирмәгәннәр.

Баш күтәрүчеләр лагерь корып урнашу белән шәһәрне алу хәстәренә керешкәннәр. Яңа җыелган крестьяннарны аерым полкларга бүлү һәм аларга командирлар билгеләүдән башлап, тупларны тәртипкә китерү, аларны яшереп алып бару өчен салам, печән олаулары китерү һәм башка бик күп эшләр эшләнгән. Болар белән Е. И. Пугачевның якын көрәштәшләре Овчинников, Творогов, Чумаков, С. Сәетов, К. Арсланов, И. Әхмәтов кебек кешеләр шөгыльләнгәннәр. Шәһәр тирәли кечкенә-кечкенә отрядлар җибәрелгән, алар Казанны камап алганнар һәм аннан беркемне чыгармаска, беркемне кертмәскә, дошман килүен күзәтергә тиеш булганнар. Шулай итеп Казан властьларының тышкы дөнья белән элемтәсе өзелгән.

1774 елның 12 июлендә иртән сәгать 4 тә Е. И. Пугачев киңәшмә җыйган. Бу киңәшмә турында мәгълүм пугачевчы И. Белобородов әсир төшкәч сорау алу вакытында түбәндәгечә сөйләгән: «12 июльдә иртән Пугачев үз янына полковникларын һәм яшерен киңәшчеләре булган Җаек казакларын — Е. Васильевны, И. Твороговны, Ф. Фе-

доровны, А. Афанасьевны, Г. Леонтьевны, татар Идыр Мәхмүтовны һәм башка барлык полковникларны, шулар рәтеннән мине дә чакырып алды да шәһәргә ничек һөҗүм итәргә икәнлеген билгеләде. Ул Казанны алганнан соң Мәскәүгә барачагы, анда патшалыкны алып, бөтен Россия дәүләтенең тәхетенә утырачагы турында сөйләде».

Хәрби киңәшмәдә хәл ителгәнчә, Казанга һөҗүм шул ук көнне иртән сәгать алтыда башланган. Күп милләтле крестьяннар гаскәре дүрт колоннага бүленеп штурм ясаган. Арча кырыннан И. Белобородов колоннасы, Казанка елгасы буйлап Минеев, ә Суконный бистәсе аша Е. И. Пугачевның үз командалыгы астында өченче колонна атакага ташланган. Ә дүртенче колонна татар бистәсе аркылы шәһәрнең көнбатышында һөҗүм иткән. Исхак Әхмәтов үз полкы белән кайсы колоннада булганын тикшерү вакытында әйтми, гомумән, ул бу сугышта катнашмадым, ди. Ләкин башка пугачевчыларның күрсәтүләре буенча аның актив полковникларның берсе булуы, батыр йөрәкле көрәшче булганлыгы билгеле. Мәсәлән, Сәлим Гаделшин һәм Борис Савельев шул турыда сөйлиләр.

Пугачевчылар хәзерге ял паркы һәм «Казан» санаториясе тирәләреннән гимназистлар һәм генерал П. Потемкин саклаган линиягә һөҗүм иткәннәр. А. С. Пушкин әйткәнчә, алар буш куллары белән (восстаниечеләрнең коралы бик аз булган) гимназистларны да, генералны да куганнар һәм губернаторның җәйге йортын алганнар. Бу йорт хәзерге Гоголь урамыннан Казанкага төшкән җирдә булган. Хөкүмәт гаскәрләре Кремльгә качканнар. Генерал П. Потемкин үзенең бер язмасында: «Халык күпчелеге белән явызга (Е. И. Пугачевка — С. А.) бирелгән булганлыктан, аңа каршы тормады, ә минем кул астымда булган татарларның яртысы дошман ягына чыкты», дип язган. Суконный бистәсенә һөҗүм ясаучы Пугачев колоннасы аны бик тиз алган, чөнки суконочылар аңа каршы сугышмаганнар. Баш күтәрүчеләр монда да хөкүмәт гаскәрләренең тупларын тартып алганнар һәм аларны тау өстенә куеп (хәзерге Финанс-экономика институты урынына), шәһәр урамнарына картечь белән ата башлаганнар. Генерал Баннер, Ларионовлар моннан да тизрәк Кремльгә качканнар. Дүртенче колонна татар бистәләреннән Мокрый бистәсенә, аннан адмиралтействога бәреп кергән. Тиздән Кремльдән кала бөтен шәһәр баш күтәрүчеләр кулында булган. Кремльне алуның зур әһәмиятен аңлаган Е. И. Пугачев аны тиз генә камап алган. Ул үзе кибетләр рәте булган сәүдә йортын (хәзерге Татарстан дәүләт музее урынында) алып, шунда кремльгә каршы ике туп куйган. Минеев аның кушуы буенча хатын-кыз монастыре (хәзерге Педагогия институты тулай торак йорты) капкасы төбенә дә ике туп куйган. Тагын бер туп кремльдән көнбатышта, хәзерге Бауман урамы башына куелган. Кремльне тупка тоту башланган. Кремль эченә яшеренгән хөкүмәт гаскәрләре шулай ук аларга ут ачып җавап биргәннәр. Кремльне алырга мөмкин булган. Ләкин шәһәр төрле яктан яна башлаган. Бу баш күтәрүчеләрнең стихияле рәвештә изүче сыйныфлардан үч алулары булган. Соңыннан исәпләү нәтиҗәсендә шәһәрдә барлыгы 2091 йорт, 74 казна яки дәүләт өе, 777 кибет һәм сәүдә йорты, 28 чиркәү янганлыгы билгеле булган. Болардан башка адмиралтействоның 90 йорты, 10 нан артык «завод»ы янган. Бары тик восстаниегә кушылган Суконный һәм татар бистәләре генә яндырылмыйча калганнар.

Янгын чолгап алган шәһәрдә кремльне штурмлау инде мөмкин булмаган. Шуның өстенә тиздән подполковник Михельсонның гаскәр белән Казанга якынлашуы турында хәбәр алынган. Пугачев гаскәрне бик тиз җыярга һәм Арча кырында сугышка хәзерләнергә боерык биргән. Арча кырыннан Иделгә кадәр таралган армияне җыю авыр булган, билгеле. Крестьяннарның күбесе төп эшне эшләдек, Казанны алдык дип уйлаган, гомуми бурычны аңламаган. Исхак Әхмәтов та никадәр тырышмасын, үз отрядын җыеп бетерә алмаган. Җыелган кадәр гаскәр белән Е. И. Пугачев Арча кырында Михельсонны ут яудырып каршы алган. Төнгә кадәр дәвам иткән бу бәрелеш бер якка да җиңү китермәгән. Пугачев Казанканың аръягына чыгып лагерь корган. Иртәгесен Михельсон Казан гарнизоны белән кушылырга ният иткән. Пугачевка таралган гаскәрне яңадан җыярга кирәк булган. Михельсон гаскәренең шәһәр гарнизоны белән кушылуына комачаулык итә алмаган Пугачев гаскәрләрне Сухая река авылында тупларга була. Ул һәм аның якын көрәштәшләре зур энергия белән армияне көчәйтү, ныгыту эшенә тотынганнар. Пугачев Исхак Әхмәтовны чакырып алган да: Алабугада

мин сине җибәрми калган идем, хәзер сиңа да вакыт җитте. Бар үз якларыңа, берничә иптәш ал да, яңа полк төзеп кайт, дигән. Полковник үзенә ярдәмгә күптәнге иптәшләре Сәлим Гаделшинны һәм Борис Савельевны алып Олы Кавал авылы ягына чыгып киткән.

Сәлим Гаделшин Бөгелмә өязе Бикметова (Денисово дип тә йөрткәннәр) авылының ясаклы крестьяны булып солдатка алынган булган. Полковник Чернышев командасы составында Оренбург янындагы 13 ноябрь сугышында катнашкан һәм Пугачев ягына чыккан. Шуннан бирле полковник И. Әхмәтов кул астында сугышып йөргән. Чуваш крестьяны Борис Савельев шулай ук аның күптәнге көрәштәше булган. Алар авылларда Пугачев өндәмәләрен, указларын укып йөриләр, крестьяннар гаскәренә яңа сугышчылар җыялар. Ләкин бу отряд белән аларга яңадан Е. И. Пугачев җитәкчелегендә сугышырга туры килми.

15 июль көнне Е. И. Пугачев, кул астына 15 меңгә якын кеше җыйналгач Михельсонга каршы сугышка чыгарга һәм Казанны яңадан алырга карар биргән. Ул яңадан Арча кырына килгән һәм монда хәлиткеч сугыш башланган. Ярым-йорты коралланган крестьяннар зур түземлек һәм гайрәт белән регуляр армиягә каршы 4 сәгать буена сугышканнар. Ләкин, искиткеч батырлыкларына карамастан, алар җиңелгәннәр. Восстаниечеләрнең ике меңгә якыны үтерелгән, 5—6 мең кеше әсир төшкән. Ядрәләре белән тугыз туп, 17 байрак хөкүмәт гаскәрләре кулына төшкән. Пугачев кечкенә бер отряд белән Иделгә таба качып киткән.

Шулай итеп, Казан өчен сугышлар 10 июльдән 15 июльгә кадәр дәвам иткән. Крестьяннар сугышының иң югары ноктаPларының берсе булган Казанны алуда төрле милләт крестьяннары кулга кул тотынып көрәшкәннәр. Бу аларда социаль бердәмлек хисе, алдагы көрәшләрдә тагын да бердәмрәк чыгыш ясау рухы, изүчеләргә каршы буйсынмаучылык тәрбияләгән.

15 июльдә кичкә таба Олы Кавал авылына Казан янында сугышта катнашкан кешеләр кайткан. Алар Е. И. Пугачевның җиңелүе турында хәбәр таратканнар. Шул хәбәрдән соң Исхак Әхмәтов җыйган отряд таркала. Авыл байлары, сотник һәм староста үз яраннарын ияртеп Исхаклар туктаган өйгә килеп керәләр һәм аларны кулга алалар. Исхак Әхмәтовны иптәшләре белән бергә арканнар белән бәйләп, Кавал авылы сотнигы Сәхибкол Үтәгәнов сак астында Казанга алып киткән һәм властьларга тапшырган. 27 июльдә яшерен комиссиядә алардан сорау алу үткәргәннәр.

Без югарыда язганнарны нигездә өнә шул сорау алу вакытында бирелгән мәгълүматлардан алдык. Хәзерге вакытта алар Мәскәүдәге Борынгы актлар үзәк дәүләт архивының 6 фонд, 1 тасвирлама, 467 эшнең 2(4) өлешендә саклана.

Полковник Исхак Әхмәтов эше буенча комиссия түбәндәге карарны чыгара: Е. И. Пугачев тарафыннан полковник дәрәҗәсе бирелгән Исхак Әхмәтовны һәм аның көрәштәшләре Сәлим Гаделшинны, Борис Савельевны чыбыркы белән кыйнарга, борын-колакларын кисеп, йөзләренә тамгалар салырга һәм гомерлек каторгага җибәрергә.

Халык бәхете өчен үзен корбан иткән батырның соңгы язмышы әлегә кадәр ачыкланмаган.

# ШӘҺРЕ БОЛГАР

Урта гасырларда Идел Болгариясенең башкаласы булган Болгар шәһәре калдыклары республикабызның Куйбышев районында урнашкан. Шәһре Болгарга X йөз башында нигез салына һәм ул XV йөзнең утызынчы елларына кадәр яши. Аннан соң Идел-Кама төбәгенең политик үзәге Казан каласына күчә.

Урта гасырларда Болгарның даны бик еракларга тарала, ул Көнчыгыш белән Көнбатышны тоташтыручы күпер булып хезмәт итә, халыкара сәүдә үзәгенә әверелә. Шәрык авторлары бу шәһәр турында күп истәлекләр язып калдыралар, рус елъязмаларында исә ул «Бөек Болгар» дип телгә алына.

Тарихи мәгълүматлар һәм археологик материаллар бу шәһәрнең болгарлар тормышында гына түгел, гомумән Идел-Чулман, Урал буе халыклары язмышында зур роль уйнавы турында сөйлиләр. Болгар шәһәре Идел Болгариясе ирешкән казанышларны чагылдыручы көзге булган. Болгар осталары күрше халыкларның экономикасына, һөнәрчелек һәм сәнгатенә дә зур йогынты ясаганнар, заманның производство һәм культура казанышлары белән башлыча болгарлар ярдәмендә танышканнар.

Элеккедән калган бу шәһәрлекне саклау эше Петр I исеме белән бәйләнгән. 1722 елның май аенда император Болгарда була, хәрабәләрне тамаша кылып йөри. Ә китеп барганда шәһәрлектәге җимерек биналарны (ул чакта аларның күбесе әле исән була) мөмкин кадәр сакларга, төзәтергә, аунап яткан гарәп язулы кабер ташларын җыеп, андагы текстларны күчереп алырга, тәрҗемә итеп үзенә җибәрергә әмер бирә. Ул киткәч, монда чыннан да кайбер эшләр эшләнә, манараларның берсе ремонтлана, түбә ябыла. Бу — Россия тарихында культура истәлекләрен саклау буенча беренче боерыклардан була. Шуның белән Болгар шәһәрлеген һәм андагы истәлекләрне өйрәнүгә нигез салына.

Болгардагы истәлекләрне фәнни өйрәнү, реставрацияләү һәм музей оештыру эше өч этаптан тора. Башлангыч чорда (1722 — 1877 еллар) академик экспедицияләр һәм крайны өйрәнүче галимнәр — Казан университетының фәнни көчләре тарафыннан шәһәр тарихы буенча бәй материал туплана. С. М. Шпилевскийның «Борынгы шәһәрләр һәм Казан губернасының башка болгар-татар истәлекләре» исемле китабы һәм IV Археология съезды хезмәтләре шушы эшнең йомгагы булды. Бу дәвердә Идел Болгариясе һәм бигрәк тә Болгар шәһәре турында бай мәгълүмат җыела, фәнни әйләнешкә күп төрле язма чыганаклар, борынгы акчалар кертелә. Бу эшләрне П. С. Паллас, И. Лепехин, Ф. Эрдман, П. Шмидт кебек галимнәр оештырган академик экспедицияләр башкарды.

Болгарда беренче археологик казу эшләрен 1864 елда В. Г. Тизенгаузен башлап җибәрә. 1877 елны Казанда булган IV Археологик съезд уңаеннан Болгарда бу эшләр тагын җанланып ала. Истәлекләрне саклауны яхшырту җәһәтеннән Болгар шәһәрлеге Казан университеты каршында эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте карамагына тапшырыла. Шушы вакыттан Болгарны өйрәнү тарихының икенче этабы башланып китә. Бу чорда фән әһелләренең шәһәрлеккә игътибары арту белән беррәттән, истәлекләрне саклау буенча да кайбер практик чаралар күрелә. Бу эшкә күпмедер сумма билгеләнә, штатта торучы ике каравылчы куела. Иң яхшы сакланган «Кара палата» эчендә Болгарның музее оештырыла. Губернаның төрле почмакларыннан монда гыйбадәт кылырга килүче халык арасында беренче экскурсантлар да күренә башлый. Бу дә-

елларда да (1887, 1892-93 һәм 1913—1916 еллар) шәһәрлек мәйданында археологик тикшеренүләр һәм төрле саклану чаралары күрелә, «Ак палата», «Җәмигъ мәчет», «Ханнар төрбәсе», «Грек палатасы», «Кече шәһәрчек» һ. б. объектлар өйрәнелә. Нәкъ шушы чорда кайбер истәлекләрнең төзелү вакыты ачыклана. Аларның күпчелеге Болгар яңадан күтәрелеп, чәчәк аткан чорга — XIV йөзнең беренче яртысына туры килә икән. Шушы вакытта «Кара палата» белән «Ханнар төрбәсе» ремонтланып кала һәм шуның аркасында икесе дә сакланган килеш безнең көннәргә килеп җитәләр.

Илдә гражданнар сугышы барган авыр елларда да Болгарга игътибар кимеми. 1919—1920 елларда биредә Н. Э. Грабарь һәм А. С. Башкиров экспедицияләре эшли, истәлекләр төрле яклап — архитектура, археология һәм художестволы бизәү, тәзйиңләндерү күзлегеннән чыгып өйрәнеләләр. Бер яктан, бу эшләр элекке еллардагы тикшеренүләрнең дәвамы булса, шул ук вакытта алар Болгарны өйрәнүнең яңа этабын да башлап җибәрәләр. Шушы елларда Болгарда заповедник ачу мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баса.

Бөек Октябрьдан соң культура истәлекләрен саклауга игътибар бермә-бер арта һәм 1933 елның 22 сентябрендә Татарстан хөкүмәте Болгар шәһәрлеген заповедник дип игълан итү турында карар кабул итә. Бу карар буенча шәһәрлек мәйданында нинди дә булса төзелеш, ташлар җыю, үзлегеңнән җир казу, борынгы биналар һәм хәрабәләр тирәсендә җирне сөрү тыела. Әмма карар кабул ителсә дә, аны тормышка ашыру һаман кичектерелеп килә. Шуңа күрә Бөек Ватан сугышыннан соң бу мәсьәлә, ягъни Болгарны дәүләт тарихархитектура заповедниги дип игълан итү СССР Фәннәр академиясе Президиумының фәнни-методик советында яңабаштан карала. 1949 елның 14 декабрендә булган Пленум карарында Болгарны Дәүләт заповеднигы итү, аны саклап калу һәм фәнни-агарту эшендә файдалану өчен бердәнбер юл дип танылa. Әмма заповедникны оештыру өчен кирәк булган документацияне әзерләү эше һаман сузылып килә.

Археологик тикшеренүләр Болгарда даими рәвештә 1938 елдан алып барыла. СССР Фәннәр академиясенең Материаль культура тарихы институты, Мәскәүнең тарих музее һ. б. фәнни оешмалар тарафыннан дәвам иттерелгән бу тикшеренүләрне күренекле галим А. П. Смирнов җитәкли. Бөек Ватан сугышы елларында тукталып торган бу эшләр сугыштан соң кабат башланып китәләр.

1938—1941, 1945—1949 елларда башланган эшләр дә Болгар тарихына бай материал өстиләр, шәһәрнең әүвәлге районнары, һөнәрчеләр бистәсе, шулай ук шәһәр кырыйлары тикшерелә. Һөнәрчеләр торган районда XI — XIII йөзгә караган металлургия производствосы калдыклары табыла. XIII — XIV йөзләрдә болгарлар, Көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып, чуен коюны көйләп җибәрәләр. Болардан тыш бакырчылар, тире эшкәртүчеләр, чүлмәкчеләр, сөяктән төрле әйберләр ясаучыларның остаханәләре дә табыла.

1930—1940 еллардагы тикшеренүләр шулай ук Болгарның тарихи һәм социаль топографиясен ачыкларга да ярдәм итәләр. Хәзер инде шәһәрнең барлыкка килүен, үсүен, аерым кварталларның тарихын, элекке хәлен күз алдына китереп була башлый. Тикшеренүләр вакытында табылган әйберләр Болгарда яшәүче халыкның тормыш-көнкүрешен, яшәү рәвешен генә ачыклап калмыйча, шәһәрнең башка өлкәләр, илләр белән булган элемтәләрен дә ачып салалар. Гомер-гомергә халыкара сәүдә үзәге булган Болгар урамнарында Урта Азия, Иран, Кытай, Кавказ, Византия, Русь һәм төньяк өлкәләрдән килгән кешеләрне дә очратырга мөмкин булган. Әрмәннәр белән русларның монда үз колонияләре булуы билгеле.

1950—1957 елларда эшләгән Куйбышев археологик экспедициясе дә Болгар тарихын өйрәнүгә күп яңалык кертте, галимнәр алдына яңа мәсьәләләр куйды. Экспедициянең төп бурычы — Куйбышев гидроэлектростанциясен төзү аркасында су астында калырга тиешле археологик истәлекләрне тикшерү иде. Бу эш А. П. Смирнов җитәкчелегендә Казан һәм Мәскәү археологлары тарафыннан алып барылды.

Утызынчы еллардан соң үткән егерме ел вакыт эчендә Болгарның популярлыгы үсә, халык монда торган саен күбрәк йөри, төрле экскурсияләр оештырыла һәм шушы уңайдан җәмәгатьчелек алдына кабат бу тарихи шәһәрлекне заповедник итү мәсьәләсе килеп баса.

Болгар шәһәрлеге, союзкүләм әһәмияткә ия булган объект буларак, якын елларда музей оештырылачак объектлар исемлегенә кертелә һәм шушы эшкә әзерлек чаралары күрергә кирәк дип табыла. Шу-

шы карар нигезендә ТАССР Культура министрлыгы да Болгарда даими экспозициясе булган археология музее ачу, архитектура истәлекләрен фәнни фиксацияләү, хәрабә хәлендәгеләрен консервацияләү турында карар кабул итә. 1964 елдан Болгарның архитектурасын өйрәнү җанланып китә. Бу эшне дә А. П. Смирнов җитәкли.

Шушы чорда Казан шәһәре реставрацияләү мастерское тарафыннан Болгардагы истәлекләрне халыкка күрсәтү өчен реставрацияләү, саклап калу эшләре башлана. Бу эштә архитектор С. С. Айдаров аеруча зур тырышлык күрсәтә.

1966 елның 5 сентябрендә ТАССР Министрлар Советы 454 номерлы махсус карар кабул итте. Карарда шәһәрлекне әйләндереп алган урларның эчке ягында җир сөрүнең тыелуы, истәлекләр янынан үткән юлларның ябылуы, елга ярындагы йөк причалының эше туктатылу һәм шәһәрлектән нинди дә булса балчык алып чыгуның да рөхсәт ителмәве турында әйтелгән иде. Бер елдан соң ТАССР Министрлар Советы 409 номерлы «Болгар шәһәрендә тарихи һәм архитектура истәлекләрен саклауны яхшырту турында» дигән тагын бер карар кабул итте, ә 1968 елны хезмәт ияләре депутатларының Куйбышев район Советы башкарма комитеты «Заповедник ачу уңаеннан төзелеш һәм төзекләндерү эшләрен көчәйтү» турында карар чыгарды. ТАССР Министрлар Советы тарафыннан расланган бу карардан соң, ниһаять, **1969 елның 1 июлендә** Болгар шәһәрлеге истәлекләре нигезендә **Болгар Дәүләт тарих-архитектура заповедныгы оештырыла.**

Заповедникны оештыру алдыннан саклanырга тиешле зона проектын һәм Положениесен булдыру өчен байтак эшләр башкарыла. Бу документларда Болгар шәһәрлеге генә түгел, Идел Болгариясенең Биләр, Сувар, Иске Казан кебек башка зур шәһәрләрнең дә дәүләт тарафыннан саклана торган территорияләр дип игълан ителүе әйтелә. Әмма бу эш әлегә Болгар шәһәрлегендә генә тормышка ашырылды. Заповедникны оештырганда Новгород, Псков, Херсонес һәм «Танаис» кебек тарих-архитектура заповедникларының күпьеллык тәҗрибәсе исәпкә алынды.

Болгарда заповедник оештыру өчен сәбәпләр җитәрлек иде: беренчедән, ул зур әһәмияткә ия булган тарих-архитектура истәлеге, икенчедән, шәһәрлек үрнәгендә болгар-татар культурасының тууын, үсүен, чәчәк атуын күрсәтү өчен зуррак мөмкинлек ачыла. Өстәвенә ул Идел-Кама, Урал буе, Русь һәм көнчыгыш халыкларының ерак гасырлардан килгән дуслыгын, интернационализм нигезләрен пропагандалаучы объект та булып хезмәт итәчәк иде.

«Бөек Болгар» — яхшы сакланган истәлекләрдән санала. Шәһәрлектә төрле характердагы истәлекләр бар: «Җәмигъ мәчет», «Ханнар төрбәсе», «Кече манара», «Грек палатасы», «Ак палата» һәм «Кызыл палата» дип йөртелгән борынгы мунчалар, хөкем йорты «Кара палата», Болгарның көньяк читендә урнашкан «Кече шәһәрчек», аннан тыш торак йорт калдыклары, шәһәрлекне уратып алган биек урлар һәм тирән үр чокырлары. Әйткәнебезчә, шәһәрчек Куйбышев район үзәге белән янәшә, Идел ярында ук тора. Моннан Казанга, Ульяновскига, гомумән Идел буеның башка шәһәрләренә су юлы үтә. Бу хәл исә Болгарга килүне, аны тамаша кылуны бермәбер җиңеләйтә. Заповедник ачылганчы ук монда инде археология музее эшли иде. Шулай итеп, Болгар Дәүләт тарих-архитектура заповедныгында, фәнни-тикшеренү һәм культура-агарту оешмасы буларак, кичекмәстән үз вазифаларын башкарырга керешү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар иде.

1960—70 елларда биредә саклау чараларының беренче этабы тәгәлләнде. Әле заповедник ачылганчы ук өйрәнелгән «Җәмигъ мәчет», «Кече манара», «Монастырь базы», «Изге Николай чиркәве», «Ханнар төрбәсе» кебек XIII—XIV йөзләргә караган истәлекләрдә консервация-реставрация эшләре башкарылды.

1983 елны XIV йөздә төзелгән җәмәгать мунчасы «Ак палата»ны өйрәнү тәмамланды. Бу мунча XIX йөзгә хәтле монда килеп киткән галимнәрне һәм сәяхәтчеләрне үзенең матурлыгы белән әсир иткән. Кызганычка каршы, XIX йөзнең икенче яртысында ул ишелеп төшә һәм безнең көннәргә инде хәрабәләр хәлендә генә килеп җитә. Казан шәһәрендәге махсус «Росреставрация» мастерское тарафыннан эшләнгән проект буенча килачәктә бу бина өлешчә торгызылачак һәм реставрацияләнәчәк. Аны тамаша кылу өчен шунда ук махсус мәйданчык эшләү дә күздә тотыла.

Болгарның көньягындагы «Кече шәһәрчек»не өйрәнү дә инде тәгәлләнеп килә. Археологлар шәһәрчекнең таш ныгытмаларын, капкасын, аерым бина калдыкларын өлешчә тикшерделәр, эчке территорияне казыдылар. Хәзер объектларны, беренчел

реставрация этабын үтеп, туристларга күрсәтер хәлгә китерделәр. Соңгы елларда заповедникта моннан тыш та байтак бина һәм төрле остаханә калдыклары табылды. Әмма кирпеч һәм балчыктан салынган йортларны консервацияләү технологиясенең һаман да әле эшләнеп җитмәве сәбәпле бу эшләрне тәмамлау тоткарланып килә.

Болгарның архитектура истәлекләре, урлары, төрбә нигезләре h. б. биналар шәһәрлекне карап йөрүче туристларның маршрутларына кертелә баралар. Бер һәм ике көнлек туристлык маршруты экскурсантларда җуелмас тәэсирләр калдыра. Алар археологлар һәм реставраторларның эшенә югары бәя бирәләр. Мәсәлән, заповедникның Археология музеендагы журнал битләрендә шушындый язулар очрый: «Заман үзгәрә, кеше дә үзгәрә, ә тарих шул килеш кала... Бу бөеклек таңга калдыра! Моннан күңелең сафланып, киләчәккә ышанычың тагын да артканын сизеп китәсең». (Казан шәһәреннән, артистлар.)

«Бу борынгы культураны киләчәк буыннар өчен саклау өстендә көчләрен кызганмый эшләгән кешеләргә рәхмәтебезне белдерәбез». (Тольятти шәһәре эшчеләре.)

Татарстан һәм күрше республика хезмәт ияләренең журнал сәхифәләрендә чагылыш тапкан тәэсирләреннән башка Венгрия, Болгария, Польша, Чехословакия, ГДР, Финляндия h. б. илләрдән килгән кунаклар калдырган язулар да очрый. Кыскасы, Болгар заповедннгының даны һәм абруе үскәннән-үсә, халык монда торган саен күбрәк йөри.

Болгарга килүчеләрнең саны арту заповедник алдында яңа бурычлар куя. Бу бурычлар истәлекләрне музейлаштыру, тәзекләндерү эшен тагын да яхшырту һәм туристлар өчен уңайлы шартлар тудырудан гыйбарәт.

Шушы җәһәттән 1980—83 елларда шәһәрлек капкасыннан үзәктәге истәлекләр комплексына кадәр асфальт юл салынды. Успение чиркәвендә Болгар музееның яңа экспозициясе әзерләнә. Бу экспозициядә борынгы чорлардан XV йөзгә кадәр дәвам иткән Болгар шәһәре тарихы күрсәтеләчәк. Шулай ук шәһәрлектә йөрү өчен юл күрсәткеч басылып чыкты, архитектура истәлекләре төшерелгән значоклар һәм Болгарның картосхемасы ясалды.

Әле эшлисе эшләр дә байтак. ТАССР Министрлар Советының 1978 ел, 28 декабрь карары буенча Болгарның үзендә туристик суднолар туктый алсын өчен әзерлек эшләре башланды. Хәзер «Метеор» кебек суднолар гына Болгарга килергә теләүчеләрне канәгатьләндереп җиткерә алмый, заповедникның үз ярында туктау өчен причал булдыру ихтыяҗы көн тәртибендә тора. Киләчәктә монда туристлык базасы төзү дә күздә тотыла.


Күренә ки, заповедникта әле эшләнәсе эшләр дә байтак. Эшләнгәннәре турында сүз алып барганда А. П. Смирновның фидакарь хезмәтенә сөрым тукталмыйча мөмкин түгел. Күп еллар дәвамында шәһәрлекне өйрәнү, Археология музее оештыру, истәлекләрне саклау һәм фәнни реставрацияләү өчен әзерлек эшләре дә аның исеме белән бәйле.



*Болгар шәһәрлегендә табылган савыт-саба. XIII—XIV йөзләр.*

Заповедник оештырылу белән мондагы тикшеренүләр аның төп эшенә әверелде. Казу эшләре заповедникның бюджетына

кертелде. Әгәр беренче елларда тикшеренүгәр әле А. П. Смирнов төзегән план буенча алып барылса, соңрак бу юнәлештәге эшләрнең күләме бераз тарайды, средстволар күбрәк шәһәрлектәге истәлекләрне саклауга һәм заповедникта салыначак биналар урынын казып тикшерүгә тотыла башлады. Шулай да, алып барылган казу эшләре, нинди максат белән башкарылуларына карамастан, квалификацияле археологлар тарафыннан тиешле методик югарылыкта үткәрелделәр. Болгар шәһәрлеген өйрәнүгә алар күп нәрсә өстәде, шәһәр тарихын ачыклауда, Идел болгарлары культурасының кайбер мәсьәләләрен хәл итүдә зур ярдәм күрсәттеләр.



*Сөяктән уеп ясалган камчы сабы.*

Кыскасы, соңгы еллардагы казу эшләре шәһәрлекнең үзәгендә (Т. А. Хлебникова, М. Д. Полубояринова, Л. Л. Савинкова, Г. Ф. Полякова, М. Г. Кремеровский), көнчыгышындагы «Кече манара» тирәсендә (Н. Д. Аксенова), көнбатышындагы аэродром районында (Н. Д. Аксенова, М. Д. Полубояринова, Г. Ф. Полякова, Г. М. Кремеровский, И. В. Васильева), көньягындагы «Кече шәһәрчек»тә (Л. А. Беляев, Т. А. Хлебникова) үткәрелделәр. Соңгы биш ел эчендә «Ак палата» дип аталган борынгы мунчаны өйрәнү дә тәмамланды (Р. Ф. Шәрифуллин, Т. А. Хлебникова).

Шулай итеп, заповедник оешканнан соң үткән 14 сезон эчендә Болгар шәһәрлегендә археологлар тарафыннан 7873 квадрат метр мәйдан тикшерелде, бик күп кыйммәтле күзәтүләр ясалды. Хәзер инде казылган һәр районның тарихын, культуралы катламнарның характерын, нинди чорда нинди тормыш барганын төгәл әйтеп була. Бу мәгълүматлар Болгар шәһәренең ул заманнардагы тормышын төгәл күз алдына китерергә ярдәм итә.

Әүвәлге Болгарның чикләрен һәм характерын ачыклауны шәһәрлекне өйрәнүнең гаять зур уңышы дип атарга була. IX йөз ахырында X йөз башында төзелә башлаган Болгар иң элек очлаеп Идел ярына чыгып торган борында — биек яр өстендә урнаша. Гомумән, болгарлар шәһәрләр төзү өчен урынны сайлый белгәннәр. Моның өчен алар табигый ныгытылган, дошманнан саклаunion өчен уңай урыннарны эзләгәннәр. Болгарның дә бер ягында биек, текә Идел яры, икенче ягында сузылып киткән тирән чокыр. Чокыр кырыйлары имән дивар белән ныгытылган. Ачык калган кыр ягына ур өеп, ур алдына тирән чокыр да казыла — менә дигән ныгытма-замок килеп чыга. Болгар шәһәре дә шулай ныгытылган. Язма чыганаклар әйтүенчә, X йөз башында ук Болгар Урта Иделдә һәм Чулман тирәләрендә яшәүче төрле кабиләләрне берләштергән дәүләтнең политик үзәгенә әверелә.

Болгар үзенең үсеп килгән вакытында Хәзәр дәүләте шәһәрләрен хәтерләткәнгә охшый. Алар кебек үк тиз арада һөнәрчелек остаханәләре, гади халык яши торган кварталлар белән (посад) уратылып алына. Болгарның шулай тиз үсеп китүе, ныгуы, чын шәһәргә әверелүе болгарларның монда килгәнче үк утрак тормышка күчә башлаулары турында сөйли. Утрак тормышка шулай тиз җайлашуның икенче сәбәбе — шәһәрнең зур елга юлы өстендә урнашуыннан килә — тирә-якта уңдырышлы җир-

ләр, яр астында гына зур болыннар җәелеп ята. Гарәп авторы Ибне Рустә сүзләренә караганда, Болгар IX—X йөзләрдә үк инде халыкара сәүдә үзәгенә әверелгән. X йөз башыннан Болгар үз акчасын суга. Акча сугу исә аның мөстәкыйльлеге турында сөйли. X—XI йөзләрдә Болгар тирәсендә кырчылык-көтүчелек юнәлешендәге авыл хуҗалыгы производствосы көчәеп китә. Игенчелектәге уңышлар читкә икмәк сатуны җәйләп җибәрергә мөмкинлек бирә. Шәһәрнең һөнәрчеләр яшәгән районы XI йөздә әверүчә ныгый, монда тимер коючылар, металл эшкәртүчеләр, тиречеләр, бакырчылар, чүлмәкчеләр һ. б. һөнәр ияләре яши. Алар җитештергән продукция өлешчә читкә дә чыгарып сатыла.

мергә әверелгән шәһәргә кире кайтып урнашучы халык баштарак землянкаларда торырга мәҗбүр булган. Шәһәр тиз генә терникләнеп китә алмаган. „Әмма XIII йөзнең икенче яртысына караган культуралы катламнарда аның яңаруы, яңадан көч туплавы, күтәрелеп китүе чагыла. Яңабаштан акча сугарга керешәләр, һөнәрчелек үсә, монументаль биналар калкып чыга. Шәһәрнең мәйданы да үсә.

XIV йөздә Болгар кабат бай һәм матур шәһәргә әверелә. Шушы вакытта яшәгән бай сәүдәгәрләрнең, аксөякләрнең йорт нигезләрен казыган археологлар бик күп кыйммәтле әйберләр таптылар. Алар арасында Иранннан, Кытайдан, башка ерак илләрдән китерелгән йорт кирәк-яраклары, бизәнү әйберләре дә очрый.



*Рәссам Н. Г. Чернецовның «Болгардагы мунча» картинасыннан. 1839 ел. Хәзерге көндә Мәскәүдә Третьяков галереясында саклана.*

Шәһәрлекнең үзәк өлешендә алып барылган казу эшләре нәтиҗәсендә монгол яуларына кадәрге чорның икенче яртысында Болгарның ничегрәк үсүе, территориясе һәм ныгытмалары ачыкланды. Соңрак чорларга караган катламнарда исә бу ныгытмаларның гына түгел, гомумән бөтен шәһәрнең 1236 елгы монгол яуларында ни дәрәҗәдә җимерелүе күренде. Көл катламы урыны-урыны белән егерме сантиметрга җитә. Шушы яулар вакытында кара кү-

1970 елларда башкарылган казу эшләре шәһәрнең соңрак чордагы тормышы турында да мәгълүматлар бирде. Моңа хәтле 1431 елгы таланудан соң Болгар яшәүдән туктаган дип исәпләнә иде. Әмма шушы тикшеренүләр бу һөҗүмнән соң да шәһәрнең берара яшәгәнлеген күрсәтте. Шәһәрнең үзәк өлешендә Казан ханлыгы чорында да тормыш дәвам иткән. Монда, күрәсең, изге җиргә гыйбадәт кылырга килүчеләр, аларга төрле хезмәт күрсәтүчеләр,

зират, ханнар төрбәсен, хәрабәләрне саклаучылар яшәгәндер, чөнки Казан ханлыгы чорында да шушы зиратка мәет алып килеп күмүләре билгеле. Бу дәвердә шәһәр инде элекке кебек гөрләп яшәмәгән.

Болгардан өч чакрымда урнашкан «Кече шәһәрчек»нең төзелеп бетмәвен археологлар 1361 елгы вакыйгалар белән бәйлиләр. Мондз Алтын Урда ханнарының кулы үйнагандыр, күрәсең. Болгар янында үсеп чыккан бу шәһәрчекнең киләчәктә хәтәр ныгытма-замокка әвереләсен алар вакытында сизеп алганнар һәм төзелешне туктаткаңнар булса кирәк.

Яңа гынз тикшерелеп беткән җәмәгать мунчасы «Ак палата» турында да бер-ике сүз әйтеп китәсе килә. Ак таштан төзелгән бу бинз үзенең планировкасы һәм бизәлүе белән шәрык мунчаларын хәтерләтә. Дүрт почмаклы, уртасында фонтан атып торган биек гөмбәзле залдан почмакларда урнашкан юыну бүлмәләренә керәсең. Таш идән астан үткән төтен юллары ярдәмендә җылытыла. Чүлмәк торбалар аша җылы һәм салкын су килеп тора. Юынып арыгач, залга чыгып җылы идәнгә утырасың, хәл аласың, таныш-белешләрең белән әңгәмә корасың, җае чыкса, шушында ук сәүдә эшләрен дә җайлыйсың, илкөн хәбәрләрен ишетәсең. Мунча бер үк вакытта клуб ролен дә үтәгән, шәһәр халкының очраша торган җире дә булган.

Болгар шәһәрлеге, аның культуралы катламнары шәһәр тормышы, тарихы турында сөйләү белән берргттән Идел болгарларының тарихи язмышын, бэбэлэрыбыз үткән катлаулы юлны да чагылдыралар. Бу бөек шәһәр болгар бабаларыбызның бөтен культура казанышларын үзенә сеңдергән. Ул тирә-юньдәге халыкларны үз тирәсенә туплаган, аларга зэманның культура казанышларын керткән, байтак вакытлар бердәнбер мәркәз булып торган. Халыкара бәйләнешләр үзәге булган Болгарның Көнчыгыш Европа тарихында да роле зур.

Болгар шәһәрлегендә инде байтак еллар дәвамында алып барыла торган казу эшләре аркасында заповедник фондында бик күп табылдыклар тупланды. Бүгенге көндә бу фондларда төрле характердагы 50 меңнән артык табылдык саклана. (Шушыңа Биләр филиалындагы материалларны да кушсаң, аларның саны 120 меңгә җитәчәк.) Ел саен аларның саны үсә бара. Бу хәл исә музейның экспозициясен яңартырга ярдәм итә, белгечләргә шәһәрнең һәм Идел Болгариясенең культурасын өйрәнү мөмкинлекләре арткаңнан-арта бара.

Хәзерге көндә бу фондларда СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Археология институты, Дәүләт тарих институты, Мәскәү университеты, Болгар заповедникы, Куйбышев университеты археологлары, тарихчылары, тел белгечләре, эпиграфистлары, антропологлары, нумизматлары катнашы белән коллектив эш алып бәрыла. Заповедникта башкарылган күпьеллык тикшеренүләргә йомгак ясала. Якын еллардэ бу хезмәт басылып та чыгачак. Шулай ук «Ак палата», «Кече шәһәрчек» һәм шәһәрнең һөнәрчелек районы буенча да аерым хезмәт бастыру күздә тотыла. Бу хезмәтләр яңз материалларны фәнни әйләнешкә кертәчәк, киң катлам укучыларга Болгар шәһәре һәм Идел Болгариясе тарихы буенча ышанычлы мәгълүматлар чыганагы булып хезмәт итәчәкләр.

**Җәмит МӨХӘММӘТШИН,**
Болгар дәүләт тарих-архитектура заповедникы директоры.

**Тамара ХЛЕБНИКОВА,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

# САБА ҖИЛЕДӘЙ...

*Аллаһияр Вәлиуллинның туууына 60 ел*

Байлар Сабасы... Бу борынгы авыл исемендә тышкы мәгънәдән битәр яшерен, эчке мәгънә күңелне җәлеп итә. Әйе, бу яклар урман-суга, басуклырларга бай, әмма иң олы, бәһасез байлык — әлеге төбәктә яшәүче моңлы җанлы, көр күңелле тырыш кешеләр, сәләтле, уңган-булган кешеләр!

Ничәнче кат Шәмәрдән станциясендә төшеп, таныш юл буйлап Сабама кайтам. Тирә-яктагы бөдрә ак каеннар яшел яулыкларын болгап калалар. Ә колакта зәңгәр күзле көләч якташым Аллаһияр Вәлиуллинның Саба турында, аның кыю егетләре, тырыш һәм көләч «апалары, җиңгиләре, сөйкемле киленнәре» турында иҗат иткән җыр яңгырый:

*Их Сабаның юллары ла,*
*Урман аша барасы;*
*Безнең Саба егетләрен*
*Белә Казан каласы!*

1924 елның җәй чилләсендә туган Аллаһияр әтисе Гарифулланың шатлыгы һәм куанычына әверелә. Җор телле, шаян холыклы, терекөмеш кебек җитез бу малай бик яшьли җыр һәм бию белән мавыга башлый, үзе дә төрле уен коралларында уйнарга омтылып карый. Моңа, әлбәттә, яшүсмернең кардәше Хөснул Вәлиуллинның да йогынтысы булмый калмагандыр. Ничек кенә булмасын, әлеге яшел урманлы Саба юлы урта мәктәп тәмамлаган егетне Казан юлына алып чыга. Язгы урманны яңгыраткан көккүк авазы, моңлы кошлар җыры, иске «полуторка»ның мотор көенә кушылгач, әллә нинди ят яңгырашлы, дәртле марш булып тоела. Казан музыка училищесында яраткан инструменты трубада уйнаганда да аның күз алдында шушы кояшлы, көккүк-сандугачлы язгы урман аланы тора, колагына, ерак кайтаваз булып, көтүче быргысының иртәнге өндәү авазы ишетелә...

Юк, музыка коралында уйнап кына калып булмый, Аллаһиярның үз күңелендә ташып торган хис-моңнарын нота станына теэеп карыйсы килә. Егетнең музыкага сәләтен сизеп алып, тиздән аны композиторлык бүлегенә күчерәләр, һәм ул тәҗрибәле педагог, композитор Ю. В. Виноградов кул астында музыка серләрен өйрәнә башлый...

Шулай туры килә: Аллаһиярның да яшьлеге Бөек Ватан сугышының ут-төтене, шартлау-гөрелтеләре артына күмелеп кала. Кырык дүрттә генә, демобилизацияләнгәннән соң, ул янә М. А. Юдин җитәкчелегендә композиция буенча укуын дәвам итә ала. Сугыш һәм аннан соңгы авыр еллар аның язмышына да кагылып уза, чәчләренә ак бәс сибә. 1946 елда ул Ташкент консерваториясендә укый башлый, ә ике ел-

дан соң Казанга кайтып, 1952 елга чаклы консерваториядә сизгер җанлы педагог һәм музыкант Альберт Семенович Леман классында уку бәхетенә ирешә.

Консерваторияне Аллаһияр Вәлиуллин «Тынычлык җиңәр» исемле симфоник поэмасын язып тәмамлый. Яшь композиторның диплом эше саналган бу күләмле симфоник әсәр шул заман татар совет музыкасының, бигрәк тә аның яңа, симфоник жанрында күренекле әсәрләрнең берсе буларак кабул ителә.

Дистәләгән вокаль-инструменталь әсәр авторы А. Вәлиуллин училищеда укыганда ук фортепиано өчен «Элегия», труба һәм виолончель өчен пьесалар, унлап җыр иҗат итә. Инде шушы әсәрләрендә ук аның гаять халыкчан композитор булуы ачыклана. Аның «Син генә теләгәнем» җырын кем генә белми икән?! Ә бит бу җыр халык арасында инде күптән «Өтнә көе» дип йөртелә, һәм аның авторын хәзер бәлки белгечләр генә беләдер. Бу — чын мәгънәсендә халыклашкан, димәк, бәхетле язмышка тап булган уңышлы җыр. Консерваториядә укыганда да А. Вәлиуллин җыр язуын ташламый, чорга лаеклы, актуаль яңгырашлы җырлар иҗат итәргә омтыла. «Тынычлыкны яклыйбыз» (Ә. Фәйзи сүзләре), «Шахтер егет» (Ә. Ерикәй) шундый җырлар рәтенә керә. Боларга композиторның «Волга-Дон» (З. Мансур), «Агитатор Фәридә» (Ш. Галиев), «Ленин яши» (К. Нәҗми), «Братскида яңа ГЭС бар» (М. Хөсәен), «Бескозырка» (Ф. Зәки сүзләре) һ. б. җырларны өстәргә мөмкин.

Якташымның җырлары ачык, ягымлы, садә моңы, дәртле агышы белән аерылып торалар. Композиторның еш кына халык сүзләренә көй язарга алынуы да идея-эстетик эзләнүләрендәге әлеге үзенчәлек белән аңлатыладыр. Халык сүзләренә ул «Өтнә көе»ннән тыш, «Безнең илләр», «Ленинизм нурлары», «Гөлчәчәктәй үсәчәк», «Ал чәчәк ата илем» җырларын да иҗат итте. Аларның кайберләре бүген дә үзешчән сәнгать коллективлары тарафыннан яратып башкарыла. Шагыйрь М. Хөсәен сүзләренә язылган «Ямьле колхоз җирләре» — композиторның хор өчен иҗат ителгән иң уңышлы җырларыннан берсе.

1972 елда композиторның бер-бер артлы ике китабы дөнья күрде: берсе — «Безнең илләр» исемле җырлар җыентыгы, икенчесе — скрипка һәм фортепиано өчен язылган ике интермедия һәм бию. Авырганлыгына да карамыйча, композитор яшьлек дәрте белән Ленин, Коммунистлар партиясе, туган ил һәм аның каһарманнары турында җырлар язды («Ленинга», «Коммунист», «Шәймәрдәнов-комиссар»). Авыл җиренә, колхоз кырларына, анда яшәгән гади кешеләргә гашыйк композитор «Безнең авыл» (Х. Вахит сүзләре), «Кырлар буйлап» (М. Хөсәен), «Мактау җыры» (З. Нури сүзләре) кебек күтәренке рухлы, ачык яңгырашлы, дәртле җырларында замандашларының уй-хыялларын, хисләрен үтемле итеп әйтеп бирергә омтыла.

Шулай да композитор үзенең төп иҗат көчен музыканың эре формаларын үзләштерүгә юнәлдерелгән. Аның кыллы музыка кораллары өчен язылган квартеты, симфоник оркестр өчен увертюрасы һәм «Тынычлык җиңәр» исемле симфоник поэмасы җитди эзләнүләр нәтиҗәсе, җитлеккән иҗат җимеше булып санала. Югары аһәң, күтәренке гражданлык хисләре белән сугарылган «Тынычлык җиңәр» поэмасы тыңлаучыны гадилеге, музыкаль теленең табигый яңгырашы, халыкчанлыгы, форма камиллеге һәм җыйнаклыгы, төп фикернең логик эзлеклелектә бирелеше белән җәлеп итә. Халкыбызның тыныч шартлардагы бәхетле тормышы әлеге әсәрдә киң колачлы һәм истә калырдай итеп гәүдәләндерелә.

Композиторның беренче симфониясе дә, гәрчә сирәк башкарылса да, татар совет симфоник музыкасын баеткан җитди әсәр булып саналырга хаклы. Автор анда халык иҗаты хәзинәсеннән мул файдалана. Киң агылышлы моңлы җыр, симфоник темага

иркен сулыш өстәп, аның яңгыраш көчен үстереп җибәрә, тирән гомумиләштерүләр ясарга этәрә. Симфониядәге беренче кисәкнең өстәмә партиясе — шундый уңышлы табышларның берсе. Хәрәкәт, динамикага бай бию-такмак ритмиканың ачык яңгырашын, акцентларны дөрес билгеләргә ярдәм итә. Симфониядәге скерцо темасы нәкъ менә такмак характерында язылган. Гомумән алганда, А. Вәлиуллинның бу әсәре дә күңелгә ятышлы яңгырашы, халык интонацияләренә якын булуы белән истә кала.

Ачык чырайлы, кече күңелле бу иҗатчы күз алдында оптимист рухлы, хыял-фантазиягә бай, шат күңелле кеше булып калган. Иллегә дә җитмәгән, әмма инде чәчләре ап-ак тузганакны хәтерләткән Аллаһияр абзый һәрвакыт халык арасында кайнады. Бигрәк тә Татарстан халык иҗаты йортында эшләгән дәвердә аның ярдәм кулын, файдалы үгет-киңәшен, эшлекле тәкъдимнәрен йөзләгән культура учагы хезмәткәрләре тоеп яшәделәр. Композитор үзешчән сәнгать коллективлары өчен берничә халык көен эшкәртте, һәвәскәр композиторлар белән кирәкле һәм кызыклы әңгәмәдәресләр алып барды, республика күчмә театры һәм курчак театры спектакльләре өчен музыка язды, дистәләрчә конкурс, фестиваль-смотрларда жюри члены булып катнашты... Кыскасы, бай иҗат тормышы белән яшәде.

Композиторның иң кыю, олы һәм изге хыялы — «Язгы җилләр» операсы тәмамланмыйча калды. Язылып бетсә, ул, һичшиксез, А. Вәлиуллин исемен генә түгел, татар опера сәнгатен дә югарырак күтәргән булыр иде....

Менә инде ничәнче кат Шәмәрдән станциясендә төшеп, таныш юл буйлап Сабама кайтып барам. Йомшак кына язгы җилләр — «саба җиле» исә. Тирә-яктагы ак каеннар тәмамланмаган операның «Язгы җилләр» хор ариясен көйли сыман. Менә-менә урман бетәр дә иркен басуга чыгарбыз. Анда бу җырны баш очындагы тургай дәвам иттерер төсле:

*Барам, үзем җырлыйм шунда,*
*Ә җырларның канаты киң.*
*Җырлар, җырлар!*
*Кече яшьтән*
*Сезне өзелеп яраттым мин!*

Бәс, бу җыр да Аллаһияр Вәлиуллинның «Кырлар буйлап» дигән җыры икән лә!.. Язгы җилдә Саба егетенең моңлы сазы зеңлидер кебек тоела, моң дулкыннары, саба җиледәй рәхәтлек биреп, күңелгә кагыла шикелле.

**Рафис ӘХМӘТ.**

# ИГЕЛЕКЛЕ ЭШ КЕШЕСЕ

*Тәрҗемәче Вил Ганиевкә 50 яшь*

Тәрҗемә эше — игелекле шөгыль. Һәм, шул ук вакытта, ул — халыклар, аларның әдәбияты һәм культурасы, рухи дөньясы, көндәлек тормышы алдында җаваплы миссия дә...

Шул эшне үзенең гомерлек бурычы санаган кешеләргә без аерата рәхмәтлебез. СССР Язучылар союзының тәрҗемә Советы җитәкчесе Вил Ганиев — әнә шундый кеше.

Аның Мәскәүдәге эш бүлмәсенә килеп кергәч тә үзенә бер төрле җылылык бөркелүен тоя башлыйсың. Ул җылылык киштәдән исемнәре белән үк тартып торган китаплардан бөркелә. Әнә Тукай, Такташ, Җәлил, Гафури, Дәрдмәнд, Ибраһимов, Бәширов, Туфан... Татар, төркмән поэзиясе антологиясе, башкорт, казах, кыргыз әдипләренең китаплары... Кыскасы, биредә илебез халыкларының рухи хәзинәсе мул тупланган. Туктаусыз хәрәкәттәге сүз сәнгатенең бер мәгарәсе сыман бу.

Вил Ганиев менә шушында эшли, оештыра, халыклар дуслыгының әдәбиятта гәүдәләнешенә үз өлешен кертә, иҗат итә. Ул инде менә утыз ел буе тәрҗемә итә.

Аның тәрҗемә өлкәсендәге беренче уңышлары Муса Җәлил иҗаты белән бәйле. 1955 елда, әле Казан дәүләт университетының рус теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда Муса Җәлил шигырьләре белән рухланган Вил Ганиев аларның үз күңелендә русча «сөйләшә» башлавын тоя.

1957 елны, татар әдәбияты һәм сәнгатенең Мәскәүдәге декадасы вакытында, ул беренче тапкыр нурлы башкалага килә. Моңарчы инде ул М. Җәлил, Мозаффария, Г. Кутуй, З. Мансур, Г. Афзал кебек шагыйрьләрне русчага тәрҗемә итә. Беренче уңышлар биргән илһам канатлары аны Тукай шигърияте дә якынайта.

Тукай — дөнья поэзиясенә үз балкышын, татар халкы рухының кабатланмас нурын биргән шагыйрь. Иҗатының камиллеге, сугышчан эстетикасының бөеклеге белән халык рухының йөзек кашы булып танылган шәхес. Аның шигырьләрен тәрҗемә итү рус һәм бөтен дөнья шигърияттен тирәнтен белүне сорый. Бу — олы бурыч, зур таләп.

В. Ганиевнең моңа омтылышы теоретик эзерлектән башлана. Мәскәүдәге дөнья әдәбияты институтында татар шигърияттен русчага тәрҗемә итүгә багышланган диссертациясе аны шушы олы максатка якынайткан төпле нигез була. Шулай ук бөек төрек шагыйре Назыйм Хикмәт, төркмән поэзиясенә нигез салучыларның берсе Бәйрәмхан шигырьләрен тәрҗемә итү дә аның өчен зур мәктәп була.

В. Ганиев Дәрдмәндне дә русчага тәрҗемә итә. Ә бу шагыйрьнең бер генә шигырен дә кинәт кенә тәрҗемә итү мөмкин түгел. Дәрдмәнд рухын бар асылында тоюга ул Бабич, Туфан шигырьләрен үз күңеле һәм каләме аша үткәрү белән ирешә. Шушы ук алымны М. Гафурины тәрҗемә итүгә дә нигез итеп ала. Аныңча, М. Гафуриның нинди дер демонлык асылы, гыйсъянчылык рухы белән Һ. Такташ иҗаты ара-

сында уртаклык бар. Бу М. Җәлилнең беренче шигырьләренә дә хас. Аларның иҗатларындагы шушы уртак сыйфатны тәрҗемә итү вакытында искә алу В. Ганиевкә ярдәм итә. Бу — тәрҗемәче өчен шатлыклы ачыш, шуны ул укучыларга да җиткерергә тырыша. Ә икенче яктан шагыйрьләребезнең кайбер русча тәрҗемәләрдә сүлгән, шәхси үзенчәлекләрдән мәхрүм кыяфәттә яңгыравы, ниһаять, тиешле тану һәм данга ирешә алмыйча, гадәтилеккә дучар булуы шагыйрьләр иҗатының бер-берсенә карата диалектик үсешен, рухы традициясен, новаторлык сыйфатларының таяну ноктасын исәпкә алмаудан килә торган чир. Бу — тәрҗемә дигән иҗат эшчәнлегенең без тиз көндә игътибар итәргә һәм дәва кылырга тиеш проблемасы. Гомумән, шагыйрьләрнең бер-берсенә мирас рәвешендә күчә килгән уртак рухи, социаль-эстетик һәм телстильдәге сыйфатларны үзара нисбәттә карау Вил Ганиев иҗатының иң төп үзенчәлекләреннән берседер. Мәсәлән, Муса Җәлилнең «Алтынчәч» дигән драматик поэмасын тәрҗемә иткәндә ул Пушкинның «Борис Годунов» трагедиясе рухын даими игътибарында тота. Чыннан да, К. Барскаяның «Муса Җәлил Пушкиннан өйрәнгән», дигән фикере бар. Мисал өчен, Хан мәмәд монологы белән Борис Годунов монологы арасында аваздашлыкны сизми мөмкин түгел. Һәр ике монолог эчке сулышы, пульсы, рухы белән күңелдә бер үк тойгы уяталар, бер үк сыйфаттагы тәэсир көченә ияләр: «Достиг я высшей власти»... «Душа тревогой сумрачной объята»... Менә бу күзәтү тәрҗемәчегә әлеге монологны Пушкин интонациясендә тәрҗемә итү уе кузгата, шуңа эчке хокук бирә.

Ә үз алдында подстрочник кына тотып, нибары шуңа гына таянып эш итүче тәрҗемәче мондый гомумиләштерүдән, анализдан, тоемнан һәм эчке ышанычтан мәхрүм. Ул әсәрнең төп рухын саклаудан битәр, сәләтен иң әүвәл русча тәрҗемәнең «шомалыгына» сарыф итә. Оригиналсыз эчке интонацияне бирүе авыр. Ә менә М. Җәлилнең «Томаулы гашыйк» шигырен тәрҗемә иткәндә В. Ганиев бөтенләй бүтәнчә эшли. Әсәрдәге кыз конторада эшләүче итеп бирелә. Тик бу русчада үз функциясен үтәми торган бер деталь генә булып кала. Автор ни әйтергә теләгән? Шуны ачыклап, русчада шуңа адекват яңгыраш табу Вил Ганиевнең бу шигырь тәрҗемәсен уңышлы иткән. Кайбер тәнкыйтьчеләрнең әлеге шигырьне тупасрак рухта тәрҗемә итү кирәклеге хакында сүз кузгатканы бар, янәсе, ул солдатлар өчен мәзәк сыйфатында язылган. Әмма Вил Ганиев ачкыч итеп шигырьнең тоткынлыкта, үлем көтеп ятканда язылуын ала. Димәк, анда мәзәк үзмаксат түгел. Мәзәк сөйләмәк өчен төрмәдә богаулы кулга сөрмә очы һәм кәгазь ертыгы алу кирәкми. Биредә хис, омтылыш икенчедер, ягъни ихлас чакларны сагынудыр... Томаулы гыйшык салган беркатлы борчуны төрмә чынбарлыгы белән янәшә куеп, шагыйрь гуманистик рухны алга сөрә. Вил Ганиев тәрҗемәсендә әнә шул самими сагыну һәм коточкыч чынбарлык көрәше шигырьнең төзелешендә, образлылыгында, интонациясендә бирелә.

В. Ганиев иҗатының төп юлы — классика. Ни өчен? Чөнки ул әдипләр иҗатында фикер тыгызлыгы, моң, сурәтләү чараларының гадилеге, сыгылмалы ритм, идея һәм аны бәян иткән стиль ачыклыгы яши. В. Ганиевнең үз тәрҗемәләренә дә ачыклык, интонация чисталыгы хас, алар чуарлыктан, ялган пафостан азат. Хәзерге заман шагыйрьләренең әсәрләре дә аны иң әүвәл шушы җәһәттән җәлеп итәләр...

Күп шагыйрьләрнең әсәрләре В. Ганиевнең күңел дәрьясында икенче тел алалар, яңа гомер белән яши башлыйлар. Ә икенче гомер — әдәби әсәрнең бәхете ул.

**Әхәт ГАФФАР.**

# «ШИНЕЛЬЛЕ ЮМОР» ДӘФТӘРЕННӘН

## Төгәллек

— Хәрби эштә, лейтенант Вошке, иң мөһиме — төгәллек.
— Так точно, полковник әфәнде. Бүген менә руслар безне тагын төп-төгәл ун пункттан алып ыргыттылар.

## Теге дөньяда

— Ишеттеңме, Мориц? Геббельс үзенең соңгы речендә безнең дивизия солдатларына тиздән шоколад, балык уылдыгы һәм рус аракысы бирәчәкләр дигән бит.
— Теге дөньяда нәрсә ашатканны каян белә иден?

## Генераллар сөйләшә

— Бухарест янында дивизия командиры булып күпме сугыштыгыз?
— Белмим. Сәгатькә карап торырга вакыт булмады анда.

## Французча бәяләү

Гитлерчы:— Безнең югалтулар зур дигәнгә ышанмагыз сез.
Француз: — Мин шулай итәм дә! Бөтенегезне кырып бетерсәләр дә, мин барыбер: «Югалту зурдан түгел!» — диячәкмен.

## Минск гарнизонында

— Нишләп син болай үзеңә кабер казып куйдың әле, Ганс?
— Бүген булдыра алган эшеңне иртәгегә калдырма дигән кагыйдә белән яшим мин.

## Мәкальгә төзәтмә

— Син, Гюнтер, «Тел Киевка кадәр җиткерә» дигән мәкальнен нәрсә аңлатканын беләсеңме?

— Ул, мөгаен, Геббельс теле турындадыр. Ләкин аның теле безне Киевка түгел, ә Берлинга хәтле үк җиткерер дип куркам мин.

## Берәүнең «бәхете»

— Карлга ничектер рус пулясы тимичә калган бит әй. Ничек эләкте икән аңа бу бәхет?

— Партизаннар куйган минага эләгеп шартлаган, мәрхүм...

## Табып бирерләр

Чигенгәндә Фриц бер фельдфебельдән сорый икән:

— Әйтегезче, зинһар, миңа үз полкымны ничек табарга икән?

— Борчылма, әсир төшкәч сиңа аны руслар табып бирерләр.

## Элемтә өзелүдән куркалар

— Капитан Шульц, синең солдатларың ник бүген чигенделәр?

— Алар, генерал әфәнде, сездән аерылып калып, штаб белән элемтә өзелүдән куркалар.

## Иске тавышлар

— Курт Блицграбе, сез Гете, Гейне, Шиллерларны яхшы беләсезме?

— Ничек белмәскә ди: аларның китапларын мин сугышка чаклы ук Берлинда яндырган кеше.

— Тарас Шевченконы да беләсезме?

— Аны да беләм: музеennан бик яхшы биш гобелен эләктергән идем..

## Әзерлек

— Полковник, сез иртәгә башланасы һөҗүмгә әзерме?

— Әйе, генерал. Иң кирәге әзер: офицер әфәнделәрнең шәхси әйберләрен җыеп тылга озаттык инде.

## Йөри алмабыз, ахрысы

— Син ничек уйлыйсың, Вилли, без кайчан да булса Мәскәүдә ду китереп йөри алырбыз микән?
— Белмим, Отто. Минемчә, без инде гомумән, беркайчан да йөри алмабыз, ахрысы.

## Берлин мәктәбендә

— Хәзер, балалар, үзегезне Көнчыгыш фронтта дип хис итегез. Бөек Германияне яклап сугышасыз. Һәм барыгыз да шул турыда инша яза башлыйсыз.
Биш минут вакыт уза.
— Минем әзер, укытучы әфәнде!
— Шулай бик тизме? Нәрсә яздың соң, Гансик?
— Васыять, укытучы әфәнде.

## Тотальниклар сөйләшә[1]

Бабасы:— Кайларда югалып йөрисең, эт койрыгы? Монда бабаңны фронтка куалар, ә син җил куасың... Вакытында өйгә кайтырга исеңдә дә юк. Колагыңны бормый булмас, юеш борын!
Оныгы:— Беренчедән, мин берничек тә югалып йөрмәдем, ә хәрби хезмәткә алу комиссиясендә булдым. Икенчедән, юеш борын түгел, ә ефрейтор мин. Өченчедән, рядовой Шульц, сезгә үрә катып сөйләшергә боерам, өлкән чин алдында басып торуыгызны онытмагыз!

## Төртеп төшерүләр дә саналгач...

— Парашют белән ничә тапкыр сикердегез?
— Бер.
— Ә кәгазьдә унбер дип язылган?
— Ун тапкыр безне самолеттан төртеп төшергәннәр иде, бәлки шуларны да санаганнардыр...

Материалны төрле чыганаклардан
**Зәки НУРИ** әзерләде.

[1] Тоталь мобилизация — тоташтан, барысын да хәрби хезмәткә алу.

## Шигырь белән сөйләшүче халык

Акмулла бер төркем казакъ кешеләре белән Оренбургның кәрвансараена килеп керә. Кымыз, казылык, кубыз белән мәҗлестә бик күңелле генә сөйләшеп, үләң әйтеп утыралар болар. Бер кәрванчы татар Акмулладан сорап куя:

— Остаз! Бу казакълар синең шәкертләреңме әллә? Телләре бик үткен, сүзләре шигырь кебек. Алар да шагыйрьме?

Моңа җавап итеп, Акмулла болай дигән:

— Юк, алар шагыйрь түгел, кордаш! Һәр казакъ кешесенең сөйләме — шигъри мәкаль булыр!

— Гади казакъның гади сөйләме шигырь булгач, шагыйренең теле нинди булыр икән? — дип гаҗәпләнгән кәрванчы.

— Гади казакъның гади сөйләме — шигырь, ә акынның теле — бөек җыр! — дигән Акмулла.

## Бай Акмулла

Акмулладан сораганнар:

— Кем син? Каян кая бармыш көнең? — дигәннәр.

— Мин Казаннан казакъка барамын! — дигән шагыйрь. — Казакъларга казан алып барам. Далаларда йөрдем, бәйгеләрне күрдем. Мин үзем дә инде казакъ булдым. Казан казакъсыз, казакъ казансыз яши алмас, туган! Мин башкортта йөрдем, уйнадым курай, сөйләдем хикмәт сүзләре. Атам-анам сабый чакта татар моңын көйләсә дә, башкортсыман булдым.

— Алайса, син Акмулла чәчән! — дигәннәр юлаучылар.

— Хак сүз, халык арасында мине шулай йөртерләр, — дигән Акмулла.

— Алайса, син бай адәмсең! — дигәннәр аңа.

— Дөрес! Һәр халыкка үз булудан да зур байлык каян килсен?!

## Такташ песие

Һади Такташ бер пьесасында шундый аңлатма автор сүзе язып куйган була: сәхнә күренешендә, диванга утырып, койрыгын кыйблага каратып, бер песи битен, колак артларын юа.

Артистлар песине сызып ташларга кушалар. Такташ песине пьесадан алырга теше-тырнагы белән каршы тора. Шулай озак кына тарткалашканнан соң, режиссер әйтә:

— Һади, кирәк чакта диванга утырып, битен юа ала торган песи алып килә алсаң, песине сәхнәгә чыгарабыз! — ди.

Такташ бераз уйланып утыра да кинәт шаркылдап көлә башлый һәм песине пьесадан сызып ташлый.

*«Кызыклы хәлләр»не журнал өчен Р. Батулла әзерләде.*

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ X СЪЕЗДЫ

21 майда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында Татарстан АССР язучыларының чираттагы X съезды ачылды.

Залда — язучылар, Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунаклар, республикабызның партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмалары вәкилләре, сәнгать һәм культура эшлеклеләре, промышленность һәм авыл хуҗалыгы эшчәннәре. Кунаклар арасында СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе, Социалистик Хезмәт Герое С. Михалков, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе Ә. Мирзаһитов, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары А. Волков һәм Н. Доризо, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Чувашия АССР Язучылар союзы идарәсе председателе А. Емельянов, Мари АССР Язучылар союзы идарәсе председателе Н. Рыбаков, язучылар Г. Имамвердиев (Азербайҗан), В. Карамазов (Белоруссия); Тураб Тула (Үзбәкстан), Н. Бәйрәмов (Төркмәнстан), К. Укаев (Кыргызстан), А. Кальве (Латвия), Т. Җумаморатов (Каракалпакстан), С. Самсонов (Удмуртия), К. Абрамов (Мордовия) һ. б. бар иде.

Съездны РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким ачты.

Съездның эш органнары сайлады.

Съездда катнашучылар зур рухлану белән КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш К. У. Черненко җитәкчелегендә КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы составында Почетлы президиум сайладылар.

Республика язучыларының иҗади эшчәнлеге һәм ТАССР Язучылар союзы идарәсенең ике съезд арасындагы эше турындагы отчет докладын идарә председателе Гариф Ахунов ясады.

Съездда СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе, Социалистик Хезмәт Герое С. Михалков чыгыш ясады.

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе отчеты белән комиссия председателе Рәис Даутов чыкты.

Аннары жанрлар буенча өстәмә докладлар тыңланды. Съездның беренче көнендә поэзия буенча — Илдар Юзеев, проза буенча — Мөхәммәт Мәһдиев, драматургия буенча — Туфан Миңнуллин, әдәби тәнкыйть буенча Тәлгат Галиуллин, балалар һәм яшүсмерләр өчен әдәбият турында — Шәүкәт Галиев, очерк һәм публицистика турында — Марсель Зарипов сөйләде.

22 майда съезд үзенең эшен дәвам итте.

Татарстанда яшәүче рус язучыларының иҗаты турында Нонна Орешина һәм тәрҗемәчеләр эшчәнлеге турында Кыям Миңлебаевның өстәмә докладын тыңланды.

Аннары Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Гаффар, Брежнев бүлеге җаваплы секретаре Р. Вәлиев, Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев, республика укучыларының А. Алиш исемендәге әдәби берләшмәсе җитәкчесе Р. Миңгалим, Казан телевидениесенең әдәби-музыкаль тапшырулар редакциясе баш редакторы Р. Миңнуллин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Н. Доризо, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары Б. Мулюков, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Б. Леушин, «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең йортлар төзү комбинаты начальнигы М. Бибишев, Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсенең лаборатория начальнигы А. Зыятдинов чыгыш ясады.

Татарстан язучылары форумын СССР Язучылар союзы идарәсе председателе Ә. Мирзаһитов, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Чувашия АССР Язучылар союзы идарәсе председателе А. Емельянов, Г. Имамвердиев (Азербайҗан), В. Карамазов (Белоруссия), К. Укаев (Кыргызстан), Т. Тула (Үзбәкстан), Н. Бәйрәмов (Төркмәнстан), Т. Җумаморатов (Каракалпакстан), Мари АССР Язучылар союзы председателе Н. Рыбаков, С. Самсонов (Удмуртия) тәбрикләде.

Съездда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд ТАССР Язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады.

Идарә составына А. Әхмәдуллин, Г. Ахунов, Н. Алешков, Ә. Баянов, Р. Вәлиев, Ш. Галиев, Т. Галиуллин, Ә. Гаффар, А. Гыйләҗев, Зөлфәт, Ә. Еники, М. Мәһдиев, М. Маликова, Р. Миңнуллин, Т. Миң-

нуллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин, Р. Мөхәммәдиев, В. Нуруллин, Н. Орешина, Р. Фәйзуллин, М. Хәбибуллин, С. Хәким, Р. Харис һәм И. Юзеев сайланды. Ревизия комиссиясенә Р. Даутов, Г. Паушкин, Ҡ. Сибгатуллин, Р. Төхфәтуллин, Р. Хәмид сайланды.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов, ТАССР Министрлар Советы Председателе И. Х. Садыйков, КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге инструкторы С. В. Потемкин, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре В. С. Дергунов, КПССның Казан шәһәр комитетының беренче секретаре М. М. Сухов, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

ТАССР Язучылар союзының яңа сайланган идарәсенең беренче утырышында идарә председателе итеп Туфан Миңнуллин, аның урынбасарлары итеп Разил Вәлиев, Илдар Юзеев, җаваплы секретарь итеп Мөхәгыйт Хәбибуллин сайланды.

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе итеп Рәис Даутов сайланды.

«Казан утлары» журналының баш редакторы итеп Ренат Харис расланды.

## ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ УКУЫ

18 майда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында иҗат интеллигенциясе өчен даими эшләүче семинарның чираттагы занятиесе булды.

Семинарда катнашучылар алдында философия фәннәре докторы, профессор В. А. Разумный (Мәскәү) «Хәзерге шартларда совет кешеләрен идея-әхлакый яктан тәрбияләүдә әдәбият һәм сәнгатьнең үсә баручы роле», тарих фәннәре кандидаты, СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты хезмәткәре Е. А. Белов «Ерак Көнчыгышның политик проблемалары» дигән темаларга лекцияләр белән чыктылар.

Семинарда Казан шәһәренең тарихи һәм культура ядкарьләре турында ТАССР культура министры И. Н. Алиев һәм Казан шәһәр Советы башкарма комитетының секретаре Л. Г. Космынина сөйләде.

## В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУГАН КӨНЕНӘ БАГЫШЛАП

Казанда һәм республикабыз районнарында, юлбашчыбыз В. И. Ленинның туган көненә багышлап, һәр елны традицион сәнгать фестивале үткәрелә.

17 апрельдә Казан дәүләт консерваториясенең Актлар залында тантаналы рәвештә ачылган бу сәнгать бәйрәме концертларында «Ленин һәм музыка» темасы тирән чагылыш тапты. Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт филармониясенең ТАССРның халык артисты Р. Салаватов җитәкчелегендәге симфоник оркестры чыгышын тамашачылар яратып кабул иттеләр.

Фестиваль көннәрендә язучылар В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Ленин мемориалында, шәһәребезнең культура сарайларында, предприятиеләрдә һәм мәктәпләрдә әдәби очрашулар уздырдылар. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында 20 апрель көнне оештырылган «җомга кичәсе» В. И. Ленин тематикасына багышланды.

Бу көннәрдә казанлылар һәм башкалабыз кунаклары Татарстан Художниклар союзының Күргәзмә залындагы «Ленин һәм аның эше» дигән яңа экспозициягә зур кызыксыну белән карадылар.

## XIX ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышлап уздырыла торган традицион әдәбият һәм сәнгать бәйрәме быел да шәһәребезнең культура сарайларында, клубларында «Казан язы» дигән әдәби-музыкаль кичәләр белән башланып китте. Ул кичәләр танылган язучыларыбыз һәм сәнгать осталарыбызның хезмәт ияләре алдындагы иҗат отчеты рәвешендә узды.

26 апрель көнне, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре юлбашчыбыз В. И. Ленин һәйкәленә, А. Пушкин, Г. Тукай, М. Горький, М. Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр куйганнан соң, Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Тукай һәйкәле алдында шигъри митинг башланды.

Митингны кереш сүз белән шигырь бәйрәмен уздыру комиссиясе председателе шагыйрь Ренат Харис ачты.

1984 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге премиясенә лаек булучылар — язучы Ә. Еники, композитор Б. Мулюков, шагыйрь Г. Рәхим, дирижер В. Васильев, артистлар З. Сөнгатуллина һәм Х. Бигичев чыгыш ясадылар.

Аннары сүз шагыйрьләргә бирелде. РСФСРның М. Горький һәм ТАССРның Г. Тукай исемендәге премияләре лауреаты С. Хәким, Н. Арсланов, М. Садри, Ә. Баянов, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары Ш. Галиев һәм Р. Фәйзуллин, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Гатауллин, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллин В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенткасы И. Ихсанова, Арча педагогия училищесы укучысы А. Гайфуллина үз әсәрләрен укыдылар.

Казанның 35 нче һәм 124 нче мәктәп укучылары Габдулла Тукай шигырьләрен укыдылар.

Шигырь бәйрәме дәвамында үзешчән сәнгать коллективлары чыгышы, китап һәм сувенир сәүдәсе оештырылды.

Шигъри митингта КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Ф. Г. Зыятдинова катнашты.

26 апрельдә «Казан утлары» журналының әдәби постында — Татарстан атом

электр станциясе төзелешендә Габдулла Тукайның туган көненә багышланган шигырь бәйрәме уздырылды.

Эшчеләр һәм төзүчеләр алдында Казаннан килгән язучылар — Ш. Рәкыйпов, Ә. Рәшитов, «Казан утлары» журналы хезмәткәре Р. Әхмәтҗанов, шулай ук ТАССР Язучылар союзының Брежнев бүлеге язучылары Н. Мадъяров, Я. Игәнәй, Г. Кашапов, Н. Алешков h. б. лар чыгыш ясады. Шигъри митингта төзүчеләргә «Казан утлары» журналы бүләге — танылган язучыларның автографлы китапларыннан төзелгән китапханә тапшырылды. Ул «Казан утлары»ның АЭСтагы уникаль китапханәсенә нигез булачак.

Митингта чыгыш ясап, «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең төзүмонтаж идарәсе начальнигы Р. Сәлахов АЭС төзүчеләр исеменнән язучыларга рәхмәт әйтте.

Брежнев шәһәрендәге шигырь бәйрәме «Россия» кинотеатры алдындагы зур мәйданда үткәрелгән митинг белән ачылып китте. Анда Брежнев язучылар оешмасының җаваплы секретаре Р. Вәлиев, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь И. Юзеев, КПССның Тукай район комитеты секретаре Ф. Г. Гиниятуллина чыгыш ясады. Аннары бәйрәм Алабуга педагогия институтының Брежнев филиалының актлар залына күчте. Анда Казан һәм Брежнев шагыйрьләре, үзешчән сәнгать коллективлары һәм студентлар катнашты.

Шигырь бәйрәмнәре шулай ук Арча районының Тукай-Кырлай авылында, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә, республикабызның Тукай исемен йөрткән колхоз һәм совхозларында да уздырылды. Сарман районының бөек шагыйрь исемен йөрткән совхозында һәм колхозында үткәрелгән шундый бәйрәмгә Казаннан шагыйрь Р. Гәрәй, язучыларның Әлмәт оешмасыннан Ә. Гаффар, К. Булатова, Н. Әхмәдиев килгән иде. Зур хәзерлек белән оештырылган бу тантанада КПССның Сарман райкомы секретарьлары Нәкыйф Вәлиев һәм Люция Зиннурова, шулай ук Сарманда яшәүче автордардан Х. Хәйруллин һәм Ә. Габиди катнашты.

## ОТЧЕТ-САЙЛАУ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

23 апрельдә Казанның Актерлар йортында Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегенең чираттагы отчет-сайлау конференциясе булды.

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсенең отчет доклады белән идарә председателе РСФСРның халык артисткасы Р. А. Җиһаншина, ревизия комиссиясенең отчет доклады белән ревизия комиссиясе председателе вазифаларын башкаручы ТАССРның халык артисты Ю. В. Борисенко чыктылар.

Докладлар буенча фикер алышуларда СССРның халык артисты Ш. Биктимеров, В. И. Качалов исемендәге Зур драма театрының баш режиссеры, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. И. Басин, Казан язу җайланмалары заводының бүлек мөдире Р. Ш. Новикова, ТАССРның атказанган артисты В. А. Фейгин, РСФСРның атказанган артисты К. Гайнуллин, Әлмәт дәүләт драма театры директоры Р. Фатыйхов, драматург Р. Хәмид, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Ә. Бакиров, Бөгелмә рус драма театры артисткасы Т. Ф. Мычилкина, Минзәлә дәүләт драма театры режиссеры Л. Садриев, Бөтенроссия театр җәмгыяте президиумы председателе урынбасары И. Д. Ярцев катнашты.

Конференциядә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыгыш ясады.

Конференция эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнаштылар.

Конференциядә Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составлары сайланды.

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе итеп Р. А. Җиһаншина, ревизия комиссиясе председателе итеп Ю. В. Борисенко сайланды.

## ОЛЫ БҮЛӘКЛӘРНЕ ТАПШЫРУ

1983 елда халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне яхшы оештырган өчен Татарстан АССР — РСФСР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның, авылда культура-шефлык эшендәге уңышлары өчен ТАССРның Берләштерелгән дәүләт музее — СССР Культура министрлыгы һәм ВЦСПСның, план заданиеләрен һәм социалистик йөкләмәләрне уңышлы үтәгәне өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры РСФСР Культура министрлыгы һәм культура хезмәткәрләре профсоюзы үзәк комитетының күчмә Кызыл байраклары белән бүләкләнгән иде.

17 апрельдә Казанның Яшьләр үзәгендә шушы олы бүләкләрне тапшыруга багышланган тантаналы җыелыш булды. Аны ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

Байракларны РСФСР культура министры урынбасары А. И. Шкурко тапшырды.

Җыелышта КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыгыш ясады.

Республиканың партия һәм совет оешмалары вәкилләре, культура работниклары үзләренең чыгышларында партия һәм хөкүмәтебезгә зур рәхмәт әйтеп, культура төзелешендә, хезмәт ияләренә коммунистик тәрбия бирүдә яңа уңышларга ирешергә әзер торуларын белдерделәр.

Аннары ТАССР культура министрлыгының республика халык иҗаты һәм культура-агарту эше фәнни-методик үзәгенең

халык уен кораллары оркестры концерты булды.

Тантаналы җыелышта КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире А. И. Афанасьев, культура бүлеге мөдире М. М. Мусин иптәшләр катнашты.

## БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕНДӘ

Май аенда Мәскәүдә өч йөзләп яшь язучы — күп милләтле совет әдәбияты вәкилләре катнашында яшь әдипләрнең VIII Бөтенсоюз киңәшмәсе булып узды. СССР Язучылар Союзы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты тарафыннан оештырылган бу форумда Татарстаннан яшь язучылар Ә. Мушинский, И. Юлаев, Р. Сәлимҗанов һәм М. Вәлиева катнашты. Аларның иҗаты киңәшмә секцияләрендә тикшерелде һәм уңай бәя алды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Балалар әдәбияты секциясенең 3 апрельдә булып узган утырышы Татарстан китап нәшриятында соңгы елларда балалар һәм яшүсмерләр өчен басылып чыккан китаплар турында сөйләшүгә багышланды. Фикер алышуда ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Ш. Галиев, Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев, язучылар Н. Дәүли, Г. Латыйп, Җ. Тәрҗеманов, Ф. Миңнуллин, М. Әгъләмов, М. Хәсәнов, Р. Кукушкин, Татарстан китап нәшрияты редакторы С. Сибгатуллина һ. б. лар катнашты.

Утырышта шулай ук секциянең соңгы еллардагы эшчәнлегенә йомгак ясалды, секциянең яңа бюросы сайланды.

## ТЫНЫЧЛЫКНЫ ЯКЛАП

31 мартта Магнитогорск шәһәренең Мамин-Сибиряк исемендәге тезүчеләр культура сараенда «Тынычлык хакына» дип исемләнгән зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Аны Магнитогорск шәһәренең «Яшьлек» татар-башкорт җыр һәм бию ансамбле һәм Чиләбе шәһәренең М. Җәлил исемендәге өлкә әдәби берләшмәсе (житәкчеләре — үзешчән композитор Р. Бакиров һәм шагыйрә С. Гәрәева) оештырды. Кичәне әдәби берләшмә члены Э. Сафина алып барды. Казаннан килгән шагыйрь М. Хөсәен чыгышын, әдәби берләшмә члены, Бөек Ватан сугышы ветераны Ә. Рафиков шигырьләрен, җыр һәм бию ансамбле әзерләгән әдәби-музыкаль композицияне тамашачылар җылы каршыладылар. Кичәдән җыелган керем тулысы белән Тынычлык фондына тапшырылды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет хореография сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасы Зөһрә Хәмитовна Ильясовага, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 18 май Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Юрий Владимирович Борисенкога, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 18 май Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Самат Шакирга (Самат Фәтхерахманович Шакировка), Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 14 май Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, ТАССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 28 апрель Указы белән, Әлмәт татар драма театры артисткасы Дамира Нәҗмиҗановна Кузаевага «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Рузия Идиятулловна Закировага, ТАССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 28 апрель Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет хореография сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының балет солисткалары Мәһдиева Надежда Эрнестовнага һәм Хәмдиева Зөлфия Рахимовнага, ТАССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 18 апрель Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әлмәт татар драма театрының баш режиссеры Рөстәм Абдерәшитович Абдуллаевка, ТАССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 28 апрель Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әлмәт татар драма театры артисты Фоат Фәхретдинович Зариповка, ТАССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 18 май Указы белән «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

# ҖИР КЕШЕНЕ КҮТӘРӘ

Туган җиргә мәхәббәт... Татарстан сынлы сәнгате хәзинәсенә үзеннән күркәм өлеш керткән рәссам Мәснәви Хәйретдиновның (1924—1983) кырык еллык иҗат эшчәнлеге дәвамында тудырылган әсәрләренең лейтмотивын шушы өч сүз белән генә дә аңлатып буладыр шикелле.

Татарстанның нефтьле районнары табигате һәм кешеләре Мәснәви Хәйретдинович картиналарында аеруча үз итеп, күңел җылылыгы белән сурәтләнгән. Бу табигыйдер, чөнки рәссам егерме елдан артык Лениногорскида яшәде, үзенең геройлары белән якыннан аралашты, үзе дә бу якларның табигатенең газиз баласына әверелде. Кеше җирне, җир кешене күтәрә... Сынлы сәнгать остасының «Оператор», «Кызлар», «Игенче» дип исемләнгән картиналарын карaганда, татар халкының гаять тирән мәгънәле әнә шундый мәкале искә төшә. Әлеге әсәрләрдә хезмәт темасы Ватан образы белән органик рәвештә берләштерелеп бирелә.

Туган җиргә мәхәббәт авторның пейзажларында бигрәк тә калку чагыла. Гомеренең соңгы елларында мондый жанр буенча ул аеруча нәтиҗәле иҗат итте һәм кеше белән табигать берлеге турындагы уйлануларына ниндидер йомгак ясарга да өлгерде. Нечкә лиризм, күңел җылылыгы, кыскасы, табигатькә шагыйрәнә караш иҗатчы эзләнүләренең төп юнәлешен билгели. Туган җирнең бөеклеген тирәнтен аңлау авторны бер караудa гына ачылып бетмәслек кабатланмас пейзаж образлары тудыруга китергән, һәм шулар нигезендә рәссам «Туган ил» исемле бөтен бер цикл иҗат иткән. «Ана булу», «Яшьтәшләр», «Саф җил», «Көзге җыр» кебек картиналарның исемнәре генә дә авторның кеше һәм табигать темасын төрле яклап гәүдәләндерергә омтылуын күрсәтә. Кеше үзенең уй һәм хисләренә бары тик табигатьтә генә аваздашлык таба, табигать белән күзгә-күз очрашканда кешенең күңеле үтәли күренә... Картиналардан әнә шундый фикер аңлашыла.

Рәссам туган як темасына һәрвакыт тугрылыклы булып кала, үзе җәлеп иткән мотивка әледән-әле мөрәҗәгать итә. Әлмәт яклары, Лениногорск тирәләре, ярсу Ык буйлары гүзәллеген ул төрлечә ачарга омтыла, беркайчан да үзен-үзе кабатламый, безне инде таныш «аланнар»га алып чыгарга тырышмый һәм шул рәвешле яраткан темасының үзгә катламнарын ачуга ирешә, аны яңа нюанслар, яңа образлы эчтәлек белән баета.

...Колынын үзенә сыендырган көмешсу бия, әйтерсең, әле генә иртәнге томанда коенган. Табигать гүзәллеге белән яшәү матурлыгының камил гәүдәләнеше! Шушы гармониянең бер өлешенә саксызрак кагылсаң, икенчесе дә шундук үзенең гүзәллеген җуяр шикелле....

Татарстанның халык рәссамы Мәснәви Хәйретдиновның «Ана булу» дип исемләнгән картинасына кеше һәм табигать проблемасына кагылышлы әнә шундый гаять тирән мәгънә салынган. Сынлы сәнгать остасы безне менә шушы бөек гармониянең бер генә төсен дә җуймаска чакыра. Һәм, гомумән, аның һәрбер әсәре дә туган җир гүзәллеген һәм яшәү матурлыгын тирәнрәк тоярга ярдәм итүләре белән кыйммәтле.

**Вера ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның бүлек мөдире.

Тышлыкның дүртенче битендә: В. И. Качалов исемендәге Зур драма театрында Л. Зорин пьесасы буенча куелган «Патша авы» спектакленнән күренеш.

Рөстәм МАНСУРОВ фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)